

# Казан утлары

10. 1984



# КАЗАН УТЛАРЫ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС
ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-
ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ
АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

10

1984


## *Бу санда*


М. ХӘБИБУЛЛИН. **Кубрат хан.** Роман . . . . . 3
Г. ЛАТЫЙП. **Хәрби оркестр.** Шигырьләр . . . . 65
Р. НИЗАМИЕВ. **Канатлы җыр кирәк кешегә...** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 70
Ф. ГАЛИЕВ. **Командировка.** Повесть . . . . . . 76
Э. МОСТАФИН. **Туган якка кайтып барышлый.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 122
Ә. МӘХМҮДОВ. **Яшәеш уты.** Шигырь . . . . . . 124
Г. МӨХӘММӘТШИН. **Дүрт юллык хис.** Шигырьләр 125

Г. ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Т. ЗУЕВА. **Казанда Тукай урыннары** . . . . . . 127

ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

М. ӘМИРХАНОВ. **АЭС кызлары** . . . . . . . 128

БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 40 ЕЛЛЫГЫНА

К. ХӘМЗИН. **Безнең бабайлар** . . . . . . . . 134

КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ ИЮНЬ (1983 ел) ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

И. НИЗАМИЕВ. **Китап! Китап! Китап** . . . . . . . 138

БИБЛИОГРАФИЯ

Р. МОСТАФИН. **Сез бу хатны минем укыганда...** 146

М. Ю. ЛЕРМОНТОВНЫҢ ТУУЫНА 170 ЕЛ

М. ПОПОВА. **Халык шагыйре** . . . . . . . . . 153

СӘЙФИ КУДАШКА 90 ЯШЬ

Ә. ЕНИКИ. **Аның йөге — ил милке** . . . . . . . 159
С. КУДАШ. **Хәсән Туфанга шигъри хатлар. Халкыбызның каһарман бер кызы** . . . . . . . 161



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

ЮБИЛЕЙЛАР

Т. НАСЫЙРОВ. **Революционер һәм журналист** . . 170

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

М. МӘХМҮТОВ, Ә. КӘРИМУЛЛИН. **Мәгърифәтче Шиһап Әхмеров** . . . . . . . . . . 174
Р. КАДЫЙРОВ. **Гали Мәхмүдов — хаттат** . . . . 179
Р. ТУФИТУЛОВА. **«Яшь ленинчы»га 60 ел** . . . 183

**Кызыклы хәлләр** . . . . . . . . . . . . 188

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . . 189

**Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары** . . . . . . . . . . . . 191

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . .192

*Баш редактор*

**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия:*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**ӘХӘТ ГАФФАР**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ** *(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ** *(баш редактор урынбасары)*
**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**НУРИХАН ФӘТТАХ**
**СИБГАТ ХӘКИМ**
**РИЗВАН ХӘМИД**
**НИЛ ЮЗИЕВ**
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Роман **М. Хабибуллина** «Кубрат хан» (окончание). Детективная повесть **Ф. Галиева** «Командировка (История одной клеветы)».
Стихи **Г. Латыпа, Р. Низамиева, Э. Мустафина, А. Махмудова** и **Г. Мухаметшина**.
«К 100-летию Г. Тукая»: рис. **Т. Зуевой** из цикла «Тукаевские места в Казани».
Зарисовка **М. Амирханова** со строительства ТатАЭС.
«К 40-летию Великой Победы» — зарисовка **К. Хамзина**.
Статья **И. Низамова** о проблемах распространения книжной продукции.
В разделе «Библиография» — рецензия **Р. Мустафина** на трехтомное собрание сочинений Хади Такташа.
Материалы к юбилеям М. Ю. Лермонтова, С. Кудаша и В. Шафигуллина.
В рубрике «К истории культуры»: статьи «Просветитель Шигап Ахмеров», «Каллиграф Гали Махмудов» и «60 лет газете «Яшь ленинчы».
«Занимательные истории», «Дневник культуры», «На наших обложках» — творчество художника **Е. Зуева**.

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина.*

Производствога бирелде 27.7.1984 ел. Басарга кул куелды 1.10.1984 ел. ПФ 09038. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 64049. Заказ К-294. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1984 ел.

## Мөсәгыйт Хәбибуллин

# КУБРАТ ХАН

РОМАН

### 23



Балкыр илханнан ике-өч көн саен хәбәр килеп торды. Җаек бәк төп алае белән Әтил буйлап югарыга киткән икән. Батбай илхан исә дәшмәде, киткән бер йомышчылар эзсез югала тордылар. Кубрат ханның моңа җаны көйде, әмма кавханнарына әйтергә ашыкмады. Аланнар белән төркиләр арасында вак-төяк чуалышлар булып алгандыр. Балкыр илхан хәбәр итеп тора — каган Биләмҗирдә, алае да шунда, яу чыкканы юк. Ниһаять, Кодрак илханнан хәбәрче килеп җитте. Җаек бәк Эске кирмәнне камаган, Чәчкәне сорый икән. Чәчкә үзе теләп Җаек бәккә чыга һәм аны Биләмҗиргә озаталар. Бу хәбәр белән килгән йомышчыны чак кына кыйнап ташламады Кубрат хан. Йөрәк купмаслык хәбәрме, ничек хан янына кереп шул сүзне әйтмәк кирәк! Чәчкәне Биләмҗиргә алып китеп баралар!.. Кодрак илхан кая, Адай тархан, Чакай буйтур ни караганнар?!

Хәбәрче чыгып киткәч, Кубрат хан үз-үзенә урын таба алмады. Таңре шаһит, каган өчен яуламады ул җәйләү-биләмәләрен. Нигә һич югы Аппак кайтмый? Ни кылып ята көтригурлар ыстанында?

Кубрат хан бүлмә буйлап йөренде-йөренде дә кече кавханга философны чакырырга кушты.

Философ Иоанн Фасиан көттерми килеп тә җитте.

— Киңәш ит, философ, ни кылыйм? Кызым Чәчкәне каган бәге әсир иткән, каганның башкаласы Биләмҗиргә алып китеп бара икән. Кодрак илхан каганның уң кулы Җаек бәккә каршылык күрсәтмәгән... Өлкән угланым Батбай дәшми, җибәргән йомышчыларым әйләнеп кайтмыйлар... Киңәш бир, философ, яу чабарга боерыйммы, биредә көтимме каганны?..

— Олуг хан,— диде философ хан янәшәсенә утырып.— Синең кулыңда төгәл мәгълүматлар бармы?

Кубрат хан шикләнеебрәк философка карады. Гадәттә, философ Димашкъ кафтаны киеп йөрер иде, бүген исә аның өстендә кызылга зәңгәр буй төшкән Рум чапаны иде, билен шул ук төстәге путә белән буган.

---

Ахыры. Башы 8—9 саннарда.

— Димәк, төгәл мәгълүматларың юк, олуг хан?
— Ни киңәш итәргә исәбең, философ?
— Дәүләт белән дәүләт арасында орыш булыр алдыннан дошманның көчен, кайчан яу чыгасын төп-төгәл белергә кирәк, хан.
— Шуннан-шуннан?
— Бәлкем безгә, базилевс илчеләре булып, хан кызын каган кулыннан алырга язгандыр, олуг хан.
— Тәңрем!
— Аллаһы-тәгалә ярдәм итәр, олуг хан.
— Итәр,— диде хан философка карамый гына.— Итәр...
Кубрат хан кузгалды, гасабиланып ишекле-түрле йөри башлады.
— Миңа бер кораб бир, Кубрат хан. Румда ясалган галера. Без — Рум илчеләре. Патрикий Симеонны алырмын.
— Патрикий Симеон нигә?
— Дин әһеле — ил әһеле, хан. Дин әһеленең илче белән булуы каганны тәмам инандырачак. Мин Болгар аша бармам Биләмҗиргә. Барыр юлым диңгездән булмас, әүвәл Тын елга буенча күтәрелербез, аннары галераны арбада тартып Этилгә чыгарырбыз. Бер рәттән илчеләр дә, багучылар да булырбыз.
— Максатың, философ?
— Максат, олуг хан, кызың Чәчкәне ничек кенә булса да кулга төшерү, каганның чын уй-теләген белү...
— Сезне танучылар табылса?..
— Мин сакал үстерәм, патрикий Симеонны хәзәрләрдән белгән кеше булмады кебек.
— Ишкәкчеләр итеп кемне алырсыз?
— Ишкәкчеләргә көтригурларны алырга булыр, Румда ишкәккә күбрәк алар утыра.
Кубрат хан янә йөренеп килде, философ каршына туктады.
— Сиңа билгеле булса кирәк, философ, кызым Чәчкәгә каган яучылар җибәргән иде, мин аларны куып диярлек кайтарып җибәрдем, ә ул әнә нинди мәкерле җай уйлап тапкан — ниндидер юллар белән Эске кирмәндәге Чәчкәне кулына төшергән. Биләмҗиргә алып кайтып җиткерсәләр, каган миңа янә яучылар җибәрер, бу юлы инде ышанып җибәрер, риза булсам-булмасам да каган Чәчкәгә өйләнер. Төрки халкы бу никахны кабул итәр, мин каган белән орыша да алмам. Чәчкә базилевс угланы Юстинианга ярәшкән. Бер кызны ике тапкыр ярәшмиләр... Әллә соң тәңре шулай телиме, философ? Кичә бик яман төш күрдем, ни дип юрарга да белмәдем, төш юраучыга әйтергә курыктым.
— Төш юрау уйдырма ул, хан.
— Уйдырма,— диде хан шикләнә калып,— уйдырма. Сиңа уйдырмадыр да бит. Каганда төптәңре булып Үрәгәй карт тора. Яше йөзгә җитеп килә бугай инде. Төптәңре Ирсан юкка чыкты, аның шунда булуы бар, философ.
— Биләмҗирдә безнең кешеләр дә бар, олуг хан. Төптәңре Ирсан илен саткан икән, аны юлдан тиз алып ташларбыз.
— Соңгы сүзең ошатмадым, философ...
Кубрат хан тәхетенә менеп утырды, уйга калды. Шактый утыргач кына:
— Мин риза, философ. Кайчан сәфәр чыгарсың?
— Мөмкин булса, иртәгә үк кузгалыр идем, олуг хан.
Кубрат хан таягы белән дөңк итеп идәнгә төртте, шундук кече кавхан килеп керде.
— Кече кавхан, философ Иоанн Фасианга иң яхшы грек галерасын сайлап бир, сораган кешеләрен бир. Хан казнасыннан бүләкләр биреп җибәр, кайсын сорый шуны илтеп корабка төят. Кулына ике мең алтын тапшыр. Мин әйттем.

— Баш өсте, олуг хан. Барысы да син дигәнчә булыр. Олуг хан, кыеп әйтер сүзем бар иде. Аппак ханша кайтты, дала як капкасын узып килә.

— Сөенечеңә рәхмәт, кече кавхан.— Кече кавхан чыгып киткәч, Кубрат хан философка таба борылды:— Койрыкчыны үзем бирәм, койрыкчың оста Денис булыр.

— Мин риза, хан. Мин китим, минем юлга җыенасым бар.

— Ак юл сиңа, философ. Исән-имин кызым алып кайтсаң, бәһам шул галера булыр. Мин әйттем.

Ишектә ханша Аппак күренүгә, Кубрат хан тәхетеннән төште, ханшага каршы китте.

— Ханым, Кубрат!— диде Аппак һәм ашыга төшебрәк ханга якынлашты.— Ханым, алҗыдым, юл бик озын булды...

Кубрат хан хатынын кочты, битеннән үбеп алды.

— Көбер хан ни хәлдә ята?

— Көбер хан ун төмән алай белән Маныч елгасына килергә вәгъдә итте, ханым. Ханым, мин ишеттем...

— Тынычлан, ханша.— Кубрат хан хатынының кулыннан алды, түр бүлмәгә алып кереп китте.— Чәчкә кызыбыз исән... Иртәгә философ Биләмҗиргә китә.

Ханша кисәк туктады, яшьле күзләре белән ханга карады.

— Әйтеп бетер, Җаек бәкнең кызыбыз Чәчкәбезне тотык итеп Биләмҗиргә алып китүе...

— Хак, ханша...

— Кубрат, җый алай, дәш илханнарны, чап яу Биләмҗиргә, коткар кызыбызны!

Аппак ханша ханның җиңенә тотынды, башын күкрәгенә төртте.

— Бердәнбер кыз баланы, хан. Ничек оялмый, ничек аны җир упмый, тәңрем...

— Илханнарга дәштем, алаем җыюлы, ханша. Тынычлан. Барыбыз да Маныч елгасы буена җыелырга булдык. Кодрак илханга хәбәр салдым, аңа да булган алае белән шул тарафка хәрәкәт итәргә куштым. Илбарыс буйтур аңа ярдәмгә китте.

— Каган сине картайган дип бара икән, ханым.

— Чәчкәне үзенә алмакчы каган, безнең белән карендәшләшмәкче. Ашиннар белән каберең якын булмасын. Әйе, мин картайдым, ханша. Халык сарык түгел, күрә. Әмма минем илханнарым бар, минем бөркетләрем! Бу юлы мин ашинлыларның Табгачка житеп тамырын корытырмын. Шунсыз безгә рәхәт яшәү килмәс, ханша.

Кубрат хан тәхетенә менеп утырды, таягы белән дөңк-дөңк идәнгә төрткәләп алды.

— Төпчегем Аслан кирәк миңа бүген. Кайтсын, кайтарсыннар!

— Киләсе җәйгә Аслан илхан император угланы Юстиниан белән Фанәгүргә килергә булган, хан.

— Соң булмасмы, ханша? Үзем сорадым, үзем үк ышанмый утырам. Кем әйтте?

— Көбер хан әйтте, аның Патшакала тулы шымчылары.

Кубрат хан йомышчысын дәшеп алды:

— Табын хәстәрләгез, кымыз куегыз,— диде.

— Яуга кузгалуың кайчан булыр, ханым?

— Биләмҗирдән философ кайткач, ханша.

— Ул тиз генә кайта алмаса, хан?

— Кайтыр, ханша. Дошман белән орышыр өчен башта аның көчен, алай чамасын белергә кирәк.

— Төптәңре Ирсан Батбай илхан кулында икән, ханым? Илханны

ак киезгә утыртып, олуг хан итеп аксакаллардан күтәртәм, дип йөри икән.

Кубрат хан кашын-күзен җимерде, бер тын дәшми торды.

— Ханша,— диде Кубрат хан тешен кысып.— Ханша, миңа каршы төшкән кешене — үз угланыммы ул, иң якын кавханыммы, тарханыммы — көне-сәгате белән ат коерыгына тактырачакмын. Миндә хәзер грек уты бар. Кубрат хан беркемгә дә бирешмәс.

— Ут дошман өчен, илең саклап калу өчен акыл кирәк, хан. Батбай илхан сиңа каршы булса нишләрсең?

— Дошманнарым белән ни кылам, шулай итәрмен, ханша. Баш кисүдән кылыч тутыкмый.

Икенче көнне илчеләр корабын Биләмҗиргә озаткач, Кубрат хан алачыкка Симай ата янына юнәлде. Хан хәзер көн аралаш диярлек алачыкта була, грек уты тутырылган чүлмәкләр белән кызыксына иде. Алачыкка килгән саен Кубрат хан Симай ата эшенә куанып бетә алмады. Грек уты тутырылган чүлмәкләр белән алачык амбарлары тулды, аларны күргән саен Кубрат ханның күңеле тынычланып кайта иде. Дивар башларына ташаткычлар куйдыртты һәм һәр ташаткычка алыплар билгеләде, грек уты тутырылган чүлмәкләр бирергә боерды, аларны грек белгечләреннән ничек кабызырга, ничек атарга өйрәтергә кушты. Грек уты тутырылган чүлмәкләрнең шартлавын сынарга Кубрат хан үзе дә килде. Ут төшкән җирдә мәхшәр килгәндәй бар нәрсә дөрләп яна иде.

Сынаулардан Кубрат ханның күңеле күтәрелеп кайтты. Юк, Болгар хәзер беркемгә дә бирешмәс, аңарда грек уты бар. Их, үз гомерен дә бер егерме яшькә ташлый алса икән?!

Сарайга кайткач, Кубрат хан кече кавханны чакырып алды.

— Кече кавхан, Аспарух илханга йомышчы җибәр. Юлда булса да куып җитсен һәм менә бу хатны аңа тапшырсын. Тамга ханныкы. Мин әйттем.

Хатны Кубрат хан кичтән үк яздыртып куйган иде. Хатка нинди җавап килер, Кубрат хан белми. Алай да Аспарух илханга ышана хан, килер вәгъдәләшкән төбәккә. Ә менә Батбай илханга өченче йомышчы җибәрә инде. Батбай илханга ул төптәңре Ирсанны Маныч елгасы буена, орыш кырына алып килергә боерды. Төптәңре өлкән илхан белән килә кала икән, алар килүенә елга буенда корбан чалдырыр ул. Бу хәл үзенә күрә бер бәйрәмгә әверелер. Шунда Кубрат хан төптәңре Ирсанны кичерер, шунда илханнарның берсен ак ат тиресенә күтәртеп хан итәр.

Көн төшлеккә авышкач, Кубрат хан бүлмәсенә узды, аны ханша көтә иде инде. Табын янында элек илханнардан берәү яисә Чәчкә кызлары булыр иде, хәзер әнә икәүдән-икәү генә калдылар, икесе дә шул турыда уйлап, күзгә-күз карашып алдылар.

Табын янында Кубрат хан ханшага әйтте:

— Аштан соң Эске кирмәннән кайткан йомышчы Чаптар алыпны кабул итәм. Син дә керерсең, ханша,— диде.

Ашап-эчкәч, Кубрат хан тизрәк тәхет бүлмәсенә ашыкты, кабалана төшебрәк тәхетенә менеп утырды, йомышчыны дәшәргә кушты. Аның тизрәк Эске кирмәндәге хәлләрне беләсе килә иде. Ул арада ханның янәшәсенә ханша килеп утырды. Йөгерә-атлый йомышчы алып килеп керде, хан каршына килеп баш орды.

— Кадерле хан, гүзәлләрнең гүзәле ханша, кыюлыгым җитеп хәбәр итәм: буйтурның йырмак алае Эске кирмәнгә килеп җитте. Барысы да исән-сау кирмәнгә кереп урнашты...

— Йә-йә, сөйлә,— диде хан сабырсызланып.

— Олуг хан, сөенче, ятим угланыбыз Илбарыс буйтур, төнлә белән Әтил елгасын йөзеп чыгып, Җаек бәктәге җиде тотык болгар алыбын

һәм кызыгыз Чәчкәне коткарды, Чәчкә кызыгыз хәзер Эске кирмәндә Кодрак илхан кулында!

Кубрат хан тәхетеннән сикереп торды, йомышчыны кочагына сөреп алды. Аннары таягын төя-төя йомышчыларны чакырды.

— Кече кавхан, сарайдагы бар булган булышчыларны чакыр. Тиз! Сөрәнче, оран сал, җыелсыннар тәхет бүлмәсенә.

Бүлмәгә бик тиз халык җыелды, шуннан Кубрат хан йомышчы алыпка:

— Сөйлә, алып!— диде.

— Мин сөйләдем бит инде, олуг хан.

— Тагын бер әйт.

Йомышчы алып янә тәүге сүзләрен кабатлады. Шуннан соң Кубрат хан йомышчыны янә кочагына алды, уңлы-суллы битләреннән үпте.

— Истәлекче, яз! Атың, атың ничек багатыр?

— Мин багатыр түгел, хан олуг, йомышчы алып.

— Берегең кемдә?

— Алостаз Дәянда. Атым Торгын булыр, хан.

— Истәлекче, яз! Торгын алып бүгенге көннән минем багатырым булыр. Кече кавхан, багатырга хан алаеннан бер түмән алай бир, берегe белән алостаз Дәянда булыр. Мин әйттем.

— Баш өсте, олуг хан.

— Буйтур Илбарыс үзе котыла алмады, олуг хан. Аны Җаек бәк әсир итеп Биләмҗиргә озатты.

Ханша аһ итте, әмма Кубрат хан аның ягына хәтта әйләнеп тә карамады.

— Тәңре бар икән әле, буйтур исән,— диде хан.— Багатыр, син иртәгә иртүк Эске кирмәнгә кузгал. Кирмән камауда булса да, булмаса да Кодрак илханга хәбәр итәргә тырыш. Олуг хан тиз арада Маныч елгасына таба кузгала, Кодрак илхан шунда килсен. Үзең белән ун алып ал.— Хан кече кавханга таба борылды.— Актай кавхан, минем алаемнан багатырга ун алып бир, сыналган, үткер алыплар бир. Мин әйттем.

Ханша телгә килде.

— Ханым, Чәчкә кызыбыз артыннан бүген үк алай җибәр, яисә үзең юлга чык. Алып кайт Фанагүргә баламызны.

— Ханша, Кодрак илхан кызыбыз Чәчкәне Маныч елгасына алып килер, мин аңа шулай боердым. Кирмәндә һичкем белмәгән яшерен капка бар.

— Хан, каганның уң кулы Җаек бәк янә Эске кирмәнгә кузгалган. Ул кулына Чәчкәне төшермичә тынычланмас.

— Илчеләр кайтмыйча мин Фанагүрдән кузгалмыйм, ханша.

Кубрат хан барчасына да баш иде, бу аның китәргә рөхсәт диган шартлы билгесе иде. Хан янында ханша гына калды.

— Ханша, менә ничә көн инде император Ираклийдан сурәткә табынучылар агыла. Ни кылыйм?

— Кабул ит, җир бир. Кеше кешедән, таш таштан ерак китә алмый.

Кубрат хан шахмат бүлмәсенә таба кузгалды.

— Ханша, базилевс ачуланмасмы икән? Ул аларны анда утта яндыра икән, төрмәләргә яба, илләреннән сөрә.

— Хан, син бөтен хәбәрне дә соңга калып ишетәсең. Император Ираклий Патшакалада юк, сарациннар белән орышып йөри. Безнең ятим угланыбыз да әнә каган кулына әсир төшкән. Буйтур Чәчкәне ярата иде.

— Яратумы, ханша, игелекле эш. Ярату гаеп түгел, яратмау гаеп. Алар бер анадан туган балалардай үстеләр. Туган туганны яратмаса, туган-туган белән тату яшәмәсә, илгә афәт килер. Кичә генә базилевстан җиде кораб корал килде. Мин вәгъдәмдә калам, минем базилевс-

ның ачуын китерәсем килми, ханша. Мин беләм, беләм, ханша, алар бер-берсен яраталар иде, ярату гаепме дим ич!

— Базилевс каганга да корал сатып ята, үзең күрдең, буйтурың алып кайтып күрсәтте. Ә син, хан, каганның сәүдәгәрен иленә кайтарып җибәрдең.

Хан бакчага чыкты, алмагач төбендәге эскәмиягә утырды.

— Бу арада минем башым катты, ханша. Корал сатуда мин базилевсны гаепли алмыйм. Мин ул турыда бик күптәннән ишетә киләм. Базилевс аны күз буяу өчен эшли. Рум императоры безгә корал гына түгел, ефәк, киҗү тукымалар, имбир, борыч, җиләк-җимешләр дә җибәреп тора. Син, ханша, кыска акыллы дип уйлыйсың кебек мине. Ханың ул хәтле кыска акыллы түгел. Мин Биләмҗиргә шымчы илчеләр җибәрдем. Алар бөтенләй хәзәрләр көтмәгән яктан барып керерләр Биләмҗиргә, шул җайдан ул яктагы биләмәләрне дә күрерләр. Җаек бәк ни кылып ята анда? Мин философка зур өмет баглыйм, ханша.

— Илчеләрең исән-сау әйләнеп кайтырлармы? Каган башларын кистермәсме? Аларны иң әүвәл Үрәгәй кабул итмәс. Төптәңре Үрәгәй гомер-гомергә румнарны яратмады.

— Каган Үрәгәйне тыңлармы, ханша. Картайган инде төптәңре Үрәгәй, бер аягы белән гүрдә тора. Үрәгәй түгел, мине төптәңре Ирсан борчый, ханша. Батбай углан аның коткысына бирелде, сихерләде илханны карт төлке, сихерләде, әле дә булса хәбәре юк. Киткән бер йомышчым әйләнеп кайтмый.

— Илне яшь илханга бирер идең хан. Картайдың, шик-шөбһә белән яшисең.

Кубрат хан кисәк торып басты, текәлеп ханшага карады, ханның карашын ханша иягeн чөя төшебрәк кабул итте. Хан аңа бер сүз дә әйтмәде, борылды да сарайга таба китте. Кинәт җавапсыз калуының сәбәбе бар иде: ханша сүзендә хаклык күрде ул. «Мин үзем дә күрәм ич, нигә ул ашыктыра мине!»— дип уйлады хан, артыннан килүче ханшаның аяк тавышларына колак салып. Шик юк, орышка кадәр Бөек Болгар алаен илханнарның берсе житәкләргә тиеш. Әмма кайсы илханга тәвәккәлләп ил-җәйләүләрне тапшырырга?..

Йулыш каганны заманында җизнәсе Җаек бәк коткарып калды. Ашин ыруы җир йөзендә каламы, юкмы дип бөтен Тын елга, Әтил суы буйларының асты-өскә килгәндә уникe яшьлек Йулыш илханны Җаек бәк Хорезмга алып китә. Кубрат хан куа бармады, яулаган җәйләүләрне барларга, элек каганга буйсынган бәкләр белән араны өзәсе бар иде. Бәкләрнең кайберләре аны шундук олуг хан итеп кабул иттеләр, әмма баш күтәрүчеләре дә булмады түгел, аларның күбесен юк итте Кубрат хан, беришесе Кубраттагы гайрәтне күреп буйсынырга мәҗбүр булдылар. Хәзер әнә шул бәкләр Йулыш илханны каган итеп ак киездә күтәргәннәр, җәйләүләр даулыйлар, алай җыялар, каганны яклыйлар. Әйе, тагын бер күзгә-күз очрашасы бар икән әле ашинлылар белән. Хәзер инде Кубрат хан ашинлыларның берсен дә калдырмас, беришесен ат коерыгына тактырыр, беришесен камытка утыртып, Фанәгүр төрмәләрендә черетер. Мәгәр моның өчен Кубрат ханга иң әүвәл Йулыш каганны җиңү кирәк иде. Йулыш каганны Хорезм шаһы яклый, төмәнтөмән алай бирә. Ә Хорезм шаһы император Ираклийның кан дошманы. Менә шушындый җаваплы чорда ханша тәхеткә үзең теләгән илханны утырт дип җанга тия. Тәхеткә яңа хан утыруга, илханнар үзара орыш башламасlarмы? Батбай әнә әле үк баш бирми.

Кубрат беркайчан да ханша Аппакның ни теләвен аңлап бетермәде. Ханша әле елмая-көлә, шатлыктан тау чишмәседәй чылтырый башлый, әле елга өстенә төшкән иртәнге томан кебек тынып, йомылып кала. Моңа кадәр Кубрат хан Аппагы турында беркайчан да баш бетереп уйлан-

мады. Көче-куәте шул хәтле биек иде ки, күп вакытта ул ханшаны күрде дә, күрмәде дә, киңәш-сабакларына бик сирәк колак салды, хәтта тыңлаган чакларында да ахыр чиктә үзенчә эшләде, үзенчә хәл итте. Аппак бар — әйбәт, юк — ансыз да яши алыр кебек иде. Бүген исә Кубрат хан, гомерендә беренче тапкыр дияргә була, уйга калды. Аппак аны яратып яшәдеме? Укытучы Константинның хатларын укыганда хан бернәрсәгә шаккаты иде: чынлап та шулай яратып була микән бу хатын-кыз затын?

Алар сарайга керделәр, Кубрат хан янә Аппакка күз төшереп алды. Хикмәтле хәл: ул ханшада шундый гүзәллек күрде ки, әйтерсең ханша бу чибәрлеген кая булса яшереп торган иде. Хан үзенең хатынына беренче тапкыр, күп еллар элек булганнан соң, кабат янә бер сокланып карады. Шушы бергә яшәгән елларда Тугрыханның тәкәббер кызы аңа биш ир бала, бер кыз бала табып бирде. Яратып яшәдеме икән ирен? Яраткандыр, яратмаганда алты бала табып бирер идеме? Әле булса хәтерендә, күктәге айдай чибәр кыз озын керфекләрен еш-еш каккалап каршына килеп баскач, Кубратның аяк астындагы җир чайкалып киткән кебек булган иде. Тәмам сихерләде шунда Тугрыхан кызы яшь Кубрат ханны. Бу халәттән бик тиз айныды айнуын Кубрат хан, әмма Аппакны күргәч тә ул чакта яшен суккан кебек катып калган иде. Торабара гадәтләнә башлады, беренче күргәч тә яшен чыбыркысыдай чәчрәп киткән мәхәббәт югалган кебек иде, инде менә картаеп килгәндә тагын әллә нишләде Кубрат хан. Ханшасы ханша гына түгел, гүя күктән төшкән фәрештә иде. Нишләп алай картайган көнендә шундый шашынып ярату килде микән? Әллә соң мәхәббәт дигәне картлыкта янә бер әйләнеп кайтамы?.. Әллә үлеме якынаямы?.. Үләр елында иң якын кешеләрең турында уйлый башлыйсың диләр бит. Кубрат ханның Аппагы-чынлап та гүзәлләрнең гүзәле. Бер аксакал Аппакны күргәч: «Чү-ү, олан, әйтмә каты сүз хатыныңа, бу балага тәңре кулы тигән, юкса бу кадәр сылу була алмас иде»,— дигән иде. Ул вакытта Кубрат хан аксакалның сүзләренә колак та салмады. Менә бүген исә, еллар үтә-үтә бала тапмый башлагач, Аппагы яшәреп, тагы да гүзәлләнеп киткән кебек...

Кичә ул Кафа һәм Судаг каласы сәүдәгәрләреннән гәрәбә муенса сатып алган иде. Сарай имчесе: «Муенса тамак чиреннән дәвалый»,— дигән булды. Ә Кубрат хан аны бөтенләй башка максат белән алган иде — хатынын куандырырга теләде. Тәхетенә килеп утыргач, Кубрат хан кесәсендәге муенсасын капшап карады. Муенса кесәдә иде. Аннары әкерен генә торды да Аппак янына килде, кесәсеннән муенсаны алып, хатынына кидерде. Аппак кисәк кенә ханның күкрәгенә капланды һәм тынып калды. Кубрат ханның йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Ниһаять, Аппак күзләрен күтәрде, мөлаем елмаеп, ханның күзләренә карады. Янә Кубрат хан үзе дә аңлап бетермәгән ниндидер югалып калу тойды. Аппакның күк йөздәй зәңгәр күзләрендә шатлык чаткылары җемелди иде. Кубрат ханның җаны актарылды, ул яшь чактагы кебек чак кына ханшаны кулына күтәреп алмады.

Бит күпме сулар акты, күпме бала тапты ханшасы аңа, күпме язлар килде, туйлар булды, ханша күзләрендә мондый яну күрмәде ул. Диңгездәй зәңгәр икән бит ханшаның күзләре! Әтил буйларын айкап, берәүләре белән орышып, икенчеләре белән килешеп, өченчеләрен буйсындырып йөргәндә ул аның сылу гәүдәсен генә күз алдында тоткан икән. Бөтен сылулыгы күзләрендә икән бит ханшаның. Аппакны Фанагургә алып кайткач, ханшаны күрергә базилевс сәүдәгәрләре килде. Күрделәр дә грек сәүдәгәрләре Аппакны, тәмам телсез калдылар — хода үзе биргәндер бу гүзәллекне диярләр иде. Кубрат хан юри ишетмәгәнгә сабышып йөрер иде, мәгәр ханшасы өчен горурланыр, сиздерми генә хатынына сокланыр иде.

Янә бер хәл ап-ачык булып хәтерендә калган Кубрат ханның: баш-

тагы мәлләрне ханша аның бер эшенә дә кысылмады, әмма үз фикерен әйтергә дә куркып тормады. Аның фикерен кабул итү-итмәве Кубрат ханның үз эше иде, мәгәр әйтәсе сүзен эчендә йомып калмады, кирәк чакта киңәшчесе булды. Юк, ул бәхетле яшәде Аппак белән. Бары тик бернәрсә ханның эчен пошыра: соңгы вакытта ханша илханнар турында сүзне ешрак кабатлый башлады. Ә Кубрат ханның тәхеттән төшәсе килми. Көтригурлар ат өстендә туа, ат өстендә үлә, диләр, Кубрат хан да үзен шушы тәхеттә туган кебек хис итә башлаган иде соңгы вакытта. Әйе, үлсә дә Кубрат хан тәхеттә үләр...

## 24

Денис кораб башында утыра, йөгереп килгән дулкыннар көймә читенә килеп бәреләләр дә янәдән су эченә кереп сеңәләр. Тын елганы менүгә, ыстандагы көтригурлар көймәне озын арбага куйдылар, мичәүләп атлар җиктеләр дә Әтил суына китереп төшерделәр, хәзер кораб ишкәксез дә су агымы белән шактый тиз түбәнгә таба төшә иде. Тагын ике-өч көннән Хазар диңгезенә җитәрләр, аннан ярты көнлек юл кала.

Денис бер нәрсәгә төшенеп җитми иде: әйтик, император белән Кубрат хан берләшеп каганга яу килмиләр?.. Кубрат хан Рось кнэзе белән дә килешү булдыра алыр иде. Һәркем үзе өчен генә кайгырта.

Башына килгән уйларны читкә куеп, Денис туган илен исенә төшерде. Үзен Кубрат ханга биреп җибәргән князь Ратомирга әле булса ачулы иде ул. Онытa алмады туган якларын, башта төшләренә кереп изаланды, Агасике кызына өйләнгәч кенә каядыр төшеп югалды туган як төшләре. Эгина барысын да оныттырды. Денис аннан башка берәүне дә күрмәде, күрергә дә теләмәде. Эгина аның өчен тормыш үзе, яшәү мәгънәсе иде. Эгина су анасы, әллә шымчы булып чыкты шунда. Хәзер дә оныта алмый Эгинаны Денис. Ул аны менә хәзер су төбеннән килеп чыкса, кабул итәр иде, ул гынамы, әйдә диңгез алласы патшалыгына дисә, ике дә уйламый төшеп китәр иде.

Койрыкчы Денис күлмәк астындагы перун алласын капшап карады, алла урынында иде. Ул, тынычланып, янәдән уйга чумды. Беркөнне Эгина шул алласын муеныннан салдырып алган да үз йоласының тавык тәпиен тагып куйган. Денис сикереп торды да тәрене салып, почмакка атып бәрде һәм перунын табып муенына такты. Эгина шунда: «Варвар, варвар, варвар»,— дип такмаклый-такмаклый, үкереп-үртәлеп жылаган иде. Көчкә тынычландырды Денис хатынын. Ул чакта аның су анасы икәнен белми иде әле.

...Ышаныч төрлечә килә икән кешегә. Кубрат ханга биреп җибәргәч тә Денис кача ала иде. Чөнки беренче төндә үк хан аңа сак куймады. Нәкъ менә шуның тәэсирендә килде бугай Денис Фанәгүргә. Ул вакытта Фанәгүрне корып кына яталар иде әле. Кайчандыр греклар нигез салган каланы әүвәл болгарларның бабалары һуннар җимереп китәләр. Бары тик болгарлар оешып, Кубрат хан ярым утрак тормышка күчкәч һәм Фанәгүрне үзенең башкаласы итеп сайлагач кына греклар яңадан бирегә күпләп күчеп килә башладылар, төзелеш эшләренә керештеләр. Кубрат хан аларга аз түләмәде. Калага юллар салынды, су үткәрелде, кала тирәли биек дивар өелде.

Денис перунын уч төбенә кысты. Перун алласы аны бик күп жирләрдән исән-имин алып кайтты, боерса, бирердән дә исән-сау әйләнеп кайтыр. Хәйләкәр дә соң бу философ. Базилевс илчесе, имеш. Таба бит әй! Әйтәм аны Кубрат хан үз ягыннан ерак җибәрми, башы түгәрәк икән тәре таккан бу нәмәстәнең. Хан кызы Чәчкәне каган кулыннан алмак булып бара. Хәер, бу философта мең хәйлә бар, диләр, кирәк икән сихерли дә ала, имеш. Бу грекларның барысы да сихерчеләрме

әллә?.. Философы сихерчедер, дин әһеле Симеон — юк. Әллә ул да Эгина кебек ырымчымы?..

Денис янә бер хикмәтле хәлне исенә төшерде. Бервакыт Фанәгүрдә кисәктән дөнья куйган грекны күмделәр, күмделәр дә каберенә агачтан тәре ясап утырттылар. Фанәгүрдәге чиркәү башына да шундый ук тәре куелган. Әйе, греклар каберләренә тәре утыртып куялар, Денисны болгарлар ничек күмәрләр, росьлар кебек яндырырлармы, әллә булмаса болгарлар кебек бөтен корал-байлыкларын куеп җир астына ләхет алып тыгарлармы?.. Моңа кадәр Денисның бу турыда уйланганы юк иде әле, бүген исә Биләмҗиргә сәфәр чыккач, ул кисәк үлем турында уйлана башлады. Әллә соң аңа да үлем якынаямы? Юкса, нигә уйлана башлады ул үлем турында?..

Ханның бу йомышын да исән-сау башкарып кайтса, Денис уй-теләген ачып салыр иде. Бәлкем, хан аны тыңларга да теләмәс, ә бәлкем Денисның үтенеченә каршы да килмәс. Кыскасы, рось Денисның Кияүкаланы кайтып күрәсе килә иде, үзе туып-үскән Ворух елга буйларын. Соңгы вакытта Рось ягыннан Фанәгүргә сәүдәгәрләр сирәк килә башлады. Денис моның сәбәбен белергә тиеш. Бәлкем әле Кубрат хан Ратомир князьгә грек утының серен дә ачар. Роська кайтырга рөхсәт алса, Денис үзе белән Илбарыс буйтурны да алыр иде.

Денис яр буендагы халыкның корабка карап калуларына игътибар итте. Көнләшеп карыйлар кебек тоелды аңа. Әйе, карагыз, карагыз, бу корабны Денис үзе ясамаса да, моннан зурракларны ясый ала ул. Мондый корабларны күргәннәре юктыр әле аларның...

— Күргәннәре бар, моннан да зуррак корабларны күргәннәре бар,— диде аның янәшәсенә килеп баскан философ.— Император кораблары. Хәзәр диңгезе аша Әтилнең өске башына күтәрелә башлады. Каган белән император солых төзеп яталар. Хәзәрләрдә хәзер йөздән артык грек галерасы бар...

Денисның күзләре шар булды: ул бу уен күңеленнән генә әйткән иде ласа, ә философ аның ни уйлаганын әйтте дә бирде! Сихерче түгел диген инде бу грекларны шуннан соң.

— Философ, ә без исән-сау кайта алырбызмы? Сине барысы да күрәзәче, диләр.

— Анысы бер алла кулында,— диде философ. Төн илләре яклап искән җилдән кафтанына төренә төште.— Бүген төнлә суытмагае, җил төньяктан исә башлады.

— Иоанн Фасиан, изге кешеме әллә син, барысы да шулай, диләр?

— Без барыбыз да табигать балалары, варвар, алла коллары.

— Мин дәме?

— Син дә, мин дә, аллаһы-тәгалә ни тели, шуны кыласың.

— Мин үз аллам алдында языклы, философ. Кеше үтердем.

— Син аны үзең теләп үтермәгәнсең, алла кушкан, я булмаса князең, ханың.

— Кемең, кемең?!

— Императорлар, ханнар, князьләр, каганнар. Алар канга сусый, аларга җәйләүләр җитми. Минем белән сиңа биләмә кирәкми, безгә ике-өч адым җир җитә.

— Миңа анысы да кирәкми, философ. Росьлар үлгән кешеләрен көймәгә салып яндыралар.

Шул вакыт корабка таба килүче бер көймә күренде. Баганада Рум дәүләте әләме булса да, көймә корабка якын ук килде. Алда диңгез җәйрәп ята иде инде.

— Каган тарханы,— диде философ койрыкчы Дениска.— Боргалама, туры диңгезгә чык. Яр буеннан ерак китмә.

— Әй, корабтагылар, сез кайсы илдән?

— Византия илчеләре, галиҗанәпләре император Ираклий корабы, хөрмәтле тархан. Мин базилевс илчесе Иоанн Фасиан буламдыр.

Хәзәрләр Иоанн Фасианны аңламадылар, философ сүзләрен төрки телдә кабатлады.

— Денис, тагын да чынрак булсын өчен син минем тылмачым булырсың. Кораб императорныкы, илчесе Иоанн Фасиан,— диде аңа философ.

Бераздан көймәдәгеләр баш кага-кага китеп бардылар.

— Беләсеңме кемнәр иде болар?— диде философ.— Каганның елга сакчылары, елга тамагында торалар. Хәзер алар судан чыгарлар, шунда ук каганга йомышчы чаптырырлар, Рум императоры Ираклийдан илче килә диячәкләр.

— Син моны каян беләсең, философ?

— Логика,— диде Иоанн Фасиан.

— Нәрсә-нәрсә?

— Логика. Шундый фән бар дөньяда.

...Бераздан корабка таба килүче өч-дүрт көймә күренде. Көймәләрне беренче булып күреп алган Денис:

— Философ, тагын көймәләр!— дип кычкырды.

— Һәй, корабтагылар, кай тарафка сәфәр тотасыз?— дип кычкырдылар алдагы көймәдән.

— Рум илчеләре, Биләмҗиргә юл тотабыз.

Көймәдәгеләр тиз арада киңәшеп алдылар, ә үзләре һаман корабка якыная баралар иде.

— Юлбасарлар болар, алыпларны дәш!— дип боерды философ.

Денис әче итеп сызгырып җибәрде, шундук өскә унике алып менеп басты, уникесендә дә ук-җәяләр, сөңгеләр, орыш кораллары. Әмма көймәдәгеләр гүя алыпларны күрмәделәр дә, һаман корабка якыная бардылар. Алдагы көймә борынына кара сакаллы киң битле берәү менеп баскан, кулында калканы, җәясе-угы.

— Һәй, корабтагылар,— дип кычкырды кара сакал.— Товарларыгызны ташлагыз. Без сезгә гомер бүләк итәбез, сез безгә — товарларыгызны!

— Хәзер, хәзер ташлыйбыз, эттән туган юлбасар,— дип Денис укчыларга боерды:— Юлбасарларга атыгыз!

Көймә ягына уклар очты, көймә башындагы кара сакал чак кына суга егылып төшмәде. Ике көймә кораб янына ук килеп җиттеләр. Корабтагыларны укка ала башладылар. Кайсыдыр утлы ук җибәрде, корабның койрык очына ут капты. Кисмәк белән су алып өч-дүрт кеше утны сүндерергә ташланды. Корабтагы ике алып, аркаларына ук кадалып, суга очтылар.

Философ койрыктагы ташаткычка бер чүлмәк грек уты куйды. Моны күреп алган Денис:

— Беренче көймәгә, әнә шул кара сакал утырган көймәгә җибәр, философ!— дип кычкырды, үзе уктан атты.

Философ чүлмәк пилтәсенә ут салды, ташаткычның бавына кылычы белән чапты. Ут чәчеп барган чүлмәк көймә янына барып төште, яман шартлады һәм кара сакал шундук суга егылды. Икенче чүлмәк икенче көймәгә очты, анысы нәкъ көймә өстенә төште, көймәгә гөлт итеп ут капты. Юлбасарлар тиз-тиз ярга таба ишә башладылар. Юлбасарлар көймәдән сикереп исән калырга теләгән иптәшләрен дә алып тормадылар.

Денис мангаеннан тирен сөртте, философ янына килде.

— Син чынлап та сихерче икән, философ.

— Койрыкчы Денис, корабны ярдан ераграк тот, тиздән Биләмҗир булыр,— диде.

Философ шулай дисә дә Биләмҗиргә бу көнне җитә алмадылар.

Кичкә таба диңгез өстенә томан төште, күп тә үтми сибәләп яңгыр ява башлады. Патрикий Симеон өске катка күтәрелде, уңлы-суллы чукынып алды, койрыкчы Денис янына килде.

— Сак бул, томан. Ишетәсеңме, койрыкчы, сак бул,— диде.

«Ә моны нигә алып бара икән философ,— дип уйлады Денис, дин әһеле кушканга ризалыгын белдереп, ияк какты.— Кулыннан тәре төшкәне юк».

— Һәй, син, бир ярдәмчеңә койрыкны, кил әле бире,— диде патрикий Симеон Денисқа.

— Ни йомышың төште койрыкчыга, йола башы?

— Утыр янымә, менә монда, ышыкка.

Дин әһеле күрер күзгә куркак кына кебек иде, тегенең янәшәсенә килеп утыруга, Денис үзе дә аңлап бетермәгән тартыну тойды.

— Карале, Симеон, синең үз алланны күргәнең бармы?

— Алла күзгә күренәме, тәүбә диген, Денис. Аның сурәте генә күз алдында булырга тиеш. Моннан соң алай димә, авызыңнан җил алсын андый яман сүзләрне.

— Күргәнең юк, димәк. Ә менә мин перунымны гел куенымда йөртәм. Шулай миңа тынычрак, шулай җанга якынрак. Ә синең кайда йөридер ул аллаң — бер шайтан үзе белә.

Патрикий чукынып алды.

— Аллаһы-тәгаләнең кодрәте зур, варвар. Шушы гөнаһларыңнан арыныйм, тазарыныйм дисәң, хәзер үк әйткән сүзләреңнән тәүбә ит.

— Ничек итеп?

— Як-ягыңа төкеренеп, чукынып ал. Менә болай,— патрикий Симеон уңлы-суллы чукынып, уң һәм сул иңе аша төкеренеп алды.

Денис аның хәрәкәтләрен кабатлады. Патрикий Симеон канәгать калды.

— Баштан ук христоска иман иткән булсаң, хатының Эгина да китмәгән булыр иде синнән.

— Ул сихерче, ырымчы иде, су анасы сурәтендә йөрде.

— Бернинди дә су анасы түгел иде ул, Денис. Мин барысын да беләм. Перуныңнан ваз кич тә, менә бу тәрене муеныңа так. Минем сүзем тыңласаң, Фанәгүргә кайтуыңа хатының Эгина өеңдә булачак.

— Фанәгүрдә, өемдә!?.. Сөйләмә тузга язмаганны, Симеон. Димәк, син дә сихерче икәнсең. Соң, моңа ничек ышанмак кирәк. Без монда, ә ул синең кодрәтең белән Фанәгүрдә, имеш.

— Минем кодрәтем белән түгел, христос кодрәте белән. Бер киңәш сиңа, варвар: тартып өз дә перуныңны, ташла диңгезгә, шундук аллаһытәгалә алдында йөзең яктырып китәр.

— Диңгезгә!? Акылдан шаштыңмы әллә син! Перун аллам — минем җаным да, тәнем дә.

— Җаның үлгәч күккә ашар, тәнең җирдә черер.

— Әйтмә миңа моннан битәр андый сүзләр, әллә ни эшләп ташлавым бар,— диде Денис һәм дин әһеле ягына әйләнеп тә карамый китеп барды.

Кояш кинәттән чыкты шикелле. Диңгез өстендәге томан таралмаган иде әле, корабка таба көймә килүе күренде. Өске катка менеп баскан философ:

— Каганның тарханы, басма төшерегез!— дип боерды.

Тархан корабка кермәде, төшергән басмага аяк басмады.

— Сәфәрчеләрне кем дип белик?

— Бөек Рум галиҗәнапләре император Ираклий илчесе корабы булыр, олуг тархан.

«Шәп әйттең,— диде философ янәшәсендә басып торган Денис-

ка.— Шушы мизгелдән син минем тылмачым, мин төркине белмим. Ишеттеңме, койрыкчы!»

Каган тарханы Румнарның кораб очына эленгән әләмгә күз төшереп алды, үзенә генә аңлаешлы бер киная белән елмаеп куйды.

— Каган сезне кабул итәрме-юкмы, белмим...

Иоанн Фасиан басмага керде, тарханның уч төбенә бер янчык алтын ташлады. Каган тарханы янчыктагы алтынның авырлыгын чамалап, уч төбендә сикертеп алды. Моны күреп Денис: «Җиңел котыла бу сихерче, Кубрат хан алтыннары белән»,— дип уйлап куйды.

— Каганның кабул итүен тиз арада хәбәр итәрләр, Рум илчесе,— диде тархан һәм көймәсен борып китеп барды.

— Философ, алтынны күбрәк бирмәдеңме бу күпкән корсакка?

— Юк, койрыкчы, күп бирмәдем. Политика беркайчан да акча санаганны яратмый, Денис. Акча санаган политика я ота, я оттыра. Ә миңа оту кирәк, без каганга зур йомыш белән килдек.

— Һы, бу политика дигәнең миңа караңгы. Отуга китсә, мин риза. Карале, философ, каганның сарае тулы җария кызлар, ди. Хакмы икән шул?

— Эгинаны оныта да башладыңмы әллә, Денис. Хатын сатып алырга исәбең бармы? Әйе, җария кызлар каганда җитәрлек. Сорасаң бирүе бар. Мәгәр син сорамассың. Син минем бары тик тылмачым гына, койрыкчы Денис, ишетәсеңме, тылмачым...

— Ярый-ярый, баш өсте, философ. Барысын да син дигәнчә итәрмен. Алай да кыйммәт икән ул политика дигәнең.

— Кыйммәт, Денис. Бик кыйммәт. Политика дөньядагы бар нәрсәдән дә кыйммәт.

— Сатмаса, һич югы бүләк итеп бирел җибәрсен иде бер җариясен.

— Арысланнан сөяк артса да, шакалдан артмый, Денис. Хатын да политика өчен генә кирәк аңа.

— Тагын шул политика,— диде Денис кәефе кырылып.

— Менә тыңла, Денис. Каган Кубрат хан кызы Чәчкәгә өйләнде, ди. Булуы бармы мондый хәлнең? Бар. Каганның Кубрат хан кызы Чәчкәгә өйләнүе булыр, икенче көнне үк булмаса да, күп тә үтмәс, каган алае белән Фанәгүргә килеп төшәр, төрки дөньясы башына янә Ашин ыруы менеп утырыр... Аңлашылдымы?.. Ә хәзер бар, койрыкка үзең бас. Тиздән каган бухтасына җитәрбез.

Кораб туктап, басманы салуга, алар янына тәүге тархан килеп басты.

— Философ, болай булса Кубрат хан кызын төшендә дә күрмәячәк. Күрәсең ни кыланалар.

— Варварлыгың сиздермәсәң иде, Денис. Мин сиңа кабат әйтәм, син минем бары тик тылмачым. Минем бер сүземә дә кысылмыйсың.

— Баш өсте, философ. Барысы да син теләгәнчә булыр. Хәзәр каганы яшь, бик тә үткер, диләр. Эшебезне сизмәсен дип борчылуым, философ.

— Борчылма, барысы да әйбәт булыр. Каган Кубрат хан кызы Чәчкәгә гашыйк. Мәхәббәт бар җирдә политика таркау булыр, шулай ди Кубрат хан.

— Никадәр куәткә ия бу политика дигәнең, философ.

— Политика ул ике дәүләт арасындагы мөнәсәбәт, бәйләныш.

— Кем ясый соң ул политика дигәнне?

— Дәүләтнең зирәк даирәләре, акыллы башлар.

— Хәйләкәр кеше акыллы буламы, философ?

— Хәйлә ул — корал, җәясез ук. Бак әле калага, кара әнә, кара. Кирмән сала белмиләр, ә кала Фанәгүрдән зуррак. Халык ул — көч, куәт, Денис. Ә көч белән исәпләшмичә булмый.

Философ артына әйләнеп карады, каганга дигән бүләкләрне күтәр-

гән алыпларны күздән кичерде. Барысы да ул уйлаганча бара иде әлегә. Каравыл башлыгына җиттеләр, Иоанн Фасиан аңа янә бер янчык алтын ташлады.

— Һай кыйммәт икән бу политика дигән нәрсә, философ,— диде Денис каравылбашның уч төбенә барып төшкән янчыкка карый-карый.— Бәһасез икән бу политика дигән нәрсә.

— Кайгырма, тылмач. Ахыр чиктә сине кол итеп сатармын.

— Философ!

— Тылмачмы син, Денис?!

— Адым саен ришвәт алалар!

— Ришвәт алу Болгарда юк дисеңме?

— Ришвәт бирүчеләрне дә, алучыларны да Фанәгүрдә ат коерыгына тагалар.

— Хак әйтәсең, Денис. Ришвәт халыкның дәүләткә булган ышанычын югалта, гаделне кимсетә, яманга юл ача.

Каган сараена килеп җитүләре булды, аларга көймә белән килгән тархан каршы чыкты. Тархан гүя Денисны күрмәде дә, грекчаны ватаҗимерә илчегә мөрәҗәгать итте.

— Хәериең, илче! Рәхим ит!

— Ишетәсеңме, төркичә аудар. Нәрсә авызың ачып катып торасың!

Денис философ грекча әйткән сүзләрне үзенчә төкми-чәчми төркичә аударып бирде. Тархан бик канәгать калып, алдан китте, илчеләр бүләкләр күтәргән хезмәтчеләре белән аңарга иярделәр.

Каган бүлмәсенә килеп керделәр. Ул тоташ кызыл ефәктән тегелгән чапан кигән, башында чите кеш тиресе белән каелган калпак сыман кием. Йулыш каган Димәшкъ сәүдәгәрләре китергән басра келәмендә кырын ята иде, илчеләр килеп керүгә, тирәсендә биеп йөргән җариялəрне алып китегез дип, харәм агаларга кул селтәде.

Йулыш каганга җитәрәк, Иоанн Фасиан илче аңа бил бөкте, аның хәрәкәтләрен Денис тылмач та, хезмәтчеләр дә кабатладылар. Шуннан соң гына философ:

— Күк йөзе астындагы изгедән изге, игелекледән игелекле Йулыш каган, Бөек Византия илчесе Иоанн Фасиан сезгә озын гомер җиңел һәм якты юл, арысландай батырлык, юлбарыстай кыюлык тели. Император галиҗәнапләре сезгә, кодрәтле каган, күптин-күп сәламнәр юллый.— Философ тылмачка күз ташлады, Денис уянып киткәндәй, философның сүзләрен төркигә аударды.— Күк йөзе астындагы бердәнбер изге һәм игелекле каган, император галиҗәнапләре Ираклий сезгә бүләкләр җибәрде...

Илче Иоанн Фасиан бүләкләрне каган алдына илтеп куярга боерды. Хезмәтчеләр бүләкләрне куя бардылар, китә бардылар. Бүләкләр килә башлауга, каганның уң кулына яһүд килеп кунды. Аның төркине шәп белүен илче соңрак белде-белүен, әмма баштан ук шикләнә калган иде ул аңардан. Тылмачның кирәге калмады, яһүд Иоанн Фасианның сүзләрен сүзгә-сүз тәрҗемә итә башлады.

Бүләкләр янында камалы тун ята. Бу тунны Кубрат ханга император Ираклий тектереп җибәргән иде. Әнә нишләтә политика кешене, үз тунын биреп җибәргән Кубрат хан, дип уйлады Денис.

— Гаян,— диде каган артына карамый гына,— Алып куй бүләкләрне.— Каган илчеләргә күз төшерде.— Инде дәрәҗәләрегезгә карап утырышыгыз, илчеләр.

Илчеләр дәрәҗәләрен белеп, төрлесе төрле түмәрләргә утырышкач, каган урыныннан күтәрелде, дәү гәүдәсен җиңел генә йөртеп, урап килде, иң биек түмәргә менеп утырды.

— Минем император Ираклийга рәхмәтем зур, илче. Базилевска әйт, илче, каган синең игелегең онытмаган диген. Дөрес, миңа базилевс-

ның бар кылган эшләре дә ошамый. Әйтик, нигә дип ул илендәге яһүдләрне кысырыклый, җәберли, илләреннән куа?..

Философ кадәр философ каганның бу соравына аптырап калды. Ул ни әйтергә белми дип әһеле патрикий Симеонга карады.

— Бөек каган,— дип алгарак чыкты патрикий Симеон, философның күз карашыннан ук сүзнең үзенә бирелүен аңлап.— Бөек каган, без бары тик монда император илчеләре генә. Яһүдләрне кабул итеп, сез үзегезне императордан да игелекле итеп күрсәттегез. Без аңа, бөек каган, сезнең киңәшне тотып, бу ялгышны төзәтергә кушарбыз.

Каган җаваптан канәгать калды, урыныннан купты да сыгылмалы адымнар белән аш ягына таба кузгалды.

Табынчы илчеләрне ашка дәште.

Аш ягында барысы да әзер иде инде. Барысы да табын тирәли утырыштылар. Табындагы ризык-нигъмәтнең исәбе-хисабы юк иде. Аш ягы бүлмәсенә йөзләгән кеше сыярлык. Әмма бүген халык аз, каганның якыннары гына чакырылган, күрәсең.

Әүвәл каган көмеш савыттан элеп кенә алтын җамнарга кымыз салып бирде. Бу эшне Йулыш каган якын кешеләре килгәндә генә башкара иде бугай, тәмләп, озаклап бүлде. Каган һәр кунакка җамнарны үзе өләште. Аннары үз җамын күтәрде дә:

— Илчеләр хөрмәтенә!— диде.

Табынчы аштан житешергә кыстап йөрде, кунаклар алдына теге я булмаса бу ризыкны күчергәләп куйды.

Ашап утырганда каган янына берәү килде, колагына гына нидер әйтте, каган аның белән килешеп, ияк какты. Күп тә үтми аш бүлмәсенә бер әсирне алып керделәр. Денис әсир ягына әйләнеп карау белән «аһ»! дип җибәрүен сизми дә калды. Ярый моңа игътибар итүче булмады, барысының да күзләре куллары артка каерылып бәйләнгән әсирдә иде. Алар каршында өс киемнәре ерткаланып беткән Илбарыс буйтур басып тора иде. Буйтурның йөзе шешенгән, күз кабаклары кызарган, иреннәре яргаланган. Философ буйтурны күрде дә авызына капкан ризыгын чәйнәүдән туктап торды. Аннары каганга карады.

— Колмы, сатугамы?— дип сорады.

— Кубрат ханның асрауга алган угланы Илбарыс буйтур булыр бу, илче. Мин төрки халкының батыр угланнарын мыскыл итәргә теләмим, чишегез кулларын, салып бирегез бер җам кымыз!— дип боерды каган.

Аның боерыгын шундук үтәделәр. Куллары чишелгәч, Илбарыс буйтур беләкләрен угалап торды, табындагыларга күз йөртеп чыкты. Табынчы аңа кымыз китерде, әмма буйтурның күзләре илчеләрдә иде. Әнә, философ берни булмаган кебек сөяк кимерә, койрыкчы Денис ни кылырга белми алтын җамын әйләндергәләп утыра, дин әһеле патрикий Симеон гына үз күзләренә үзе ышанмыйча, шаккатып, буйтурга карап тора...

— Иә, буйтур, эч. Эч тә сиңа әйтәсе сүзем бар. Мин синең кем икәнеңне беләм, буйтур. Сине рәнжеткән кешеләрне, телисең икән, җәзага тартырмын. Мәгәр бер шарт белән: миндә калсаң гына...

Буйтур, юк дигәнне белдереп, әкерен генә башын чайкады.

— Калмыйсың?— дип сорады каган.

— Юк, каган, калмыйм.

— Уйла, буйтур. Каласы булсаң, мин сиңа алай бирермен, Кубрат хан биргән дәрәҗәң алырсың... Инде барысыннан да баш тартасың икән...— Каган бер тын дәшми утырды.— Менә монда, минем табында Рум илчеләре утыралар, сәүдәгәрләр,— диде янәшәсендә утырган яһүднең сүзен кабатлап каган.— Кол сатып алучы сәүдәгәрләр...

Денис каганның бу сүзләреннән авызын ачып ни әйтергә белми

торды, иллә философ аны кисәтеп өлгерде. Менә илче аягүрә басты, кол ягына күз дә сирпеми:

— Колны мин алыр идем, бөек каган,— диде.

— Ал, илче,— диде каган.

— Бөек каган. Мин кызлар яратам, кыз-каравышларың юкмы? Бу буйтур урынына мин Кубрат хан кызы булса, мин сиңа, каган, мең алтын түләр идем...

— Кубрат ханның кызын аласың килдемени, илче?

Каганның кинаяле соравын шундук аңлап алган Иоанн Фасиан югалып калмады.

— Әйе, ярты дәүләтем биреп булса да.

— Ярты дәүләт. Бәлкем, мин аңа алмашка бөтен бер дәүләтен сорармын, илче?

— Юк, бөек каган. Бөтен бер дәүләтем бирә алмыйм. Акыллы илбашы кыз өчен илен-халкын сатмый.

— Мин ул кызны базилевсның угланы белән ярәшелгән икән дип ишеттем. Хакмы шул, илче?

— Хак, бөек каган.

— Базилевс угланына кызны үзем алып бирәм... кайбер җәйләүләре хакына.

— Сезнең кодрәтегез киңдер, каган. Алай да...

— Ышанасың килмиме?.. Ярый, илче, мин сине ышандырырмын. Тиздән мин Болгарга яу чабам. Болгарның җәйләүләре генә түгел, Фанәгүр дә минем кулда булыр. Императорга шарт куям, илче: хан кызын аңа алып бирсәм, император миңа Боспор һәм Херсонесны бүләк итәр...

— Сезнең киңәшегезне императорга җиткерермен, каган. Ә хәзер миңа бу колны сатыгыз, хан кызына акчам җитмәс,— дип көлде Иоанн Фасиан.

— Мең алтын булыр бу кол, илче.

— Мең алтын ук, каган.— Философ җавап бирми торды, ашыгып эшне бозып куюы бар иде.— Яу чыкканда акча күп кирәк шул, каган... Ярый соң, мин риза.

— Алыш-бирешне хәзер үк хәл итәрсең, илче.

Көмеш табакка куеп, базда тирләп чыккан эчемлек китерделәр, каган аны кеше башы хәтле алтын савытка бушатты. Аннары күтәреп яртысын эчте, калган яртысын илчегә сузды.

— Бөек каган, минем бу хәтле эчемлекне туганнан бирле эчкәнем юк.

— Эчмәгән булсаң, эчеп кара. Ал савытны кулыңа, илче!

Иоанн Фасиан курка-курка савытны кулына алды. Савыт кеше башына охшатып ясалган иде.

— Ай-һай, авыр икән. Түнмәм микән соң моны эчкәннән соң, бөек каган?..

— Белеп эч, илче. Бу алтын савыт эчендә менә бу буйтурның ыру агасы Ураган каганның баш чирәбе булыр. Тиздән мин сиңа Кубрат ханның баш сөягенә төренгән савыттан эчертәчәкмен!

Нинди тапкыр сүзле философ та каганның бу сүзләреннән соң бер мәлгә югалып калды, теләсә-теләмәсә дә буйтур ягына күз ташлап алды. Илбарыс угланының йөзендә кан әсәре калмаган иде.

— Эч-эч, илче! — диде каган.

Иоанн Фасиан савытны күтәреп, бик озак эчте, аннары савытны каганга бирде. Каган тагын савытка тутырып эчемлек салды.

— Инде Саклаб кавхан угланы буйтур Илбарысны эчерегез!

Табынчы шундук каганның боерыгын үтәргә кереште. Әмма буйтур эчәргә теләмәде. Буйтурны ике яклап бөтереп алдылар, егып диярлек авызына эчемлек койдылар. Бу хәлне күреп, Денисның күзләре шар

булды, ул бармак буыннары агарганчы кулындагы алтын җамны кысты. Шул хәтле кысуга җам кечерәя бара кебек иде. Түзмәде, Иоанн Фасианның аягына басты, имеш, әйт бер сүз, син бит сихерче, сихерлә үзләрен!

Ниһаять, буйтурны эчерделәр, әмма каганның хикмәтләре моның белән генә бетмәде, ул шул савыттан табындагыларның барчасына да эчемлек эчертеп чыгарды. Дениска чират житкәч, койрыкчы савытны кулына алмый торды. Иоанн Фасиан аңа теш аралаш: «Денис, түз, түз!»— дип кабатлады.

Философ тавышында эчке калтырау тоеп, Денис сул як яңагы тартыша башлавын тойды. Яңак тартышуы шул чаклы нык иде ки, Денис ни кылырга белми яңагына ябышты. Ул арада Илбарыс буйтурны ике кулыннан сөйрәп алып китә башладылар. Дин әһеленең йөзе кәгазьдәй агарынып китте, калтыранган кулы белән уңлы-суллы тәртенеп алды.

— Бөек каган,— диде философ бераз исерүен сиздерергә тырышып.— Бөек каган, колымны корабка илтсеннәр иде.

Каган килешеп ияк какты. Иоанн Фасиан капчыгыннан зур янчык белән мең алтын чыгарды, аны уч төбендә тотып торды, аннары каганның көмеш савытына ташлады.

— Житә,— диде каган, илченең кыланышыннан канәгать калып.— Житә. Булыр.

Яңадан табынга утырыштылар. Иоанн Фасиан табынга килеп утыргач та үзендә берәүнең карашын тойган иде. Башта ул моңа игътибар итмәскә тырышты, әмма серле караш аны әкрен генә җеп белән үзенә тарта сыман иде. Ниһаять, түзмәде, Иоанн Фасиан каерылып шул якка карады. Аңа чал чәчле, сирәк сакаллы, ни сәбәпледер гаять дәрәҗәдә чуар киенгән, маңгае су салырдай ермачланган төптәңре Үрәгәй карап тора иде. Иоанн Фасиан аны бу карт белән таныштырмасалар да таныды — төптәңре Үрәгәй. Нәкъ менә шулай күз алдына китергән дә иде ул аны. Илченең карашын төптәңредә күрүгә каган:

— Төптәңре Үрәгәй,— диде.— Төптәңренең күрәзәлеге бөтен төрки дөньясына билгеле. Төптәңренең сиңа хөрмәте зур, илче. Аның сиңа берничә сорау бирәсе килә.

Картның карашы шундый иде ки, гүя ул сине үтәли күрә.

Төптәңре Үрәгәй урыныннан кузгалмады, кулындагы кояшка охшатып ясалган йомры башлы кам таягын гына күтәрә төште.

— Минем илченең төп йомышын беләсем килә: килү ниятең каганның уй-ниятен белүме, әллә Кубрат хан кызы Чәчкә язмышымы, илче?

Мәкерле, мәкерле иде төптәңре Үрәгәйнең соравы, Иоанн Фасиан бер тын уйланып утырды. Ниһаять, башын күтәрде, төптәңре Үрәгәйгә карап түгел, каганга карап әйтте:

— Мондый сорауга җавап бирмәскә дә хакым бар, каган. Иллә минем алга аксакал сорау куйган икән, җавап бирми дә булмастыр. Кадерлем аксакал, бөек каган, табындагы каган якыннары, кеше кешенең уен белсә, аны бик тиз алла итәләр. Шуның өчен алла — күктәдер, без — җирдәдер, алла колларыбыздыр. Без бер-беребезнең ни уйлаганын бары тик гоман гына итә алабыз, кеше уен белү мөмкин түгел. Яшермим, император Ираклий төрки халкының иң көчле булган ыру башының уй-теләкләрен бик белергә телидер. Әмма каган аңа күңелендәген ярып әйтерме?.. Кеше күңелендәге бар серне белү куәтен хода үзенең колына бирмәгән. Кеше уен беләм дигән кеше йә ялганлый, йә гоман итә. Мин ышанам ки, бөек төрки халкының бөек каганы минем императорыма хак сүзләрен генә әйтеп җибәрер. Бөек Болгарга яу чабарга нияте бармы каганның, юкмы?

Сорауга сорау белән килгәч, төптәңре Үрәгәй тамак кырды, каган утырган урынында борсаланып алды.

— Император Ираклий минем уй-теләгемне белергә тели икән, әйтәм, илче: мин чынлап та Болгарга яу чабарга булдым. Кубрат хан буй-

сынмый икән, мин аның белән орышачакмын һәм хан башыннан савыт койдырачакмын!

Үз җавабыннан үзе канәгать калган каган ияген чөя төште, Иоанн Фасианның күзләренә текәлеп карады. Моны сизеп, философ аңа ияк какты, җаваптан канәгать калуын аңлатты.

— Бөек каган, мин сезнең җаваптан канәгатьмендер.

— Илче икенче сорауга җавап бирсен,— диде төптәңре Үрәгәй.

— Хөрмәтле аксакал Үрәгәй. Мин дә синең кебек кеше күңеленә керергә бик тә яратам. Иллә мин дә синең кебек үк җир кешесе. Беләм, аксакал, акыл кешегә яшәү гомере белән генә килми. Акыл кешегә уку белән дә килә. Син исә укый да, яза да белмисең. Сине бернинди дөньяви хәлләр дә кызыксындырмый. Сиңа картлык килгән. Син мине, аксакал, гомереңбуена җыйган акылың белән шаккатырмакчысың. Әгәр дә мәгәр Кубрат хан кызы гүзәлләрнең гүзәле менә монда була икән, мин аның өчен ярты дәүләтем бирер идем. Император Ираклий да шулай итәр иде аны. Сиңа инде, кадерлем аксакал, бернинди дә кыз кирәкми, каган янында яшәү өчен сиңа бары тик акыл сату кирәк. Акыллы фикер һәрчак табылып тормый. Яшәү өчен яшьлек кирәк. Артык әйткән булсам, күңелегезгә авыр сүзләр төшергән булсам, кичерә күрегез, аксакал. Чөнки, картлык кичерә алуы белән, яшьлек дуамаллыгы белән ямьледер.

Иоанн Фасианның җавабы каганга ошады, ул беренче булып кеткелдәп көлеп алды.

Төптәңре Үрәгәй кисәктән көч-хәл белән аягүрә басты, күккә кам таягын күтәрде.

— Кубрат хан каган Фанәгүргә барып җитүгә дөнья куйган булыр. Миңа моны хәзер генә тәңре җиткерде.

Барысы да күзгә-күз карашып алдылар. Иоанн Фасиан уйлады: «Әйе, чынлап та хикмәтле кеше икән бит бу төптәңре. Каган Болгарга яу чабар, Фанәгүргә барып җитмәс борын Кубрат ханның үлеме турында хәбәр алыр. Бөтен Болгар алаена куркӳ килер. Ил бер мәлгә хансыз калыр, шул чакта Болгарга каган килеп керер. Хәйләкәр каган Болгарны алу белән Үрәгәй картны юк итәр, чөнки карт аның турында бик күп белә. Төптәңре итеп болгардан куяр. Ә тегесе үз чиратында болгар халкына каганны мактар, каганга дан җырлар».

— Җаек бәгем Кубрат ханның Эске кирмәнен камауда тота. Мин олуг бәгемә ышанам, ул ханның гүзәл кызын кулына төшерер, илче. Хан кызын мин императорга җибәрермен,— диде каган.

Илче Иоанн Фасиан каганга түбәнчелек белән бил бөкте.

— Император барысын да сез теләгәнчә итәр, бөек каган. Мин аны моңа хәзерләрмен...

Каганның сөйләшү кыяфәте Иоанн Фасианга ошамады. Кысыграк күзле, юантык гәүдәле, колак эченнән йоннары күренеп торган каганның йөзендә өмет юк иде. Ул чынлап та Болгарга яу чабар, орышыр. Әгәр дә мәгәр шул вакытта Кубрат ханның гомере өзелсә, Болгарны җиңәр һәм хан кызын кулына төшереп, император Ираклийга шартлар куяр — Боспорны, Херсонесны сорар.

— Бөек каган, яу чабуны кай вакытларда башларга исәбегез? Кыюлыгым җитеп әйтәсем килә, сәүдәгәрләр үтенече бу. Орыш барганда император аларны җибәрми торыр иде.

— Яу чабуның вакытын берәүдән дә яшерәсем килми. Тиздән, бик тиздән. Кабат әйтәм, Эске кирмән камауда инде. Күп тә үтмәс, Болгар безнеке булыр. Кубрат хан Рось кнәзьләре белән килештә яши, росьларны мин дошман күрәм, Болгардан соң Роська яу чабам. Кубрат хан яклы булган бер генә Дулу ыруы да исән калмас. Сәүдә калалары Кафага, Судагка үз тарханнарым утыртырмын. Ил чикләремне империя җир-

ләренә илтеп терисем килә минем. Моны миңа тәңрем ирештерер. Шулай дип житкер императорыңа, илче.

Каган кул чапты, илчеләр белән сүзе бетүен аңлатып, кул ишарәсе ясады. Илчеләргә китәргә мөмкин иде.

Политика мәсьәләсенә килгәндә Иоанн Фасиан теләгенә иреште. Денис барысын да күреп, тыңлап утырды, философның һәр сүзен жиренә житкереп, төгәл итеп аударырга тырышты. Философ Иоанн Фасиан бик нечкә һәм оста итеп, каганның дәрәжәсен төшерми генә, күңелен рәнжетми генә тегенең бөтен уй-теләген суырып алды. Корабка кайту юлында Денис Иоанн Фасианнан шул турыда сорады.

— Философ, син каганны сихерләдең бит. Каганнан бар илче дә исән чыкмый диделәр. Христосың ярдәм иттеме?

— Денис, күз буу, сихерләү, ырымлау — барысы да кешедәге акыл белгесе. Моны бары тик белемле, укыган кеше генә, аның да акыллысы гына аңлый ала.

— Каган дамы?

— Каган укый-яза белә. Ә менә аның төптәңресе укый да, яза да белми. Тормыш тәжрибәсенә генә таянып эш итмәкче. Тормыш ул сукалаган жир кебек: икмәк чәчмәсәң, шайтан таягыннан башка һич нәрсә үсми.

— Философ, каган миңа императордан гаделрәк күренде. Ясакны уннан бер итеп кенә сала икән, әсирләрен кол итми, өйләндерә, жәйләү бирә. Синең императорыңда сарай тулы соры корт, уенчы, куштаннар. Ни өчен ярты грек Болгарга күчеп килде дип беләсең, авыр ясактан качып. Ник дәшмәс булдың, философ? Дөрес сүзгә жавап юкмы?.. Синең императорың исә башка йоладагы кешеләрне йә утта яндыра, йә дар агачына аса.

— Император көч ул, куәт ул, бер сүз белән, хаким ул. Ә хакимгә каршы сүз әйтмиләр. Сүз әйтәсең икән, башсыз калуың бар... Син әйбәт укучы, Денис,— диде философ һәм койрыкчыны басмага алдан кертеп жибәрде.— Боер, Денис, кузгалабыз!

Ишкәкчеләр урыннарына утырдылар, басма алынды, кораб кайтыр юлга төште. Бер янчык ришвәт алып калган тархан аларга кул изәп калды. Кораб су юлына төшеп, тигез генә бара башлагач, философ койрыкчы Денис янына килде.

— Син мине кичер, Денис. Син акыллы кеше булып чыктың. Күрәм, синең тизрәк буйтурны күрәсең киләдер. Ашыкма. Әнә күрәсеңме, ике көймә озата киләләр. Каган шымчылары. Чын хәлебезне белсәләр, каган безгә үлемнең иң яманын сайлар.

— Буйтур астамы?

— Аста. Борчылма, аны ашаттылар, эчүен дә ким куймады. Йоклый ул, ял итсен. Каган шымчылары аны өстә күрсәләр, безне Этил тамагына кертмәсләр.

— Әйт әле, философ, синең христиан йолаң тәңредән дә, перуннан да өстенме?.. Ә мин беләм, христиан йоласы барысыннан да яман...

— Йола ул, Денис, дәүләтнең акылы, ышанычы, яшәү чарасы. Йола ул кеше күңеле, ә күңел сине якламаса, ягъни халкың — дәүләт үлә, юкка чыга. Мин күрдем, хәзәрләрдә дә дәүләт туып килә. Каганны яһүдләр уратып алган, киңәшчеләре дә, сабак бирүчеләре дә яһүдләр. Моннан шундый нәтиҗә ясарга була: каган тиздән яһүдләр йоласын кабул итәр.

— Чынлап та күрәзәчеме әллә син, философ?

— Күрәзәче, Денис, яшәү тәжрибәм белән, уку-белемем белән күрәзәчемендер...

— Этил елгасы тамагында туктатмасалар, без котылдык болай булгач, философ.

— Котылу юк безгә, Денис,— диде Иоанн Фасиан.— Без барыбыз да кеше кешесе...

Әтил тамагын кич белән уздылар, берәү дә аларны туктатмады. Икенче көнне иртән яңа көнне каршы алгач, ашагач-эчкәч кенә Денис койрыкны ярдәмчесенә бирде һәм буйтурны өскә алып менде.

— Сөйлә,— диде ул буйтурның күзенә карамый гына гаепле кеше сыман.— Барысын да сөйлә. Кубрат хан шомда, яу көтә. Каганның Кубрат хан кызын кулына төшерә алуы мөмкин хәлме?

— Җаек бәктә утыз мең алай, Кодрак илханда биш-алты мең җыеламы-юкмы. Җаек бәк Кодрак илханны тиз генә ала алмас. Кирмәнлык, килер ягы текә, тирәли су җибәрелгән. Шулай да...

— Каган хан кызы Чәчкәне кулына төшерсә үзенә алырмы, император угланына җибәрерме?

— Белмим, Денис,— диде буйтур, ул Денис янәшәсендә утыруына һаман ышанмый кебек.

— Син хан кызын ярата идеңме?

— Мин аны әле дә яратам, Денис.

— Ничек үзеңне әсир иттеләр, Көбер хан биргән йырмак алаеңкая?..

Илбарыс буйтур төкми-чәчми барысын да сөйләп бирде. Денис башын чайкый-чайкый тыңлаганнан соң әйтте:

— Туганкаем, хан кызына өмет тотып ялгышмыйсыңмы син? Кубрат ханны беләм мин, ул үлгәндә дә сүзендә торыр. Шигем арта башлады, хан сине бу якларга юри җибәрмәдеме икән? Бәлкем, ялгышамдыр. Хәзер ни кылырга исәбең?

— Күчүгә җитүгә, ат алам да Эске кирмәнгә китәм.

— Анда хан кызы Чәчкә, шулаймы?

— Шулай, Денис. Хан кызы Чәчкә генә түгел, минем йырмак алаем да анда.

Денис елга өстенә күз ташлады. Елга тын иде, кораб әкрен генә өскә үрли.

— Кубрат ханны мин аңлый башладым кебек, Илбарыс.

— Мин дә. Төптәңре белән бәхәскә кермәскә кирәк иде аңа. Төрмәләргә ябып изалаган бичараны.

— Әйе, булды андый хәлләр дә.— Төптәңре сүзен ишетүгә, буйтурның йөзе үзгәрде, Денис сүзне икенчегә борырга ашыкты.— Беркөнне миңа патриканй Симеон беләсеңме, нәрсә диде? Иоанн Фасиан күктән ашкан, әүлия, ди. Әллә соң чыннан да шулаймы? Каган белән сөйләшүен күрсәң иде син. Каган кадәр каган тегенең белән килешеп утырды. Ә сине ничек иттереп сатып алды... Юк, күктән иңмәсә дә, акыл иясе бу философ. Беләсеңме, ул миңа варвар дими башлады.

— Минем өчен ике кеше изге — укытучы һәм Аппак ханша.

— Аппак ханша?! Ә Кубрат хан?

— Ул бик еш ялгыша башлады. Янынан якыннарын биздерде.

— Төптәңрене әйтәсеңме?

— Аны да.

— Кеше түгел, ат та абына, буйтур.

— Ат абынадыр, кеше исә абынмаска тырышырга тиеш. Аерата хан.

— Хак әйтәсең, буйтур. Безнең ыруны Ратомир князь йотты. Шундый заман килде хәзер, ыру-ыруны, дәүләт-дәүләтне йота. Ахырзаман житүедер...

— Каганның Болгарга күзе кызган. Куәте-кодрәте житсә, бер кабуда йотар иде.

— Йотмый торсын, тамагына тыгылыр. Кубрат ханда грек уты бар. Болгарны тиз генә ала алмас каган... Ышанасы килми...

Кучештә аларны көтәләр иде инде. Буйтурны исән-имин күргәч, аны таныган алыплар берәм-берәм килеп кочаклашып күрештеләр. Аңа шундук кием-корал, ат бирделәр. Атка менгәч, буйтурның күзләре яна башлады. Дала җиле шулай исерттеме аны? Корабны алып киткәннәр иде инде, буйтур ат өстендә баручы философ Иоанн Фасианны куып җитте, атыннан төшеп, алдында баш орды.

— Философ, Фанәгүргә кайткач, укытучыга минем өчен бил бөгеп сәламем җиткер. Рәхмәтемнең чиге юк, ак юл сезгә!

— Син кая юл тотмакчысың, буйтур?

— Эске кирмәнгә, алаем янына.

— Эске кирмән камауда, буйтур.

— Туган җәйләүнең урманы да минем өчен ыстан, философ.

— Ак юл сиңа, буйтур!

Буйтур сикереп атына атланды, ат тоякларыннан балчык чәчрәтә-чәчрәтә Эске кирмән ягына таба чапты. Буйтур бераз киткәч кенә Денис аңына килде. Ул башта кычкырып карады, аннары атын кузгатырга маташты, мәгәр куып җитә алмавына ышанды — аты бик өтек иде, кучештә торучы алыплар җигәргә ярамаган атларын гына бирәләр.

Денис кабаланып философ янына ашыкты. Иоанн Фасиан бер кая да ашыкмый, бер көйгә җай гына бара иде. Денис аны куып җитте дә атын янәшәдән атлатып китте.

— Философ, буйтурны нигә җибәрдең?

Иоанн Фасиан аңа дәшмәде, әмма тезгенен җыя төште, сирпелеп Денис ягына карап алды.

— Буйтур Илбарыс хан кызы Чәчкәне ярата. Бу аңа язык.

— Язык?! Ярату языкмы, философ!

— Ярату язык түгел, хан кызын ярату язык. Кубрат хан моны теләми. Син беләсең булса кирәк, Денис, ханнар беркайчан да үзләренә хыянәт иткәннәрне кичермиләр. Исеңә төшерәм: хан кызы базилевс угланы Юстинианга ярәшкән.

— Буйтур хыянәтчеме, философ? Ни сөйлисең син?

— Мин ни сөйләгәнемне беләм, Денис. Менә син ни кылганыңны белмисең кебек. Мин буйтурга бары ярдәм итәргә теләдем. Аның Кубрат хан кызы Чәчкәгә гашыйк икәнен белсәм, каганнан сатып алмаган да булыр идем. Кубрат хан аның үлемен теләгән. Бер төмән алай белән утыз мең алае булган Җаек бәккә каршы җибәргән, үләсен белеп җибәргән.

— Аһ, яман сөйлисең, философ. Бик яман сөйлисең. Кубрат хан буйтурны угланнарыннан да якын күрә.

— Шуңа да ул аны үлемгә җибәрә, якын күргәнгә. Ханнар, императорлар теләсә кемне үтерә алалар, Денис. Алар бары тик үзләренә ясаган игелекне генә кабул итәләр. Эшләп кара син аларга нибары бер яманлык, башың шундук җәллад балтасына керер.

— Философ, мин синнән торган саен курка барам. Биләмҗиргә барганда мин синнән алай ук курыкмый торган идем.

— Мин үзем икебез өчен дә курка башладым, Денис. Безне нинди йомыш белән җибәрде Кубрат хан?.. Каган кулыннан хан кызын коткарырга. Кая ул кыз?! Кая!? Эске кирмәндә, камауда. Шулай дип котылырсыңмы Кубрат ханнан? Котылмый тор, ханнар кулы каты була, Денис, бик каты була.

— Анысын хак әйтәсең, философ. Мине әнә Ратомир князь эх тә димичә Кубрат ханга биреп җибәрде... Алай да минем җан тыныч, каганның кайчан яу чыгуын белдек.

— Белмәдек, Денис. Кага безгә дөресен әйтмәгәндер, әйтмәс. Үти алмадык Кубрат ханның йомышын. Аңарга каганның яу чыгу хәбәрен болай да көне белән житкерәләр. Ханга кызы кирәк, Денис, аңлыйсыңмы шуны... Йа, хода!

Шымчылар башы җилләнеп Кубрат хан янына юнәлде, ишек янында торучы сакчыларга ул хәтта сирпелеп тә карамады.

— Олуг хан, яман хәбәр кайтты. Җаек бәк утыз төмән алай белән Эске кирмәнне камаган. Йулыш каган төп алае белән Балкыр илханның йырмак алаен чигенергә мәҗбүр иткән. Балкыр илхан бар булган алаен җыеп,каганның алаен тоткарларга маташа.

Һич тә көтмәгән бу хәбәрне ишетүгә, Кубрат хан тәхетеннән купты, алостаз Дәян янына килеп, ике иңеннән тотты.

— Илчеләр, илчеләр кайттымы?— Ханның кашлары җимерелде, күзләрендә зәһәр очкыннар күренде.— Илчеләр кая?!

— Олуг хан, илчеләр Көбер хан ыстанында, бүген-иртәгә кайтып җитәргә тиешләр.

— Ханшаны дәшегез!

Каударланып ханша килеп керде, керде дә ашыгып хан янына үтте.

Менә шулай борчылып, гасабиланып килеп керүе, һәр мизгел кайгыртып торуы белән кадерле иде Аппагы аңа. Ханшаны күрүгә, хан тынычлана төште. Барып тәхет янында калган таягын алды.

— Ханша,— диде ул хатыны Аппакка таба борылып.— Хакмы, хак түгелме, бер тәңре үзе белә, Көбер хан минем илчеләрне тоткарлаган икән. Шымчыларым Көбер ханны каган белән элемтәгә кергән дип җиткерделәр... Ышанып җитмим җитүен, ханша, мәгәр күңелдә тынычсызлык. Җыен янә ыстанга. Үзең белән теге вакытта алып барган алаең алырсың. Мин әйттем.

Ханы кушканга карусыз буйсынырга өйрәнгән Аппак ханша:

— Мин барысын да син кушканча итәрмен, ханым,— диде.

— Синең артыңнан ук үзем кузгалам. Ыстан аша китәрмен. Көт!

— Мин энем Көбер ханның каган белән элемтәгә керүенә ышанмыйм, ханым. Кеше сүзе кеше үтерер, диләр. Хуш, ханым!

Кубрат хан беравык китеп барган ханша артыннан карап калды. Эченнән генә хәерле юл теләде.

— Алостаз Дәян, җый кавханнарны, җый аксакалларны. Киңәш мәҗлесе булыр. Иң ышанычлы алыпларыңны Аспарух илхан белән Батбай илханнарга җибәр. Маныч елгасына юл алсыннар.

— Олуг хан, Аспарух илхан юлда, Батбайга киткән икенче алып юкка чыкты.

— Тагын берне җибәр.— Хан битекчегә борылды.— Битекче, тагын бер хат яз, минем тамганы куй!

Иртәнге кояшны каршы алуга, сарайга берәм-берәм аксакаллар, кавханнар җыела башладылар. Аларның кергән берсе тәхеттә утыручы Кубрат ханга бил бөкте һәм үзенә тиешле урынга барып утырды. Кайчандыр Кубрат хан шушы аксакаллар белән дала бетереп, җәйләп, яу чабып йөри иде. Хәзер әнә аларны да дөнья газабы урталай бөккән, битләрендә тычкан кереп качардай җыерчыклар. Алар белән яу чабып йөргән чакларда шактый яшь булган Кубрат ханның да, әйтерсең, биленә җәя бөкләп тыкканнар иде. Алай да күңел дигәнең каядыр ашкына. Дала шулай дәшәме?.. Нәрсә бу, тән картаеп, җан шулай гел яшь каламы? Азак кавханы гына кара син, нинди горур, тәкәббер тота үзен. Аның бүген дә кул астында бер төмән алай. Бир син аңа яңа йөгән салган тулпарны, сикереп атланыр да орышка ташланыр шикелле тора. Барчасы да утырышкач, Кубрат хан кулына кам таягын алды.

— Аксакаллар, кавханнар, Бөек Болгарның олуг ханы Кубрат яуга чыга. Фанәгүрне сезнең карамакка калдырырга булдым.

— Каган Фанәгургә килеп җитмәс!— дип чәчрәп чыкты берсе. Әмма аны шундук тынычландырдылар.

— Ятып калганчы, атып кал, хан, бездән фатиха,— диештеләр аксакаллар.

Барчасы берәм-берәм сүз алды, киңәшен әйтте. Кубрат хан Азак кавхан ягына күз ташлады. Сүз сорамый иде ул. Ниһаять, Азак кавхан күтәрелде.

— Хан, кеше үз гомерендә дүрт төрле рәхәт кичерер, диләр. Күз ачып йомганчы үткән рәхәт, бер көнлек рәхәт, бер айлык рәхәт һәм гомерлек рәхәт. Күз ачып йомганчы үткән рәхәтне кеше татлы мизгелләрдә алыр, бер көнлек рәхәтне улы тугач алыр, бер айлык рәхәтне өйләнгәч алыр, гомерлек рәхәтне байлык килгәч алыр, дигән борынгылар. Бөек Болгарга байлык килде. Көнчеләр табылды. Йулыш каган Болгардагы байлыкка кызыга, ханның Чәчкә кебек гүзәл кызына күзе төшкән. Илең-халкың, байлыгың саклыйм дисәң, олуг каган, корал тота алган бар кешеңне алып, каганга каршы чык. Кызың бирмә, кызың белән илең, илең белән динең китәр. Ил каласын бары тик биш сыйфат бизәр ди: гадел хөкемдар, бай базар, оста имче, су юлы, бай күрше. Боларның барысы да Болгарда бар. Синең бурычың, олуг хан, илең, халкың җәйләүләрең, байлыгың саклап калу. Чакыр безне яуга, бир корал!

— Аксакаллар, кавханнар, яуга -яу белән чыгыйк!

— Яуга — яу белән!— дип кычкырыштылар кавханнар, аксакаллар.

— Олуг хан,— диде Азак кавхан барысы да тынгач.— Таркауны хан гына түгел, тартай да җыя алмас. Тартай такылдаганда син бөркет булып һавага күтәрел! Кызың орыштан соң кияүгә бирерсең. Кыз картаймый, бал искерми, олуг хан.

— Иртәгә өйләдән соң кузгалабыз, кавханнар! Хушыгыз! Мин әйттем.

Дала өстендә рәшә тибрәлә. Зәңгәр күктә тилгәннәр талпына, юк, талпынмыйлар, йөзәләр сыман. Кубрат хан үзенең яраткан Тимер-күк айгырында бара, арба шагырдаганы, атлар пошкырганы, яу йөргәндә була торган шау-шу, мал-җан авазлары даладагы бар булган тереклекне хәрәкәткә китерде. Кай тарафтандыр килеп чыккан карсак төлке кылганнар арасыннан елтыр күзләре белән карап тора. Бу нинди мәхшәр тагын, даланы кеше заты басты. Тимер очлым кигән, калкан һәм ук-җәяләр таккан җайдакларны күптән күргәне юк иде инде карсак төлкенең. Хәтерендә, бер тапкыр менә шундый киемнәргә киенгән җайдаклар үзара орыштылар, бер-берсен кадаштылар, кисештеләр, суештылар, дала өстендә яман авазлар яңгырады. Шул орыштан соң күпләре далада ятып калды. Карсак төлке атна буе кан исенә исереп йөрде, күзе тонды, ни кылырга белмәде. Дала тулып яткан мәетләрне бүреләр, шакаллар, бөркетләр, козгыннар атна буена ашадылар. Җыелды ала карга, тилгән-карчыга... Карсак төлке, башын аякларына салып, аларның талаша-тиргәшә үләксәләр тирәсендә әвәрә килүләрен кылганнар арасыннан гамьсез генә карап ятты. Карсакның тамагы тук иде инде. Шул сыйланудан соң карсак төлке төп азыгы тычкан исен toймый җәфаланды, борын тирәсеннән ят кан исе китмәде. Кешеләр далага тулгач, карсак төлкенең борын очына тагын шул ис килеп кунды. Ымсынудан ул тәмам исерде, кешеләрдән калмас булды. Бу юлы да карсак төлке алдатмас, татлы кан исенә исереп, куе кылганнар арасында атналар буена ятыр.

Кубрат хан далага чыгу белән кылганнар арасындагы карсак төлкене күрде. Карсак төлке әле юкка чыга, әле көтелмәгән җирдә пәйда була иде. Баш очында тилгәннәр тибрәлә. Козгыннар күренми. Баш

очында козгыннар күренә башладымы, орышка күп калмаган дигән сүз. Козгын орыш буласы төбәккә ике-өч көн алдан килә, ә карсак төлке орыш булганны көтеп айлар буена ияреп йөрер. Карсак күренер дә китәр, козгын күренер дә йотар, ди торган иде Саклаб кавхан яу чапканда. Их, янында кырык еллар электәге Саклаб кебек кавханнарың булса икән. Алай да Кубрат ханның ул чорны яңадан кайтарасы килми, ул чорның үз авырлыгы бар иде. Кубрат хан Бөек Болгар дәүләтен оештырып йөрде, хәзер исә аны яклап калырга кирәк. Иллә кинәт картлык килде. Дәүләт атадан балага калыр, дип картлар хак әйтәләр. Бөек сүзләр. Кубрат хан дәүләтне оештырды һәм хәзер угланнарына калдырырга мәҗбүр. Ә бит кайчан гына бу дөньяга мәңгегә килгән кебек йөри иде. Бу аның соңгы орышы булыр. Әйе, картайды хан ат менеп яу чабарга. Орыш кыры тәхет түгел, орыш кырына баш иеп килмиләр, сине үтерү өчен кылыч, сөңге, ук тотып киләләр. Кубрат хан бу орыш кырында ятып калса да, үкенмәс. Хан урынына илханнары бар.

Аспарух илхан андадыр инде, Маныч елгасына барып җиткәндер, атасын көтәдер.

Ханны алостаз Дәян куып җитте, атын янәшәдән атлатып китте.

— Олуг хан, иртәгә иртән кояш чыгышка дәү җәйләүгә җитәчәкбез. Шактый юл үтелде, елга буена сибеләп төшеп, төнликме әллә?

Хан күтәрелеп күккә карады. Козгыннар күренми иде, ә карсак төлке кылганнар арасында — һаман ияреп бара. «Төнгелеккә туктагач, сөяк ташларга булыр үзенә»,— дип уйлады хан, туктарга боерык биргәннән соң. Су буена килеп җиткәндә аңа чатыр корганнар иде инде. Башта ханның чатырга керәсе килмәде, хатирәләргә бирелеп, элеккеге кебек иyргә башын куеп, ачык һавада йоклыйсы килде. Әмма шундук черкиләр бәйләнде, рәхимсез кыланып тешләделәр, учак яныннан китмәстәй иттеләр.

Ашап-эчкәч, Кубрат хан чатырга кереп ятты. Үз янына һичкемне чакырмады, аның беркем белән дә сөйләшәсе, киңәшәсе килми иде. Күңел төбендәге яман бер уй тынычлык бирми. Батбай илхан нигә йомышчы алыпларны тоткарлый, нигә аңардан хәбәр юк?.. Көбер хан Маныч елгасы буена килерме, каган белән элемтәгә керүе хак булып, кая да булса китеп калмасмы? Көбер хан апасын ничегрәк кабул итте икән? Кубрат хан өчен боларның берсе дә вак мәсьәлә түгел. Каган белән орышны нәкъ менә шул вак дигән мәсьәләләр хәл итәчәк иде. Кубрат ханда һәр бишенче алып көтригур, һәр йөзенчесе гректыр. Грекларны Кубрат хан ташаткычларга билгеләде.

Йокы килми дә килми. Кубрат хан чатырыннан чыкты, алостаз утырган учак янына килде.

— Алостаз Дәян, елганың аръягында ат көтүе утлый. Кемнеке булыр?

— Көбер хан көтүе, олуг хан, белештек.

— Алостаз Дәян, әйдәле минем белән.

Олуг хан белән алостаз чатырга үттеләр, Кубрат хан юлбарыс тиресенә кырын ятты.

— Олуг хан,— диде алостаз Дәян,— Олау яңа гына килеп җитте, кай төбәккә туктасыннар?

— Үзләре урын табарлар, болын киң,—диде хан.— Утыр әле, алостаз, яныма. Әйт әле, Дәян, төптәңрене коткаручы чынлап та Батбай илханмы? Сынадыңмы, тикшердеңме?..

— Ачык белүче юк, олуг хан. Батбай илхан булырга тиеш.

— Өченче йомышчы кайтмый... Бу ни булыр бу, алостаз Дәян? Шулай ук үз угланымның башын җәлладтан чаптырырга туры килер миканни?.. Әйт сүзең, Дәян?!

— Углан синеке, телисең икән — ат коерыгына тактырасың, телисең — башын чаптырасың, олуг хан.

— Тагын бер хәбәрче җибәр, алостаз Дәян. Җибәр. Битекчедә әзер хат бар, тамгам куелган, ал да җибәр. Инде шунда да килми икән, орыштан соң мин аның чыннан да башын чаптырырмын. Игелексез бала — җан имгәге.

Кубрат хан чатырдан алостаз Дәянга ияреп чыкты, битекчедән әзер хатны алып, хәбәрчегә биргәнне күзәтте, хәбәрче ыстанны ташлап, йомышка чыгып киткәч кенә чатырына керде. Моңа кадәр киткән хәбәрченең әйләнеп кайтмаулары, алостаз Дәянның төптәңрене коткаручы Батбай илхан булырга тиеш дип аяк терәп сөйләшүе Кубрат ханның тәмам кәефен бозган иде. Хан Батбай илханның хыянәтенә ышана да, ышанмый да иде. Әгәр дә мәгәр Батбай илхан чынлап та Йулыш каганга баш орып барган булса, Кубрат хан угланның мәетен илгә күмдермәс, шакалларга ташлатыр, я булмаса кол итеп сатып җибәрер.

Алостаз Дәян килеп керде.

— Олуг хан, алыпларның кайберләре сукраналар. Имеш, төптәңре кая, нигә Батбай илханга киткән хәбәрчеләр юк. Безгә төптәңре сайларга кирәк, олуг хан.

— Алостаз Дәян, тотып китер миңа шул алыпның берсен. Тотып китер! Әллә соң үзең шулай сөйләнеп йөрисеңме? Алып сөйләсә башын кистерермен, син сөйләсәң ат койрыгына тагармын. Батбай илхан килер ул. Төптәңре кирәк икән, бар ул бездә. Чакыр Азак кавханны!

— Азак кавханны?!

— Әйе, Азак кавханны. Иртәгә кояш чыгуга, аны төптәңре итеп кулга күтәрербез. Мин әйттем.

Алостаз Дәян уфтанып куйды.

— Олуг хан, хәбәр иттеләр. Аспарух илхан ике көн элек Маныч елгасына таба үтеп киткән.

— Аспарух илхан ун мең алае белән безне көтеп алыр. Мине Көбер хан бераз борчый, алостаз Дәян.

— Мин Көбер ханга ышанам, олуг хан. Кешеләрем аны алай җыя диделәр. Җәйләүдән-җәйләүгә чаба икән.

— Бар, йокла, алостаз Дәян. Иртә кичтән хәерлерәк. Ишетәсеңме, тартай кычкыра. Җәй уртасы. Бу вакытта Кубрат ханның беркайчан да яу чапканы булмады. Мал симертә торган вакыт, игелекле вакыт. Мал симертеп җәйләүдән-җәйләүгә күчеп йөрисе иде, булмады, яу кузгалдык, тәңре ярлыкый күрсен.

* * *

Көтригурлар ыстанына өйлә вакытында килеп җиттеләр. Кубрат ханны албагучының алыплары каршы алды. Ыстанда халык аз, барысы да җәйләүдә булып чыкты. Ханша, чатырыннан чыгып, Кубрат ханны үзе каршылады. Күрде дә ханшаны хәрби киемнән Кубрат хан, үз күзләренә үзе ышанмый торды. Ханшаның ике ягына икешәр җансакчысы баскан, арттан да өчәү ияргән, җансакчыларның очлымнарында тәңре билгесе — кояш сурәте.

— Рәхим ит, ханым. Атам Тугрыхан ыстанына кунак булып килдеңме, әллә йомышың төшепме?

Ханшаның киная белән әйтелгән сүзләрендә азмы-күпме хаклык бар иде. Кубрат хан сакалын сыйпады, үзалдына көлемсерәп куйды.

— Ханшам, болай ук хөрмәтләп каршы алырсың дип уйламаган идем. Кабул ит, йомышлы кунакка килүем.

— Рәхим ит, ханым,— диде ханша һәм алдан китте.

Аппак аңа борылып карады, чатырның ишеген күтәрде, ханны уздырды. Биредә бөркүлек, әмма кечкенә өстәлдә көмеш савытлар белән

кымыз, эчемлек тора иде. Ханша аңа бер чокыр кымыз салып бирде, утырырга урын күрсәтте.

Хан бик теләп бер чокыр эчте, яңадан салдырды. Кайчандыр, борын-борын заманда көтригурлар даласында бары тик хатыннар гына яшәгәннәр, дип сөйлиләр. Хатын-кызлар орышканнар да, яуга да чапканнар, ауга да йөргәннәр, аш-мазарны ир-атлары караган, имеш. Төркиләрнең бер токымы скифлар аларны ир-ата дип йөрткәннәр. Димәк, ирләр хезмәтен башкаручы хатын-кызлар. Греклар аларны амазонкалылар дип атаганнар. Ир-ата хатыннарга каршы хәтта бөек Искәндәр дә яу килүдән баш тарткан, имеш. «Хатыннарны җиңүдән мине бер тарихчы да данламас, инде мине хатыннар җиңә кала икән, тарихчылар исемемне дә искә алмаслар»,— дип әйтеп әйткән, имеш. Бу хикәятне Кубрат ханга Патшакаладагы бер аксакал сөйләгән иде. Кубрат хан ул хикәяткә чын күңеленнән ышанган иде. Менә шул хикәяттәге амазонка булып басып тора иде ханша аның алдында.

— Кубрат,— диде ул ягымлы тавыш белән ханның бөтен уйларын чәчеп-сибеп.— Кубрат, Көбер хан алай җыярга җәйләүләренә чыгып китте. Ике-өч көннән ул Маныч елгасы төбәгендә булыр.

— Ханша, Батбай илханга тагын бер хәбәрче җибәрдем. Тәңре кылган булса, ул да Маныч елгасына килер.

— Зур орышка җыендың, Кубрат, кодрәтең җитәрме?

— Миндә грек уты бар, ханша. Төрки дөньясында булмаган корал.

— Орышны грек уты түгел, йөрәк уты хәл итә, хан.

— Йөрәк утым кабынмаса, Фанәгүрдән дә кузгалмаган булыр идем, ханша. Йөрәгемә ут капканга яу чыктым. Кеше җәйләүләренә яу чабарга дип түгел, үз җәйләүләрем саклап калырга барам.

— Мин синең өчен куркам, ханым. Кая төптәңре? Кая Батбай илханнан йомышчың?

— Төптәңре итеп бүген иртән кавхан Азакны кулларга күтәрдек. Азак кавхан Ирсан хыянәтчедән мең тапкыр акыллы кеше. Мин аңа ышанам, ул минем ыруым данлар.

— Мин бу көннәрдә яман төшләр күрдем, хан.

— Төшеңне яхшыга юра. Яхшыга юраган — яхшы бетәр, начарга юраган алып китәр, диләр.

## 26

Кояш кичтән үк кызарып баеган иде, иртән дә кемгәдер ачу тоткандай борчулы кыяфәттә килеп чыкты. Кирмәндәге һәммә кеше, һөнәрчеләрдән алып сакчыларга кадәр, таңредән игелекле көн теләп, җиргә тезләнделәр, кулларын күккә күтәрделәр. Кодрак илхан таңредән мәрхәмәт сорап күккә күтәрелгән меңнәрчә кулларга карады. Бармы син, таңре! Булсаң, коткар халыкны! Яман Җаек бәктән, аның күп санлы алаеннан коткар!

Көнне каршы алгач, һәркем үз урынына урнашты. Кирмәндә уникe төмәнгә якын алай. Җаек бәкнең киләсен ишетеп, Кодрак илхан субашларны — Чакай буйтурны чакырды. Җаек бәк килергә бер көн кала, үзенең алае белән ул килеп җитте, алар артыннан ук Илбарыс буйтурның йырмак алае белән Камай багатыр кирмәнгә кереп урнашты. Җаек бәк кирмәнне кичкә таба камый башлады. Аның сөрәнчеләре менә ике көн инде хан кызының чыгуын сорыйлар, алтын таулар ышандыралар. Өченче көнне Җаек бәк беренче һөҗүмен ясады. Өерелеп килгән хәзәрләрнең күбесе дивар буенда ятып калды, болгарлардан да үлүчеләр булды. Субашлар белән буйтур Илбарысның йырмак алае килеп кушылгач, Кодрак илхан Җаек бәкне болынга чыгып каршы алырга булган иде, соңыннан бу уеннан кире кайтты. Хәзәр ачык җирдә остарак орыша, кирмән алу алар өчен ятрак, Җаек бәктәге алайны күргәч, Кодрак

илхан кирмәндә калуына куанып бетә алмады. Дивар буенда калган мәетләрне Җаек бәк кешеләре таңре белән җыеп алдылар һәм Этил ярындагы бушлыкта кабер казып күмделәр. Елга яры буенда беренче кергәп калкып чыкты. Җаек бәкнең мәргәннәре атларын чаптырып барган җайдан шул хәтле укка төз аталар иде ки, болгарлардан да югалтулар шактый булды. Болгарлар һәлак булганнарны кирмән түрендәге каберлеккә күмә бардылар, яралыларны аерым өйгә ташыдылар, аларны имче җитәкчелегендә хатын-кызлар карады, алыпларның ярасына имче җыйган үләнне капладылар, төнәтмә эчерделәр.

Көне-төне белән Җаек бәк кирмәнгә һөҗүм итмәде, каядыр ауга чыгып китте, ике-өч көн йөреп кайтты. Кайтты да янәдән сөрәнчеләреннән оран салдырды, хан кызының чыгуын, хан кызы чыкса, шундук камауны ташлап китәргә әзер булуы турында хәбәр итте. Камауның икенче атнасында кирмәндә азык-төлекне үлчәп-бүлеп кенә бирә башладылар. Кирмәннең ике башындагы коеларны көн-төн сакладылар. Җаек бәк яклылар булып, коега үләксә ташлаулары бар иде. Кодрак илхан белән Адай тархан гына белгән тагын бер кое бар барын, аны беркемгә дә күрсәтмәделәр. Мая азык Адай тархан кулында, гомумән, ризык-нигъмәт белән ул шөгыльләнә иде. Җаек бәк көннән-көн усаллана бара, дивар буенда алыплары күбрәк ятып калуга карамастан, һөҗүм итүне туктатмый. Кичә кичкә таба бәкнең берничә алыбы баскычлар белән диварга күтәрелделәр, әмма бик тиз юк ителделәр. Баскыч куючыларга болгарлар кайнаган сумала койдылар. Баскычлары-ниләре белән тәгәрәп төшкән алыпларның әрнү-сызлану тавышы йөрәк яргыч булды. Өсләренә кайнар сумала койганнан соң Җаек бәк тагы да зәһәрләнә төште. Ахыр көньяк дивар буена чыбык-чабык ташыта башлады.. Болгарның иң мәргән алыплары аларны укка тоттылар, әмма тарлавык яклап хәзәрләр агыла торды. Һәркөн, кояш чыгып көн тууга, Җаек бәк сөрәнчеләреннән капканы ачыгыз дип оран салдыра, Чәчкәнең чыгуын сорый. Бары тик шуннан соң гына һөҗүм итә башлый.

Кодрак илхан кояш баеп, кирмәнгә хәзәрләр һөҗүм итүдән туктауга, Адай тархан өенә багатырларны җыйды, киңәште. Сүз күбрәк хан кызы Чәчкә турында барды, әмма Чәчкәне чыгарып җибәрик тә котылыйк дип берәү дә кыеп әйтмәде. Киптерелгән итләр, балыклар бетеп бара, атлар кирмән эчендәге чирәмне җиренә кадәр кырып бетерделәр, сарай диварлары бүрәнәсен кимерә башладылар. Хатын-кызлар балаларга кипкән эремчек, кычыткан пешереп ашатуга кадәр җиттеләр.

Этил елгасының көньягында тарлавык, тагын да арырак төбәк-төбәк каенлыклар, аннан бераз баргач имән агачлары белән капланган куе урман башлана. Шул яктан Кубрат ханнан ярдәм килергә тиеш. Һәм нәкъ шул якта, урман буенда Җаек бәкнең албагучылары күренә. Бик ерак булгангамы, ат өстендәге кешеләр далада утырган балбалларны хәтерләтәләр иде. Офык читендә зәңгәр рәшә тибрәнә, көн тагын эссе булыр, су эчүчеләр күбәер, атлар эсседән интегер.

Кодрак илхан янәшәсенә Чәчкә килеп басты, килеп басты да туганының беләгенә сарылды. Кодрак илхан күзләрен офыктан алмыйча, сеңлесенең башыннан сөйде.

— Туганым, күрәм бит мин, күрәм. Һәр көн киңәш-сабакка җыеласыз, сөйләр сүзегез юк, минем турымда әйтергә берәү дә кыймый, хәтта син дә... Җаек бәккә мин кирәк икән...

Кодрак илхан сеңлесенең күзләренә карады.

— Әйтмә алай, Чәчкә. Тыел, хакың юк. Син илхания, каравыш кыз түгел, хакың юк алай дияргә.

Чәчкә туганының күкрәгенә башын салды да елап җибәрде. Кодрак илхан сеңлесен калтыранган иңнәреннән кочып алды, тамак төбенә килеп тыгылган төерне йотып җибәрә алмый торды.

— Тыел, Чәчкә, ишетәсеңме, тыел. Җаек бәк кирмәнне ала алмас,

камап торыр-торыр да китеп барыр. Грек осталары кирмәнне Җаек бәк алырлык итең кенә салмадылар.

— Кая минем сөйгәнем Илбарыс буйтур, кая, туганым! Ул мине, синең җаналыпларыңны коткарды, үзе юк, юк! Каган аның күзләрен чокыткандыр, ат койрыгына тактыргандыр...

Кодрак илхан, өстенә кайнар су бөркегәндәй, кисәк читкә тайпылды, сеңлесенең күзләренә карады, аннары битләреннән учы белән тотты да:

— Игелекле сеңлем Чәчкә, чынмы бу?.. Чынмы Илбарыс буйтурны яратуың?!

— Өлкән абам, мин аны яратам, яратам!

— Кем белә?— дип сорады Кодрак илхан һәм гүя тамагы чатнап китте.— Кем белә тагын? Әйт?!

Чәчкә як-якка башын чайкады.

— Беркем дә белми. Ул да мин... Мин ялганладым, ул миңа синең кебек үк якын туганым гына. Сине яраткан кебек аны да яратам. Ә ул юк, аны әсир иттеләр!..

— Чәчкә, Чәчкә, алма юк белән котымны. Атам ишетсә, минем дә, минем уң кулым Илбарыс туганның да... Без камауда, Җаек бәк китәр ул. Кичә греклар коралланды, моңа кадәр аларның корал тотканнары юк иде әле. Без сине Җаек бәккә бирмәбез, туганым, бирмәбез. Сине Җаек бәк Биләмҗиргә алып китсә, атама, анама, ир туганнарыма ни әйтермен, ни күзем белән күренермен!..

— Кирмәндә көннән-көн авырая бара. Җаек бәкнең мәргәннәре дивар өстенә менә башладылар, ашарга бетеп килә, итләр кортлады, бияләр сөт бирми, кирмән аланында ат утларлык чирәм калмады. Бир әмер, туганым, берничә атны суярга. Балаларга, яралыларга?!

— Юк-к, Чәчкә сеңлем. Тагын бер тапкыр юк. Яу атларын болгар ачка үлгәндә дә суймады, яу атларын суеп ашасак тәңре каршы төшәр.

— Ач капкаларны, туганым, чыгарып җибәр мине. Тиздән кешеләреңә ашарга бетәр, чир килер, мәетләрне күмәр җир калмас. Җаек бәк барыбер кирмәнне алыр, анда инде ул беркемне дә кичермәс, балаларга кадәр кырыр, елгага батырып үтерер.

— Чәчкә, Кубрат хан кызы илханияме син?! Кубрат хан кызы Чәчкә... Әйтмә алай, хакың юк! Сине атам бөтен мәҗлес алдында Рум императоры угланы Юстинианга вәгъдә итте. Син ярәшкән. Атамыз Кубрат хан үлгәндә дә сүзендә торыр. Син аны беләсең, ул бирегә киләдер инде, үзе килмәсә кавханнарын җибәргәндер...

Ул арада Җаек бәкнең сөрәнчеләре оран сала башлады. Аларның тавышлары елга буйлап аръякларга чыга, тау-урманнарга барып орына һәм кайтаваз булып кирмән өстендә яңгырый иде:

— Кодрак илхан, Бөек Болгарның бөек илханы, төрки халкының җир-сулар, дала-җәйләүләр башы Йулыш каганның уң кулы Җаек бәк Әтил буйларын калдырырга вәгъдә итә. Кирмәндәге һәр алып, һәр оста, һәр сәүдәгәр исән калыр, мал-мөлкәтләренә кагылучы булмас. Каган Кубрат хан белән кардәшләшергә тели. Ике туган төрки арасында күпме кан коярга мөмкин, илхан, акылыңа кил, бир хан кызы Чәчкәне!..

— Сайра-сайра, бугазыңа сөяк тыгылгыры. Юк!— дип йодрык янады сөрән салучылар ягына Кодрак илхан.—Юк, кычкырма булмастайны!..

Чәчкә өчен куркыныч көннәр килде. Ничәмә көн инде ул рәтләп йоклый алмый. Кайчак Чәчкә Илбарысны үз янында итеп күрә. Менә алар болында чәчәкләр арасында утыралар, янәшәләрендә атлар утлый, алар, башларын селкеп, чебен-черкиләрне куалар, баш селкүләренең гайрәтен күрсәтер өчен матур итеп пошкырып та куялар. Илбарыс бер чәчкә өзеп ала һәм алар чәчкә таҗларын йолкый-йолкый язмышларын юрыйлар. Бергә... бергә түгел... бергә... бергә түгел... Чәчкә

таҗлары «бергә» дигәнне әйткәндә күзгә-күз карашып алалар, шул караштан икесенең дә бит алмалары алсулана, йөрәкләре ешрак тибә торган иде. Аннары кисәк тынып калалар, йөрәкләр генә сөйләшә, тел табардай татлы сүзләр калмый. Шуннан Илбарыс аны кулыннан ала, сикереп торалар, кулга-кул тотынышып, зырылдап әйләнергә тотыналар. «Гүзәл син, Чәчкә, бар чәчкәләрдән дә гүзәл Чәчкә!»— дип кычкыра Илбарыс, Чәчкә күңеле тулышкан шатлыктан ни кылырга белми күләргә керешә, аннары йөгереп китә, нәкъ Кызтуйларындагы кебек йөгерә. Куып житсен, житсен аны сөйгәне — Илбарысы!

Бу — аларның ундүрт-унбиш яшьлек чагы. Күп тә үтми, Рум илчеләре килде, Чәчкәне Рум императоры угланына ярәштеләр. Исәя башлаган чагы иде Чәчкәнең, ул бу ярәшүгә житди нәрсә итеп карамады. Аның каравы атасы-анасы бу ярәшүгә зур өметләр баглый иде. Хәзер әнә аның артыннан Йулыш каган йөри, кирмән кадәр кирмәнне бер аның өчен өч атна инде камауда тота, кешеләр үлә, балалар ачка интегәләр. Барысы да Чәчкә аркасында...

Йулыш каган турында төрлечә сөйләүчеләр бар. Берәүләр аны мактыйлар, яшь чактагы Кубрат хан белән чагыштыралар, икенчеләре хурлыйлар, аның ыстанында бүлмәләре тулы жарияләр, дип куркыталар. Йулыш каган төрки телдә сөйләшә, таңре йоласына табына — шуңамы, Чәчкә киләчәк язмышы белән килешә дә башлаган иде инде, тик аның өчен кешеләр генә кырылмасын, төркиләр генә бер-берсен суешмасыннар. Һәр көн иртән кояш чыкканда таңрегә тез бөгеп сорады Чәчкә, коткар, насыйп итмә каганга, дип үтенде. Аны таңре ишетте, Илбарыс сөйгәне аны Җаек бәк кулыннан коткарды, үзе әсир төшеп булса да коткарды. Хәзер әнә тагын килгәннәр Йулыш каганның йомышчылары, аның өчен орышалар, кан коялар. Җитмәгәнме аларга сөйгәнен әсир итүләре! Кайларда икән сөйгәне Илбарыс! Исәнме? Ул аның үле гәүдәсен булса да күрергә тиеш, шунсыз ул берәүгә дә кияүгә чыкмас, император угланы Юстинианга да, Йулыш каганга да. Кем аңа бүген Илбарыс сөйгәне турында тел очына куеп бер сүз әйтә ала? Кем?! Чәчкә аңа бар булган мөлкәтен бирер иде. Кем булсын? Җаек бәк. Ул аны әсир итте, ул аның кайда икәнен дә беләдер...

Эске кирмән камауда, кирмәнгә кош та очып керерлек түгел, Җаек бәкнең мәргәннәре кирмән ягына таба очкан кошларны да укка алалар. Менә ничә көн инде Чәчкә шулар турында уйланып, каңгырып йөри.

Аның яныннан гына Кодрак абасы белән Адай тархан үтеп киттеләр. Чәчкә агач артына посты. Абасы белән тархан каравыл алыпларны тикшерәләр. Чәчкә төп өйгә таба юнәлде. Адай тарханның хатыны өченче бала табарга җыена. Чандыррак гәүдәле, күк күзле бу хатын юанаеп киткән. Чәчкә өйгә килеп керүгә, ул дәү йөгән рум шәле белән капларга маташты. Чәчкә үзалдына елмаеп куйды. Кияүгә чыкса, ул да шулай юанаер микән? Түр яктан әниләре кебек үк кара чәчле ике ир бала керде һәм икесе дә сөйләшенеп куйгандай, әниләренең күлмәк итәгенә килеп сыендылар.

Балалар һични аңламыйлар, аларга Җаек бәк камады ни дә, камамады ни кирмәнне. Җаек бәк кирмәнне алса, бу ир балаларны Биләмжиргә озатыр, берничә елдан шул ук балалар каган байрагы астында Болгарга килерләр. Кеше язмышы белән әнә ничек уйный каганнар.

Кичә Җаек бәк алыплары кирмән дивары буена чыбык-чабык ташый башладылар. Дивар тирәли канау казылып, су җибәрелгән иде, чокырны чыбык-чабык, туфрак белән тутырдылар. Җил кирмән ягына исә башлау белән Җаек бәк чыбык-чабыкка ут төртергә боерыр. Җаек бәкнең алыплары дивар буенда күпләп ятып калсалар да, һөҗүмне туктатмыйлар, һаман килә торалар. Ук житмәс урында диварга менү өчен баскыч үрәләр, ташаткычлар көйлиләр. Баскычлардан менеп, кир-

мән эченә сикерүчеләр ешайганнан-ешая барды. Кирмән кыл өстендә тора иде. Шушындый хәлдә Адай тархан балаларының берни булмагандай шукланып йөрүләре Чәчкәнең ачуын китерде. Ул Табгач сәүдәгәрләре китергән көзгедән карады. Күзе көзгегә төшүгә, бөтен гәүдәсе калтыранып китте: карлыгач канатларыдай кыйгачланып киткән кашлары җыерылды, керфек очларына энҗедәй яшь бөртеге кунды, сылучибәр йөзенә алсулык йөгерде, чырае кырысланды, йодрыклары йомарланды. Ул Илбарыс буйтурны табар! Табар да Җаек бәккә әйтер, җибәр мине шул буйтур белән илемә, дияр, атам сиңа Эске кирмән җәйләүләрен бүләк итәр, дияр.

Чәчкә гасабиланды, ишекле-түрле йөренде, үз-үзенә урын таба алмый изаланды. Ахыр грек битекчесен чакыртты. Битекче килгәч, ул аңа хат язарга боерды.

— Яз, битекче!— Битекченең кара бөдрә чәчләре маңгаена сибелеп төшкән, кулында каз каурые.— Яз. «Атам-анам, ир туганнарым, мена өченче атна инде Эске кирмәнне каганның Җаек бәге камауда тота. Җаек бәк дивар тирәли чыбык-чабык өя, безне терелэй куырмакчы. Көн-төн ташаткычлардан афәт яудыра. Тиздән ул чыбык-чабыкларга ут салыр, кирмән дөрләп яна башлар. Болгар алыплары көннән-көн кими, бер кабергә унар мәет салалар. Тәңре шаһит, атам-анам, мин сезнең сүзегездән чыкмадым. Кирмән кешеләре миңа бүрегә караган кебек карый башладылар. Мин аларның күзенә күренергә куркам, җаным кая куярга белмим. Җаек бәк һәр көнне мине сорап сөрәнчеләреннән оран салдыра. Мин язмышым белән килештем, атам-анам, кирмәннән чыгарга булдым. Яздырган битегем бирер кешем юк. Мин аны грек битекченең үзендә калдырам.— Чәчкә шулай диюгә, грек битекченең күзләре зураеп китте, суган суына манган каурые калтырана башлады.— Яз, битекче, яз,— диде Чәчкә.— Язмыштан узмыш юктыр. Мин шулай кылдым, атам-анам. Битекне яздыручы кызыгыз Чәчкә булыр...»

Чәчкә битекченең кулыннан каурыйны алды, тамгасын салды. Битекче пергаментны бөтәрләде дә куенына тыкты, илханиягә түбәнчелек белән бил бөкте.

— Битекче, битекне күз карасыдай сакла, болгарлар килгәч, олуг хан кулына тапшыр.

Грек чукынып алды, китәргә дип борылды, Чәчкә аны туктатты. Ул битекченең учына балдак салды.

— Хәериең, илхания.

Чәчкә бераз уйланып торды да муенындагы затлы ташлардан ясалган гәрәбә муенсасын салып бирде.

— Илхания, боларны кемгә тапшырыйм?— диде битекче.

— Үзеңә булыр, битекче.

— Юк, илхания, чәчкәдән яфрак өзмиләр. Бирмә миңа бу бизәкләреңне. Гүзәл затларны гүзәл әйберләр бизәргә тиеш. Чәчкәсез болын булмый, болын күрке — чәчкә.

Грек түбәнчелек белән илханиягә бил бөкте һәм Чәчкәгә әйберләрен кире кайтарды.

Кодрак илхан белән Адай тархан Чәчкәне тыңларга да теләмәделәр. Мәгәр Чәчкә күрде, икесе дә аның күзләренә туры карарга куркалар, карашларын читкә алалар.

Эңгер иңеп килә, Чәчкә әкрен генә торды, сак кына адымнар белән ишеккә юнәлде. Көндез ул кирмәннән чыгып китә алмаячак, дивар өстендә көн-төн каравыл алыплар тора. Аларның хан кызын танымаулары да мөмкин, нәкъ менә шуның аркасында укка тотулары бар иде.

Җаек бәк ягына чыгу уе аңа көтмәгәндә, һөнәрчеләр урамыннан узып барганда килде. Йөри торгач, Чәчкә каберлекләр күршесендәге ат абзары янына килеп чыкты. Шунда ул берәүнең күңелле итеп чикыл-

давын ишетте. Чәчкәнең күңеле кызыксыну хисе белән тулды. Ул ат абзары артынарак үтте. Кочаклашып торган ике яшьне күрде дә шым булды. Абзар почмагына сыенып ике яшь басып тора, алар бер-берсенең кочагына кереп иңгәннәр кебек иде. Егет кызның колагына нидер пышылдый, ә кыз наз хиссиятеннән тулышкан күңелен тыялмыйча кеткелдәп көлеп ала.

— Атам риза, анам риза, Айгөл, быел Кызкуыш туенда сине куармын.

— Айгөл түгел минем атым, Айтаң.

— Айтаң дим. Кудырырсыңмы?!

— Тоттырырсыңмы диген, җүләрем!.. Куарсың, мәргәнем. Бөтенләй йөгереп тә тормамын, борылырмын да сиңа каршы йөгерермен. Кирмәнне камаган Җаек бәк кенә китсен...

— Җаек бәк хан кызы Чәчкә чыкмыйча беркая да китмәячәк, Айтаң.

— Мин булсаммы хан кызы, мәргәнем, мин булсаммы? Мин кешеләрдән кан койдырмас идем, чыгар идем Җаек бәк каршына. Аны Иулыш каган сорый икән бит. Каган үзе!

— Мәргәнем, мәргәнем, кытыгым килә, кочаклама алай...

Кыз янә татлы итеп тыенкы гына көлеп ала, егеткә сүз әйтә, әмма Чәчкә инде аларны ишетми, ул ни кылырга белми, бер кавымга тәмам аптырап, басып тора. Аннары әкрен генә кузгала да, тәвәккәл бер фикергә килеп, өйгә таба атлый.

Шунда аның каршына багатыр килеп чыкты.

— Хан кызы Чәчкә, нишләп бу тирәдә йөрисең? Кодрак илхан сине кирмән бетереп эзли.

Кодрак илханның сул кулы Ишкул икән. Багатыр Илбарыс буйтурга суеп каплагандай охшаган иде. Бәлкем, эңгер куелыгы аны шулай күрсәткәндер...

— Ишкул багатыр, кая синең буйтурың — Илбарыс?

— Буйтур минем йөрәгемдә, илхания. Ул һәрвакыт минем белән булыр. Ул сине коткару өчен башын салды, илхания.

— Мине коткару өчен,— дип кабатлады Чәчкә.— Аны Җаек бәк ат койрыгына таккандыр, минем өчен җанын алгандыр.

— Анысы бер аңа билгеле, илхания. Буйтурым турында начар уйлыйсым килми. Ул чынлап та батыр йөрәкле иде. Җаек бәк аңа кылычын күтәрмәс, аны алып кадерен белә, диләр. Илбарыс буйтур Болгарда бер мәргән иде. Без дә төшеп калганнардан түгел. Җаек бәк торыр-торыр да камауны ташлап китәр, борчылмагыз, илхания.

— Ишкул багатыр, мин ни кылырга тиеш соң?

— Көтәргә, сабыр итәргә, илхания.

— Ишкул багатыр, мин кирмән диварында сакта торырга телим. Бирегез миңа ук-җәя, бирегез корал. Мин кешеләр алдында үземне акларга телим.

Ишкул багатыр арттан атлаучы алыбына Чәчкә илханиягә хәрби киемнәр бирергә боерды. Алып аны бер өйгә алып керде, хәрби киемнәр бирде, илхания киенгәндә чыгып торды.

Чәчкә хәрби киемнән чыкканда караңгы төшкән, урамнарда кисәү тотып каравыл йөри иде инде.

Иртән ул яңа көнне каршы алгач та Җаек бәкнең чатыры күренгән диварга менде. Диварга менгән хәрби киемдәге алыпны күрделәр дә, барысы да кемгәдер охшатып, аптырап калдылар. Беренче булып Чәчкәне абасы Кодрак таныды.

— Хан кызына килешерме болай йөрү, Чәчкә?

— Килешер, абам. Яманның ачуы яман, мин дә хәзәрләрне уктан алырга телим.

— Әнә, күрәсеңме, чатырны. Җаек бәк бүген нидер кылырга тели, бар меңбашларын җыйды, тегеләре аның сүзләрен куәтләп һай-һай кычкыралар. Әнә, кузгалдылар да. Барыгыз да ышыкка, укларны әрәм-шәрәм итмәскә! — дип боерды Кодрак илхан.

Хәзәрләр бүген аерата кыю кыландылар, диварга якын ук килеп укка тота башладылар. Кайберләре читәннән ышык ясаганнар, шуларны күчерә-күчерә һаман диварга якынлашалар. Болгарлар ягында ук кадалгач кычкырып җибәрүчеләр ешая башлады, шул чак Чәчкәнең колагы янынннан гына сызгырып ук узды. Чәчкә үзенә ук аткан алыпның йөзен ап-ачык күрде. Атын чаптырып килүченең чыраенда иман юк, икенче уравында ул угын төзрәк җибәрер шикелле тоелды хан кызына. Ие дөрес булган икән, җайдак җан-фәрманга чабып янәдән әйләнеп килде һәм накъ Чәчкәгә төбәп уктан атты. Чәчкә ышыкка посып өлгерде. Әйләнеп караса, янындагы алып, берни булмаган кебек хәзәрләргә ук арты ук ата иде. Чәчкә торып басты, җәясен тартты. Әнә баягы алып өченче тапкырга әйләнеп килә. Чәчкә аңа ук җибәрде, илханиянең угы җайдакның иярено кадалды.

— Ур-ра, ур-ра! Тиде, тиде!— дип кычкырып җибәрде Чәчкә.

Кояш күтәрелә башлауга, хәзәрләр тагын да кыюлана төштеләр, ышык читәннәр артына яшеренеп килгән алыплар дивар башындагы болгарларны берәм-берәм чүпли башладылар. Чәчкә янындагы алып та кинәт берьякка авып төште, аның күкрәгенә ук кадалган иде.

Бу юлы хәзәрләр елга яклап килмәскә булдылар, күрәсең. Бөтен көчләре белән бер төбәккә бәрделәр. Өелгән чыбык-чабыкка кисәү тотып йөгерүчеләр күренде. Аларны болгарлар укка ала тордылар. Чәчкә ук-җәясен ташлады, йөгереп дивардан төште.

Әйе, капканы ачтырырга! Зур сәүдә капкасын ачтырырга! Мәгәр кем ачсын аңа капканы. Чәчкә капкага таба йөгерде. Менә ул капка. Капка янында алыплар. Чәчкә янә диварга менде, түбән карады, аста баш әйләнмәле иде. Янә аска төште. Капканы дүрт сөңгече саклый, беркемне дә якын җибәрмиләр. Чәчкә капкага якыная башлаган иде, алыпларның берсе аңа сөңгесен юнәлтте.

— Алып, ялтырат табаның бу тирәдән. Кодрак илхан якын килгән бер кешене сөңгегә алырга кушты! Һәй, сиңа әйтәм түгелме?!

Чәчкә үзәк урамга барып чыкты. Аннары хәзәрләр аерата ныклап һөҗүм иткән дивар буена таба китте. Монда шау-шу, монда үлекләр, монда яралылар, монда фәкать аның өчен ике туган халык арасында үтереш, суеш бара иде. Чәчкә Кодрак абасы белән Адай тархан баскан манарага менде. Андагылар утлы кисәү тотып килүче хәзәр алыпларын укка алалар иде. Чыбык-чабык өеменә ут салырлармы — кирмәнне тәтен күмәчәк, ул чакта инде чынлап та соң булуы бар! Берәр чара кыласы иде. Ә чара юк, чарасызлык үлемгә илтә иде болгарларны. Абасы хәрби киемдәге Чәчкәне күргәч тә аптырап калмады.

— Син нишләп монда? Хәзер үк төшеп кит!

— Абам, мин Җаек бәк ягына чыгарга булдым.

— Адай тархан, алып төшеп кит хан кызы Чәчкәне!— дип боерды Кодрак илхан.

Чәчкә Кодрак илханның җиңенә килеп сарылды.

— Туганым, кадерлем, мин шулай телим, коймагыз кан. Атам мине кичерер, кирмәндә меңләгән бала-чага, хатын-кыз, бертуган төркиләр...

Бу юлы илхан белән тархан күзгә-күз карашып алдылар.

Тәүге сүзенең кайнарлыгын сүрелдермәс өчен Чәчкә тагы да ныграк ялварырга тотынды:

— Туганым, минем өчен курыкма. Бәк тимәс, ул мине туры каган йортына озатыр. Хан кызын тәңре саклар. Мин үзем теләп чыгам,

абам, атама шул турыда битек яздым. Ул грек битекчесендә. Хан кызын тәңрем саклар, саклар, саклар,— дип Чәчкә кулларын күккә сузды.

Манара түбәсе очында баш сыярлык кына тишек калдырылган иде, шул тишектән зәңгәр күк йөзе күренә, шушы зәңгәрлек Чәчкә күзләрендә чагылып-чагылып киткәндәй булды. Әйе, аны тәңре ишетте. Бу хәлне күреп Адай тархан да, Кодрак илхан да кулларын күккә күтәрделәр.

— Йа, тәңрем, игелек бир хан кызы Чәчкәгә, йа, тәңрем...

Кодрак илхан янына бер алып йөгереп килде.

— Илхан, хәзәрләр диварга менәләр, үтеп керүчеләре бар.

— Сөрәнче!— дип кычкырды Кодрак илхан.— Сөрәнче, оран сал. Кубрат хан углань Кодрак илхан капканы ачудан баш тарта. Хан кызы Чәчкә Җаек бәк янына үзе чыга!..— Аннары Кодрак илхан сеңлесен кочып алды, бер тын дәшми торды.— Орыш киемнәрең сал. Җаек бәк янына хан кызы булып чык,— диде һәм сеңлесенең чәч хаситәсендәге тәңкәләргә кагылып алды. Урта тәңкәдә кояш сурәте иде, тәңкәнең уртасында чын кояшны хәтерләтеп зөбәрҗәт таш җемелди. Түгәрәк йөз, киң маңгай, аска таба очлаебрак килгән яңаклар, зәңгәр күзләр, кайтарылып торган озын керфекләр хан кызы Чәчкәне әйтеп тә, күреп-карап та туймаслык матур итә иде.

Сөрәнче оран сала башлауга, яр башындагы чатырдан Җаек бәк чыкты. Ул берара болгар сөрәнчесенең кычкырган сүзләренә колак салды да һөҗүмне туктатырга боерык бирде. Җаек бәкнең өстендә яшел чапан, башында түбәсенә кош каурые кадаган очлым, билендә зур аеллы пута иде.

Хәзәрләр һөҗүм итүне туктаттылар, Җаек бәктән боерык көтеп, бәк чатыры тирәли җыелдылар. Җаек бәктә килгән мәлдәге алай юк иде инде. Өч атна эчендә Җаек бәк шактый алаен югалтты...

Хан кызы Чәчкәне киендереп, җиде җансакчысы белән капкадан чыгарып җибәргәләгәнче шактый вакыт узды. Капка ачылганны көтеп Җаек бәк нык кына гасабиланды, бары тик капкалар ачылып, аннан чыгып килгән хан кызы күренгәч кенә башындагы очлымын салып, яр астына ташлады.

Җиде алып озата килгән хан кызы чатыр янына килеп җитте, алыплар аны аяк астына кулларын куеп кына аттан төшерделәр. Кубрат хан кызы Чәчкә олуг бәк алдына килеп баш иде, язмышын аңа тапшыруы турында әйтте. Җаек бәк хан кызы артында басып торган болгар алыпларына күз төшереп алды. Хан кызын аның бер ишарәсеннән үлемгә ташланырга әзер булган алыплар озата килгән иде.

Җаек бәк — дөнья күргән, илләр гизгән кеше. Хан кызын күргәч, бер мәлгә телсез калды, ул аны кем белән тиңләргә дә беләмәде — гүзәллекнең чиге юк иде Кубрат хан кызында. Уйлап өлгергәне шул булды: хан кызын Йулыш каган беркемгә дә бирмәячәк, күрү белән гашыйк булачак...

Җаек бәк сүзендә торды, үлекләрне җыеп күмгәч, ул чынлап та Этилнең түбән ягына таба — Биләмҗиргә юл алды.

Җаек бәк алае күздән язгач, Эске кирмән халкы капкаларны ачтылар, су буйларына, болыннарга сибелделәр. Аларның куанычлы тавышларыннан елга буйлары яңгырап торды.

## 27

Таң атты. Көнчыгыштан зәңгәр күккә таба кояш нурлары сузылды. Кубрат хан бик аз йоклады. Торды, иңенә чапанын салып, чатырдан чыкты. Көн туар алдыннан янә бер тапкыр орыш кырын күрәсе килә иде аның. Маныч елгасы өстендә куе томан, томан әкрен генә кояшбаешка

таба агыла, елганың як-ягында албагучы алыплар йөренә. Хан чатырдан чыгу белән ике җансакчысы сүзсез генә аңа иярде. Дәян алостаз билгеләгән җансакчылар. Хан аларны гүя күрми, ул бөтен күңеле-җаны белән орыш буласы кырны күздән кичерә иде.

Алтмыш икенче язы килде аның. Алтмыш икенче язын яши бу якты дөньяда, бик күп орыш, кан-яшь күрде, орышта арысландай сугышты, җиңү өчен гомерен кыл өстенә куйган чаклары булды. Болгар халкы аңа үпкә белдермәс. Кубрат беркайчан да куркак җан булмады, аның кыюлыгына хәтта дошманнары көнләште. Бу орыш аның гомерендә иң соңгы сугышы булыр. Кубрат хан җанын-тәнен биреп орышыр. Шуңа дип килде ул бирегә. Болгар бабасыннан калган кылычы тутыкмады әле, үткен тора. Йулыш каган Кубрат ханны җиңәм дип мактанган, имеш. Иртәрәк мактанмадың микән, Ашин ыруы оныгы? Ашыкмадыңмы?.. Орыш кырында мактанырга түгел, орышырга кирәк булачак. Кем алдырыр, бер тәңре белә.

Каган да юлга чыккандыр, түзмәгәндер. Балкыр илханнан хәбәр килде, каганның йырмак алае белән очрашкан, хәзәрләрне урап алып кырып бетергәннәр. Бу хәбәрне ишеткәч, каган Балкыр илханга бар көче белән ташланыр. Балкыр илханга бик авырга килсә, хан Маныч елгасына чигенергә әмер җибәрде.

Кубрат хан грек уты тутырылган чүлмәкләр һәм ташаткычлар куелган арбалар янынннан узды. Арбаларны ике бөҗра каравыл саклый. Уяулар. Хан килеп җитәр-җитмәс үк бил бөгәләр. Ташаткычлар белән эш итәргә хан аерым буйтур билгеләде. Буйтур дәрәҗәсе алган грек хан арбалар янына килеп җитүгә, алгарак чыкты, йодрыгын кысып, бе... әзер дигәндәй кулын күтәрде. Кубрат хан аңа: «Күрәм-күрәм, игелеклесез!»— дип, ары китеп барды.

Болай барысы да җайда кебек иде. Каганга Фанәгүргә барырга башка юл юк, ул теләсә-теләмәсә дә шушынннан узачак. Орыш өчен Маныч елгасы буе иң уңай урын дип табылды. Кай тирәдә хәрәкәт итә иде каган, Кубрат хан белеп бетерми иде. Балкыр илхан артыннан киткән албагучы алыплар кайтып житмәделәр, илханның хәбәрчесе дә озаклады. Югыйсә Балкырдан һәр көн хәбәрче килеп тора иде. Бүген ул шуңа йоклый алмый — Балкыр илханнан түземсезлек белән хәбә... көтә. Ул гынамы, йокы алмауның икенче сәбәбе дә бар иде: Батб... илханга киткән дүртенче хәбәрче дә суга төшкәндәй юкка чыкты. Ас... рух илхан уң кулына килеп урнашты, рәхмәт илханга, игелекле угл... булды. Кодрак илхан да Җаек бәкне җиңеп бу тарафка юл тотса, ... әйбәт булыр иде дә, аның көче чамалырак, Җаек бәк орышларда ка... ланып беткән кеше, кирмәнне камауда тотадыр, чыгарга ирек би... дер. Аннары каган биредә җиңелсә, Кубрат хан Җаек бәкне үзе б... п сытачак. Бу юлы ул Җаек бәккә качарга ирек бирмәс, үзе башын ...әр ашиннар ыруын аякка бастырып йөргән бәкнең. Көбер ханнан ...әр юк, мәгәр Кубрат хан Аппакка ышана иде. Кубрат хан аларны ел...ың өске ягындагы чәүкәлеккә яшерергә булды. Иллә бу уен кавх...ары белән киңәшәсе бар әле. Балкыр илханның беренче җиңүе ха... ка- натландырып җибәргән иде. Кубрат болай дип уйлады. Балкы...белән очрашуда йырмак алаен югалтканнан соң, каганның аны Куб... хан- ның төп көче дип уйлавы бар. Ачуы кабарган каган Балкыр...ырына житкәч, Балкыр артыннан ташланыр, илхан орыша-сугыша М...ыч ел- гасына таба чигенә башлар, ә монда каганны грек утларын...тырган ташаткычлар белән Кубрат хан көтеп тора. Менә шунда ...мәгәнен күрер каган, менә шунда булыр төп орыш, Маныч елгасы ...енда.

Киңәш мәҗлесен Кубрат хан Көбер хан килгәч кенә ж...р. Алар барысын да уртага салып сөйләшерләр, киңәшерләр. Киңә...е эш тар- калмас, дигән картлар.

Болгар хәзәрне җиңә калганда Кубрат хан нишләрг...белер иде.

Иң әүвәл ул Биләмҗирне барып алыр һәм андагы ашинлыларны кырыр, кала башлыгы итеп Балкыр илханны куяр. Бөтен түбән Этил буйлары, Хәзәр диңгезе, диңгез буенда яшәгән халыклар аңа буйсыныр, аңа ясак салыр. Шуннан соң Кубрат хан Тимер Капкага юнәлер, Батбай угланны эзләп табар. Үз баласын ул үзе хөкем итәр. Үз кулы белән...

Барысын да бер төбәккә китереп уйлаганда бу орышны булдырмаска да була иде Кубрат ханга. Чәчкә кызын каганга бирергә дә... Мәгәр гасырлар буена кан үче барган ашиннар белән кардәшләшәсе килми аның. Моңа барса, аны ата-бабалары каргар, теге дөньяга баргач, тәңре алдында җәзасын бирерләр. Юк, Дулу ыруы белән Ашин ыруы беркайчан да килешмәсләр. Орыш булыр, булачак, ул инде башланды да — Эске кирмән камауда, Балкыр илхан каганның йырмак алаен тар-мар иткән.

Маныч елгасы киң дә, тирән дә түгел, әмма ат йөзеп чыгардай уҙыннары да бар. Нишләргә? Елганы кичеп каршы алыргамы, әллә бирєдә орыш кыры булдырыргамы?.. Аръякта тигезлек, дала — орыш өчен уңайрак, бу якта — чокыр-чакыр, атлар белән хәрәкәт итү кыен булачак.

Кубрат ханны философ Иоанн Фасиан куып җитте. «Бик вакытлы килдең, философ, синең фикереңне дә белермен»,— дип уйлады Кубрат хан. Философ Иоанн Фасиан аңа Биләмҗирдә булган хәлләрне сөйләгән, хан барысыннан да хәбәрдар иде инде.

— Хәерле иртә, олуг хан!

— Иртә хәерле, философ, кич ни булып бетәр. Бүген төнлә яман төш күрдем, философ, сиңа гына әйтимме, төш юраучыны да дәштеримме?

— Төш юраучың да бармы, хан?

— Бар. Болгар баба җәйләүдә төш юраучы тоткан. Төш юраучы күңелгә ышаныч өсти, философ.

— Юраучы ике ялгышыр — бер үләр. Аның хан төшен ялгыш юравы да бар бит. Анда инде хан аны кичермәс.

Ханның күңеле-уе башкада иде. Алар чатыр янына урап кайттылар, калкулыктан орыш кырын күзәтә башладылар. Орышу өчен уңайлы урын түгел иде Маныч елгасының сул ягы.

Иоанн Фасианны буласы орыш кырына кызыксыну китерде. Аның беркайчан да орышларда катнашканы булмады. Ул тарих яза иде, тарихы өчен бу орыш иң гыйбрәтле орышларның берсе булыр: ике туган алык бер-берсен кырырга җыеналар. Мондый хәлләр бик борын заманнарда да булгалаган, әмма варварлар аны белмиләр, тарих аларга ... фән, алар бары тик үз тарихларын беләләр. Үз тарихларында туган ... ан белән орышу гадәти хәлгә әверелеп киткән.

— Грек уты куелган арбаларны мин, олуг хан, урта бер төбәккә куя идем. Грек уты каган кулына төшмәскә тиеш. Борынгы грек тарихчылары оныкларына алтын хәрефләр белән язып калдырган васыятьләр бар: дошманың һәрчак үзеңнән көчлерәк итеп исәплә, орышка керәсе алыпларның күңеленә җиңү ялкыны сал, орышның изге икәнен раслап киләсе орышка багышлап корбан чал.

— Көчне көч белән җиңәләр, философ. Йулыш каганда көч зур дип җиткерәләр шымчыларым. Мәгәр болгарларның үзеннән икеләтә көчле дошманны да җиңгәннәре бар. Миндә грек уты, миндә яу чабып дан казанган кавханнар, буйтурлар. Орыш беркайчан да алдан исәпләнгән уй буенча бармый, философ. Һәр орышның үз язмышы буладыр.

— Туктатырга мөмкин булса туктат орышны, олуг хан.

— Ташу ташканда елганы бумыйлар, философ. Дала болгар, хәзәр белән тулы. Бер казанга ике тәкә башы сыймый. Йә болгар ия булып калыр далага, йә хәзәр.— Йә — Дулу ыруы, йә — Ашин ыруы...

— Императорларга, ханнарга корал түгел, иң әүвәл акыл өләшер идем мин.

— Философ, теләнче теленнән тапкан, диләр бездә. Син минем теләнчем, киңәшчем. Киңәшең бир, әмма сабырым төкәндермә. Үзең үк әйтеп торасың, килгән кунакларына Ураган каган башыннан кымыз эчерә дип, Дулу ыруы шуңа түзеп торсынмы? Коралсыз — җиңү юк, алайсыз — ил юк. Миндә тегесе дә, монысы да бар.

— Болгарга яңа дин кирәк, олуг хан. Яңа дин — яңа корал ул.

— Мин тәңрем белән аякка бастым, тәңрем белән бу якты дөньядан да китәрмен, философ. Яңа йоланы илханнар тапсын. Орыштан соң илханнарымның берсен олуг хан итеп күтәрттерермен. Шуның хакына корбан чалдырырмын, Дулу ыруы янә бөтен төрки дөньясына баш булып калыр.

Кубрат хан бүген ачулы иде, аңламады философның ни әйтергә теләгәнен, әллә аңлап та санга сукмадымы, ачу-нәфрәт белән тулган йөрәк киңәшче эзләми. Философ, олуг хан белән килешеп, аңа баш иде.

Ул арада томан таралды, кояш чыкты. Кубрат ханның тез астына киез китереп салдылар, ул кулларын күккә күтәреп тәңредән игелекле көн теләде. Философ аңа гаҗәпләнеп карап торды. Менә ничә ел инде ул шушы варварларны кеше итәргә тырыша, әмма бер адым да алга бара алмады, тәңре — алар өчен барысы да. Ханга кадәр кулларын күккә күтәреп чыгып килгән кояштан яхшы көн теләп. Мәгәр соңгы елда бу йоланың кеше күңеленә якынрак торуына инана башлады кебек философ. Көннең матурлыгы, аның ялынган-ялварган кешесенә игелекле булуы әнә шул кояш һәм күк йөзеннән тормыймыни. Димәк, күк-кояштан матур һәм игелекле көн теләү бер дә варварлык түгел икән бит! Христиан чиркәүгә килеп Гайсә пәйгамбәрдән изгелек көтә. Ни катнашы бар ул сурәтнең туып килгән көнгә? Һични?! Философ моны белә, әмма күңеле балачактан ук шул рәсемнән изгелек көткәнгәме, үзе дә күп чакта Гайсә пәйгамбәр сурәте каршына тезләнеп аңардан мәрхәмәт сорый иде.

Кубрат хан догасын тәмамлады, аягына басты, аның тез астындагы киез кисәген җансакчысы шундук чатырга алып кереп китте.

— Орыш аръякта булыр, тәңре шулай киңәш итте,— диде хан һәм философка әйләнеп тә карамый сөрәнчесенә боерык бирде.

Философ Иоанн Фасиан дәшмәде, аның Кубрат ханны рәнҗетәсе килми иде. Соңгы мәлдә ул үзе дә икеләнебрәк калган иде. Хан үз-үзен җиңүгә ышандырды, бөтен бер алай башында торган кеше өчен бу зур өмет иде. Өмет иткән — морадына ирешкән. Философ күптәннән төшенгән иде инде: бу ике туган халыкны бер-берсенә котыртучылар — Табгач белән Византия дәүләте императорлары. Нәкъ менә шулар өчен кулай иде бу зур халыкның бер-берсен кырулары. Бу халык берләшеп көчәйсә, ике империягә дә кыенга туры киләчәк. Моны императорларның икесе дә яхшы беләләр һәм һичнинди элемтә тотмыйча, әчке бер тоемлау аша гына аларны бер-берсе белән орыштыралар иде. Иң әүвәл бу халыкны алар икегә аердылар: көнбатышка йөз тоткан Дулу ыруына һәм көнчыгышка йөз тоткан Ашин ыруына. Калганы бик тиз эшләнде. Императорлар үзләренә йөз тоткан ыруларны булдыралган кадәр мактарга, төрле бүләкләр белән алдарга, юмаларга, кирәк вакытта горурлыкларына кагылып мыскыл итәргә дә күп сорамадылар. Нәтиҗә күз алдында иде. Дала төрки белән тулды, тагын бер-берсе белән орышырга җыеналар.

Көнне каршы алганнан соң ашап алдылар һәм хан боерыгы б·енча аръякка күчә башладылар. Ханның чатыры җыелды, хан күк ·агырга атланды. Кубрат хан белән янәшәдә Аппак бара иде. Аръякка кичкәндә хан артына каерылып-каерылып карады. Ул шул тарафтан Көбер ханны көтә иде. Ханша моны аңлады һәм ханны тынычландырырга теләп:

— Кубрат ханым, килер ул, килер Көбер хан!— диде.

— Мин Көбер хан өчен борчылмыйм, ханша. М·н Эске кирмәннән

хәбәрче көтәм. Җаек бәк Эске кирмәнне һаман камауда тотамы икән?.. Ярдәм итә алмыйм. Тотрыкланып тора алсалар гына ярар иде.

— Философ коткарганнан соң Илбарыс буйтур барып җиткәндер.

— Аның анда барып җитмәве дә мөмкин, ханша.

— Ханым, асрауга алган булса да, ул минем күкрәгем имеп үскән баламдай якын, әйтмә алай балага. Ул китергән игелекне илханнарыңнан күргәнең булмады!

Хан дәшмәде. Аппак ханша хаклы иде.

* * *

Уң якка чыккач, хан орыш уеннары уздырырга булды. Орыш кырындагы хәрәкәтне аның үз күзе белән күрәсе килә иде. Аспарух илханның унике төмән алаен хан уң кулга куярга булды, сул кулына алостаз Дәянны. Төп алай башына үзе басар. Маныч елгасының уң ягында тигезлек, дала башлана иде, хан чатырын куйган төбәккә калкулык өеп куйдылар, аны чирәм кисеп капладылар, хәзер хан буласы орыш кырын шул калкулыктан күзәтә иде. Төптәңре булып алган Азак кавханны Кубрат хан үз янына алды. Азак кавханның бер төмән алае бар, төптәңре булырга өйрәнмәгән кавхан орышка талпына, әмма аны хан кырт кисеп тукттаты:

— Төптәңре алыплар күңеленә җиңү коткысы сала. Бер төмәнгә генә түгел, ул бөтен алайга баш, Азак кавхан. Төптәңре Азак,— дип төзәтте үзен Кубрат хан.

Кубрат хан шундый урын сайлады ки, Йулыш каганга уртадан килүдән башка чара юк иде. Кичә ул уйлады-уйлады да, олауны елганың сул ягында калдырды, Кубрат хан җәяүле алай тотмады. Киресенчә, алай артыннан көтү-көтү ат йөртте, орышка ат өйрәтүчеләр булдырды. Ук-корал ясаучылар һәм олау белән өлкән яшьтәге, әмма кулларында корал тотарлык кавханнар җитәкчелек итә. Кирәк икән, алар ук-корал ясаучылардан, олаучылардан бер-ике төмән оештырып, елганың уң ягына чыга алалар. Моның өчен аларга Кубрат ханның боерыгы кирәк булачак. Мәгәр Кубрат хан орышны бу хәлгә барып җитмәс дип ышана.

Кубрат хан калкулыктагы орыш кырын күзәтте. Дала ягыннан җылы җил исеп куйды. Хан, йөзен җилгә куеп, көнчыгышка күз ташлады. Балкыр илхан чигенә башлаган булса, шул тарафтан килеп чыгарга тиеш иде. Әлегә барысы да ул теләгәнчә бара. Мәгәр орышның кагыйдәсе юк, орыш алдан уйлаган исәп буенча бармый. Моңа Кубрат ханның күп тапкырлар инанганы бар. Шуңа карамастан, ханга орыш барышын алдан күрә белү кирәк иде. Тик ничек күрмәк кирәк! Көбер хан һаман килеп җитми, Эске кирмәннән хәбәрче юк, Балкыр илханның язмышы да ачык түгел.

Уеннарны башларга вакыт иде, Кубрат хан кулындагы таягы белән Аспарух илханга кузгалырга боерды. Көньяк-көнчыгыш тарафтан ун төмәннән артык атлы алай тоташ бер ташкын булып кузгалып китте. Аспарух илхан, Кубрат хан уйлаганча, грек уты куелган арбаларга таба ташланды. Дала ат тояклары тупылдавыннан уянып, сискәнеп киткәндәй булды. Аспарух канатын җәя башлауга, алостаз Дәян кузгалды, Кубрат хан Азак кавханны үз урынына төп алай башына куйган иде, аңа да кузгалырга боерык бирде. Иллә Аспарух илхан Кубрат хан уйлаганча итмәде, алган кисәк борып, елганың югары ягына ташланды. Андагы чәүкәлекләр артында Көбер хан булырга тиеш, ә ул килеп җитмәгән. Күп тә үтми Аспарух илхан үз алае белән елганы кичеп чыгар, олауны тар-мар итәр һәм Кубрат ханның аркасына төшәр. Хәйләкәр, хәйләкәр Аспарух илхан. Кубрат хан алостаз Дәянга елганы кичеп, Аспарух ил-

ханның юлына аркылы төшәргә дип, боерык җибәрде, әмма Аспарух илхан елганы кичеп чыгып килә иде инде.

Кубрат хан уенны туктатырга боерды. Ул аларның барысын да — меңбашларны чатыр янына дәшергә кушты. Атлары тирләп чыккан буйтурлар, меңбашлар чатыр тирәсен уратып алдылар. Кубрат хан аларга рәхмәтен белдерде, буйтурларны, кавханнарны калдырып, меңбашларга таралырга боерды.

Буйтурлар, кавханнар чатыр тирәсенә җыелгач, хан барысына да күз йөртеп чыкты.

— Алыпларым, буйтур орыш кырында сынала. Аспарух илхан нигә сәләтле икәнен уенда ук күрсәтте. Алостаз Дәян, киңәшең әйт. Ничек каршыларга исәбең каган алаен?

— Олуг хан, алайларны бергә, бер төбәккә җыеп, бер көч булып бәрик.

— Төптәңре Азак, син ни әйтерсең?

Кубрат хан Азак кавханга карады, түшенә зурлыгы белән дә, ялтыравы белән дә төптәңре Ирсаннықыннан һич тә ким булмаган алтын таңкә таккан, кан кызыл чапан кигән Азак күтәрелде.

— Олуг хан,— диде яңа төптәңре барысының да карашын чәүкәлеккә җәлеп итеп.— Мин болай итәр идем.— Азак төптәңре Кубрат ханның җансакчылары тигезләп куйган ком өстәл янына үтте, хәнҗәр очы белән орыш кырын сызып күрсәтте.— Төп көч, олуг хан, миңа калса, бераз сыеграк. Каган алае төп көче белән уртага бәрсә, ул аны шундук ерып чыгар һәм хан калкулыгына ташланыр...

— Яхшы, төптәңре Азак, киңәшеңне исәпкә алырбыз. Инде син әйт, Аспарух илхан.

«Углан» дияргә ничектер яхшысынмады Кубрат хан, бүгенге орыш уенынннаң соң өченче угланын үзе белән тиң күрә башлады. Угланның өстендә тимер көбәк, аякларында күн итекләр, очлым уртасына кояш сурәте чүкелгән, борынын каплап, җәйпәк ук төшерелгән. Илханның җансакчысы комны тигезләде. Аспарух хәнҗәрен тотып, ком өстәл янына үтте.

— Атам,— диде ул нигәдер.— Мин каган алаен чак кына алгарак барып каршы алыр идем. Без елгадан ерак китә алмадык, каган безне кысрыклый башласа, җәелергә урын калмас, кичүгә ташланган болгарларны хәзәрләр укка алырлар. Мин болай уйлыйм, атам, төп көчнең беренче сафына укчыларны куярга. Укчылар укка алгач та икегә аерылып китәләр, хәзәрләр каршына ташаткычлар килеп баса. Хәзәрләр инде яу килә, чигенергә соң, шунда грек уты телгә килсен иде. Бу хәл каганның төп көчен тар-мар итәргә мөмкинлек бирер. Калганын ике яктан уратып алган болгар алайлары хәл итәр, ягъни мин дә, алостаз Дәян. Хәзәрләргә арбаларны күрсәтмәү хәерлерәк булыр. Һәр арбаны сөңгечеләр белән уратып капларга кирәк, күзгә ташланмасыннар, арбаларны укчылар артыннан килүче сөңгечеләр дип белсеннәр.

Аспарух илхан сөйли, мавыгып, орыш кырын ачык күреп сөйли, ә Кубрат ханның йөзенә сизелер-сизелмәс кенә елмаю куна бара иде. Хан үзе дә сизмәстән түшен киеребрәк басты, ата угланыннан канәгать иде. Ул аңа киләчәктә Дулу ыруын дәвам итүче олуг хан буласын орыш уенында ук исбат итте.

— Ниятең-киңәшең миңа ошый, илхан. Инде мине тыңлагыз, кавханнарым, буйтурларым. Аспарух илхан дөрес әйтә. Йулыш каганның төп көчен алгарак чыгып каршы алырга кирәк. Без җиңәрбез, алыпларым. Без каганга яу килмәдек, без җәйләүләребезне дошманнан йолып алып калырга дип бире килдек. Грек утын атып бетергәч, ике якка аерылып киткән сөңгечеләр ташаткыч арбаларны аръякка кадәр озата барырлар. Мин әйттем.

Кавханнар таралгач, Кубрат хан чатырга керде һәм түр яктагы түшәк өстенә ауды. Шундук аның янына Аппак килеп җитте.

— Ни булды, ханым?

— Хәлем бетеп тора, ханша. Олыгайдым мин, ханша, картлык шулай сиздерми генә киләмедер.

— Юк, син картаймадың, ханым. Көчле, куәтле син.

— Юк, ханша, картайдым.

— Картаймадың, Кубрат. Син еллар үтә-үтә тагы да көчәя, гайрәтләнә генә барасың. Син каһарман алып, батыр ир!

— Балалар үсте, Аппак. Син хаклы, Аспарух илхан бүген үк тәхеткә утырырдай кеше. Ак ат, ак тай тап. Орыштан соң корбан чалырбыз, ак ат тиресенә салып, Аспарух илханны олуг хан итеп күтәрербез.

— Икенче угланың Эске кирмәндә камауда, ханым.

— Каганны җиңгәч, Аспарух илхан Эске кирмәнгә китәр, Җаек бәк каберен шунда табар. Мин инде картайдым, ханша.

— Әйтмә алай, ханым, сиңа барысы да ышана, син алар өчен тәңре дә, хан да, гайрәтле Кубрат та.

— Батбай углан кая? Нигә һаман килми? Аңа җибәрелгән йомышчылар кая?.. Төптәңрене үле яисә тере көйгә миңа тотып китерсеннәр. Мин аны үз кулларым белән...

— Тынычлан, ханым. Төптәңре Батбай илхан кулында, диләр.

— Ханша, Батбай илханга үпкәм зур, ай-һай зур, ханша. Углан каганга баш орган булса!..

Чатыр эченә ханның җансакчысы керде.

— Олуг хан, сөенче, Көбер хан алае белән килеп җитте!

Кубрат хан сикереп торды, йөгереп чатырдан чыкты, кулын маңгаена куеп, аръякка карады. Әйе, аръякта чынлап та алае белән Көбер хан иде.

— Ханша, философны дәш. Миңа аның киңәше кирәк.

Философ Иоанн Фасианны китереп тә җиткерделәр.

— Философ,— диде Кубрат хан Иоанн Фасиан чатырга килеп кергәч.— Уз түрдән, утыр... Истәлекчене дәшегез,— диде ишектәге сакчыга Кубрат хан.

Истәлекче керде, пергамент алып, бер читкә утырды.

— Философ, әйт әле, кем ул кол?

— Борынгы греклар колны сөйләшә белгән ике аяклы хайван дигәннәр, олуг хан.

— Иоанн Фасиан, бабаларың бик яман кеше булганнар. Кол ике аяклы хайван, имеш... Төркидә кол зур хокукларга ия, философ. Ул өйләнә, җәйләү ала, алып булып орыша ала. Мин үземне халкымның колы итәр идем, философ.

— Олуг хан, кыеп әйтергә батырчылык итәм, син үзеңне халкың колы түгел, халкыңның тәңресе итәр идең, әмма халкың ышанмас дип куркасың.

Кубрат хан куе кашларын җыерды, бер тын уйланып ятты, ниһаять, ул авыр карашын философка төбәде. Бу караштa чакыру да, ялвару да, үтенү дә, өндәү дә, боеру да бар иде.

— Дәвам ит, дәвам ит, философ, фикереңне әйтеп бетер. Син Болгарда ханга теләсә ни әйтә алырга хаклы бердәнбер кеше.

— Олуг хан, Йулыш каган миңа яман сүзләр сөйләде.

— Мин тәңре дә, пәйгамбәр дә түгел, философ. Мин үз гомеремдә бик күп хыянәтчеләр күрдем, мин аларның беришен ат койрыгына тактырдым, беришен астырдым, җәлладтан чаптырдым. Әмма моннан минем дусларым артмады, киресенчә, кими барды. Тәңре — күктә, мин — җирдә, халкым белән. Әгәр дә мәгәр каган миңа янаган икән, баш сөягемнән кымыз савыты ясармын дип әйтеп әйткән икән, ул бәхәсне орыш хәл итәр, орыш күрсәтер.

Иоанн Фасиан гасабилана башлады, чапан төймәләрен барлап чыкты. Авыр иде аңа бу кеше белән әңгәмә алып баруы. Бу кеше аңа сөйләшкән саен яңа яклары белән ачыла бара иде. Алай да күңелендәген әйтеп бирергә булды.

— Адәм баласы рух белән, җәнлек тырнак белән көчле, хан.

— Рухым — тәңре, илем — Болгар, дошманым — каган, син кемем, философ? Әнә, күрәсеңме, кылганнар арасында карсак төлке,— Кубрат хан сикереп торды, чатырдан чыкты, аңа философ иярде.— Әнә күр, күр үзен. Мин аңа һәркөн сөяк ташлыйм. Миннән калмый башлады. Кем ашата, шул кеше булыр кол хуҗасы. Мәгәр аны греклар кебек кол дип тә, кеше дип тә, ике аяклы сөйләшә белгән хайван дип тә әйтмиләр, карсак төлке, диләр.

Хан аңа: «Син кем?»— димәде. Философ ханның ни әйтәсен болай да аңлады. Әйе, ул чынлап та базилевс шымчысы, ул Кубрат ханга зур миссия белән җибәрелде. Ләкин аның күңеле көннән-көн базилевстан читләшә, бу кешегә якыная бара. Ул үзендәге бу үзгәрешне ни дип аңлатырга да белми. Бу кешедән сере юк иде аның. Булганын да әйтергә булды.

— Олуг хан, базилевс сарациннар белән сугышка киткән, улы Юстиниан син куйган вакытны озаксынып, Фанагуригә кузгалырга җыена икән. Углан белән бик күп бүләкләр, корал, ике төмән алай килә.

Көтелмәгән бу хәбәрдән Кубрат хан бермәлгә ни әйтергә белми торды. Һич аңлап бетермәле түгел бу грекларны, бүген бертөрле, иртәгә икенче төрле сөйлиләр.

— Кызым Чәчкә Эске кирмәндә, философ. Эске кирмән камауда. Мин үзем дә Чәчкәне түземсезлек белән көтәм. Каган җиңелгәч, Эске кирмәнгә юнәлермен, Җаек бәкнең башын кисеп Әтилгә ташлармын. Кубрат хан вәгъдәсендә торыр, кызын император угланы Юстинианга бирер. Мин беләм сине, философ, нинди максат белән Фанагуригә килүең турында. Болгарларга христиан йоласын тагудыр максатың... Шулаймы... Күңелеңдәген укып рәнҗетмәдемме, философ?..

— Рәнҗетмәдең, олуг хан. Илем-йолама хыянәт итә алмыйм. Алай иткәндә мин үз-үземә дә дошман булыр идем. Күрәзәлегең бар икән, олуг хан.

Философ кисәктән Кубрат хан алдында түбәнчелек белән баш иде һәм сүзе бетүен аңлатып, читкәрәк китеп басты.

Уйланырлык иде философ Иоанн Фасианга. Күп күрде ул кешеләрне, алла булырга теләгәннәрен дә күрде. Әмма аларның берсендә дә мондый акыл күрмәде. Кем бу Кубрат хан исемен йөрткән кеше? Әллә соң чынлап та күктән төшкән тәңре илчесеме? Пәйгамбәрме?! Нинди нечкә политик, нинди акыллы юлбашчы! Ашиннар ыруы өскә чыкса, харап булачак бөек төрки халкы. Аларның беркайчан да ил-дәүләтләре булмас, гел үзара орышып яшәрләр. Сакларга, менә кемне сакларга кирәк төрки халкына!

Иоанн Фасиан үз императорын Кубрат хан белән чагыштырып карады. Һәр мәәктән, ипподромнарда уздырылган уеннардан тәм табып, күңел ачып яшәгән, дәүләт эшләрен тулысы белән логофетына тапшырган император Ираклий оста дипломат Иоанн Фасиан алдында кисәк бик кечкенә гәүдәле ил башлыгы булып калды. Гаять дәрәҗәдә вакчыл, интриган, мин-минлек чире белән бала чактан ук чирли башлаган императорның тәхетенә менә кемне утыртыр иде ул. Бик күп илләрдә булган, һәр илдә дин-йола даирәсендәге галим-голәмә белән тормышын кыл өстенә куеп бәхәсләргә кергән Иоанн Фасиан гомерендә беренче тапкыр императоры өчен оялу тойды. Кем җырын җырлый ул? Императорныкын... Хак анысы, философ киләчәккә карап эш итте, мәкерле император урынына үзе укыткан, үзе белем биргән, үзе тәрбияләгән Юстиниан киләчәк иде. Әнә шундый өмет белән яши Иоанн Фасиан. Ул

углан үзенә хатын итеп менә шушы бөек кешенең кызын да алса, үлсә дә үкенмәс иде философ.

Болгарга куылыр алдыннан философ Иоанн Фасиан император Ираклийга керде. Аның янында дин башы Фотий, логофет Барда утыралар иде. Логофет олы кеше иде инде. Аны һични кызыксындырмый, картлык белән бергә аңа битарафлык, гамьсезлек килгән. Ул Иоанн Фасианга күтәрелеп тә карамады. Сорауларны күбрәк дин башы Фотий бирде. «Философның Болгардагы төп максаты,— диде ул бик озак вәгазь укыгач.— Кубрат ханны христиан итүдән гыйбарәттер».

Императорны исә күбрәк Болгардагы төзелеш эшләре, кирмән диварларының биеклеге, киңлеге, нинди материалдан өелүе кызыксындырды. Шулай ук аны борчыган нәрсә Төн илләре халыклары икән. Йомгаклап болай диде император: «Һәр варвар христиан булмаса да ярый,— дип дәвам итте ул сүзен бармакларындагы энҗе кашлы йөзекләренә карап.— Мәгәр алар империягә бирелгән, ышанычлы халыклар булырга тиешләр. Империягә карата шул халыкларда хөрмәт уяту — менә синең максатың нидән гыйбарәттер. Хәерле сәфәр сиңа, философ».

Менә шул өч кеше бөтен бер империя белән идарә итәләр иде. Халыкларны ничек бер-берсенә өстерергә мәкерле юллар менә шул өч кеше башында туа һәм меңләгән куштаннар аша дөнья халыкларына җиткерелә иде.

Күп нәрсәгә төшенде Болгарга килгәч Иоанн Фасиан. Болгарның ханыннан алып, хөкемдарларына кадәр гаять дәрәҗәдә гадел булулары, ришвәткә бирелмәүләре, ясакларның халык өчен җиңел икәнен күрде. Әле ул Кубрат хан дәүләтендәге тәртипләргә көнләшеп карады, әле биредә Византиянең кайбер тәртипләре булмавына әрнеде. Җитмәсә шул дәүләт турында базилевска мәгълүматлар җыярга тиеш. Һәм ул аны җыяр да. Мәгәр ул мәгълүматлар империя өчен бер дә уңай мәгълүматлар булмас. Мондый мәгълүматлар җыйган өчен аны базилевс мактамас, кайту белән тагын бераэр илгә сөрер. Ул аңа каршы сүз әйтергә дә калдырмас, каршы әйт син императорга, ул сине шунда ук еретиклыкта гаепләр, ә андыйларның язмышы Румда ут учагында тәмамлана.

Менә шул хакыйкатьне аңлагач, Иоанн Фасианның киләчәген томан каплады бугай. Философ үз гомеренә беренче тапкыр диярлек аптырап калды. Ахыр түзмәде, тагын хан янына килде.

— Олуг хан, кичер мине. Грек халкы борын-борын заманнан ук үзен башка халыклардан өстен күрде. Теле-дине ят булдымы, грек халкы өчен ул — варвар, сакаллы сабый. Болгарга килгәч, мин бернәрсәгә инандым, олуг хан, нинди телдә генә сөйләшмәсен, нинди йолага гына табынмасын, һәр халыкта да акыл ияләре бар, һәр халыкның мөстәкыйль дәүләт төзергә хокукы бар. Грек халкы башка халыклардан бер дә өстен түгел икән. Мин шуңа инандым, олуг хан.

— Философ, халкың турында яман сөйләү ярамас иде. Синдәй акыл ияләрен биргән халыкны варварлар белән тиңләп булмый.

— Була икән, олуг хан, була икән, моны киләчәк исбат итәр.

— Ялгышма, философ. Грек халкының эшенә мин сокланып бетә алмыйм.

— Соклану адәм затына бер дә ят сыйфат түгел, олуг хан. Соклану — кешелек билгесе. Бөек Византия дәүләтен император Ираклий төземәгән, ул җимерүчеләр рәтенә керер. Грекны бөек халык итүчеләр һәрчак күләгәдә кала килделәр. Бүген Византия бик авыр чор кичерә, олуг хан. Византиягә байлыктан азыну чоры килде. Байлыктан дөрес файдаланмасаң, ул байлык нинди камил дәүләтне дә черетер, таратыр, гамьсезлек һәм битарафлыкка юл ачар, диләр акыл ияләре.

— Менә мин, Бөек Болгар дәүләтенең олуг ханы, синең акыллы

киңәш[illegible], философ. Акыл — хаклык билгесе, әйт сүзең: кемнәр аша император белән элемтәдә торасың?

Кубрат хан йөренеп килде. Ханның аягында йомшак сафьян итек, өстендә византия чапаны, күкрәгенә таккан алтын кояш сурәте әле уңга, әле сулга селкенә. Бил путасында да шундый ук алтын аел, кылыч кынысы жиргә тиеп-тиеп киткәли.

— Олуг хан, мин сине данлар өчен килдем бирегә. Тиздән минем император Ираклий угланы Юстиниан үз янына алыр. Аның логофеты булып алгач, мин сиңа үземнең тугрылыклы булуымны исбат итәрмен. Ышан миңа, олуг хан.

— Син хаклы, философ. Кеше нинди телдә генә сөйләшмәсен, нинди йолага гына табынмасын, аның күңеленә ышаныч, бары тик ышаныч аша якынаеп була.

Хан, философ белән сүзе бетүен аңлатып, зәңгәр рәшә тибрәлеп торган офык читенә карады, аннары Көбер хан туктаган чәүкәлеккә күз ташлады. Хан чатырына таба үзенең буйтурлары белән кайнеше Көбер хан килә иде. Киңәш мәҗлесенә өлгермәде Көбер хан, әмма Кубрат хан белән ул килешер. Кубрат хан кайнешенә дә хатыны Аппакка ышанган кебек ышана иде.

## 28

Бу көннең таңы бик озак атты. Ханга хәбәр килде: кичә кичке якта каганның төп көче Балкыр илхан белән очрашкан. Бик каты бәрелештән соң Балкыр яралана. Җансакчылары аны каган алыпларыннан аерып алалар, тиздән бире килеп җитәргә тиешләр икән.

Кубрат хан бар көчләрен тәртипкә куеп, түземсезлек белән Балкыр илханны, аны куып килгән каганны көтә башлады. Нићаять, кояш чыгып, тәңредән игелекле көн теләгәндә офыкта Балкыр илханның алае күренде. Кубрат хан аларга каршы албагучыларын җибәрде.

Килеп җиттеләр. Балкырның башы җиңелчә генә һәм янбашы яраланган икән, яралы угланы яныннан ханша бер мәлгә дә китмәде. Кубрат хан Балкыр илханның алыпларын ашатырга-эчертергә кушты, аннары меңбашларны җыйды, унбашларга, йөзбашларга аерырга боерды. Барысы да әзер булгач, аңа килеп әйттеләр: каган белән орышта Балкыр илхан өч төмәнгә якын алаен югалткан. Балкыр илхан алаен хан үзенең төп алаена кушты. Шуннан соң гына яралы угланы янына керде. Хәлен сорады. Балкыр углан аңа елмаймакчы итте, әмма йөзе тартышып, чытылып китте. Угланының дала җилендә ярылып, кәшәләп беткән йөзен, кан саркып торган иреннәрен күрде дә хан, грек табибын чакырырга кушты. Табиб килгәч ул:

— Мине дәвалаган кебек үк дәвала, алтын белән итәгең тулыр,— диде.

Балкырның икенче ярасы янбашында. Янбашына ук кадалган булган, аны җансакчысы тотып тора, Кубрат хан укның агулымы-юкмы икәнен тикшерергә кушты. Табиб аңа агулы түгел икәнен әйтте. Шуннан ул тынычланып, чатырдан чыгып китте. Чатырга кабат әйләнеп керде, табибның яралы янында әвәрә килүенә карап торды. Хан Балкыр илханнан берни дә сорашмады, аталы-уллы ир-атлар күзгә-күз карашып кына сөйләштеләр. Күрә-аңлый иде Кубрат хан: угланына озак карап тора башласа, тегесе күзләрен йома, авыртынудан битәр чигенергә мәҗбүр булуына, шактый алаен югалтуга әрнешә кебек иде илхан.

Әйе, орыш җиңел булмаячак. Кубрат хан моны каган белән Балкыр илхан бәрелешеннән үк сизде. Албагучылар хәбәр китермиләр, каган

күренми иде. Нигә озаклады? Исәпләүләре буенча, каган моннан ике көн элек Маныч елгасында булырга тиеш иде инде.

«Җаек бәкне көтәме?»— дип уйлады хан. Нәкъ менә шул уй аңа көн буена тынгылык бирмәде. Әмма кузгалырга ярамый иде. Каганда көч житәрлек, каган Җаек бәксез дә орышны башлап җибәрә ала. Шулай булгач, нигә ул һаман юк?

Билгесезлек Кубрат ханны тәмам хафага салды. «Әллә соң,— дип уйлады ул (бу уен хан күңел түрендәрәк тота иде, ә уй дигәнең калка да чыга, калка да чыга),— каганның Чәчкәне кулына төшерергә исәбеме?.. Бик мөмкин ич! Җаек бәк, ниһаять, Эске кирмәнне ала һәм хан кызы Чәчкәне кулына төшерә, шуннан соң гына үзен көтеп торган Йулыш каганның төп көченә килеп кушыла. Кулына Чәчкә төшкәч, Йулыш каган аңа шарт куяр: йә кызың, йә үлем?..»

Кубрат хан башын кысып тотты, як-якка чайкалып торды. Кодрак илхан кирмәнне тота алырмы? Орышларда сакалы агарган Җаек бәк бер-бер хәйлә белән капкаларны ачтырмасмы?..

Кубрат хан янына Балкыр углан килеп керде, ул инде йөри ала иде.

— Утыр, углан. Ун көн көтәбез каганны. Нигә килеп җитми?

— Каган килер, көчен барлыйдыр, атам, без аны шактый туздырдык. Аннары аның Җаек бәкне көтеп алуы да бар, атам.

Кубрат хан текәлебрәк угланына карады. Бу углан да минемчә уйлый икән, димәк, каган чынлап та Җаек бәкне көтә, ә ул килми дә килми. Килер иде, кирмәнне алалмый.

Кубрат ханның эченә җылы йөгергәндәй булды.

Шул чак чатырга җансакчысы йөгереп килеп керде.

— Олуг хан, офыкта каган!

Офыкны тоташ сөңге очы томалаган шикелле иде. Күпме алай белән килгән каган — төгәл генә белүче юк. Бу көнне орыш булмады. Бары икенче көнне генә, кояш чыгып, көнне каршы алгач, елга буендагы томан сыегып юкка чыккач кына ике як та орышка әзерләнә башлады.

Хәзәрләр дугасыман булып басканнар. Сугыш кырына күз төшерү белән Кубрат хан Аспарух илханга сул яккарак җәелә төшәргә боерды. Аспарухның җәелә баруын күреп, хәзәрләр дә сафларын киңәйтә төштеләр. Төп көче белән каган уртада иде. Төп көчен ул укка оста тезгән, һәр баскыч саен бер алып арта бара.

Кубрат хан кавханнарына боерык бирә торды һәм бер мизгелгә дә дошманнан күзен алмады. Аппакка һәм философка елганың аръягына чыгып китәргә боерды.

Кубрат хан атын сорап алды. Күк айгырын китергәч, яшьләргә хас житезлек белән сикереп атланырга иткән иде, өзәңгегә аягын куюга, туктап калды, әмма шул мизгелдә үк ханның җансакчысы аның аяк астына кулын куярга өлгерде. Хан хәтта игелекле җансакчысына күз дә ташламады. Кулына тезгенен алды, аты шундук бии-бии алай алдына таба кузгалды.

— Болгарлар, алыпларым, кардәшләрем,— диде хан өзәңгесенә баса төшеп.— Хәзәрләр каганы безне үзенә буйсындырмакчы, җәйләүләребезне, калаларыбызны яулап, хатын-кызларыбызны, бала-чагаларыбызны Биләмҗиргә алып китмәкче. Аннан ул аларны кол итеп Мысырга, Франкларга, Румнарга сатып җибәрер. Мин сезгә ышанам, алыпларым, хатыннарыгызны, апа-сеңелләрегезне хәзәрләргә әсир итәргә юл куймассыз! Без — болгарлар, кардәш көтригурлар — җәйләүләребезне, апа-сеңелләребезне беркемгә дә бирергә җыенмыйбыз. Без үз җәйләүләребезне саклыйбыз, без үз җәйләүләребез өчен орышабыз, без җиңәрбез, алыпларым. Тәңре безнең якта!

Кубрат хан һәр төмән алай каршына туктап сүз әйтте. Хан әйләнеп

башлады.

— Олуг хан, Эске кирмәннән хәбәр килде. Җаек бәк кирмәнне ташлап, бирегә юл тоткан.

— Алостаз Дәян, Эске кирмәнгә иң ышанычлы атчабарың җибәр. Кодрак илхан үзенең алае белән бирегә ашыксын. Мин әйттем.

— Баш өсте, олуг хан. Йомышчы хәзер үк китәр. Олуг хан, кыеп әйтергә батырчылык итәм: төп алайны кайсы илхан җитәкләр?

Кубрат хан саф-саф тезелеп торган алайларга күз ташлады.

— Төп алай алдында Балкыр илхан булыр, алостаз Дәян.

Соңгы мәлдә генә уена килгән фикерен ныгыту өчен Кубрат хан барган җайдан җансакчыларының берсенә Балкыр илханны чакырырга кушты. Чатыр янына җитәрәк, аларны Балкыр илхан куып җитте.

— Атам, дәштеңме?

— Дәштем, углан. Углан, тәңре киңәше белән мин сине төп алаем башына куярга булдым. Акылың белән орыш. Кыюлык белән батырлыкны бутама, үзеңне сакла, әмма дошманнан куркып орыш кырын ташлама. Курку — җанварга гына хас сыйфат. Син олуг хан угланы, онытмасаң иде шуны. Иңгә-иң килгән алыпларың ташлап, алга ыргылма, җүләр үлем дан китерми.— Кубрат хан атыннан төште, путасын салды, аның өстенә кылычын куйды һәм каршына килеп баскан Балкыр илханга бирде. Балкыр илханның җансакчысы атын тотып торды, илхан исә атасына тез чүкте.

— Атам, олуг хан, угланың Балкыр син биргән бабамнар кылычын нык тотар. Дошман алдында куркып калмас, илен-җирен халкын саклап, соңгы тамчы канына чаклы орышыр.

Балкыр илхан кылычны кынынннан тартып чыгарды, йөзеннән үпте, кылычны кире кынысына тыкты, путаны биленә буды, сикереп атына атланды.

Кубрат хан калкулыкка менеп басты. Ике як та орышка әзер иде, әмма бу як та, теге як та кузгалырга боерык бирми тора иде. Кубрат хан орыш кырын янә бер кат күздән кичерде. Чәүкәлеккә күз төшереп алды. Чәүкәлек артында уникe мең алыбы белән аның боерыгына әзер булып Көбер хан тора иде. Каган аны күрми, күрергә дә тиеш түгел.

— Алостаз Дәян, сөрәнчегә әйт, мәргәннәргә алышырга оран салсын. Укчы мәргәннәрдән соң мәйданга сөңгечеләр чыгар! Мин әйттем.

Болгар сөрәнчеләре оран салуга, хәзәрләр ягыннан ике мәргән мәйданга таба кузгалды.

— Нигә ике мәргән?— дип сорады хан.

— Олуг хан, Эске кирмәнгә йомышчы китте.

— Нигә ике мәргән дим мин сиңа, алостаз Дәян?!

— Каган шулай теләгәндер, олуг хан. Ике икән, без дә икене чыгарыйк.

— Бу Ашин ыруы гомергә гадел итеп яши белмәде. Чыгар ике мәргәнең, алостаз Дәян! Мин әйттем.

Болгарлар ягыннан да ике мәргән кузгалды, алар атларын юырттырып кына бер-берсенә якынлаша башладылар. Ук җитәр ара калгач, болгар мәргәннәренең берсе уңга, икенчесе сулга чаптырып китте. Хәзәр мәргәннәре дә як-якка аерылдылар.

Алышчы алыплар дошманнарны сайладылар, уктан алыша башладылар. Кош кебек очып барган аттагы мәргәнне укка алу җиңел түгел, әмма аңа нәкъ менә очып барган кошны укка алган өчен мәргән исеме бирелә. Ук атыш уеннары булган саен Кубрат хан иң оста мәргәннәргә кораллар, бүләкләр өләште. Менә хәзер алар үз сәләтләрен күрсәтергә тиешләр иде. Кайсы як алдырыр, кайсы мәргән өстен чыгар?..

Мәргәннәр бер-берсенә якынлашкан арада Кубрат хан үз янына алостаз Дәянны дәштереп алды. Хан күк атка атланган, аты калкулыкта,

Кулыш каган да калкулыкта иде, ул да ат өстен[illegible]. Ул
арада ни сәбәпледер каган атын алыштырды, ак атка менеп атланды.
Мәргәннәр уктан атыша башладылар. Болгарларның бер мәргәне атыннан очып төште, мәйданда ятып калды, аның аты кешни-кешни болгарлар алаена таба китте. Болгар ягында «аһ!» дигән аваз дулкыны узды, хәзәрләр ягы исә сөңгеләрен күтәреп: «Алдыр! Алдыр!»— дип кычкыра башладылар.
Уң якка киткән мәргәннәр укларын бушка аттылар, бер-берсенә тигезә алмадылар. Алышкан мәргәне ятып калуга, сулдагы хәзәр мәргәне уң якка чапты. Болгар мәргәне аны күрә идеме — юкмы, әмма тамаша кылган алай гү-ү килде, мәргәнгә куәт биреп кычкырырга тотындылар. Шуннан тагын тынып калдылар, барысы да тәңре кулында иде. Бер кешегә — ике кеше. Бер мәргәнгә — ике мәргән.
«Тәңрем, булыш мәргәнгә!» — диде Кубрат хан.
Хан белә иде, укчы мәргәннәрдән соң сөңгечеләр чыгачак, сөңгече ятып калган хәлдә дә орышны алыплар алышы хәл итмәячәк. Әмма нигәдер хәтта шул алышта да оттырасы килми иде ханның. Беренче мәргәне атыннан авып төшкәч, ханның йөрәге кысылып куйды, хан үзе мәйданга чыгып китәр дәрәҗәгә җитеп ярсына башлады.
Ул арада ике хәзәр мәргәне болгар мәргәнен уртага алдылар. Болгар мәргәненә беркая да китәр урын клмады.
Хәзәрләр ягында: «Алдыр, алдыр, алдыр!»— дип кычкыралар, болгарлар исә тынып калдылар.
— Кем угланы алыша?— дип сорады янәшәсендәге алостаз Дәяннан хан.— Кем угланын чыгардың?
— Алышучы, олуг хан, Азак кавхан угланы Әмәт.
— Азак кавхан угланы!?
— Әйе, олуг хан. Төптәңре үзе теләде.
Ул арада алышучылар арасында тагын бер хикмәт булып алды. Ике хәзәр мәргәне болгар алыбын шул чаклы кыстылар ки, теге җәясенә ук элгән килеш бер урында әйләнә башлады. Мәргән үзе тирәли чапкан хәзәр мәргәннәренең ачылганын көтә иде.
— Ат, ат!— дип кычкыра башлады болгарлар. Мәргән үзенә очкан уклардан йә ат өстенә ятып кала, йә укка калканын куя. Бождра тагы да кечерәйде. Шунда бер хикмәт булып алды: болгар алыбы ат өстенә яту белән хәзәр алыбы җәясен тартты, болгар мәргәне берьякка тайпылып калды, ук исә икенче яктагы мәргәннең атына барып тиде, ат куркынудан өркеп китте, шунда болгар алыбы җәясен җибәрде. Ук хәзәр мәргәненең култык астына кадалды. Мәргән берьякка ауды, аты аны хәзәрләр ягына чаптырып алып китте. Хәзәр мәргәне иптәшенең үлемен күреп, бер мәлгә каушый калды, күрәсең, болгар алыбының чираттагы угы аның ботына кадалды. Мәргән укны ботыннан тартып алды, җәясенә элде, мәргән керешен тартырга өлгерми калды — болгар алыбының икенче угыннан ул атына чалкан авып төште.
— Уклар агулы идеме?
— Олуг хан, алышларга агулы уклар бирелми,— диде алостаз Дәян.
Кубрат хан төркиләрдәге бу язылмаган законны бик яхшы белә иде, күңелен тынычландыру өчен генә сорады, аның исән калган болгар алыпны үтертәсе килми иде.
Ук мәргән алыпның кулына тигән, ул, канаты сынган коштай белә-ген салындырып, Кубрат хан янына килеп туктады. Кубрат хан мәргәнне атыннан төшерергә кушты, үзе дә төште, килде дә алыпны кочагына алды, аннары алтын саплы хәнҗәрен бүләк итте, «ур-ра!» кычкырды. Болгар алае өстендә ур-ра тавышы яңгырады, хәзәрләр дәшмәделәр.
— Сөңгечеләр!— дип оран салдылар ике яктан да.
— Сөңгече бераү генә чыга,— диде алостаз Дәян.

Кубрат хан: «Нигә?»— дип сорамады, атына атланды.

— Сөңгечегә кем угланы чыга, алостаз Дәян?

— Тимерче Кулбай угланы Бәкер, олуг хан.

— Яхшы, чыксын,— диде хан.

Сөңгечедә таза ат, тимер калкан, җиде аршин озынлыгындагы сөңге иде. Сөңгеченең үз исеме түгел, атасының аты Кубрат ханның хәтерен җәлеп итте. «Кулбай, Кулбай,— дип уйлады ул хәтерен барлап.— Кулбай угланы!»

Тимерче Кулбай бер яудан да калмады, хәзер әнә Симай ата белән бер алачыкта эшли. Орышка җыенганда сакалы биленә җиткән Кулбай хан каршына килеп баш иде. Нык өзәңгеләр, тамгалы очлымнар, ялгаусыз күкрәкчәләр, ничек төшсә дә очлы ягы белән өскә карап торган ыргаклар уйлап тапкан тимерче Кулбайны хан белә иде. Тимерче ханнан угланы Бәкерне үзенә җансакчысы итеп алырга үтенде. Кубрат хан аңа ярый диде бугай. Кулбай шунда ханга: «Олуг хан, җансакчың итеп алсаң, угланым тәнең генә түгел, җаның да саклар»,— дигән иде. Мәгәр хан Кулбайга биргән вәгъдәсен бик тиз онытты, ул хәтта Бәкернең кем булуын да белешмәде. Ә ул алостаз Дәянда булган икән.

— Сөңгечене калдырып булмыймы?— дип сорады Кубрат хан.

— Соң инде, олуг хан. Аннары бу алып уеннарда гел бүләкләр ала килде.

— Ярый!— диде килешеп Кубрат хан. Ул сөңгечесе дә укчылар кебек хәзәрләрдән өстен чыгар дип өмет итә иде.

— Тәңре сәләт бирсен батырга!— диде хан, мәйданга таба китеп барган алыпның киң җилкәсеннән, кулындагы озын сөңгесеннән күзен алмыйча. Мәйданга якыная башлауга, дошман сөңгечеләре атларын чаптырып киттеләр.— Алостаз Дәян, сөңгече алып бер генә ялгыша, тәңре саклый күрсен батырны!

Заманында болгар алыплары сөңге атуда гел өстен чыга килделәр. Элек орыш алдындагы алышларга укчыларны чыгармый торганнар иде, сөңгечеләр генә чыгар иде. Сөңгедә болгарлар һәрчак диярлек өстен чыктылар. Шул җиңү болгар алыпларына куәт бирер иде.

Ике сөңгече атларын чаптырып бер-берсенә таба килгән чакта әнә шул үткән хәлләрне исенә төшереп өлгерде Кубрат хан.

Сөңгече алыплар бер-берсенә якынайдылар, менә тиздән сөңгеләр кара-каршы очачак. Болгар алыбы беренче булып сөңгесен атты, әмма хәзәр алыбы да сөңгесен җибәрергә өлгерде, ике яктан да ух! дигән аваз яңгырады, сөңгечеләрнең үрә баскан атлары яман тавыш белән кешнәштеләр.

Кубрат хан болгар алыбы тәнен үтәли чыккан сөңгене күрде. Алып, җил алгандай, ияр өстеннән очып төште, икенче мәлдә Кубрат хан хәзәр алыбының да ирдән җиргә очып төшүен күрде. Хәзәр алыбының да күкрәген сөңге тишеп чыккан иде. «Калканнарын куярга өлгермәделәрме?»— дип уйлады Кубрат хан. Ике якта да тып-тын калдылар, бары тик алыплардан арынган атлар гына кешни-кешни икесе ике якка юыртып киттеләр.

«Кичер, Кулбай, кичер ханыңны,— дип кыймылдады ханның иреннәре.— Кичер, саклый алмадым угланың...»

Сөңгече алыплар мәйдан уртасында ятып калдылар. Кубрат хан беренче булып аваз салды:

— Кузгалырга!

Алостаз Дәян үз алае башына чапты. Дала кисәк бөтен җир йөзе белән хәрәкәткә килде. Хан калкулыктан хәрәкәттәге алайларын күзәтте. Каган да калкулыкка менеп баскан, аның айгыры әллә каян күренеп тора иде.

Беренче булып кузгалу вак мәсьәлә түгел иде. Беренче хәрәкәт дошманга төп юнәлешне ачып бирәчәк. Боерык буенча беренче булып Аспарух илхан кузгалды, әмма ашыкмады, илханның каган хәрәкәтен беләсе килә иде, күрәсең. Аспарух илханның бу мөстәкыйльлеге Кубрат ханга ошады. Шул ук вакытта ул әнә шул ашыкмавы белән ханны шиккә дә калдырды: илхан үзлегеннән һөҗүм итмәкче... Алай субашларының дикъкатен җәлеп итү өчен Кубрат хан җансакчысына Болгар әләмен күтәреп, төп алай каршына чыгарга боерды. Византия тукымасыннан тегелгән, уртасына ал-алтын-көмеш җепләр белән кояш сурәте чигелгән әләмне тотып алай алдына килеп басуга, болгарлар ур-ра! кычкыра башладылар.

— Болгарлар, алга!— дип кычкырды төп алай башындагы Балкыр илхан. Бөтен орыш кырында «ур-ра», «ур-ра!» авазы дулкын-дулкын булып яңгырады, ат тояклары тупылдаудан дала сискәнеп, тетрәнеп киткәндәй булды.

Орыш кырында ак чәчле кылганнар чайкала, елгага таба үләннәр куера, чәчәкләр күренә башлый. Иртән алайларны карап йөргәндә Кубрат хан тагын карсак төлкене күрде. Җанвар-киек аңа иялəшкән, һәрчак сөяк көтеп йөри иде, ә хәзер кан исен сизүгә, кисәк юкка чыкты. Аның каравы, баш очында козгыннар урала иде.

Менә дошман белән ике ара кыскарганнан-кыскара бара. Менә грек утын каплап килгән укчылар укка ала башладылар, күп тә үтми алар икегә аерылып киттеләр, алга сөңгечеләр чыкты, алар да икегә аерылдылар, шунда ташаткычлар куелган арбалар алгы сафка килеп басты. Күн ояларга грек уты тутырылган чүлмәкләр куелган, филтәләр кабызылган, керешләр тартылган.

Күргән сурәтне кинәт кенә ханның зиһене кабул итмәде, әмма күзләре дөрес күрә иде — хәзәрләрдә дә ташаткычлар куелган арбалар, аларның да алгы сафтагы сөңгечеләре икегә аерылып киттеләр һәм ташаткычлар куелган арбалар алгы сафка килеп басты.

«Хәзәрләрдә ташаткычлар!»— дип уйларга өлгерде генә Кубрат хан, шунда ук ике яктан да бер-берсенә чүлмәкләр оча башлады.

Хан атының тезгенен шул кадәр гайрәт белән тартты ки, аты арт аякларына басты, авызы каерылудан әрнешле кешнәп җибәрде. Ике якта да чүлмәкләр шартлый, ике якта да дөрләп ут яна. Ташаткыч арбаларына ут капты, бөтен төбәк тамугъ утыдай яна башлады. Ут капкан арбалардан өркенеп, ярсынып, кешни-кешни җигүле атлар дулашты, киемнәренә ут капкан алыплар бәгырь өзгеч итеп кычкыра-кычкыра елгага таба йөгерделәр, күбесе ауган урынында ятып калды. Кисәк булып алган бу мәхшәрдән ике як та орышны туктатып тордылар. Атларның, кешеләрнең терелəй януларын күрү, аларның йөрәк өзгеч тавышларыннан, ярдәмгә чакыруларыннан йөрәккә кан савылгандай булды.

Шул чакта каган калкулыктан чаптырып төште һәм төп алае каршына чыгып, әләмчесе янына килде, кылычын чыгарды, өзәңгесенә басып:

— Алдыр! Алга!— дип кычкырды.

Аңа каршы дәррәү төстә алае белән Балкыр илхан кузгалды. Кубрат хан да түзмәде, төп алайга таба чапты. Ханның зиһенен бер уй биләде: «Хәзәрләрдә грек уты! Хәзәрләрдә грек уты! Каян?! Базилевс сатканмы?!»

Алайга җитәрәк ул бернәрсәгә игътибар итте: грек уты белән атышкан төбәктә арбалар янып бетеп бара, төп алайлар уң яктан урап чыгып, бер-берсенә якынлашып киләләр иде инде. Менә алайлар кушылдылар да орыша башладылар. Кубрат ханны төптәнре Азак куып житте.

— Олуг хан, олуг хан, борылыгыз, борыл! Йулыш каган орышка кермәде, алаен кузгатып җибәрде дә кире калкулыкка чапты.

Чынлап та шулай икән бит, каган ак аты белән кире борылып калкулыкка менеп баскан. Кубрат хан атын чатыры куелган калкулыкка борды, ханга таба уклар оча башлаган иде инде. Ханның як-ягындагы җансакчылары аны үзләренчә саклыйлар иде. Чатырның арт ягында Кубрат ханның азмы-күпме мая алае бар. Ул аны һәм Көбер ханны соңгы мәлдә генә чыгарачак. Калкулыкка менгәч, шуны күрде Кубрат хан: Дәян алостаз белән Аспарух илхан дошманга дулкын-дулкын булып киләләр. Уклардан алалар да ике якка аерылып китеп, яңадан дошманга каршы киләләр. Кайчандыр Этиолан баба шулай орышкан.

Бар җирдә дә каты орыш бара. Хан елганың аръягына күз ташлады, карашын офыкка күчерде. Шул яктан Батбай илхан килеп җитәргә тиеш иде. Ә ул юк та юк. Кодрак илханнан хәбәрчеләр килеп тора. Җаек бәк кирмәнне ташлап киткән. Чәчкә кая? Хәбәрче берни дә белми иде, белепме әйтергә кушмаганнар?

Шул чак атын күбеккә батырып, хан янына хәбәрче килеп туктады, чабып килгән уңайга атыннан сикереп төште, куенындагы битек төргәген төптәңре Азакка сузды, тегесе үз чиратында аны ханга бирде.

— Төптәңре Азак, кызым Чәчкә Җаек бәк кулында. Ни кылыйм?

— Олуг хан, барысы да тәңре кулында. Җаек бәк кызны кулына төшерү белән бирегә юл алыр. Сабыр итик.

— Син хаклы, төптәңре Азак. Җаек бәккә башка барыр җир юк. Чәчкәне без монда килгәч тартып алырбыз.

Кубрат хан янына кече кавхан килде, тезгенен җансакчысына ташлап, баш иде.

— Олуг хан, каган ягыннан шымчы кайтты.

— Кая ул?

— Чатырда, олуг хан.

Кубрат хан атыннан төште, чатырга керде. Хәзәрләр ягыннан кайткан шымчы алып ханга баш орды.

— Йә,— диде олуг хан.— Әйт хәбәрең?

— Олуг хан, төптәңре Ирсан каган ягында.

Хан шымчы алыпны баштанаяк күздән кичерде. Күптән түгел алостаз тарафыннан каган ыстанына җибәрелгән алыпны таныды ул.

— Атың, атың ничек?

— Атым Ардаш, олуг хан.

— Йә, Ардаш,— Кубрат хан шымчы алдына хәнҗәрен ташлады.— Ялган сөйләгән хәлдә...

— Олуг хан, кыеп әйтәм, төптәңре Ирсан каган ягында, алай белән яу чыкмакчы.

Кубрат хан үрелеп хәнҗәрен алды, хәнҗәр сабын нык кысудан ханның бармак буыннары агарынып чыкты, сул яңагы тартыша башлады.

— Хакмы бу, Ардаш алып?

Алып хәнҗәрен чыгарды, бармак очына чәнечте, чәчрәп киткән канны хәнҗәр йөзенә ягып, ханга сузды.

— Олуг хан, ант эчәм, төптәңре Ирсан бер төмән алай алдына баскан иде.

— Кече кавхан, ханшаны дәш!

Шулай диде дә хан кабаланып чатырдан чыкты, артына да әйләнеп карамыйча атына таба китте.

Ханша елганың аръягында иде, хәрби киемнән, янында оста мәргәннәрдән йөз алып. Алайның йөзбашы ханшаны күз карасыдай саклый иде. Күп тә үтми ханша йөз алыбы белән чатыр янына килеп тә җитте, калкулыкка күтәрелде, атын хан аты белән янәшә туктатты.

— Ханша,— диде Кубрат хан орыш кырыннан күзен дә алмыйча.—

Яман хәбәр килде. Төптәңре Ирсан каган әләме астына баскан, орышка кермәкче. Киңәшең әйт, ни кылыйм?

Ханша аһ! итте, әмма шундук үзен кулга алды.

— Батбай углан, Батбай углан кая?!

— Ул юк, ул күренми.

— Хан, кеше сүзе кеше үтерер, ди. Кая ул шымчы алып?

— Чатырда.

Ханша атыннан төште, чатырга кереп китте. Кубрат ханның күңелендә өмет чаткысы кабынып алды. Шымчының ялганлавы да бар иде. Шымчыны каганның сатып алуы да бар иде. Андыйларны да күп күрде хан. Ханшага ул барысын да сөйләр, ялганлый алмас.

Иллә өмете акланмады, ханша җилләнеп әйләнеп тә килде.

— Төптәңрене юк иткән алыпка мең алтын, хан. Төптәңре хыянәтче!

Ханша атына атланды, орыш кырына текәлеп карады.

Төп көчләр арасында каты орыш бара иде. Төп көчне җитәкләгән Балкыр илхан чигенә башлады, хан мая алаеннан бер төмән алай җибәрде. Өстәмә көч килүгә, болгарлар рәтләрен тигезләделәр. Шул якта җанөшеткеч авазлар ишетелә, башлар киселеп оча, күкрәккә, аркага кадалган ук-сөңгеләрдән аккан кан дала кылганнарын ал төскә буйый.

Әле иртән кояш чykканда тын гына йоклап яткан дала ыңгыраша, әрнешә, сыкрый иде. Баш очында козгыннар карылдый, ала каргалар оча. Көн төшлеккә җитеп килә, берьякның да алдыра алганы юк. Кубрат хан хәзер еш кына төньякка күз ташлый, аның исәбе буенча, шул яктан камаудан котылган Кодрак илхан килергә тиеш иде. Ул инде юлдадыр, атасына ярдәмгә ашыгадыр. Ни ашыкса да Кодрак илхан тиз генә килеп җитә алмаячак, әмма ханның күз карашы барыбер шул якка тартыла иде. Кодрак илхан янында Илбарыс буйтур да бардыр. Хәзер нәкъ менә шулай булуын тели иде күңел.

Орыш кырына карый-карый хан яңак итен чәйнәде. Башында мең төрле уй бөтерелә. Хәзәрләрдә грек уты? Кем биргән, кем саткан?.. Базилевсмы? Иа тәңрем, никадәр мәкер бу базилевста! Күңелнең моңа ышанасы килми, әмма нинди мәхшәр булып алды, ике якта да меңләгән кеше кырылды. Ни өчен болай эшли базилевс?.. Бит ул Кубрат ханга патрикий титулы бирде, яклап килде, балаларын ярәштеләр, исәпләре кардәшләшергә иде.

Хан янына, атын калкулыкка җан-фәрман чаптырып, алостаз Дәянның җансакчысы килеп туктады.

— Олуг хан, алостаз Дәян ярдәм сорый!

Кубрат хан чаптырып килгән атның киңәеп киткән борын тишекләренә карады һәм шундук карашын орыш кырына күчерде.

— Синдә ничә баш алып?

— Бер баш, олуг хан!

— Алостаз Дәянга әйт, ярдәм юк диген. Чигенмәскә! Бер генә башың булса, син ханга яңадан мондый хәбәр белән килмә! Мин әйттем!

Алостаз Дәянның җансакчысы атының авызын каерып борды да камчылый-камчылый, ат тоякларыннан балчык ата-ата кире чапты. Соңгы чиктә Кубрат хан алостаз Дәянга ике төмән алай җибәрде. Ханның мая алае күзгә күренеп эри иде.

Орышның иң катысы төп алайлар төбәгендә. Кубрат хан шул төбәктән күзен дә алмады. Соңга таба Болгарның язмышы нәкъ менә шул төбәктә хәл ителә кебек тоела башлады. Кинәт бер төркем кыю хәзәр мәргәннәре төп алайны урап чыгып, чатырга таба ташландылар. Аларга каршы болгарлар кузгалды. Шунда Кубрат ханның күзләренә таныш йөз чалынып китте.

ылды.— Кече кавхан, чап Көбер ханга — вакыт!

Шулай диде дә хан атын куалый-куалый таныш йөзгә таба чапты. Юк, төптәңре, син миннән китә алмассың. Китә алмассың...

Орышларда күп катнашкан, үлем күзенә карап кылычын дошманга ...й тапкырлар күтәргән Кубрат хан орыш төбәгенә якынайган саен ...зендә нииндидер ярсыну тойды.

Яшь чакларындагы орышка чапкан мәлләрен күз алдына китерде. ...убрат ханга гүя шул чаклардагы гайрәте кайтты.

— Ур-ра! Ур-ра!

Аның тавышын чәүкәлекләр артыннан өермәдәй килеп чыккан Көбер ханның алае күтәреп алды. Кубрат ханны җансакчылары, иң оста ...әргәннәре уртага алганнар иде. Ханның ур-ра кычкырып яуга ташла...уын күргәч, болгарлар ягы алдыра башлады.

Кубрат хан берәүне дә күрмәде, берәүгә дә карамады, аның кара...ы бары тик бер кешегә — төптәңре Ирсанга текәлгән иде.

Төптәңре Ирсан Кубрат йөргән яуларның берсеннән дә калмады. Ул ...әрчак орышның иң кайнар төбәкләрендә булды. Аны чынлап та тәң...е үзе саклый кебек иде, ул орыштан һәрчак исән чыкты. Шушындый ...атырлыклары аркасында төптәңре Ирсан хан һәм алыплар алдында ...брүй казанды. Уктан ала белмәсә дә, кылыч белән оста орыша иде ...өптәңре Ирсан. Шуның өчен хан җәясен алып тормады, кылычын ...лгый-болгый төптәңре күренгән төбәккә чапты.

— Ур-ра, болгарлар, ур-ра!

Төптәңре Ирсан Кубрат хан якынайгач кына болгарларны күрде, ...абаланып, җәясенә ук эләргә итте, әмма элә алмады, ук-җәясен ...ашлап, кылычын чыгарды.

Кубрат хан атының тезгенен җибәрде.

— Һоп-һоп, әйдә, алдыр!

Ат аның телен аңлый кебек иде, кош кебек очып төптәңре Ирсанга ...кыная.

«Юк, төптәңре Ирсан, китә алмассың, китә алмассың!» — дип ка...батлады Кубрат хан. Әмма төптәңре Ирсан китәргә җыенмый иде. Ул ...а Кубрат ханга таба кузгалды, аны да җансакчылары уратып алган...ар. Кубрат хан шул хәтле ярсынды, тамагы ярылырдай итеп кычкы...ра-кычкыра гайрәт белән кылычын болгады.

Иң оста мәргәннәре, җансакчылары белән үзенә таба килүче Куб...ат ханны күргәч, төптәңре Ирсан алыпларына нидер кычкырды, алар ... алайдан аерылып, Кубрат ханга каршы кузгалдылар. Ханның ...лыплары төптәңренең сакчыларын бүлеп алдылар, ике арада орыш ...итте.

Кубрат хан селтәнүле кылычына бөтен булган гайрәт-көчен салды. ...оңгы мәлдә ул төптәңре Ирсанның нәфрәтле күзләрен күреп калды. Ирсанның кылычы ханның калканына бәрелде, тимер чыңлаудан ко...лак тонгандай булды. Кубрат хан Ирсанга батып кергән кылычын бө...тен тәне белән тойды. Ирсанның башыннан очлымы җиргә очты, тәгә...рәп китте, аты җилләнеп каган ыстанына таба элдерде. Төптәңренең ...ягы өзәңгегә эләккән һәм ул сөйрәлеп диярлек бара иде. Аның ар...тыннан кылган башлары ал чәчәккә әверелеп, кызарып кала. Кубрат ...хан тезгенен алды, кирегә борылды. Җансакчылары төптәңренең алып...ларын кысрыклап, турап бетереп баралар иде инде. Кубрат хан ча...пырына борылган чакта үзенә таба чаптырып килүче каганны күреп ...алды. Җансакчылары аны уратып алганнар, каган уртада килә иде. ...брат хан атын кире борды, җансакчылары аның тирәсенә килеп ...бастылар. Кубрат хан кылычын кынысына тыкты, җәясен алды. Башта



*Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

л каган оелә укта алышырга тели иде. Атының кабыргасына аягы елән тиеп алды, алга кузгалды. Каганның җансакчылары икегә аелдылар, болгарларны урап алырга теләделәр. Әмма болгарлар да акытында сибелеп өлгерделәр.

Шул чак Аспарух илхан төбәгендә ур-ра! тавышлары ешрак ишетеә башлады. Биредә ике якның җансакчылары үзара орышып киттеәр. Төркидә язылмаган бер закон бар иде: каган белән хан каршы илгәндә җансакчылары үзара орышалар, хан белән каганга кысылыйлар. Каган да җәясенә ук элде. Хан белән каган берсе уңгарак ып, икенчесе сулгарак каерып, бер-берсенә якыная башладылар. Шул акыт көчле дулкын булып ур-ра! тавышы ишетелде. Кубрат тавыш илгән якка хәтта әйләнеп тә карамады, бу Көбер хан төп көчкә килеп кылган булырга тиеш, хәзәрләрне кысрыклый башлаганнардыр. Кубат хан каганны бер мизгелгә дә күздән яздырмады. Менә кайчан шин ыруына нокта куячак ул. Хан ашыгыбрак керешен җибәрде, ук аганның ботына барып кадалды. Каган да укны җибәреп өлгерде, убрат хан чак кына ат өстеннән очып төшмәде, аның иңбашына калган иде каганның угы. Укны ул шундук суырып алды һәм җәясенә лмәкче итте, әмма өлгерә алмады, кисәк күз аллары караңгыланып итте, ял өстенә капланды. Каган икенче угын ханга җибәрергә матаа иде, тик өлгерми калды, ханның ат ялы өстенә каплануын күргән нсакчылары аңа ук яңгыры сиптеләр. Укларның берсе каганның ына тиде. Аты куркынып, чабып китте. Алай да каган керешен җибәергә өлгерде, каганның угы кылганнар арасына килеп төште. Каганың аты ыстанына таба чаба башлауга, җансакчылары төрлесе-төрле кка сибелделәр. Болгарлар куа бармадылар. Кубрат ханның ат тезенен берәүсе алды, икенчесе ханны тотты һәм аны чатырына алып айттылар. Сак кына атыннан төшерделәр, чатырга алып кереп, түшәккә салдылар.

Көче кавхан Аппак артыннан чапты. Аппак килеп тә җитте. Атыннан төште, агарынып чатырга килеп керде.

— Кубрат!

Хан күзләрен ачты, кулындагы укны ханшага бирде.

— Табибка бир, тикшерсен, агулы түгелме...

Чатырга грек табибы чакыртылды. Ул ханша кулындагы укка күз дә салмыйча яралы янына узды, җансакчыларга ханның көбәсен, күлмәкләрен салдырырга кушты. Яра тирән түгел иде. Грек яраны ниндидер сыекча белән юды, ханның башын күтәреп, бер җам эчемлек бирярага яфрак каплады, аннары чатырдан барысына да чыгарга куш-. Чатыр эчендә ук торган ханша һәм грек табибы гына калды. Хан әкрен генә күзләрен ачты.

— Ук агулымы, табиб?— диде ул һәм авыртудан йөзе үзгәреп китте.

Табиб укны кулына алды, тимер очын теленә тигезде, аннары ханша колагына якын килебрәк:

— Ханша, ук агулы,— диде.

Грекның гаҗәпләнүенә каршы, ханша аңа:

— Кулыңнан килгәнне барысын да эшлә, табиб,— диде.

Ханшаның салкын канлылыгына гаҗәпләнеп, табиб эшкә кереште. Ханның ярасы зур түгел иде, көбә күлмәк саклаган, әмма ук агулы булу сәбәпле, хан әкрен генә сүнә барган шикелле тоелды. Ханша ул һәр даим орыш барышы турында сорашты. Табиб аңа җам бе эчемлек бирә торды.

Ханша грекtан:

— Ни эчерәсең син аңа?— дип сорады.

— Боспордан килгән «Кара доктор» эчемлеге, ханша.

— Эчемлек ханга ярдәм итәрме, табиб?

— Итәр, ханша. Заманында Александр Македонский бу эчемлекне яралы алыпларына эчерткән, яраларына каплаган. Бу эчемлектә мең шифа бар, ханша. Ләкин ук агулы булган. Ханның гомерен саклап калып булмастыр...

Ханша өнәми генә табибка карап алды һәм болгарларның алимчесен, төптәңре Азакны чакырырга кушты. Күп тә үтми, алимче белән төптәңре Азак килеп керделәр, ханша алимчегә белгәнен эшләргә ишарә ясады. Иң әүвәл алимче чатыр эченнән шайтаннарны куарга кереште. Ул чылбырлы җамга нефть, май, балавыз, тагын әллә нинди үлән төнәтмәләре салды һәм аңа ут алып, авыз эченнән генә тәңредән ханга озын гомер, ярасы тизрәк төзәлүен тели-тели уты янып торган җамны уңлы-суллы селки-селки хан тирәли йөри башлады. Табиб аңа карап торды-торды да чатырдан чыгып китте.

## 29

Биленә атасы Кубрат хан биргән алтын тәңкәләр һәм төрле сурәтләр төшерелгән, көмеш әйберләр белән бизәлгән пута буып алгач, Балкыр илхан күк-кояшка карап тәңрегә гыйбадәт кылды. Илхан янында басып торган уң кулы аңа:

— Илхан, олуг хан сиңа төп алаен ышанып бирде, хәзәрләрне куйгач, тәңре сиңа куәте белән бергә тәхетен дә бирер,— диде.

— Барысы да тәңре кулында, Тимер. Син минем уң кулым. Каганны Биләмҗирдән кусак, мин сине анда тархан итәрмен. Күзең төшкән Җаек бәк кызына үзем яучы булып барырмын.

Уң кулы Тимер елмаеп куйды, бил путасын рәтләде, ук-җәясенә кагылып алды.

— Барысы да тәңре кулында, илхан, бәк кызы Таңбикә дә, тархан булу да. Онытма, илхан, вәгъдәң!

Орыш башланыр алдыннан гына шулай дигән иде Балкыр илхан, әмма орыш башланды, бер дә алга бара алганнары юк, киресенчә, акрын гына төш авыгы [1] житүгә, хәзәрләр алдыра башлады. Орышка Көбер хан да әллә ни үзгәреш кертмәде, каган да кайдандыр өстәмә алайлар чыгара тора. Әмма Көбер хан бер өлеш алаен Аспарух илханга җибәргән икән, аннан урра тавышлары ешрак, куәтлерәк ишетелә башлады. Шулмы куәт бирде болгарларга, төш авыгы узуга, болгарлар хәзәрләрне кысырыклап, һөҗүмгә күчтеләр. Шул чакта Кубрат ханның җансакчысы Балкыр илханны алырга килде.

— Атаң яраланды, илхан.

Балкыр илхан алаен уң кулына биреп, үзе чатырга чапты. Атыннан сикереп төште дә тезгенен җансакчыларына ташлап, атылып чатырга керде.

— Атам!

Кубрат хан терсәгенә таянып күтәрелде, Балкыр угланның дала тузаны кунган иңенә кагылып алды.

— Балкыр углан, Батбай абаң һаман килеп җитми. Мине тәңре үз янына алса, үч ал син аңардан. Мая алаем ананда булыр, бик авырга килсә, сорап ал. Мин әйттем.

Балкыр илхан атасының кулыннан үпте, битен-биткә куеп алды. Аннары чатырдан чыкты да сикереп атына атланды һәм, җансакчылар-

[1] Төш авыгы — төш вакыты.

ны иартеп, үзе орышкан төбәккә чапты. Биредә хәзәрләр болгарларның сафларын ертканнар, урап алып киләләр иде инде. Балкыр илхан килүгә шапкә болгар сафларын ертып чыккан хәзәр йөзбашының башын чабып төшерде. Йөзбашның очлымы җиргә тәгәрәде һәм утырып калды, әйтерсең йөзбашны сугып җиргә индергәннәр иде. Балкыр илхан килүгә, болгарлар сафларын тигезләделәр. Әле генә болгарлар чигенә-чигенә орышалар иде, хәзер хәзәрләр шул язмышка калды. Ханша Балкыр илхан артыннан ук аңа бер йөзбашны җибәргән икән, алар килүгә, Балкыр илхан хәзәрләрнең сафларын таратуга иреште. Аспарух илхан да хәзәрләрне уратып, кыйнап ята иде. Шунда бер җансакчысы Балкыр илханга кычкырды:

— Балкыр илхан! Сул яктан җансакчылары белән каган килә!

Балкыр илхан атын каган ягына борды, аңа хан маясыннан килгән йөзбаш иярде. Балкыр илханның очып диярлек үзенә таба килүен күреп, каган атын тыя төште.

— Минем арттан, ур-ра!— дип кычкырды Балкыр илхан.

Каган Балкыр илхан белән орышырга теләмәде, ул аңа каршы иң оста мәргәннәрен җибәрде. Балкыр илханның атына сөңге белән кададылар, аты кисәк сөрлегеп китте, илхан ат өстеннән сикереп төште, җиргә тезләнде, җәя керешен тартты. Аңа таба кылычын болгый-болгый килүче алып, кукрәгенә ук кадалуга, бер якка авып төште, икенчесен дә шундый ук язмыш көткән икән — анысы атыннан ук төшеп калды. Балкыр илхан хәзәрнең атына сикереп атланды, бу алышны җансакчылары арасында туктап карап торучы каганга таба чапты.

— Йулыш каган! Мин синең белән алышырга телим! Каган!

Ишетәләрме аны, ишетмиләрме — эш анда түгел иде. Балкыр илхан йөрәге белән кычкырды. Ул каганнан атасы өчен үч алырга тиеш! Балкырның колак яныннан гына ике-өч ук сызгырып үтте, ул һаман атын каганга таба куалады. Әмма аны каганга җибәрмәделәр, хәзәрләрнең төп алаен җитәкләгән бәк аның юлына аркылы төште. Янә каты орыш башланды.

## 30

Йулыш каган калкулыктан орыш барышын күзәтте. Ботына тигән укярасы сызлап-сызлап китә. Орыш барышы шуны күрсәтә: болгарларны җиңеп булмастыр. Күбер ханның орышка килмим дип әйтүе, ә үзенең Кубрат хан ягына басуы һәм көтмәгәндә килеп чыгуы, каганның алдан уйланган фаразларын сүтеп, чуалтып ташлады. Аспарух илхан уң канатны камап, таратып ята. Каганның уң кулы, ышанычы, өмете — Җаек бәк һаман юк. Хан кызын алып килә дигән хәбәренә ике көн булды инде, ә бәк юк та юк. Хан кызы кулына төшкәч, Йулыш каган нишләргә белер иде. Көтеп-көтеп тә Җаек күренмәгәч, Йулыш каган аңа каршы Сөләй меңбашны җибәрде. Күптән түгел генә каган ыстанына ояланган Сөләй бәк тә суга чумды, ни хәбәрчесе, ни үзе юк. Орыш кыры кайнап торганда уң кулы янында булмавы Йулыш каганның тәмам канын бозды. Җаек бәк белән Кубрат ханның кызы Чәчкә кирәк иде каганга. Югыйсә соң булып куюы бар, хәзәрләр төрле яклап чигенә башладылар. Каганда мая алай калмады. Соңгы сулышы иде хәзәрләрнең. Моны каган да күрә, әмма чатырын җыйдыртмый, кузгалмый, нидер көтә, нидер өмет итә.

Шул чак офык читендә сөңге очлары күренде. Боты сызлавын да сизмичә, Йулыш каган өзәңгесенә басты. Каганга таба шул яктан атчабар килә иде. Аның аты сөлектәй сузылып чаба, корсак астыннан уч-уч күбекләр очып кала.

— Бу Җаек бәк,— диде каган янәшәсендә баскан Әбүзәр бәккә.— Чап Җаек бәккә каршы, килер җайдан хан угланы Аспарухка ташлансын. Анда хәзәрләр кача башладылар.

Әбүзәр бәк атын камчылый-камчылый сөңге очлары күренгән якка чапты. Күп тә үтмәде, каган басып торган калкулыкка чаптырып, Сөләй бәк килеп җитте. Бәкнең айгыры еш-еш сулыш ала, яңаклары тирләүдән ялтырап калган иде.

— Ай-кояшка тиң каган, кыеп әйтергә җөрьәт итәм: Җаек бәкне Кубрат хан угланы Кодрак тар-мар иткән. Килүчеләр Җаек бәк алае түгел, Кодрак илхан алае — болгарлар, угорлар!

Каган камчысы белән Сөләй бәккә кизәнде. Атыннан төшеп, каган алдына тезләнгән Сөләй бәк торып басты, ияген чөя төшеп, каганга карады. Тазалыгы, пәһлеванлыгы белән күпләрнең котын алган, икәүдән-икәү генә калганда каганның үзен дә шомга салгалаган бәк каганнан курыкмавын сиздереп, хәнҗәренә кулын салды.

Йулыш каган янәшәсенә аты белән килеп туктаган, ат өстендә көчкә утырса да, көч-кодрәте кимемәгән Үрәгәй төптәңрегә карады, күзләре белән киңәш сорады.

— Сөләй бәкне алае белән Балкыр илханга каршы җибәр, каган. Кояш баеганчы болгарларны тоткарларга кирәк. Кояш баегач, орыш тукталыр, сиздерми генә күчеп китәрбез.

— Сөләй бәк!— дип кычкырды каган, гайрәтен күрсәтер өчен камчысын җиргә ташлады, аты өркеп китеп, ыргылып куйды, каган атын тыйды.— Сөләй бәк, Балкыр илханның язмышы синең кулда. Башын китерәсең икән, урының уң кулымда булыр!

Чынында исә бер дә алай әйтергә теләмәгән иде каган, чигенергә, чатырын җыярга җыенган иде. Кодрак илханның алае якынаеп килә, болгарлар аларны күреп тә алдылар бугай инде. Карт Үрәгәй төптәңрегә каршы килә алмады каган. Ул — төптәңре, аңа күренәрәк төшә, Үрәгәй тәңренең үзе белән киңәшеп эш итә. Каганның тәмам зиһене чуалды, яралы боты оеп-оеп киткәндәй итә башлады. Орыштан исән-имин кайталар икән, каганны зур сынау көтәчәк. Тагын ничә ел каганлык итәсең дип, Үрәгәй төптәңре аны ефәк бау белән будырып караячак. Әйтер ике ел дип, ике елдан аның башын чабып өзәрләр, әйтер йөз ел дип, йөз ел яшәмәс. Шулай ук өч ай дип тә әйтүе бар иде. Ефәк бау белән буганда, Үрәгәй төптәңре уенча, бары тик тәңре теләгәнне генә әйтәсең.

Кансыз, шәфкатьсез Үрәгәй бу гореф-гадәтне бабаларына сылтый, әмма аны үзе генә уйлап тапкан иде.

Йулыш каганның карашы Аспарух илхан ягында сибелеп-таралып кача башлаган хәзәрләргә төште. Һәм кылычын чыгарып:

— Анда, анда безнең урын, алыпларым!— диде дә атын чаптырып шул якка китте. Аңа каганның чатыр янында калган актык мая алае иярде.

## 31

Эске кирмәнгә ярты көнлек юл калгач, Илбарыс буйтур елга буена туктап, атын эчерде, үләнгә ашарга җибәрде. Буйтур су буена төште, тын гына аккан елга аның йөз сурәтен күрсәтте. Буйтурга судан үзе түгел, ят бер кеше карап тора кебек тоелды. Балачактагы суга карап, андагы сурәтләренә тамаша кылып, уйнаган чаклары исенә төште. Бер кайгысыз чаклары бар иде, дөньяга мәңгегә килгән кебек йөргән чаклары. Чәчкә гел аның уенда булды. Гамьсез уйнап үстеләр. Юксыну, бер-

берсеннән башка яши алмау аларга шактый соңгарып килде, әмма шундый иттереп килде ки, мәхәббәт уты булып кабынды. Алар бер-берсен яраталар. Илбарыс Чәчкәне табар, аңа тәңре үзе ярдәм итәр.

Шул чак яр өстендәге аты кешнәп җибәрде. Илбарыс йөгереп яр башына менде, атына атланды. Аңа таба җилле генә юырттырып хәзәр алыплары килә иде. Өчәүләр. Курыкмыйлар. Нигә куркырга? Алар өчәү, ә ул берүзе.

Илбарыс буйтур җәясен алды, ук элде. Шик юк, аңа таба килүчеләр Җаек бәк албагучылары иде. Буйтур атын яр буйлап куалап алып китте. Хәзәр җайдаклары аны куа башладылар. Алда куаклар күренде, буйтур куаклар артына чумды. Хәзәр алыплары аны урап алырга иттеләр, икегә аерылдылар, берсе каршы китте, икесе артыннан төште. Илбарыс каршы килүчене сайлады. Башта ул атын юырттырып кына барды. Мәгәр хәзәргә якынлаша башлауга, тезгенен җибәрде, атының кабыргасына үкчәсе белән төртеп алды. Ат кушаяклап чаптырып китте. Хәзәр аңа алданрак атты, әмма буйтур читкә тайпылып өлгерде. Хәзәр ук савытына үрелде, шул мизгелдә аның битенә буйтурның угы кадалды. Буйтур атын кисәк борды да артыннан бастырып килгән хәзәрләргә каршы китте. Хәзәрләр аның ни теләвен сизүдән битәр, орыш тәртибен саклап, икегә аерылдылар. Буйтур уңдагысын сайлады. Хәзәргә житәрәк ул кисәк берьякка авышты һәм икенче якка авышканда уктан алды. Хәзәрнең аты мәтәлеп китте, алып аттан сикереп төште, йөгереп барды, шунда аны буйтур куып җитте. Хәзәр кулын күтәрде, буйтур аның тәненә кылычының батып керүен аермачык тойды. Шул мәлдә аның аты бер якка ауды, өченче хәзәрнең угы ат корсагына тигән иде. Буйтур өзәңгедән аягын ычкындырып, берьякка тәгәрәде. Хәзер аны әсир итәргә теләде, күрәсең, арканын ыргытырга җыенды, әмма буйтур аңа ханҗәр ташлады. Ханҗәр алыпның аркан ыргытырга селтәнгән кулына барып тиде. Хәзәр тиз генә атын борды һәм кача башлады. Буйтур үлеп яткан хәзәр янына килде, кулларыннан ат тезгенен ычкындырды, сикереп хәзәр алыбының атына атланды. Әмма качкын алып ерак иде инде. Буйтур үлеп яткан хәзәр алыбы янына кабат килде, атыннан төшми генә аның ук савытын тартып алды.

Эске кирмәнгә юл ябык иде. Кирмән тирәсен хәзәр албагучылары карыйлар. Хәзер качкын алып ыстанга кайтып житәр, түбән болында булган хәлне сөйләр, бирегә таба йөзбаш үзе килер.

Буйтур чама белән Угорлар иленең кай тарафта булуын белә иде. Шунда юл тотты. Ул Угор князе каршына барыр да баш орып алай сорар һәм кирмәнне камаган Җаек бәк белән орышырга килер.

Көннең икенче яртысында гына буйтур Угорлар ыстанына житте. Ыстан күренүгә, кай тарафтандыр килеп чыккан угор алыплары аны уратып алдылар, туры князь сарае каршына алып киттеләр.

Күрде дә болдыр баскычларыннан төшеп килүче князь белән мәргән Ташбулатны буйтур, үз күзләренә үзе ышанмады. Мәргәне җилкәгә киңәеп киткән, киемнәре дә кызыгырлык иде.

Князь һәм мәргән аның белән кочаклашып күрештеләр.

— Ишеттек, ишеттек,— диде князь табын янына утырышкач.— Җаек бәк Эске кирмәнне камауда тота икән, хан кызы кирмәндә икән.

— Олуг князь, Җаек бәк Эске кирмәнне генә алып калмас, бире килер, ыстаның яндырыр, хатын-кызларыгызны кол итәр, ыруың тар-мар итәр. Олуг князь, бир миңа кече князең Ташбулатны, коткарыйк Эске кирмән халкын.

Князь тамак кырды, алдындагы чокырны кулына алды.

— Буйтур, угор алайга бай түгел. Җыя-җыя туплап та утыз төмән алай җыелмастыр. Заманында болгарларга каршы мин егерме төмән алай белән чыккан идем... Болгарлар алдырды. Минә ничә ел инде без килештә яшибез, Эске кирмәндә минем сәүдәгәрләрем дә бар, күчеп ки-

түчеләр дә шактый. Корал аз бездә, буйтур. Рось корал сатмый башлады, үзе кораллана. Болгарлар аз китерә.

— Эске кирмәнне хәзәрләр алса, килгәне дә килми башлар, олуг князь. Йулыш каганда алтмыш мең алай. Бире килсә ул Угорны җир белән тигезләр. Җаек бәк Эске кирмән янында ятып калса, каганның уң канаты сынар — Болгар алдырыр. Маныч елгасы буенда хәзәр белән болгар алышачак. Алышалардыр да инде. Эске кирмәнне Җаек бәк алса, аның нияте бер: каганга ярдәмгә бару.

— Булды, буйтур, булды. Әйтер сүзең аңладым. Минем соңгы җавабым иртәгә булыр.— Князь киявенә таба борылды.— Кияү, Аршак багатырга әйт, иртән-иртүк сарайга килсен.

Икенче көнне иртән, яңа туган көнне каршы алуга, кала читенә бер төмән алай килеп туктады. Алай башында олуг князьнең кияве Ташбулат иде.

Олуг князь аларны капкадан чыгарып, озатып җибәрде.

— Багатырларым,— диде ул кам таягын күтәреп.— Кардәшләребез болгарларның Эске кирмәннәре камауда. Йолып алып калыгыз кирмәнне. Мин ышанам сезгә, багатырларым, ак юл теләп калам!

Угор алыпларының күбесе сөңге белән коралланган, беришесендә чукмарбашлы күсәк, кайсыларында чылбырга бәйләнгән керпе тимер. Калканнары тактадан, очлым урынына куян бүрек. Мәгәр алгы сафта мәргән Ташбулат өйрәткән багатырлар. Алар болгар кебек ук коралланганнар: барысында да тимер калкан, кылыч, сызгыра торган уклар, көбә кигәннәре дә бар, башларында болгар очлымнары.

— Алгы сафтагы багатырларың күркәм, Ташбулат,— диде буйтур кузгалып китүгә.

— Алгы сафтагы багатырларның күбесе минем якташлар, буйтур.

Көнозын бардылар, бары тик кичкә таба гына Эске кирмәнгә җиттеләр. Әмма якын килергә кыймадылар, албагарлар җибәрергә булдылар.

Күп тә үтми албагарлар әйләнеп килделәр.

— Буйтур, кирмән тирәсендә җан иясе юк, кирмән гел ташлап киткән кебек.

— Атларга! Юыртып кузгалдык!

Капка янына килеп җиттеләр, каравылбаш буйтурны таныды булса кирәк, аскы күперләрне төшерергә боерды. Илбарыс буйтур беренче булып асма күперне үтте. Буйтур каравылбаш янына житүгә атыннан төште.

— Каравылбаш, атың ничек?

— Атым Артык, буйтур.

— Артык, хан кызы Чәчкә белән Кодрак илхан кайда?

— Буйтур, Җаек бәк кирмәнне ала башлагач, хан кызы Чәчкә үзе теләп бәк ягына чыкты. Кубрат ханнан хәбәр килү белән Кодрак илхан аны куа чыкты.

— Хан кызы үзе чыктымы?

— Хан кызын кем мәҗбүр итә ала, буйтур...

Буйтур сикереп атына менде:

— Каравылбаш, безгә юл күрсәтүче бир.

— Баш өсте, буйтур,— диде каравылбаш һәм алыпларның берсенә кычкырды.— Сарбай, буйтурга юл күрсәтүче итеп билгеләнәсең.

Юл күрсәтүче алып алар янына килеп тә туктады. Аның аты кечкенә, кызгылт-сары төстә, корсак астыннан озын булып йоннар салынган.

— Бу ат белән ерак бара алырсыңмы, юлчы?

— Минем атым арымый, буйтур. Кояш аты арымый. Бу атны мин кояшчыгышта яшәгән төркиләрдән сатып алдым.

— Атларга, юыртып!— дип боерды буйтур.

Көнозын бардылар. Бары тик кояш баегач кына юл читендәге инеш буена туктап ял итәргә булдылар... Атларын чирәмгә җибәрделәр, иллә буйтурның озак юанасы килми иде, тагын кузгалдылар.

Икенче көнне кичкенә бер елга буена алдан киткән албагучылар күренде. Алар чаптырып кире киләләр иде.

— Буйтур, кече князь!— диде килеп туктауга албагучы башы.— Җаек бәк елганың аръягында Кодрак илхан белән орыша!

— Атларга! Минем арттан!

Елганың аръягындагы болынлыкта орыш шактый барган иде инде. Кая карама — үлгән атлар, кешеләр тәгәрәп ята. Елга кичеп чыккан алайны күреп, болгарларны елгага таба кысырыклый башлаган хәзәрләр каушап калдылар. Бу көчне Кубрат ханның төп көче дип аңлаулары идеме, хәзәрләр кайсы-кая сибелеп кача башладылар. Буйтурның күзенә әрәмәлек буендагы ике көпчәкле, япмалы арба ташланды. Зиһененә килгән беренче уе: «Арбада Чәчкә!» Буйтур шунда чапты, аңа уннап алып иярде. Хәзәрләр кайсы-кая таралып, сибелеп тәртипсез рәвештә качалар иде: моны күреп, Җаек бәк бер төркем җансакчылары белән елга буйлап элдерде. Буйтур атын куалады, аннары сулгарак алды, качучыларга аркылы төшәргә исәпләде. Ара бермә-бер кыскарды, як-яктан уклар очты. Угор алыплары буйтурдан чак кына калыша төшеп чабалар. Буйтур җәясенә ук элде. Иң башлап арба атына атланган алыпны укка алды. Алып, ук тиюгә, ат өстеннән очып төште, арба ауды, арбадан тәгәрәп төшкән берәүне Җаек бәк элеп алды, ияренә аркылы салды. Шик юк, иярдәге хатын-кыз хан кызы Чәчкә иде. Буйтур тезгенен җибәрде.

— Һоп, һоп, малкай!

Җаек бәкне ике яктан да җансакчылары уратып алганнар. Бәк ышыкта, бәкне укка алу мөмкин түгел иде. Буйтур берәм-берәм дүрт алыпны уктан атып төшерде. Аның белән рәттән диярлек чаба башлаучы ике угор алыбы ятып калдылар. Елга буенда каты орыш бара иде. Җаек бәкнең калган көчләрен кадыйлар, чәнчәләр, кылыч белән турыйлар. Буйтурның ике ягында ике угор алыбы калды. Менә угорларның берсе Җаек бәкнең бер мәргәнен укка алды һәм куанычтан кычкырып ук җибәрде. Җаек бәк янында бары тик ике алып калды. Шунда бер угор алыбының атына ук тиде. Ул да артта калды. Алда Әтил елгасы күренде. Җаек бәк елга читләп чаба. Аръякка чыгарга кичү эзлиме?.. Буйтур җәясенә ук артыннан ук элде, әмма уклар тими башлады. Нидән булыр? Әллә соң Чәчкәнең җилфердәгән күлмәк итәкләре, сибелеп төшкән чәчләре каушатамы?.. Буйтурның нибары ике угы калды: берсе — Җаек бәккә, икенчесе — артыгы белән кыюланып киткән бәкнең җансакчысына. Шул чак угор мәргәне тагын бер хәзәрне укка алды, мәргән икенче мәлдә үзе атыннан егылып калды — аты сөрлектеме, ук тидеме? Буйтур әйләнеп карамады. Ул угор алыбын укка алган хәзәрнең атына тигезде, ат сөрлегеп китте, әмма елгыр алып сикереп өлгерде, ат астында калмады. Буйтур җәясен иңе аша ташлады, кылычын суырып алды. Ул хәзәргә җан ачуы белән чапты, хәзәрнең тавышына хәтта Җаек бәк тә әйләнеп карады. Һәм ул буйтурны таныды булса кирәк, атын тагын да куалый башлады.

Буйтур җәясенә ук элде, хәзәр алыбы да җәясенә ук эләргә матала, өлгерә алмады, маңгаена ук кадалды. Җаек бәк янында бары тик бер җансакчысы калды, иллә ул кисәк бер читкә борылды һәм әрәмәлеккә [illegible] аркасына соңгы укны буйтур төзәмичә

диярлек атты. Җаек бәк муенына аркан ташлагандай кинәт артка тар-тылып куйды. Шулчак буйтурның иңбашына нидер килеп бәрелде. Буй-тур атыннан очып төште, әрем куакларына битен, йөзен сыдырды, анна-ры шундук аңын җуйды. Җиргә бәрелүен дә сизмәде ул, аңына килгән-дә, ахыргача бергә орышкан угор алыбы хан кызы Чәчкәне күтәреп аңа таба килә иде инде. Чәчкәнең күкрәгендә — энҗеләр белән бизәлгән хәнҗәр сабы. Җаек бәк эше!.. Буйтур торды, алып кулыннан Чәчкәне алды. Ул бернинди дә авырту тоймады. Чәчкәне кулына тоткан килеш бөтен болын буйлап хәзәрләрне кырып килүче Кодрак илханга юнәлде. Аның күзләреннән бертуктаусыз яшь ага. Йөрәге дә сыкрап елый иде.

— Нишләттеләр, нишләттеләр сине, Чәчкәм, нишләттеләр?! Чәчкә, Чәчкә....— дип кабатлады ул ни әйтергә, ни кылырга белми. Кодрак ил-хан атыннан төшкән, аңа таба йөгерә иде инде.

Илхан килеп җитте дә Илбарыс кулыннан сеңлесен алды, беравык күзләренә карап торды, аннары чирәмгә салды, энҗеләр тезеп ясалган хәнҗәрне Чәчкәнең күкрәгеннән тартып чыгарды. Шулчак җан биргән кыз сискәнеп киткәндәй булды, хәтта нидер әйткән кебек тоелды. Код-рак илхан сеңлесенең бит-маңгаеннан үпте, чәчләрен сыйпаштырды. Ан-нары ул кисәк торды да әсир төшкән, куллары бер-берсенә аркан белә[н] бәйләнгән хәзәрләр ягына карап торды. Нидер уйлап, илхан кылычын чыгарды һәм аңа озак кына карап торгач, коралын елгага ташлады. Чәч-кә янына килде, сеңлесен кулларына күтәрде дә арбага салды. Янәшә-сендә башын иеп басып торган буйтурга:

— Боер, буйтур, кузгалырга!— диде.

— Атларга!— дип боерды буйтур.— Үлгәннәрне күмү өчен һәр йөз-баштан ун алып кала. Кузгалырга!

Уң кулы Камай буйтурның атын китерде, күк кашкасы иясен таны-ды, буйтурның иңбашын тешләп алгандай итте. Илбарыс атның ял асты-на кулын тыкты, иркәләде. Аннан атланырга итте, әмма чак кына егы-лып китмәде.

— Син яралы, буйтур?

Буйтур бернинди дә авырту тоймады, иңбашыннан кан саркып чык-кан, кул-бармакларыннан кан тама иде. Икенче омтылуда ул атына ат-ланды. Янә бернинди дә авырту тоймады, үз тәнендәге яра сөйгәне[н] югалту янында юк кына нәрсә булып калган иде.

## 32

Биләмҗирдән алып кайткан мәгълүматларны түкми-чәчми сөйлә[п] биргәч, Кубрат хан бик озак хәзәрләрнең алай саны турында сорашт[ы]. Шунда аңа философ: «Дошман никадәр көчле булса, җиңүченең дан[ы] шулкадәр зур булыр»,— дигән иде. Кубрат хан ул вакытта философ[ы] белән килешмәде. Нигә дан, мине болай да халкым ярата, дигән ид[е]. Хәзер ул аның белән килешә, шул турыда философка сүз кушарга тел[и], әмма сүзен әйтә алмый тора.

Чатырга йомышчы килеп керде, күзләрен зур ачып:

— Олуг хан, сөенче, Кодрак илхан килде!— диде.

Кубрат хан торасы итте, әмма ымсыну гына килеп чыкты, башы д[а] күтәрелмәде.

— Җи-и-нү!

Кем әйтте моны? Ханмы? Юк, тышта кычкыралар.

Чатырга кече кавхан керде.

— Олуг хан, каган чатырын да алмыйча кача башлады, болгарл[а] куа киттеләр.

Бу орыш тарих алты йөздә кырык икенче елда булды.

Агулы уктан җиңелчә генә яраланган Кубрат хан чатырында ят

аның ярасын Рум табибе шәмәхә төстәге җимеш суы белән юып тора, аннары кечкенә алтын җам белән эчәргә бирә. Кубрат хан һәр мизгел өчен тартышты. Кайчак аның хәле бөтенләй аруланып киткәндәй булды, хан сөйләшә башлады, сорашты. Хәзер дә ул, бер җам эчемлек тәнәтмә биргәч, хәле аруланыуын тойды һәм карашы белән үзенә кирәк кешене эзли башлады. Карашы аның янә философта тукталды.

— Иоанн Фасиан,— диде көч-хәл белән хан.— Иоанн Фасиан, император...

Ни әйтергә теләде Иоанн Фасианга хан — берәү дә белә алмады. Кубрат хан кисәк хәлсезләнеп китте, табиб аңа сөйләшмәскә кушты. Мәгәр хан ишетә, философтан сүз көтә иде.

— Олуг хан, олуг хан,— диде философ ашыга төшебрәк.— Император Ираклий Карду шәһресендә сарациннар белән орышта һәлак була. Тәхеткә угланы Юстиниан утырган...

Кубрат хан философның сүзләрен аңлавын төшендерергә теләп күзләрен йомып ачты. Хан кисәк торырга итте, ләкин тора алмады.

Чатырга алостаз Дәян килеп керде.

— Олуг хан, Фанәгүрдә грек утын ясаучы Симай атаны үтергәннәр...

Хан көтмәгәндә терсәгенә таянды, сөзеп алостаз Дәянга карады.

— Дала безнеке, олуг хан! Безнеке!— Алостаз Дәян ханшага таба борылды.— Ханша, орыш кырында кискен борылыш бара, алыгыз кулыгызга хан әләмен, күренегез алыпларга!

Ханша әле Кубрат ханга, әле чатырдагыларга күз йөртеп чыкты, аннары кырт борылды да чатырдан чыгып китте.

Бу вакытта орыш кырында чынлап та кискен борылыш бара иде, хәзәрләр урап-урап, кила-кайта орышсалар да, чигенәләр, качалар.

Ханша бик вакытлы килеп чыкты. Тугрыхан кызының атта утыруына шаккатмалы иде. Ханша артыннан Кубрат ханның җансакчылары, чатыр тирәсендәге кавханнар, төптәңре Азак чабалар. Ханша кулында Болгар әләме, муенына ураган ефәк шарфы җилферди. Бу хәлне күреп, каганның соңгы алыплары кача, орышырга калган бәкләре дә төрлесегөрле якка сибелә башладылар.

— Ур-ра!

Кача башлаган дошманны укка алу җиңел иде, әмма кич җитеп кояш баеп бара. Көнозын орышкан болгарлар, хәзәрләрне ерак куып тормастан, кире борылдылар.

Алтмыш мең алай белән орышка килгән каган Маныч елгасы буенда кырык мең алыбын калдырып, качып китте. Бу тиңе булмаган орышта ике яктан да шул хәтле күп халык кырылган иде ки, орыштан исән калган болгарлар үз мәетләрен генә дә атнага якын күмделәр. Җиңеп җиңелгән иде Болгар бу орышта.

## 33

Төн буена йокламадылар. Орыш кырында яралылар ыңгырашты, кемнедер ярдәмгә чакырдылар, кемдер исемнәре белән якыннарын дәшгә. Якын тирәдә бүреләр, шакаллар улады. Аякларында көчкә басып торган алыплар, иртән кояш чыгуга, көнчыгышка карап тезләнделәр. Тәңрегә исән калуларына дога кылдылар, киләсе көннең матур булуын теләделәр.

Ханша Аппак та тәңредән иң зур теләген — Кубрат ханга гомер сорады:

— Йа, тәңрем!— Син — әҗунда, мин — җирдә. Калдыр, тәңрем, Кубратым янымда, алма җанын, бир гомер... Йа, тәңрем!..

Иртә белән, бер тәңре белә, каяндыр чатыр янына ап-ак тай килеп туктады. Җанын кая куярга белмәгән ханша чатырдан чыкты һәм каршында ап-ак тайны күреп таң калды.

— Тәңре корбан җибәргән, тәңре корбан җибәргән! Тотыгыз, тот! Изге, изге җан Кубрат хан! Изге җан! Тотыгыз тайны, тотыгыз!..

Тайны шундук тотып ханшага китерделәр. Ханша тайны ак киезгә салып чалырга кушты.

Ап-ак киез китерделәр, аякларын бәйләмичә тайны ак киезгә ектылар. Дүрт кеше тайның дүрт аягыннан тотты. Төптәңре Азакка пычак китерделәр.

— Тәңрем,— диде төптәңре Азак.— Калдыр Кубрат ханның җанын, без сиңа ап-ак, саф-пакь җан бирәбез. Аның җаны итеп кабул ит, тәңрем, кабул ит, тәңрем...

Төптәңре Азак кулларын күккә күтәргән, тәңредән ханның җанын калдыруын сорый, аңа ияреп бөтен дала тулы алай тәңредән хан җанын саклауны сорый иде.

Теләкләре кабул булды: тәңре кабул итте тай җанын, Кубрат хан күзләрен ачты, үз теле белән ханшаны чакыртты.

— Синең исәнлеккә корбан чалдык, Кубрат. Тәңре колак салды, син сөйләшә башладың, син яңадан безнең янга кайттың...

— Мин үләм, ханша,— диде олуг хан. Кубрат хан чатырдагыларга күз йөртеп чыкты.— Ханша, Чәчкә кызыбыз кая?

— Ул тиздән кайтып җитәр, хан.

Кубрат хан карашын Кодрак илханда туктатты.

— Кодрак улым, сеңлең Чәчкә кая, минем аны күреп үләсем килә...

Кубрат хан көчкә сөйли, менә-менә телдән калыр кебек, ул моны үзе дә сизә, әйтер сүзен әйтеп калырга тели иде.

Кодрак илхан әле үзеннән җавап көткән атасына, әле анасына карады. Кубрат хан кузгалмакчы итте.

— Атам, Чәчкә сеңлем...— диде Кодрак илхан һәм теле аңкавына ябышкандай туктап калды.

— Ул исән, Кубрат, кызыбыз исән. Ул җигүле атта кайта,— дип илхан сүзен элеп алды ханша.

Хан тынычлангандай итте, уллары Аспарух илханга, Балкырга күзләре белән нидер әйтте, аннары бушанып, таралып түшәккә ятты, күзләрен йомды, әмма бераздан яңадан ачты.

— Ханша,— диде ул ишетелер-ишетелмәс кенә.— Ханша, Аслан угланны Патшакаладан алып кайт, Болгарга кирәк ул...— Хан күзләре белән философ Иоанн Фасианны эзләп тапты.— Илче Феофан угланы Константинны иленә кайтарып җибәр... Мине кызым Чәчкә чакыра, ханша... Аккиезгә салып...

Ханның йөзе тартышып куйды, кисәк ияге салынды, аяклары сузылып китте. Ханша иренең күкрәгенә капланды, сулгып елап җибәрде.

Кубрат хан исәнлегенә чалган корбан да, меңләгән алыпларның тезләнеп тәңредән сораулары да ярдәм итмәде, Бөек Болгар дәүләтен төзегән Кубрат хан дусты император Ираклийдан соң бик аз гына яшәп, алты йөз дә кырык икенче елның җәендә, Маныч елгасы буенда дөнья куйды. Аны һәм ханның кызы Чәчкәне атлар чаптырып менгәндә тирләп чыгардай биеклектә көрбәп өеп, өйләп-буралап, бөтен корал-әйберләрен куеп, теге дөньяда йөрер өчен атын да чалып, савыт белән эчемлекләр, нигъмәт-ризыклар калдырып, зурлап күмделәр.

## 34

Тын далада күпләр ятып калды, исәннәр тарала башладылар. Меңләгән кеше каны белән сугарылган орыш кырында яз килүгә, беренче

булып умырзая чәчкәсе баш төртә, аннары аларны күкбашлар алышты-ра, май кояшы карый башлагач кына тукранбашлар калкып чыга. Язгы янгырлы, дымлы җилләр тухтау белән дала өстен акрынлап кылганнар каплый. Алар үткәнне бүгенгегә ялгап, һаман мең еллар элеккечә тир-бәлеп чайкалалар. Биредә яшәгән халыклар тарихын белсә бары тик әкрен генә искән җилгә дә пышылдап сөйләшә башлаган кылганнар беләдер, шуңа әле булса башларын чайкап утыралардыр кебек.

Илбарыс буйтур Кодрак илханның уң кулында бара, янәшәсендә Денис. Орыштан соң Денис буйтурдан аерылмас булды, шул сәбәпле ханшага Эске кирмәнгә күчәргә теләве турында әйтте. Ханша аңа кар-шы килмәде. Илханнар, җәйләүләре бетүгә, Фанагүргә җыелырлар. Шунда Батбай углан белән ни кылырга хәл итәрләр. Кузгалыр алдын-нан ханша чатырга Илбарыс буйтурны чакыртып алды.

Буйтур чатырга килеп кергәч, ханша бер тын сүзсез генә ятим уг-ланга карап торды. Ана күзләрендә яшь иде. Буйтур тетрәнеп китте. Аның алдында ханша түгел, гүя гүзәлләрнең гүзәле, матурлыкны, чи-бәрлекне күк-кояштан алган кызы Чәчкә басып тора иде.

— Углан,— ханша шулай диюгә, хиссияткә бирелеп дөньясын онытkан Илбарыс сискәнеп китте.— Углан, әйт теләгеңне. Сине Кодрак ил-хан уң кулына сорый...

— Ак анам,— Илбарыс буйтур ханша алдына тезләнде.— Ак анам, Кодрак илханның уң кулы итеп атам Кубрат хан билгеләгән иде. Ак анам...

— Углан,— диде ханша һәм аның тавышы җәя керешедәй калтыра-нып китте.— Чәчкә юк, хан да юк, алар җир астында...

Ханша буйтурның башына кулын куйды.

— Сиңа үтенечем бар, углан. Энем Көбер хан Росьтан өйләнмәкче. Мин сине Кияүкалага яучы итеп җибәрергә булдым. Җәйләүдән Фанә-гүргә кайткач барырсың. Олуг князьгә бүләкләрне алостаз Дәян хәзер-ләр. Язга Кызкуыш туенда катнашырсың.

— Ак анам, әйтмә алай! Әйтмә!

— Углан, аның үтенече бу...

— Юю-кк, Ак анам, юк!.. Чәчкә...

Ханша буйтурның чәчләреннән сыйпады, яшь белән мөлдерәп тул-ган күзләрен читкә алды.

— Ярый, углан... Бар юлда бул... Мин әйттем.

Чатырга кече кавхан Актай килеп керде.

— Ханша, алайлар, олаулар җыелды, кузгалырга әмер көтәләр.

Ханша Аппак яшьле күзләрен сөртте, угланны аягына бастырды, башын күкрәгенә кысып беравык торды да ишеккә таба этәребрәк җи-бәрде. Шуннан соң гына кече кавханга:

— Боер, кече кавхан. Кузгалабыз!..— диде.

## 35

Кылганнар артта калды. Арбалар шыгырдаудан, атлар пошкыру-дан, арбадагы яралыларның ыңгырашуларыннан күңел тагын да са-гышлана, моңлана, сызлана иде. Әле бит кичәле-бүгенле генә Илбарыс буйтур сөйгәне Чәчкәне күрү хыялы белән йөри иде, кичәле-бүгенле генә ул бәхетле иде.

Анда да, монда да әрәмәлекләр очрый, озын-көзен шау чәчәктә утыручы күкбашлар ак кыякларын җәеп, күз тутырып кояшка карап то-ралар. Чәчәкләр буйтурны баш иеп каршы алалар, узып киткәч, баш ия-ия озатып калалар сыман иде.

Тагын ике көннән алар Эске кирмән җәйләвендә булырлар. Анда — Чәчкә эзләре, Чәчкәгә кагылышлы истәлекле әйберләр, Чәчкә рухы. Күп

тә үтми аны ханша Фанәгүргә чакыртып алыр. Фанәгүрдән йөзләгән олау белән Кияүкалага юнәлерләр. Кияүкалага буйтур үзе белән Денисны да алыр.

Денис анда үзенең сөйгәнен табар. Өйләнер. Ә Илбарыс беркайчан да өйләнмәс, Чәчкәсенә хыянәт итмәс, Чәчкә һәрвакыт буйтурның йөрәгендә булыр. Ул орыш исәбенә яшәгән ханнарга, князьләргә каршы чыгар, андый ханнарны, князьләрне яманлап җыр җырлар. Орыш һәрчак баланы анадан, туганны туганнан, атаны улдан, улны анадан, сөйгәнне сөйгәненнән, хатынны ирдән аерды. Кеше дөньяга кылычтан, уктан үләр өчен килми, ямьле кояш астында гомер итәр өчен килә. Кояш астында барысына да урын җитәрлек. Яши белеп, фидакарь хезмәт белән яшәгән кешегә бәхет тулып, мөлдерәп килә, аны аңа яраткан хезмәте китерә, үткен кылычы түгел.

Офык читендә ак болытлар кабарына, болытлар тау-тау булып, ишелеп-өелеп меңәләр. Әлеге болытлар ап-ак, тиздән алар куерыр, каралыр, авыраер һәм җиргә коеп-коеп шифалы яңгыр ява башлар. Яңгыр яуган далада үлән үсәр, маллар көр булыр, елга буйларындагы болыннар хуш исле, төрле-төрле төстәге чәчәкләргә күмелер. Аннары көз килер, кыш килер, кышны янә яз алыштырыр, карлар китеп, язлар килгәч, елга буйлары, тугайлар, болыннар уяныр — янә умырзаялар калкыр. Һәр ел, һәр яз буйтурга Чәчкәне алып кайтыр. Кеше үлсә дә, аның исемен, кылган эшен мәңгеләштерүче хәтер бар, хәтер белән мәхәббәт — үлемсез, мәңгелек!

— Денис!— Койрыкчы оста буйтурны аты белән куып җитте, янәшәдән атлатып китте.— Ишетәсеңме, Денис! Ханша мине тиздән Кияүкалага яучы итеп җибәрәчәк. Мин үзем белән сине дә алырга булдым.

— Буйтур, буйтурым, кабатла әле шул сүзләреңне тагын бер, кабатла.

Денисның куанычлы авазында туган ил белән очрашу шатлыгы да, җиңү тантанасы да, буйтурга булган хөрмәте дә, туганлашып беткән болгарлар белән аерылышу сагышы да бар иде.

* * *

...Алда Эске кирмән күренде. Исән-имин кайтып килүче ыруларын күрүгә, каланың капкалары ачылды, асма күперләре төшерелде. Ачык капкалардан, асма күперләрдән олысы-кечесе, баласы-чагасы, сөйгәннәрен орышка озаткан хатын-кызлар, кирмән сакларга калдырылган алыплар, чит-ят илләрдән килгән сәүдәгәрләр сибелеп чыкты.

## Галимҗан Латыйп

### Хәрби оркестр

Уйный, уйный
Хәрби оркестр,
Ерак юлга поход чыкканда,
Приваллардa,
Дошман яуларын
Тар-мар итеп, бәреп екканда.

Уйный, уйный
Хәрби оркестр,
Геройларны каршы алганда,
Уйный кайчак,
уйный иңерәп
(Монсы авыр була бигерәк),
Батырларны җиргә салганда.

Уйный, уйный
Хәрби оркестр,
Бәйрәмнәрдә, туйлар булганда,
Табаннарны җиңеләйтергә
Сикәлтәле, озын юлларда.

Кирәк икән,
Хәрби оркестр,
Алып керә янган утларга.
Уйнаса ул,
Уйный бик җитди,
Уйнамый ул бер дә юк-барга...

*

Исе китми аның юк-барга,
Янар таулар бардыр janында —
Баш күтәрде Гыйлаҗ — газраиле
Килгәч аның җанын алырга.

Әйтте үлем: — Әйдә, җыен, энем,
Мин бит сине килдем алырга.
Лимитың юк, правaң да бетте
Бу дөньяда бүтән калырга.

— Син соң мине кем дип белдең әле,
Адресымы әллә ялгыштың?
Синең белән алыш-бирешем юк,
Эшем тыгыз, билләр алышмыйм.

Үз хыялым, үз көнем бар минем,
Эшләнәсе эшләр җитәрлек.
Минем эшне кем башкарыр дисең,
Йөреми тор кәеф китәреп.

Анда баргач, кире кайтып булмый,
Яхшы чакта ычкын янымнан.
Сүнәр бу дип уйлыйсыңмы әллә?
Мин янартау булып кабынам.

Безнең нәсел имән токымыннан,
Аударырмын диеп уйлама.
Мин бу җирдә бер дә артык түгел,
Кирәгем бар әле дөньяга.

Дошман безне мең үлеме белән —
Туп атып та ала алмады.
Утны-суны кичкән егетләр без,
Аңлашыла булыр калганы...

## Күңелдә

Бар иде балкып торган җан.
Юк булды...
Бар гомере дөрләп янган
Ут булды.

Яктырды ул, тирә-якны
Җылытты.
Чәчәк атты, тик ул үзен
Онытты...

Уелды да калды кеше
Күңелдә.
Бирмәс аны, бирмәс хәтер
Үлемгә.

Яна белеп яшәгәннәр
Үлемсез.
Сез аларны еллар аша
Күрерсез:

Әллә каян күренә зур
Яктылык,
Һавадагы йолдыз кебек
Яктырып.

*

Иртә торсам, мин сөенәм:
Кояш чыга алланып.
Якты, ачык чыраенда
Бәйрәм төсе бар аның.

Җем-җем нурлар сибә-сибә
Керә кояш җаныма.
Әйтерсең лә чәчләремә
Әнкәм кулы кагыла.

Кояш кебек җылы иде
Аның йомшак куллары.
Сөеп-сыйпап иркәләргә
Тик вакыты булмады.

Сугыш иде, кыен иде.
Икмәге дә уңмады.
Бер телемне бишкә бүлде
Аның ябык куллары.

Кайтарасы иде аны
Берничә көнгә генә.
Сөенече сыймас иде
Яралы йөрәгенә.

Кашемир яулыгын бәйләп,
Затлы күлмәген киеп,
Йөрер иде йөгерә-атлый,
Түбәсе күккә тиеп.

Әйтер иде: «Ис китәрлек,
Дөнья бик нык үзгәргән.
Тик шунысы — саклау кирәк
Аны яман күзләрдән...»

## Бакалы урманнары

Бакалы урманнарына
Кергән саен шомланам...
Имин генә була күрсен,
Болганмасын дөньялар...

Буранлы, җепшек март ае,
Ак мамыктай кар ява.
Сәнәкчеләр килеп керде,
Мылтык атып һавага.

Берәмләп җыеп алдылар —
Исемлектә кемнәр бар:
Коммунистлар, комсомоллар,
Укытучы туганнар
Кыйналдылар, тукмалдылар,
Кара канга батканчы.
Җәзалаулар дәвам итте,
Кара таңнар атканчы.

Иртә белән китте «отряд»
Бакалы якларына,
Бик зур эш кырган шикелле,
Төялеп атларына.

Тешен кысып түзде авыл,
Кулаклар сөенделәр.
Кушылып китте кемнәрдер
Шул кара өер белән.

Икенче көн, колак кагып
Җигүле атларыннан,
Кайтып төште олаучылар
Бакалы якларыннан:

— Волком секретарен анда
Сәнәккә күтәрделәр.
Кара байракларын элеп,
Митинг үткәрделәр...

Хәтердә, бар да хәтердә,
Онытыла торган түгел.
Үткәндә шушы урманны
Сискәнә һаман күңел!..

## Уйлый идем

Уйлый идем мин үземне:
«Сабырмын»...
Аерылганга атна да юк,
Сагындым.

Күзем йомсам, күз алдымда
Торасың.
Кулым сузсам, җитми сиңа
Колачым.

Иртән торсам, кичләр ятсам —
Күңелсез.
Яна йөрәк, яна утсыз,
Күмерсез.

Ашаганым, эчкәнемнең
Тәме юк.
Синсез минем көннәремнең
Яме юк.

Без — ялгызлар, ялгызлыкны
Беләбез.
Сез, гашыйклар! Аерылыша
Күрмәгез!

*

Без икәү бергә булганда,
Онытабыз дөньяны.
Ут капкандай, яна башлый
Хатын җаны, ир җаны.
Дөньялар яктырып китә,
Күктән йолдыз явамы?
Безнең кайнар иреннәрдә
Киләчәкнең дәвамы.
Тормыш шулай алга бара,—
Калмый бер дә тукталып —
Яна торган учаклардан
Ялкын алып, ут алып...

## Чайкадым

Ил күрәм,
Дөнья күрәм дип,
Күпме җир йөрдем арып.
Чайкадым сөякләремне
Кара диңгезгә салып.

Чайкадым.
Шифасы тияр:
Тозлы су,
Тозлы һава.
Җемелдәп зәңгәр күкләрдән
Өстемә йолдыз ява.

Әй дөнья!..
Дөнья шулай ул,
Әсиргә ала җанны.
Шатлыктан,
Кайгыларымнан
Күпме күз яшем тамды.

Шулай да
Миннән бәхетле
Бар микән бүтән берәү?!
Кешегә, кая барса да,
Гел кирәк була терәү.

Үземнән бигрәк, бүтәнне
Бәхетле итим дисәм,
Бокалым тулы агуны
Мин ширбәт итеп эчәм.

Бер рәхмәт алу —
Адәмгә
Үзе бер бәхет бит ул.
Патшалар буе җитмәслек
Дан бит ул,
Тәхет бит ул.

## Үсмер чагым

Үсмер чагым.
Кием-салым
Тузган, кырык ямауда.
Зимагурлар читтән кайта,
Кем кызыкмый аларга.

Киттек чыгып Уралтауга,
Калды авыл еракта!
Шуннан башлап тимер чыңы
Сеңеп калды колакка.

Безнең кулга акча керде
Бакырдан да, көмештән.
Маңгай тирен түккән кеше
Мәхрүм түгел өлештән.

Алдык чалбар.
Алдык күлмәк.
Каеш будык билләргә.
Җилфер-җилфер маңгай чәче
Уйный кичке җилләрдә.

Кулда гармун,
Җанда сагыш,
Өйгә кайтасы килә.
Такта чемодан төбендә
Бүләгем бар әнигә.

Атна саен хатлар язам,
Хатлар алам авылдан.
Барысына караганда
Әнкәй бигрәк сагынган...

Сабантуе көннәрендә
Кайтып төштек авылга.
Шау-гөр килеп тора бәйрәм
Салкын чишмә тавында.

Учлап-учлап кәнфит чәчтек —
Байлык бездә җитәрлек,
Бала-чага, кыз-кыркынның
Ис-акылын китәреп.

— Зимагурлар кәнфит чәчә,
Баеп кайтканнар икән!..
— Сабантуйлар гына үтсен,
Мин китәм дә,
— Мин китәм...

Кулда гармун,
Җанда хыял,
Җилкендерә күңелне.
Туган-үскән җирләремә
Сагышларым түгелде.

Үсмер чактан — егет чакка
Кердек шулай ашкынып,
Башта булган хыялларны
Чынбарлыкка ашырып.

Каерылып-каерылып карыйм
Ераклашкан саен ике ара.
Иреннәрдә синең утың яна,
Куенымда синең җылың бара.

Алда юллар — киләчәгем ята,
Аякларым мине шунда тарта.
Сине уйлыйм, сине сагынам мин,
Хыялларым, шатлыкларым арта.

Ике ел ул ике гасыр түгел,
Сагынышып күрешербез әле.
Үзебездән тора, үзебездән
Киләчәге бу дөньяның, яме.

Солдат булып сине саклыйм бит мин,
Җилләремне, эчкән суларымны,
Синең белән ялан тәпи йөргән
Каз бәбкәле, яшел урамымны.

Мәхәббәтен саклыйм, шатлыкларын
Шәһәрләрнең, тыныч авылларның.
Үкчәсенә басып, тотып торам
Кузгатмыйча сугыш давылларын.

Хәерлегә булсын, хәерлегә,
Таңнарыбыз тыныч уянсын дип,
Мин басамын һаман изге сакка,
Каралмасын йөзе кояшымның.

Киткән юлларымнан кайтырмын мин,
Йөгерә-йөгерә каршы син чыгарсың.
Сөенечтән дөнья күз алдында
Кайнар яшең белән бер еларсың.

# Рашат Низамиев

## КАНАТЛЫ ҖЫР КИРӘК КЕШЕГӘ...

### Сәгать ничә?

«Сәгать ничә?» — сорый замандашлар,
«Сәгать ничә?» — сорый танышларым.
Дүрт күз белән көтеп тора дөнья
Сәгать укларының авышканын.

Сәгать суга! Шушы көмеш аваз
Каерып ача галәм читлекләрен.
Нинди өннәр алып килә безгә
Гап-гади бер җыры чикерткәнең?

Атом гөмбәзендә — кара кояш,
Бар тереклек әллә үләчәкме?
Юк! Кешеләр кулдан ычкындырмас
Мәңгелектән килгән киләчәкне.

Җирне, күкне бергә тоташтырып
Кыл уртада бүген янып торам:
Мин — галәмнең бер йолдызы кебек,
Мин — диңгезнең бер дулкыны сыман.

Берөзлексез Җирне әйләндерә
Галәмара вакыт машинасы.
Кемдер туса, исем кушасы бар,
Үлсә — каберенә таш куясы.

Сәгать суга! Зәңгәр сварканың
Очларыннан тама утлы нокта.
Философмы, күмер чабучымы —
Ә кемдер бит туды бу минутта...

Шагыйрь икән — булсын туры сүзле,
Полководец икән — мәрхәмәтле.
Кирәксә — сүз яки кылыч белән
Яклый белсен алар мәхәббәтне!

Кош очса да күкләр тетрәп куя —
Кешелекнең киеренке мәле.

Ракеталы тешен шыгырдатып,
Корбан сорый сугыш тегермәне.

Зур «план»мы кора генераллар
Дөнья картасына сеңә-сеңә?
Кай минут бу? Бишектәге сабый
Үреләдер сөтле шешәсенә.

Һаман әле сызланамы икән
Ливан кедрының сылу тәне?
Кул бирәме илләр, бер-беренә
Корыч йодрык әллә күрсәтәме?

Сәгать телләренә карый-карый
Кыл өстендә басып торучы бар,—
«Икс» көнен көтеп кенә ята
Чуалыш һәм фетнә коручылар.

Йолдызларның күчешенә карап
Дөресләгән сыман сәгатьләрне,
Үзгәртәсе, дөреслисе иде
Тормыштагы яман гадәтләрне.

«Сәгать ничә?» Шул гадәти сорау,
Искермичә, көн дә кабатлана.
Планетаның зәңгәр чатырында
Гел бәхетле минут булса кана!

Казан урамында — саф татарча,
Париж бульварында — французча,
Лондон урамында — инглизчә
Сорый замандашлар:
— Сәгать ничә?
— Сәгать ничә?

## Алмагач

Күр, загс баскычларыннан
Яңа атлап төшкәннәр...
Сөю агачы утырта
Яңа өйләнешкәннәр!

Кулларында, үзләре күк,
Алма бирер алмагач,
Икесенә — бер мәхәббәт,
Икесенә — бер агач.

Бәхетле парлар туфракка
Сала күңел яктысын:
Туфрагы да, һавасы да
Гомергә уртак булсын!

«Сукыр» дисәң дә, мәхәббәт
Алдамас ул, алдамас:
Ак бөркәнчек япкан кәләш —
Шау чәчәкле алмагач...

Алма бирер якты еллар
Якында ул, якында.
Бөрегә уяган һәр агач
Сөйли яшәү хакында.

Бардыр сөю агачына
Узучылар бәйләнеп.
Сындырсамы — кулы корсын
Таш бәгырьле бәндәнең.

Яшәргә, фәкать яшәргә
Тиешлеген аңлагач,—
Канатларын җилпи-җилпи
Үсеп китәр алмагач!

Тамырлары җирне кочар,
Яфраклары — кояшны.
Мәхәббәткә шаһит булып
Каршылар ул һәр язны.

Сизгер җаннар тояр беркөн
Күз китергән чынлыкны:
Өзелеп төшкән алма шавы
Сискәндерер тынлыкны.

Ә хәзергә... кулларында
Алма бирер алмагач.
Икесенә — бер мәхәббәт,
Икесенә — бер агач.

Туфрак белән кавыштырсаң,
Тернәкләнә тамырлар.
Җир һәм күкләр дуслыгын да
Дөнья үзе калдырган.

Илләр белән илләр дә бит
Туганлашып торсалар,
Келәм җәеп кунакларны
Каршы ала тупсалар...

Уйларым — өлгергән алма,
Чаң сугам яңгыратып:
— Әй, җирдәшләрем, безгә дә
Туганлашырга вакыт!

...Җир шары — өлгергән алма!
Нинди кылда эленеп,
Күзләргә кереп бара ул
Моңсулыкка төренеп?

## Компьютер монологы

Мин ялгыштым... Шундый ялгыштым мин!
Ут кабачак иде заманага;
Биек йортлар әверелер иде
Һәм агачлар — көйгән баганага.

Ярый әле, ярый вакытында
Шул хатамны өлгерделәр белеп,—
Үзем дә бит мин калачак идем
Галәм тузанына әверелеп.

Кош шәүләсе булып чыкты, шөкер,
Шик-хәвефле «нокта» дигәнебез.
Мин ялгыштым... Шушы хатам өчен
Хет яңакка сугып җибәрегез.

Бу җәзаның әмма мәгънәсе юк:
Тәнем чөнки — тимер нәселеннән.
Минем тимер күзәнәкләремә
Сезнең акыл, куәт яшеренгән.

Сез, к е ш е л ә р , үзегез бит мине
Ясадыгыз яшрен сарайларда.
Кемгә кайда хезмәт кыласымны
Өлгермәдем хәтта абайларга.

Ни кушсагыз, шуны башкарырга
Әзер торам тугры хезмәтчедәй.
Радар күзем айкый һаваларны
Ничәнче кыш инде, ничәнче җәй.

Радар күз дә нык ялгыша икән,
Сизгерлеге хәттин ашкан юкса.
Нишләргә соң: экрандагы «нокта»
Метеор я кошлар булып чыкса?

Технократлар камилләшә бара,
Сыйфат һаман алга үзгәрелде.
Тик шулай да ялгышканы өчен
Гафу итә алмыйм күзләремне!

Бәхәсләшмик, кеше чыкмый миннән,
Күпме генә акыл сеңдерсәң дә.
Ләкин мәнә җанлы роботка да
Әверелергә мөмкин сезнең бәндә.

Күңелендә, димәк, иманы юк —
Кемдер әгәр илен яратмаса.
Шуңадыр да, әнә, кеше-робот
Рольләргә бик тиз яраклаша.

Кайгырмый ул җирем-суым диеп,
Ни сыйныфы аның, ни милләте.
Күк йөзендә ничә алла булса —
Һәркайсына әзер гыйбадәте.

...Электрон акыл әзер тора
Эфир кочагына ташланырга.
Мин, ялгышып, «Тревога!» суктым...
Тиеш иде сугыш башланырга!

Мин ялгыштым... Гафу сорар идем
Тарихтагы зур ялгышым өчен.
Безнең учка салып язмышыңны
Син үзең дә нык ялгыштың, Кешем!

## НАТО генералының төш күрүе

Куркынычлы аваз якыная,
Офыкларны кызыл кан басты.
Качар иде, әмма җибәрмичә
Тотып тора бер-бер албасты.

Аңлашылмый вакыт төшенчәсе:
Кай гасыр соң җирдә, кай еллар?
Көтмәгәндә усал чыелдашып,
Чорнап алды аны маймыллар.

Куркытасы иде йолкышларны,
Мәргән күздә — хәйран осталык.
Ах, кызганыч, сейф бушлыгында
Онытылып калган пистолет!

Кара шәүлә, кара бөҗра булып
Кыса, каһәр, сулыш юлларын.
Фосфор сыман яшел күзләрендә
Чатнап яна ачу нурлары.

Йодрык селти кыргыйлашкан өер,
Ирек бирсәң, җәлләп тормаслар.
Чү! Боларның килеш-килбәтендә —
Таныш чалым, таныш гримаслар...

Пентагонның тимер читлегендә,
Әйе, шулар сынау уздылар,—

Нейтрон нурны «татып» карагач та
Берәм-берәм аяк суздылар...

Хәрби максат өчен кирәк иде —
Чит күзләрдән ерак яшереп,
Ябык бүлмәләрдә «сынадылар»
Маймыл бабаларның нәселен.

Ашавыннан калды шимпанзелар,
Күзгә карап сулды, киптеләр;
Кешеләрнең ничек үләчәген
Тып-тын гына хәбәр иттеләр.

Шул маймыллар, кулын суза-суза,
Күрсәтәләр канлы яктыга:
«Нейтрон үлем уйлап табучыга
Бездән нәләт! Бездән бәддога!»

Кыса бoҗра, кыса үҗәтләнеп...
Инде тәмам бетте дигәндә,
Куркынычлы төшнең «рыцаре»
Аңга килде паркет идәндә...

Дөнья белә: Әйе, үзеңнән дә
Алданрак йөри яманат.
Әйтче әле: генералмы соң син,
Әллә инде хәрби лаборант?

Матди байлык, имеш, исән кала —
Шулай диеп нәфсең алдаша.
Бу шәһәрләр — бар да каберлек бит,
Кеше рухы җирдә калмаса!

Кояш нуры күзгә ватыгында
Кире кайтарылган шикелле,
Халыкларның нәфрәт нурланышы
Көйдерәчәк шома битеңне...

Кара төндә кара генералның
Тынычлыгын алган «яман төш»,
Набат булып, төнге сабак булып
Хәтеренә шулай һаман төш!

## Вәгъдә

Киләчәккә таба оча заман:
Бергә оча күге, уҗымнары.
Тәүлек саен кайнар бәхәсләшеп,
Оран сала чуар «изм»нары.

Чилимы ул, яки Ольстермы —
Атыш бара икән урамнарда,
Кай илдә дә кургаш ядрә бит ул,
Аермасы — фәкать граммнарда.

Тирән шахта саен — ракеталар,
Үлем посып ята эчләрендә.
Бертугандыр алар, аермасы —
Мөһерендә яки төсләрендә.

Хәрби мускул, әйе, бездә дә бар,
Вазифасы аның ләкин башка...
Ант итәбез — атом йодрыкларны
Иң беренче булып кулланмаска!

«Совет яный...» — диеп бушбугазлар
Күпме генә читкә каермасын,—
Таный инде илләр һәм халыклар
Ике сәясәтнең аермасын:

Без бит көрәшәбез —җир тутырып
Арыш үссен, урман шауласынга!
Хуҗа булып, ах, йөрмәкче алар
Хәрабә һәм үлек арасында...

Тыңла, дөнья! Әйткән сүзебездә
Никадәрле изге ният, мәгънә:
Ил сагына баскан «куәт»ләрне
Кулланмаска — тантаналы вәгъдә!

Кулланмаска! Тарих каршысында
Безнең инде фикер күптән анык.
«Кнопка»га кагыл гына бары —
Көтеп тора утлы бумеранг.

Кылыч белән кылыч чарпылгандай
Ике дөнья бәрелешсә әгәр,—
Алтын гасыр михрабына җитми
Туктала да кала бөек сәфәр!

Материклар — түм-түгәрәк өстәл,
Чакыр да ал җирнең бар милләтен.
Тыныч күңел белән сөйләшергә,
Битараф тон белән түгел ләкин.

Кошларны да узып китә торган
Тизлек таптык. Без канатлы, димәк.
Тик канатлы ракеталар түгел,
Планетага — канатлы җыр кирәк!

Тынычлыкка һәйкәл торгызырбыз,
Тынычлык ул — безнең алтын кәгъбә.
Кешелекнең хәләл нигез ташын
Ныгытырга — халыкара вәгъдә!

## Фәнил Галиев

# КОМАНДИРОВКА

## (Бер яла тарихы)

ПОВЕСТЬ

### Беренче бүлек



Пыялалары ялт итеп торган киң тәрәзәдән таныш урамнар күренә, алардан арырак кар белән капланган басулар китә. Кырның калкурак урыннары каралыбрак тора. Тагын да арырак горизонтка ук терәлгән урман томан белән өртелгән. Төшке кояш якты һәм ягымлы елмая.

Әхмеров иртә килгән язның матурлыгына сокланып тәрәзәдән бераз күзәткәч, сәгатенә карады. Шеф нигәдер соңга кала иде...

Ярты сәгать элек прокурор, кабинетына чакырып, бер ел элек туктатылган җинаять эшен архивтан кире алырга һәм партия райкомының беренче секретаре янына барыр өчен үзен көтәргә кушкан иде.

Гаҗәп, секретарь ул вакыйганы ничә кабат исенә төшерде икән, һәм Әхмеровның моңа ни катнашы бар? Җинаять эшен аңа кадәрге суд тикшерүчесе Бердников алып барган иде. Бары ул гына тикшерү материалларын эчәсеннән җебенә кадәр белә. Хәер, аның үзен хәзер ничек табасың инде? Ау мылтыгын аркасына асып кайда да булса йөридер әле...

Ишек ачылып ябылу һәм аяк тавышлары ишетелде — кабинетка зифа буйлы, озын гәүдәле, укымышлы кыяфәттәге прокурор килеп керде.

— Әхмәт Шәрипович, сез әзерме?— дип коры гына сорады ул, йөзенә мөлаемлек бирә торган аксыл-соры чәчләрен бүрек астына сыпыргалап, аннан Әхмеровның киенгән булуын күргәч, кулын селтәде дә сорап куйды:— Теге эшне алырга онытмагансыңдыр бит?

— Онытмадым, Игорь Антонович. Менә ул,— диде Әхмеров һәм, ышанычлырак булсын өчен, күн портфеленең кырыена сугып алды.

— Киттек алайса. Бәйрәм Исмәгыйлович көтә...

Райком секретаренең кабинеты киң һәм якты иде, әйтерсең, ул язгы көннең бөтен матурлыгын һәм сафлыгын үзенә туплаган. Биек тәрәзәләр бераз ачып куелган, ян-якларына үтә күренмәле пәрдәләр эленгән. Кабинет уртасында янәшә куелган ике өстәл һәм ике кәнәфи тора. Кырыйдагы стена буенда язу кирәк-яраклары куелган тагын бер өстәл бар.

Кушылыбрак киткән бәсле калын кашлары астыннан төбәп карый торган коңгырт күзләре, бөркетнекe кебек борыны һәм икегә бүленгән ияге аның нык ихтыярлы, тәвәккәл кеше икәнлеген күрсәтә, өстенә кигән куе соры костюмы, шуңа туры китереп сайланган буй-буй галстугы һәм ап-ак күлмәге аның пөхтә һәм төгәл кеше икәнлеген әйтеп тора.

Дәүләтбаевның сугышка чаклы юридик мәктәп тәмамлап, фронтта хәрби трибунал члены булганлыгы һәм бу турыда горурланып искә алырга яратуын Әхмеровка райком работникларының кайсысыдыр әйткән иде. Моңа кадәр Әхмеров үзе дә секретарьда бер-ике тапкыр булды. Шул чагында ул Дәүләтбаевның хокук мәсьәләләрен әйбәт белүен аңлады. Прокурор да моны белә иде, ахрысы.

Секретарь керүчеләрне күзәткәндәй, бераз дәшмичә торды. Аннан соң утырырга кушып, өстәл кырыенда яткан папкадан берничә кәгазь алды. Аларны ашыкмыйча гына караштырды.

— Васильева Полина Ивановна... Бу фамилия сезгә таныш булырга тиеш...

Прокурор, әйе, дигәндәй, башын селкеде. Күзлек астыннан бераз сагаеп карады. Әхмеров хәрәкәтсез утыруында дәвам итте һәм маңгаен гына җыерды. Бу фамилия аңа таныш идеме соң? Таныш та, түгел дә. Пенсиягә китүче тикшерүчене алыштырыр өчен бирегә бүтән өлкәдән күчеп килгәндә, Бердников Васильева эшен тикшерүне төгәлләп килә иде. Бердников, тикшерүчеләр арасында булган гадәт буенча «икенче дәреслек» тә бармы-юкмы икәнлеген фараз кылып карар өчен башын ватмады, туган уйлары белән дә уртаклашмады, ләкин эштән бергә кайткалаганда: «Бу председатель хатын белән шул хәтле чиләндем!..» — дип зарлангалаган иде. Аннан соң ул бу эшне япты да, Әхмеровка үз өстендәге бөтен казна мөлкәтен тапшырып, «көртлекләр ауларга һәм җинаять кодексы турында бөтенләй онытырга» дип, Урал тайгасындагы поселокларның берсенә күчеп китеп барды.

— Бу эш белән Бердников шөгыльләнгән иде бугай? — Секретарь Әхмеровның уйларына җавап биргәндәй итеп әйтте.— Сез үзегез дә аннан читтә тормаган булгансыздыр, Игорь Антонович?

— Әйе, Бәйрәм Исмәгыйлович. Бу турыда мин әйбәт хәтерлим.

— Кеше буларак, Васильеваның үзен беләсезме соң?

— Без, Бәйрәм Исмәгыйлович,— дип уңайсызланып елмайды прокурор,— бернәрсәне дә күздән ычкындырмаска тырышып, һәр шәхеснең язмышын эзлекле төстә өйрәнәбез...

— Язмыш? Ну, Игорь Антонович, үзегез башлагач, мин дә әйтим инде, бу шәхеснең язмышы шактый катлаулы булган. Ул авыл советы башкарма комитеты председателе булып эшләгән. Аңлыйсызмы шуны? — Дәүләтбаев урындык аркасына сөялде.— Хикмәт монда да түгел әле. Беләсегез килсә, бу хатынның тормышы гадәти түгел. Яшьли ирсез калган. Баласы үлгән... Аның урынындагы бүтән берәү бу кайгылардан тернәкләнеп тә китә алмас иде. Ә ул алдынгы комбайнчы, бригадир дәрәҗәсенә күтәрелә. Читтән торып техникум тәмамлый. Өч ел элек орден белән бүләкләнә.— Секретарь кашын җыерып туктап калды.— Әйе, начар, бик тә начар килеп чыкты. Мин бу хатынның ярдәмгә мохтаҗ икәнлеген белә идем бит,— дип пошынып әйтеп куйды.— Аның ни язганын тыңлап карагыз әле.— Ул, һәр сүзенең мәгънәсенә ныклап төшендерергә теләгәндәй, әкрен генә укып китте. «Елдан артык вакыт үтеп китте. Менә тагын матур яз житте. Ә минем йөрәгемдәге боз һаман эреми. Тын алуы кыен, йоклап булмый. Бу алтын алкалар белән булган аңлашылмаучылык хәл ителсә, миңа тынычлап яшәргә мөмкин булыр иде. Бөтен бәла шунда. Югыйсә, күңелгә шул хәтле авыр булыр идемени? Кешеләрнең күзләренә карагач, минем гаепсезлегемә тулысынча ышанып җитмәүләрен күрәм. Алар миңа: «Син үзеңнең гөнаһың өчен тиешлесен алмадың»,— диләр кебек. Моны махсус эш алып бар-

ган кешеләр дә ышандыра алмагач, миңа, ялгыз хатынга, үземнең гөнаһсызлыгыма ничек ышандырырга? Менә шулай мин йөземә һәм йөрәгемә салынган кара тамга белән яши бирәм, миндә берәүнең дә эше юк. Мине ялгыш аңламавыгызны сорыйм. Кешеләргә файда китерә торган хезмәтем бар. Тик болай да яшәп булмый. Үземә карата шикле карашларга бүтән түзеп тора алмыйм...»

— Шикле карашларга,— дип кабатлады Дәүләтбаев.— Моннан да авыр нәрсә булуы мөмкинме соң?

Ул хатны читкә этәрде дә прокурорга сынап карады:

— Игорь Антонович, дөресен генә әйтегез әле, бу сүзләр тагын да җентеклебрәк тикшерү кирәклеге турында сөйләмиме?

Прокурор аптырап кулларын җәйде:

— Гафу итегез, Бәйрәм Исмәгыйлович, прокуратура Васильева эше белән ике ай буенча шөгыльләнде бит. Тикшерүнең бөтен чаралары да күрелде. Ачыкланган кебек иде...

Аларны тыңлап торганда, Әхмеров күпме бергә эшләү дәверендә үзе сизгер, игътибарлы, турылыклы дип белә торган җитәкчесе өчен ниндидер уңайсызлык хисе кичерде. «Сөйләшүгә артык гади карый түгел микән? Сүз гадәти бер вакыйга турында гына бармый шикелле».

Прокурорның җабавы райком секретарен канәгатьләндермәде, ул мәгънәле елмайды:

— Беләсезме, Игорь Антонович, борынгы кешеләргә дә җир чите бакча артында кебек кенә тоелган...

— Комплиментыгыз өчен рәхмәт, Бәйрәм Исмәгыйлович,— диде прокурор хәтере калып.— Әмма бу очракта җинаять эше тәмамланган һәм ул менә шушы портфель эчендә ята. Берәү дә мине ялгышуда гаепли алмас. Дәлилләр нигезсез дип табылганлыктан, Васильевага гаеп тагылмаган, киресенчә, бу эш туктатылган.

— Шулай шул, туктатылган,— диде секретарь, урыныннан торып.— Тик ничек итеп бит? Нәрсәгә таянып?— Ул өстәл тирәли әйләнеп чыкты да, яңадан урынына утырды.— Карар чыгарганда үзегез ни дип язган идегез соң?

Прокурор өйрәнелгән хәрәкәт белән портфелен ачты да саргылт тышына номерлар язылган һәм эш кәгазьләре теркәлгән юка гына бер папка тартып чыгарды, тагын сорау бирерләр дигән кебегрәк, басып торуында булды.

— Карар өлешен укыгыз әле,— диде секретарь.

Прокурор папканы кире ягыннан актарып, суд процессларындагы гадәт буенча, баскан хәлендә, тавышын күтәребрәк укып китте:

«...Гаебе исбат ителмәгәнлектән, Васильева Полина Ивановнага карата ачылган җинаять эшен тикшерүне туктатырга...»

— Менә күрәсезме,— дип бүлдерде аны Дәүләтбаев.— Исбат ителмәгәнлектән туктатырга... Бу формулировкада дөреслек түгел, томанлылык, көчсезлек ачыграк чагыла, минемчә... Сүз уңаеннан гына әйтим әле, һәрбер тикшерүнең нәтиҗәсе хаклык, бары тик хаклык кына булырга тиеш. Кеше язмышына кагылышлы булганда, бигрәк тә!

«Әйе шул»,— дип уйлады Әхмеров, элек авыл советы председателе булып эшләгән катлаулы язмышлы бу хатынны тәмле йокыдан калдырган алтын алкаларның серен беләсе килү теләге аның да күңелен кытыклый иде.

— Хәтерегез калмасын, Игорь Антонович,— диде райком секретаре, инде урынына утырган прокурор янына килеп һәм иңенә кулын салды.— Сезне начар эшләүдә гаепләргә яисә моңа хәтле башкарып чыккан эшләрегезне юкка чыгарырга җыенмыйм.— Ул прокурор кулындагы делоны алып, аның портфеленә кире тыкты.— Бердников та күрәзәче түгел бит, дигән фикерем белән килешерсез дип уйлыйм. Бәлки,

ул берәр нәрсәне күреп тә җиткермәгәндер? Бәлки, пенсиягә чыгарга ашыккандыр?

Алар бер-берсенә караштылар һәм көлештеләр.

— Кыскасы, мин сездән бу эшне тагын бер кат бик тә җентекләп өйрәнүегезне сорар идем. Нихәтле тизрәк булса, шулкадәр әйбәтрәк.

Секретарьның соңгы сүзләре аларның икесенә дә кагыла иде, Әхмеров, үзенә сузылган кулны кысарга дип урыныннан торып баскач, Дәүләтбаев бик тә үз итеп, дусларча әйтте:

— Барысын да әйбәтләп уйлагыз. Зинһар, ашыкмагыз...



## Икенче бүлек

Вагон бөтенләй диярлек буш иде. Әхмеров, бернича рәт алга үтеп, киштәгә портфелен куйды һәм тәрәзә янындагы урынга килеп җайлабрак утырды. Пальтосын ычкындырды, эшләпәсен салды. Профессиональ гадәт буенча, үзе белән баручыларны күзәтә башлады. Почмактарак яшь кенә пар утыра: бөдрә чәчле егет аксыл чәчләре иңнәренә таралып төшкән кыздан күзен дә ала алмый, үзе аның колагына иреннәре белән кагылып, нидер пышылдый, ә тегесе керфекләрен дә күтәрмичә, нәфис иреннәре белән генә елмая... Бераз мондарак ак тун кигән олы гәүдәле хатын утыра. Ул бер кулы белән алдындагы зур кәрзинен тоткан, икенчесе белән янәшәсендә утыручы салмыш ирне әледән-әле селкеткәләп куя — үз ире булса кирәк. Каршыда утырган бөкре карт таягына таянып черем итә. Әхмеров янында күгелҗем борынлы ябык кына чырайсыз ир утыра, аның бәләкәй күзләре авыр күз кабаклары астыннан җемелдиләр.

Электричка шәһәрдән район үзәгенә бара иде. Көндезен кешеләр аз йөри. Аның каравы, иртән һәм кичкә таба эшчеләр, тимер юл хезмәткәрләре, студентлар белән вагоннар шыгрым тула.

Ябык ир иртә килгән язның башка ел фасылларына булачак тәэсире турында Әхмеров белән сүз кузгатып карамакчы булды, тик ул кушылып китмәде — башка нәрсә турында уйлый иде. Кичә райкомнан кайткач, төн уртасына чаклы Васильева эшен актарып утырды ул. Каткат укыды, инәсеннән җебенә хәтле тикшерде, төшенергә тырышты. Менә хәзер укыганнарын тагын бер кат күңелдән үткәрәсе, уйларына ирек бирәсе килде. Уйланырлык нәрсәләр бар иде.

Алтын алкалар тарихы болай башланган:

Олы Карамалы авылында һөнәрчелек белән көн күргән берәүдән тол калган алтмыш өч яшьлек Уварова Евгения Ивановна яшәгән. Пенсия алмаган, ирennән калган мөлкәт исәбенә көн күргән. Кеше белән бик аралашмаган, ялгызы гына яшәгән. Елына бер тапкыр, ире Николай Кожемякин һәм уллары Володяны ияртеп, кызы Анастасия кайта икән. Бер кайтуларында малайларын әбисе янында калдырганнар. Вакыт-вакыт ерак диңгезләрдә йөзүче капитан улы Петр да кайткалаган. Карчык турында халык арасында төрле гайбәт йөргән. Имеш, кияве белән кызы буш кул белән кайтмыйлар, төрле кием-салымны астан гына кыйбат бәягә саталар икән. Ел ярым элек, Кожемякиннар тагын төянеп кайткач, милициягә борчулы хәбәр килә: янәсе, Кожемякиннар өч бәягә арттырып әйбер саталар, көпә-көндез халыкны талыйлар. Авыл советы председателе Васильева хәбәр итә моны...

Милиция килә. Спекулянтларга тентү оештыра. Әллә ни хәтле әйбер чыга.

Кожемякин шунда ук кулга алына. Тикшерү башлана...

Бер айдан соң, авылның үзендә үк суд булган. Уварованы һәм кызын шартлы рәвештә хөкемгә тартканнар. Николай Кожемякин өч елга ирегеннән мәхрүм ителгән.

Ә берничә көн үткәч, милициягә яңа гариза килеп керә. Бу юлы Евгения Уварованың үзеннән. Әле яңа гына суд мәшәкатьләреннән арынган карчык, яшен түгеп һәм бөтен изгеләр белән ант итеп, Васильевага, тикшерү башланганчы ук, ришвәт рәвешендә үз кулы белән рубин кашлы алтын алка бирүен язган. Аның бәрабәренә Васильева аның кызы белән киявен яклап калырга сүз биргән икән. Беркадәр икеләнеп торганнан соң, Васильеваның өендә тентү үткәрергә булалар. Бу эшне караучы ОБХС инспекторлары гаризага ышанып та җитмәгәннәр. Алгы бүлмәдә торган сандык эчендәге бәләкәй генә тартмадан кинәт алкалар килеп чыккач, бөтенесе дә гаҗәпкә калганнар. Кибет мөдире Поликарпова аларны таныган, алкаларны Уварованың күптән түгел генә сатып алганлыгын әйткән.

Соңыннан көтелмәгән хәл була. Уварова кинәт үлеп китә, бөтен мал-мөлкәтен, үзенең вафат буласын сизенгән кебек, теге Бакудан кайтып-китеп йөргән һәм хәзер Олы Карамалыга бөтенләйгә күчеп кайткан кызына васыять итеп калдыра.

Авыл советы председателе Уварованың әлеге гаризасын яла ягу дип әйтсә дә, алкаларның өендә, алай гына түгел, сандык төбендә үк булуының сәбәбен берничек тә аңлата алмаган. Экспертиза да ачыклык кертмәгән. Кожемякина белән аның иренә килгәндә, алар аптырашып иңнәрен генә җыерганнар. Тиздән эш тагын прокуратурага тапшырылган.

Бердников тарафыннан пөхтә итеп теркәп барылган бу эшкә кагылышлы документларны анализлаганда, Әхмеров өлкән тикшерүченең игътибарсызлыгы, янсә ялгышкан булуы турында башына кертеп тә карамады. Төптәнрәк уйлаганда, ялгышу мөмкинлеге булса да, картлач кулыннан килгәнчә тырышкан. Чын дөреслекне ике кеше генә белгән. Аларның берсе юк инде. Күрүчеләр дә булмаган. Кем хаклы соң? Фараз кылу белән генә берни дә әйтеп булмас. Тикшерү алып барганда ачыкланган дәлилләргә таянып, Бердников Васильевага гаеп ташлый алган булыр иде микән? Алган булыр иде. Алкаларны капка төбеннән түгел, ә сандыктан тапканнар. Тик бу җинаять эшен алып барганда аңлашылып бетмәгән өч факт күзгә бәрелеп тора, аларга берничек тә күз йомып калып булмый. Васильева ришвәт алган, үзе үк җинаять турында тиешле урынга хәбәр иткән. Бусы бер. Уварованың гаризасы турында белә торып та, үзен фаш итүче дәлилне юкка чыгармаган — алкаларны яшермәгән. Бу — икенчесе. Ниһаять, өченчесе — Уварова алканы Васильевага җинаять эше ачылганчы ук бирдем, дип ышандырган, ә кибет мөдире Поликарпова алканы судка берничә көн кала гына сатуын әйткән. Уварова бу вакытта гаепләү нәтиҗәсен алырга дип район үзәгенә барган булган. Ихтимал, бу фактлар Бердниковның шиген көчәйтеп кенә калмагандыр, алкаларны Васильевага явыз ният белән куйганнар дигән нәтиҗә чыгарып, тикшерүне туктатырга этәргеч ясаганнардыр? Ә бит, бер уйласаң, бу дөреслеккә туры килми кебек.

Кем тарафыннан куелган икән соң алар? Бәлки, Уварова үзедер? Фактларга нигезләнми чыгарылган нәтиҗәгә Васильева риза булмаган. Ул урынсыз тагылган гаепнең тулысы белән алып ташлануын теле.

Әхмеров үзе бу алкалар турында ни әйтә ала соң? Әлегә берни дә. Тикшерү тәмам булу белән, алкалар Уварованың кызына бирелгән. Әхмеров аларны делога теркәлгән фоторәсемдә генә күрде, ул да булса — аклы-каралы рәсем.

Әллә алар чыннан да күз явын алырлык матурлар микән, һәм Васильева, ихтыяр көчен югалтып хәтәр адым ясарга — бүләкне кабул итәргә булгандыр? Бәлки ул аның өенә очраклы гына килеп кергәндер, яисә бу аңа әшәке яла ягарга маташу булгандыр.

Яла... Әхмеровның да яла белән исәп-хисабы бар.

Ул чагында алар Идел буендагы бәләкәй генә авылда яшиләр иде. Әхмеров үз әтисенең дулкынланып торган куе кара чәчле, тере күзләреннән ягымлы елмаю китми торган озын буйлы чибәр кеше икәнлеген хәтерли. Менә дигән табип булырак, аны бөтен тирә-як белә иде. Кичләрен, текә Идел яры буенда учак ягып балык тоткан чакларда, крестьяннар: «Безнең Шәриптән чир сазлыкка да качып котыла алмый»,— дип сөйләргә яраталар иде. Бикморза улы Шәрип кешеләрне дәвалаудан үзенә тәм тапты, шуңарда яшәү максатын күрде.

Язгы чәчү эшләре төгәлләнгәч үткәрелә торган сабантуйларда аның даны тагын да ныграк шаулап ала. Сабантуй кайчандыр үзенең гаскәре белән Пугачев туктаган тау башында була. Авыл табибының көчле беләкләренә бер генә көрәшче дә чыдый алмый иде. Сабантуйдагы иң олы бүләк булган тәкәне алмыйча Шәрипнең мәйданнан чыкканы булмады.

Әнисе аның капма-каршысы инде, бәләкәй генә гәүдәле, күбәләк кебек җиңелчә. Әтисе кайчагында аны Дюймовочка дип шаярткалый иде.

Алар тыныч, тату яшәделәр. Күрәсең, әтисе дә, әнисе дә юк-бар дәгъвалар белән бер-берсенең нервысына тиюне кирәксенмичә, бер-берсенә юл куеп яшәгәннәрдер.

Әтисе кайту белән өйгә җан керә. Әнисе ашыга-ашыга мичтән бәлеш ала, барысын да өстәл янына чакыра. Әтисе көне буе башкарган хезмәтеннән канәгать кыяфәттә өстен чишенә, кулын юа. Әхмәт аның янында сөлге тотып бөтерелә, аннан соң үзе дә юына.

Җиде яшьлек чагында ул тормыш һаман да шулай дәвам итәр дип ышана иде. Ләкин көзге төн — яңгырлы, борчулы төн килде.

Әхмәт кичләрен каба кырыена утырып җеп эрләгәндә әнисе сөйли торган әкиятләрдәге куркыныч убырлы карчыклар һәм су аналары турында уйлана-уйлана юрган астында йомгак кебек бөгәрләнеп ята. Аңа куркыныч та, шул ук вакытта берәр хәл була калган очракта, янәшәдә генә, чәчәкле чаршау артында гына йоклаучы әтисе белән әнисенең явызларны куып җибәрәчәкләрен тоюы рәхәт тә иде. Авыр герләрне туп кебек кенә уйната торган әтисе белән чагыштырганда бу убырлы карчыклар белән сихерчеләр чүп кенә булып күренәләр.

Кинәт ишек шакыдылар...

Әтисен чакырып нидер әйттеләр. Ул киенә башлады, йөзеннән кан качты, иреннәре кысылды. «Борчылма»,— диде әнисенә, чыгып киткәндә Әхмәтнең битен сыйпады, кулы җылы иде. Ә урамда җил, яңгыр әүвәлгечә тәрәзәләргә бәрелде дә бәрелде...

Күп еллар узгач кына әтисен нигә кулга алуларының күңелне бимазалап торган сере ачыкланды. Карап торырга мокыт кына, басынкы гына тоелган күршеләре Габдулла, үләр алдыннан Әхмәтнең әнисен чакыртып, үзенең аны яшерен рәвештә яратуын, шуның аркасында әшәке гөнаһ та кылуын — НКВДга ире өстеннән әллә нинди ялалар тагылган хат язып җибәрүе хакында әйтеп, бөтен туган-тумачалары алдында бәхиллек сораган...

Шуларны күз алдыннан үткәргәч, Әхмеров әллә нишләп китте. Ул, авыр уйлар тәэсиреннән арынмакчы булып, бите белән тәрәзәгә капланды.

«Күк нинди зәңгәр икән!» — дип гаҗәпләнде ул. Чыннан да, ул шулхәтле якты һәм зәңгәр иде ки, гүя юл читендә үсеп утырган каеннар да,

һава төсендәге томанга төренеп, тын калганнар. Табигатьтән яз җылысы бөркелә, борчу белән тулган йөрәк тагын тынычрак тибә башлады.

Әхмеров алга таба чапкан поезд тәрәзәсеннән карап барганда, тормыш төсле кинонь хәтерләтә икән, дип уйлап куйды. Әле яңа гына каеннар тезелеп киткән иде, инде бик еракта, артта калдылар. Аларны, борынгы бер әкияттән килеп чыккандай, тәрәзә капкачлары бизәкләп ясалган агач өйләр алыштырды.

Әнә, җиңсез кофта кигән сакал-мыеклы бер ир-ат, муеннарын сузып, үзенә карап торган ике бәләкәч бозауга абзар түбәсеннән печән ыргыта... Әнә, авылның бер чибәр кызы, яңа чиләкләрендә кояш уйнатып, көяз атлый-атлый коедан су алырга бара. Юл кырыенда өстенә ГАИ хезмәткәре формасы кигән яшь егет олы гына бер шоферның документларын тикшерә...

Ул участок инспекторы турында уйлап алды. Кичтән үк, үзен станциядә каршы алуын үтенеп, аның белән телефоннан сөйләшкән иде. Тегесе риза булды. Район үзәгендә эшләүче оператив хезмәткәрләрнең күбесен Әхмеров якыннан белә иде. Ә менә Мироновка моңарчы эше төшкәне булмаса да, аның Себердән монда күчеп килеп эшли башлавын ишеткән иде. Районда булып узган милиционерлар киңәшмәсендә аны бер-ике тапкыр күргәләгән дә иде. Карап торырга күркәм кыяфәтле, озын буйлы, аксыл чырайлы өлкән лейтенант кебегрәк хәтердә калган. Аның тышкы кыяфәтендә күзгә ташланган тагын бер үзенчәлек бар кебек иде, тик хәтеренә генә төшерә алмады.

Әхмеров сәгатенә карады. Озак барасы калмаган икән.

## Өченче бүлек

Станциядә Әхмеровны тәбәнәк уазик көтеп тора иде.

Соргылт төстәге солдат бүреге, кирза итекләр кигән түгәрәк йөзле яшь кенә шофер, аны күргәч, кабинадан җитез генә сикереп төште дә хәрбиләрчә сәлам бирде.

— Исәнмесез, иптәш тикшерүче!

Әхмеров кулын сузды. Шофер кулны боксерларча каты һәм нык итеп кысты.

— Миронов җибәрдеме?— дип сорады Әхмеров, машинада берәү дә юклыгын абайлап.

— Машинанымы?— диде шофер.— Әйе, ул. Үзе Өянкеле авылында калды. Моннан ике чакрымда гына. Гафу үтенде...— Ул тигез, ак тешләрен күрсәтеп елмайды. — Сез борчылмагыз. Без аны кайткан чакта үзебез белән алырбыз.

— Бер-бер хәл бармы әллә?

— Шулай, ахрысы. Урам буйлап килә идек, каршыга кулларын болгап, елый-елый бер хатын йөгереп чыкты. Алексей Иванович туктатырга кушты. Үзе шунда калды, ә мине, сезне каршы алыр өчен, монда җибәрде.

Шофер кабина ишеген ачты да:

— Әйдәгез, утырыгыз,— диде.

Әхмеров шофер янәшәсендә утырмакчы булган иде дә, анда участковый үзе утырырга тиешлеген уйлап алды:

— Рәхмәт, миңа артта әйбәтрәк булыр,— диде.

Ул кабинадан тәбәнәк кенә бүлем белән аерып алынган салонга утырды.

Машина элеваторны әйләнеп узды, тимер юл аша чыкты, агачлык арасыннан бераз баргач, тигез кыр башланды. Монда пычрак, урыны-урыны белән күлләвекләр булса да, юлны катырган иде әле.

Алдарак, калкулык башындагы авыл күренде. Аның артында очсыз-кырыйсыз сыман урман зәңгәрләнеп киткән.

Баштарак сүзчән кебек кенә күренгән шофер беренче булып сүз башларга кыенсынгандай, тын гына утырганлыктан, тикшерүче аңа үзе эндәште:

— Колхоз председателегез яшьме, картмы?

— Зубковмы?— дип җавап кайтарды шофер.— Алтмышлар тирәсендә. Агармаган бер бөртек чәче юк инде. Үзе нык адәм әле. Алексей Николаевич белән тату эшлиләр!

— Председатель белән каршылыкка килүчеләр дә бармыни?— дип хәйләкәр генә күзләрен кысты Әхмеров.

— Юк ла,— диде шофер уңайсызланып.— Алай дияргә теләмәдем. Бездә аларның икесен ике характерлырак дип исәплиләр, ә бер-берсе белән тиз аңлаштылар.— Ул елмаеп куйды.— Мин үзем дә баштарак шулай уйлаган идем. Зубков әйбәт кеше, киң күңелле, бүтәннәр белән уртак тел таба белә.

— Әйтүеңә рәхмәт!— диде тикшерүче ягымлы гына, үзенә нинди дә булса яхшылык эшләргә теләгәнлеге сизелеп торган бу егетне уңайсызландырасы килми иде аның. «Нинди әйбәт егет»,— дип уйлап куйды.

Ул арада авылга да килеп керделәр. Әхмеров урам уртасында басып торган бер кешене күрде. Бераз баргач, аның участковый икәнлеген танып алды.

Машина әле тукталып та өлгермәде, Миронов, кояштан чагылган зәңгәр күзләрен кыскалап, кабина янына килде.

— Мөхәммәт үзе янына тау килүен тиккә генә көтмәгән икән!— диде ул һәм Әхмеровка кулын сузды, шунда ук ягымлы елмаеп, күзләрен кыскалады.

Әхмеров поездда килгәндә күпме генә уйлап та хәтеренә килмәгән теге үзенчәлекне исенә төшерде. Участковый елмаер алдыннан, уңайсызлангандай, күзләрен кыскалый икән бит.

Алар, шунда ук әллә кайчангы танышлардай, сөйләшеп киттеләр.

— Каршылый алмавым өчен гафу ит,— диде Миронов, машина кузгалып киткәч.

Юлның ике ягыннан да имән урманы башланды. Гүя мәһабәт агачлар, яз сулышын сизеп, озак һәм каты йокыдан уянгандай, көчле кулларын һавага җәеп, теләр-теләмәс кенә киереләләр иде.

— Матур бит, әйеме,— диде Миронов, Әхмеровның тәрәзәдән карап баруын күргәч.

Тикшерүче башын какты.

— Әйе, монда урманнар шәп,— дип дәвам итте участковый.— Алар синең туган ягыңны искә төшергәндер, бәлки?— Миронов шигырь сөйләп китте:

Бик хозур! Рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат;
Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап...

Әхмеров аңа гаҗәпләнеп карады:

— Син Тукайны беләсеңмени?

— Русларга Пушкинны гына укыргамыни, синеңчә?

Әхмеров моңа каршы бер сүз дә әйтә алмады.

Шактый вакыт тын бардылар. Борылышка кергәндә машина нык кына селкетеп алды, шофер юри тавышын күтәребрәк эндәште:

— Мәхәббәт капкасына якынлашабыз!

— Костя, әкренрәк бар,— дип үтенде Миро[illegible] соң Әхмеровка борылды.— Шушы матурлыкка күз сал әле син!

Юл читендә күккә үрелгән ике имән арасында өрсәң сыгылырга торган нечкә каен үсеп утыра. Имәннәр бу нәфис агач өстеннән, үзләренең ботакларын бер-берсенә сузып, алышалар диярсең, гүя алар бу гүзәл кәйнең кемгә булырга тиешлеген хәл итәргә телиләр, тик һаман бер-берсен җиңә генә алмыйлар, әйтерсең, көчләр ике якта да бертигез иде

— «Мәхәббәт капкасы»— авыл кешеләренең горурлыгы ул!— дип аңлатты Миронов.— Халыкта аның турында төрле риваятьләр йөри.

Куе чыршы урманы белән әйләндереп алынган биек калкулык башында бүрәнә йортлар күренде.

Агач күпер аша узып, машина олы урамга килеп керде. Бераз баргач, кирпечтән салынган ике катлы йорт янына килеп туктады. Ишектәге язуларга карагaнда, бирегә авыл советы һәм колхоз идарәсе урнашкан иде.

— Колхоз председателе белән танышудан башлыйбызмы, әллә?— диде Миронов.

Әхмеров ризалыгын белдереп баш какты да аның артыннан иярде.

Председатель кабинеты икенче катта икән. Кабул итү бүлмәсендәге язу машинкасында нәрсәдер басып утырган мөлаем йөзле секретарь кыз керүчеләрне күрү белән җәһәт кенә урыныннан кузгалды.

— Рәхим итегез! Василий Петрович көтә үзегезне...— дип елмайды ул.

Аларны тәбәнәгрәк гәүдәле карт ишек төбендә үк каршы алды. Аның куллары аю тәпиедәй юан һәм көчле иделәр. Сөткә манчып алынгандай ак чәчләре кара тутлы йөзен тагын да ачыбрак күрсәтәләр, ә моржныкын хәтерләткән туры борыны астындагы чаларган мыегы тәмәкедән саргайган иде. Картның зәңгәр күзләре төбәп һәм беркатлырак карыйлар.

— Әхмеров Әхмәт Шәрипович? Шулай бит? Миңа район үзәгеннән шалтыраттылар инде. Үзем Зубков Павел Степанович булам,—диде ул аларга, түргә узарга күрсәтеп.— Ничегрәк килеп җиттегез?

— Рәхмәт, Павел Степанович! Бик әйбәт килдек!— диде тикшерүче почмактагы тумбочка өстенә куелган узган елгы бодай көлтәсен карап.

— Алайса, ярар!— диде Зубков эшлекле төстә. Ул карлыккан калын тавышлы икән.— Без дә монда махы бирмәскә тырышкан булабыз шунда. Үзегез күреп торасыз, монда да яз иртә килде. Җәй кызу булырга охшый. Өч ел буе мич башыннан төшә алмыйча хасталанып яткан Пахом бабагыз да урамга чыккан бит әнә. Трактор белән чәчкечләр хакында сорашты.— Ул, үзенең сүзләренә теләктәшлек көткәндәй, күзенең кырые белән генә участковыйга карады да кеткелдәп алды.— Мин сезне Полинканың хаты буенча киләсез дип ишеттем, дөресме бу?

Әхмеров баш какты.

— Әйе...— Председатель кашларын җыерып авыр сулады.

— Нигә алай уйланып калдыгыз? Бу мәсьәләгә карата үзегезнең дә кайбер фикерләрегез бармы әллә?

Ул арада бөдрә чәчле бер хатын-кыз ишектән башын тыкты да:

— Алексей Николаевич! Монда булуыгыз әйбәт булды әле! Сезне Прохор Ильич эзләде. Аңа бер минутка гына керсәгез иде!— диде дә шунда ук юк булды.

— Мин хәзер!— Участковый чыкты.

— Күрдегезме инде. Аңардан башка бер сәгать тә торып булмый. Участковый дигән сүз үзе генә дә ни тора,— диде Зубков.

Председатель, тәрәзә янына килеп, форточканы ачты, тәмәке кабызды. Трубкасын төтәтеп, канәгать бер кыяфәттә йөткерде дә Әхмеровка таба борылды.

— Элек бетән участокка район үзәгендәге кешеләр хезмәт күрсәтте. Теләсә кем килә иде. Аннан соң участковый штаты бирделәр. Башта Хаминов Иван Тимофеевич булды. Әйбәт эшләде, инфаркт кына харап

итеп куйды үзен, пенсиягә озатырга туры килде. Аннан соң безгә шушы участковыйны билгеләделәр. Алексей белән бик тиз генә килешеп тә китә алмадык. Эшли башлавына бер-ике атна үттеме-юкмы икән, керде дә: «Акча кирәк, Степаныч. Шактый кирәк»,— ди. Ә мин әйтәм: «Ул барыбызга да кирәк, җанкисәгем, үзем дә аңардан баш тартмас идем»,— дим. «Юк ла. Миңа түгел, ди бу, авылда терәк пункт оештырмакчы булам». Шул терәк пунктлар хакында сөйли башлады. Минем янда авыл советы председателе Прохор Ильич та бар иде. Сагаеп куйдык, кайдан килгән бу акыллы баш, эшли башлавына бер атна да булмаган, авылны тиз генә шәһәргә әйләндереп куймакчы, дип уйлыйбыз.— Зубков көлемсерәп, мыегын сыпырды.— Тыңлап-тыңлап карадык та түзеп кала алмадык. «Безнең акчалар да, синең терәк пунктың да җилгә генә очмасмы соң, бу бит сиңа такта кадаклау гына түгел»,— дибез. Лешка аптырап калмады. Күптән түгел генә бездә шундый хәл булган иде, бер шофер салмыш баштан машинасын аударып, кыйммәтле йөкне харап итте, үзе белән кабинада утырып барган кеше дә нык кына имгәнде. Миронов: «Сез үзегезне генә акыллы баш дип исәплисез икән, алайса инде менә шул вакыйганы гына мисалга алыйк»,— ди. Шоферны укытырга киткән акчаны да, зыян килгән машина белән йөк бәясен дә, эшкә яраксыз булып калган кешегә түләнә торган пенсия белән аңа хәтле алган хезмәт хакы арасындагы аерманы да үзебезнең экономист белән бергә тиенен тиенгә чутлап карадык. Бик зур сумма килеп чыкты бит. Үзара да сөйләштек, райондагы җитәкчеләр белән дә киңәшеп, терәк пунктын оештырырга булдык. Дүрт ай эчендә бинасын салдырдык. Миронов анда эшләүчеләрне объект төзелеп беткәнче күзеннән ычкындырмады. Шуннан соң, кешеләр җыеп, ниндидер оператив совет, отрядлар оештыра башлады.— Ул тагын көлде.— Бу эшкә мин картлачны да тартты бит әле. Каршы килеп булмады... Дөресен әйтергә кирәк, юкка тотынмаган икән. Колхозда менә дигән тәртип урнашты!

Председатель тагын бер тапкыр трубкасыннан төтен чыгарды да, аны кулында әйләндергәләп, көлен каккач, өстәл янына килде.

— Полинка турында сораган идегез бит әле. Мин үзем алка турындагы имеш-мимешләргә тамчы да ышанмыйм. Бөтен дәлилләр аңа каршы кебек күренсә дә, ышанмыйм. Полинаны әйбәт беләм бит. Бүтәннәргә караганда күп тапкыр артыграктыр да әле. Аның кулыннан килә торган эш түгел бу, түгел...

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, аксыл төстәге ыспай костюмының якасына депутат значогы таккан озын буйлы, ябык гәүдәле ир кешене ияртеп, Миронов килеп керде.

— Таныш булыгыз, Әхмәт Шәрипович. Ә бу безнең авыл советы председателе була инде.

— Шамаев Прохов Иванович!— дип елмаерга тырышты теге, һәм баһадир көченә ия булган кешедәй, саклык белән генә Әхмеровның кулын кысты.

Ул соргылт күзле, бераз гына очлаеп тәмамланган борынлы, алгарак чыккан иякле кырык биш яшьләрендәге кеше иде. Сыек коңгырт чәчләре арасыннан пеләшләнгән урыннар күренеп тора. Маңгай чәчләре бөтеркәләнеп кашларына хәтле салынып төшкәннәр.

— Килүегез бик әйбәт булды әле, Әхмәт Шәрипович,— диде ул утырышкач.— Без монда шактый кыен хәлдә калдык бит әле.— Шамаев, сүзен дәвам итәргә кыймагандай, кулларын бер-берсенә ышкып куйды. Зубков аның бу кыланышына өнәмичә карап торды.

— Хикмәт менә нәрсәдә, Әхмәт Шәрипович,— диде Шамаев.— Сез тикшерергә дип килгән элеккеге авыл советы председателе Васильева Полина Ивановнаның соңгы вакытлардагы үз-үзен тотышы бик тә сәер һәм һич тә түзеп тормалы түгел. Әгәр сез дә катнашырга риза булса-

гыз, иртәгә шушы мәсьәлә буенча авыл советы башкарма комитеты утырышын үткәрергә җыенган идек.

Әхмеров аптыраган кыяфәттә елмайды.

— Гафу итегез, Прохор Ильич, аңлап җиткермәдем бит әле. Әгәр сер булмаса, утырышта кем сыйфатында һәм нинди максат белән булырга тиешлегемне әйтсәгез иде.

— Без Алексей Иванович белән киңәштек тә...— Шамаев сүзләрендә буталды һәм борчылган кыяфәттә участковыйга карады.

Караңгы чырай белән моңа кадәр тын гына утырган Зубков сүзгә кушылды.

— Турысын әйт син, Прохор Ильич!— диде ул, өстәл артыннан чыгып, усал төстә. Бүлмә буйлап арлы-бирле йөренде дә тагын тәмәкесен кабызып суырды. Бераз тынычлангач, Әхмеровка аңлатып бирде:

— Прохор Ильич Полинканы депутатлыктан төшерергә җыена әле монда. Хәтта шушы мәсьәләгә карата комитет утырышы уздырырга тели. Ә кулы калтырана, куркасың. Дәрәҗәле иптәшләрнең яклавына мохтаҗ. Мәнә сезне дә үз ягына аудармакчы була...

— Павел Степанович, сез юкка алай дисез,— дип кашларын җыерды Шамаев.— Эшнең миндә тормавы үзегезгә яхшы мәгълүм бит... Васильевага кыен икәнлеген аңлыйм. Тик шул хәтле төшенкелеккә бирелергә дә димәгән. Үз эченә бикләнеп, бөтен җәмәгать эшләреннән читләште.

Авыл советы председателе борчылгандай сөйләсә дә, Әхмеров аның сүзләрендәге ясалмалыкны сизенде.

— Сессияләргә йөрүдән дә туктады бит! Бөтенебезгә бүре кебек карый. Нигә алай итә ул? Депутатлар бөтенесен күрә, бөтенесен дә күрә, Павел Степанович! Безгә дә, күз йомып, гел дәшмичә генә калыргамыни?

Шамаев галстугын ачу белән тарткалап куйды да сүзеннән туктап бодай көлтәсенә карады.

— Гәп сөйләргә маһир булуыгызны бөтенебез дә белә, Прохор Ильич,— дип мыгырданды Зубков.— Аның күңел ярасын аңлап, чын күңелдән сөйләшер өчен янына бер генә тапкыр булса да барып карадыгызмы?

Шамаев шелтәләгән кыяфәттә башын чайкап, елмайды гына.

— Ай-яй-яй, Павел Степанович! Кайчагында кызып китәргә яратасыз! Юкка бит, Васильева янына баруы кыен түгел миңа. Ләкин бу хәлемдә аның янына йөрүнең уңайсызлыгын аңлагыз сез. Полина Ивановна ирсез хатын. Ялгызы яши. Үземнең дә тол ир кеше икәнлегемне беләсез. Аннан соң хәзер мин билгәгән урында элек ул утырды. Бу эштән чыгуы да үз теләге белән булмады. Аның янына йөрүемне үзара килешер өчен генә йөри дип әйтмәүләренә гарантия бармы?

— Гарантия, килешү... Эх, Прохор Ильич, Прохор Ильич...— диде Зубков, хафалану белән, үзе тәмәкесен тартып бетерергә дип тәрәзә янына килде.

Сөйләшүне болай дәвам итүнең мәгънәсе юк иде, шуңа күрә тикшерүче әңгәмәгә нокта куяр өчен сүзгә кушылды:

— Мин сезне аңладым, Прохор Ильич,— диде ул эшлекле кыяфәттә.— Кызганыч булса да, бу утырышка килә алмам. Моның өчен ике сәбәп бар. Беренчедән, Васильева хакында һәм аның борчулары турында сездән, я булмаса, бу авылда яшәгән бүтән берәүдән артыграк белмим әлегә. Икенчедән, нәкъ шушы эшне тикшереп, тиешле карар чыгарыр өчен дип килдем, моның өчен вакыт кирәк...

— Күпме вакыт кирәк булуын әйтә алмассыз микән,— дип кызыксынды Шамаев. Йөзендәге елмаюы бетсә дә, ул һаман ачык йөзле булырга тырыша иде.

— Белмим,— дип иңнәрен җыерды тикшерүче.— Тик минем вакытым күп түгел...

— Башкарма комитет утырышын кичектерергә кирәк дип уйлыйсыз инде алайса?

— Әлбәттә!

— Алайса, хәл иттек.— Шамаев урыныннан торды.— Хәзер миңа китсәм дә ярый.

Ул, кергән чагындагы кебек үк, тикшерүченең кулын йомшак кына кысты да, чыгарга юнәлде. Ишеккә килеп җиткәч, кире борылды, һаман да тәрәзә янында басып торган колхоз председателенә эндәште:

— Минә күрәсезме, уртак фикергә гаугасыз да килеп була икән бит, Павел Степанович!— диде.

Зубков ни дип тә җавап кайтармады. Шамаев чыгып киткәч кенә өстәл янына утырды. Мироновтан:

— Кунакны кая урнаштырмакчы соң?— дип сорады.

— Үземдә торыр,— диде Миронов, уйлап та тормыйча.

— Дөрес итәсең. Икәүләп күңеллерәк тә, уңайрак та булыр.

### Дүртенче бүлек

Участок инспекторы авыл кырыендагы бәләкәй генә йортта яши икән. Янәшәдә генә чыршы урманы. Шунлыктан, ишегалдында һәм тирә-якта сумала исенең аңкуы да гаҗәп түгел иде.

Әхмеров, участковыйга ияреп баскычтан менгәндә:

— Әйбәт урын сайлагансың!— диде.

— Монда шәп шул, әкияттәге өйдә яшәгән кебек миңа. Һавасын сулап туймаслык. Син бирәр җәй көне килсәң икән!

Ул ишекне ачты, эчкә кереп, өйалдындагы утны яндырды да Әхмеровка эндәште:

— Уз, Әхмәт Шәрипович!

Өй эчендә җылы иде, Миронов, үзенә кеше киләсен белеп, мичкә ягып калдырган, күрәсең.

Ул, Әхмеровны диванга утыртып, үзе алгы якка чыкты да, кухня шкафы ишеген ачкалап-япкалап, савыт-саба зеңгелдәтә башлады.

Әхмеров тирә-ягына каранды. Китап шкафында В. И. Ленин хезмәтләренең берничә томы бар иде. Маркснын «Капитал»ы, Чехов, Толстой, Тургенев, Цвейг әсәрләре белән бер рәттән Габдулла Тукайның бәләкәй генә шигырьләр китабын да күреп алгач, елмаеп куйды һәм бая урман аша чыкканда ишеткән шигырь юлларын исенә төшерде. Аннан соң комод өстендә торган тар гына рам эчендәге ут чәчеп торган ягымлы карашлы кыз рәсеменә карап тора башлады.

— Кара әле, Әхмәт Шәрипович...— Ишек төбендә Миронов күренде. Кайчандыр милиция формасы белән киеп йөргән күлмәгенең түшен ачып җибәргән, җиңнәрен сызганган, иңенә сөлге салган. Фотография янында басып торган Әхмеровны күргәч, башлаган сүзен әйтеп бетермәде, аның янына килде.

— Бу йортның хуҗасы булачак туташмы әллә?— дип, рәсемгә ымлады Әхмеров.

— Әйе,— диде Миронов.— Бераз тын торгач, ачыклык кертте.— Пединститутның соңгы курсын бетерә инде. Көзен кайтырга сүз бирде. Бөтенләйгә...

Бәрәңге чистартканда сөйләшеп киттеләр.

Миронов МВД мәктәбен тәмамлагач, башта Новосибирск өлкәсенә җибәрелгән. Ул эшләгән шәһәрдәге милиция бүлеге начальнигы этисенең фронтташ дусты булып чыккан. Әтисе исән чагында бөтенесе дә әйбәт кенә булган. Әтисе үлеп киткәч, начальникның аңа карата булган мөнәсәбәте үзгәребрәк киткән. Мироновка чамадан тыш акыл өйрәтә башлаган, тегеләй итмә, болай эшләмә, янәсе. Бәлки ул якын дус-

тының малае хакында әнә шулай «кайгыртучанлык күрсәтмәкче» булгандыр? Тик үзенең игътибар үзәгендә булуы аның күңелен пошырган. Отпуск алгач, Идел буендагы шәһәрләр буйлап сәяхәткә чыккан. Казанда да булган. (Тукай шигырьләрен менә каян алган икән!) Ә сәяхәтенең ахырында Уфадагы абыйсына да сугылган. Ул да милициядә эшли икән. Аңа хәзерге эшеннән канәгать булып җитмәвен әйткән. Икәүләп уйлашканнар да, эшләгән җиренә кире кайтып, үзен бүтән якка күчерүләрен сораган. Шулай итеп, бирегә килгән.

— Элеккеге начальнигың белән бер дә хәбәр алышмыйсыңмыни?— дип сорады Әхмеров, сынагандай карап.

— Нишләп хәбәрләшмәскә ди! Хатлар язышабыз. Җире кайтырга чакыра. Тик беркая да китмим инде.

— Яңа җирдә ничегрәк соң? Бөтенесе дә шома гына түгелдер бит?

Участковый күзләрен челт-челт китереп елмайды.

— Башта шул хәтле күңелсез булды. Сагышка түзәр чама юк, күкрәкне телеп ала иде. Дусларны, әткәйне, элеккеге эшемне сагындым.— Миронов рәсемдәге кызга аеруча бер ягымлылык белән карады.— Ярый әле ул булды...

— Хәзер ничегрәк соң?— Әхмеровка бу егет торган саен ошый барды.

— Тәртип кебек. Өйрәндем. Кешеләренә дә, агач йортларына да, чыршы урманына да...— Ул кинәт җанланып китте, күзләреннән мут очкыннар сибелде.— Үзең дә беләсеңдер инде, эштә барысы да онытыла бит. Борчуларыңнан арыныр өчен аннан да шәбрәк дәва табармын димә инде. Мин юрфакның өченче курсында да укыйм бит әле. Кайчакларда күңелсез булгаласа да, ни эшлисең инде. Андый гына бөтен кеше белән дә буладыр.— Миронов шаярыбрак өстәп куйды:— Эч пошу галәмәте сине дә читләтеп үтмәс әле.

Әхмеров аңа гаҗәпләнеп карады.

— Син мине эчпошыргыч эш буенча килгән дип уйлыйсыңмыни?

— Нишләп алай диим? Андый эшләр юк, ә эчпошыргыч тикшерүчеләр булгалый менә. Тккшерү этикасында шулай диелгән түгелме соң?

— Әйе, ләкин хикмәт этикада гына түгел шул. Председатель кабинетында бүген булган сөйләшү кызыклы ситуацияләр булырга мөмкинлегенә ишарә ясамадымыни?' Зубков дигәннән... Васильеваны нигә шул хәтле яклый икән ул? Туганнармы әллә алар?

— Туганнан да якынрак. Полина бала чагында Зубковлар семьясында ике еллап яшәгән булган.

— Менә ничек? Монысын белми идем.— Тикшерүче әле яңа ишеткән бу яңалыкны күңеленнән тагын бер кат үткәреп, сорады:— Участковый буларак, бу хатын турында үзең ничегрәк уйлыйсың соң?

— Минме? Әйтик, Чезаре Ломброзо теориясенең киресен уйлаганда, Полина Ивановна андый җинаятькә барыр иде микән?

— Аңлап җиткермәдем,— диде тикшерүче.

— Бу психиатр бишектән арынмас борын ук әшәкелек гамәле генә кыла торган тар маңгайлы, җәлпәк борынлы кешеләр төрен китереп чыгарган, ди. Андыйлар булгач, аларга капма-каршы төрдәге кешеләр дә булырга тиеш бит. Васильева тышкы кыяфәтеннән әнә шул капма-каршы төркемгә керә...

— Җитдирәк әйтсәң?

— Җитди итеп әйтсәм инде...— Миронов уйланып калды.

Әхмеровка участковый озаграк җавап бирмәгәндәй тоелды. Ниһаять, ул сүзен ялгап китте.

— Мин, Әхмәт Шәрипович, кырт кисеп кенә җавап бирергә кыенсынам әлегә... Нигә дисәң, Бердников бу эшне тикшергән чагында имтиханнар тапшырырга киткән идем. Мин кайтканда ул бу эшне тәмамлаган иде инде. Бик алҗыган иде һәм бу алкалар хакында үзенең төпле

фикере дә бар иде шикелле. Булышырга теләсәм дә, ул риза булыр иде микән. Кыскасы, минем тегеләй-болай уйларлык сәбәпләрем юк...
— Минеке исә, киресенчә, бик күп,— диде тикшерүче авыр сулап.
— Нидән башларга уйлыйсың соң?— дип сорады Миронов.
— Васильеваны чакырудан...
— Ярар, аны иртә белән синең янга җибәрермен. Үзем урманчылык хуҗалыгына китәм. Төшкә бәлки кайтып җитәрмен...
— Кайда күрермен соң мин аны?
— Терәк пунктта. Ул моннан ерак түгел. Ачкычны кая куярга икәнен күрсәтермен... Кичке аш әзер дә булды түгелме соң?
— Әйе шул. Бәрәңге дә, тәбә дә менә дигән...

## Бишенче бүлек

Йөзенең төсе китмәгән булса һәм күз төбендә күгелҗем сызыклар күренмәсә — болар озак вакытлар дәвамында борчылу аркасындадыр инде — Васильеваны матур дияргә булыр иде. Ул озын гына зифа буйлы икән, өстенә аксыл-көрән пальто, аякларына шундый ук төстәге итекләр кигән, ашыкмый гына кабинетка килеп керде дә, ишетелер-ишетелмәс итеп сәлам биреп, ишек катында басып калды. Икенче кат чакыргач кына Әхмеров янындагы урындыкка килеп утырды. Күзләре төбәп карыйлар, аларда уйлану һәм борчылу галәмәтләре сизелә.

Васильевага утыз яшь икән, тик аңа ул хәтле биреп булмый иде әле. Ул монда кергәнче үк башыннан салган чәчәкле юка яулыгын йомарлап, тын гына утыра һәм сүз башлауларын көтә иде. Үзен бирегә чакырып сөйләшергә кирәк тапканнар икән, сүзне беренче булып башларга нияте юк кебек...

— Мин — тикшерүче Әхмеров булам. Сезнең эшегез буенча килдем,— диде Әхмеров һәм кәгазьләр теркәлгән калын гына папканы өстәлгә алып куйды.

Васильева эндәшмәде.

— Сез куанмыйсызмыни?— дип, сак кына сорап куйды тикшерүче.

— Юк, нигә алай булсын?— диде ул, теләр-теләмәс кенә елмаеп.— Сезгә хәтле булган коллегагызның да үзе белән шулайрак таныштырганлыгы исемә төште.

— Бердниковмы? Белмәдем бит. Башкачарак әйтер идем.

— Башкачарак та әйтергә була...— диде хатын пышылдап кына диярлек. Кинәт, башын сәер генә чайкап алды да, калтыранган кулларын тикшерүче алдына өстәлгә куйды һәм ашыга-ашыга сөйләп китте:

— Иптәш тикшерүче... Иптәш Әхмеров... Соңгы көннәрдә мин күп уйландым. Дөреслек һәм нахак хакында, кешеләр турында. Үзем, үткәнем, киләчәгем хакында. Уйларга мөмкин булган бөтен нәрсә турында да. Беләсезме, нинди фикергә килдем? Боларның бөтенесе дә юкка гына бит. Бу тикшерүләр, сорау алулар, исәпсез-хисапсыз кәгазь җыюларның хаҗәте юк бит. Чыннан да, нәрсәгә алар?— Аның күзләреннән яшьләре атылып чыкты. Ул аларны яулыгы белән сөртеп алды.— Китегез, зинһар өчен дип сорыйм. Мин иртәгә үк район үзәгенә барып, гаризамны кире алам...

Тикшерүче аның тынычланганын көтеп торды, аннан соң аптыраганрак кыяфәттә әйтте:

— Мин сезне аңлап бетермим әле, Полина Ивановна. Үзегез хат язып, ярдәм итүебезне сорагансыз. Ихтимал, озак вакытлар уйлаганнан соң гына шулай итәргә булгансыздыр. Бу вакыйга ничәмә айлар элек булган бит. Ә хәзер...

— Әйе, язган идем. Могҗиза булмасмы дигәндәй... Бүтәнчәрәк башланып китмәсме, дип уйлаган идем. Әйбәтләп тикшерерләр, Мәскәүдән килерләр, дип...

— Нигә Мәскәүдән килсеннәр ди әле? Ә, әйе... Башкала, югары осталык... Шуларны күздә тоткан идегезмени?

Тикшерүче уйланып калды. Райком секретаре кабинетында Васильеваның хатын укыган чагында ук ул аның капма-каршы холыклы булуын: эчкерсезлек-астыртынлык, тормыш тәҗрибәсе — беркатлылык белән аралашканлыгын чамалаган иде. Хәзер ул моңа тагын бер кат ныклап ышанды. Васильеваның башкаладан тикшерүче килер дип өметләнгән булуы аны аз гына да гаҗәпләндермәде. Башларына төшкән бәладән олы шәһәрләрдә һәм оешмаларда эшләүче атаклы тикшерүчеләр, адвокатлар ярдәмендә котылырга тырышу очраклары сабыр табигатьле, тотнаклы кешеләр арасында да булгалый. Тикшерүче булып икенче генә ел эшләгән чагында, җинаять урынын карарга баргач, зыян күрүченең әтисе, мәһабәт кыяфәтле ир кеше, аңа карап-карап торды да, үзе янында басып торган әңгәмәдәшенә: «Бу малайдан башка кеше тапмадылар микәнни?»— дип әйтеп куйды. Икенче көнне ул бу ир кешене прокурор кабинетында күрде. Ышанычлы һәм авторитетлы тикшерүче таптырып маташкан. Бер атнадан килеп гафу үтенде тагын...

Тикшерүче Васильевага маңгай астыннан карап алды да үпкәсез генә әйтеп куйды:

— Болай уйлавыгыз нигезсез дә түгелдер бәлки, Полина Ивановна. Шулай да, нигә алай еракка китәргә соң? Башкаланың үз мәшәкатьләре дә җитәрлек бит. Сүз уңае булгач әйтим әле, Мәскәүдә минем белән университетта укыган ике дус егетем эшли...

Васильева тикшерүченең хәтерен калдырырдай сүз әйткәнлеген сизеп, кызарынды һәм иренен тешләде.

— Зинһар, гафу итегез,— диде ул, яулыгын тезләренә куеп, һәм кайнар яңакларын учы белән кысты.— Бөтенләй сүзгә мавыгып киткәнмен. Алай дияргә теләмәдем мин. Осталык монда әллә нәрсә түгел. Тик... Тик бу бөтен кешене дә ялыктырды бугай. Бердников Павел Федорович ике ай дәвамында тикшерде бит. Менә хәзер сез... Әллә бу...

Ул кашларын җыерды, ләкин тиешле сүз таба алмагач, авыр сулады һәм, башын аска иеп, урындыкка сеңде.

— Сәбәп шул гына икән, дөрестән дә баш ватып торасы юк.— Тикшерүче бармаклары белән өстәлне шакып алды.— Эшкә керешсәк әйбәтрәк булмасмы?

— Яхшы,— диде Васильев.— Сез, мөгаен, миннән сорау алмакчыдыр инде.

— Әйе, кызганычка каршы, тикшерү фәне хакыйкатьне эзләүнең бүтән ысулын уйлап таба алмаган шул әле,— дип елмайды Әхмеров.— Хәзер дә безнең арада әңгәмә бара дип уйларга була инде, Полина Ивановна. Бары әңгәмә генә. Минем сорауларым сезне уңайсызландырмасын. Журналистлар да сорау бирәләр бит, аларга беркемнең дә хәтере калмый.

Васильева, сезнең сорауларыгызны беләбез инде, дигәндәй, тыенкы гына елмайды.

Тикшерүче берни дә сизмәмешкә салышты, алдында яткан әлеге дело тышына карап куйды да:

— Үзегез турында сөйләгез,— диде.

— Үзем турында?— дип гаҗәпләнде Васильева.— Кызыклы булыр микән соң ул сезгә? Минем биографиямдә...— Ул кинәт сүзен бүлде, тик әле генә тикшерүчегә биргән вәгъдәсен хәтерләп, дәвам итте:

— Тыңлагыз алайса... Өянкеледә туганмын мин. Станциягә җитәргә өч чакрым кала урнашкан бәләкәй генә бер авыл ул. Монда килгәндә, аның аша да үткәнсездер. Минем балачагым менә шунда үтте инде. Әгәр дә әткәем белән әнкәем бүтән төрлерәк булсалар, балалык елларымны бәхетле дияргә дә мөмкин булыр иде. Начар кешеләр икән дип уйламагыз тагын. Бик диндар иде алар. Кичләрен дин тотучылар

безнең өйгә җыелалар. Кем генә булмый алар арасында! Ә җырлары... мәетләр ыңгырашуы кебек хәзер дә колагымда яңгырый. Мәктәптә уку, пионер җыелышларына йөрү һәм хәтта гади дуслыкның да миңа ни бәягә төшүен күз алдыгызга китерсәгез иде.

Бераз тын торгач, ул тагын дәвам итте:

— Безнең шушы председатель Павел Степанович булмаса, белмим, нәрсә белән беткән булыр иде икән. Бервакытны өйдә яңа гына гыйбадәт кылу башланган иде, безгә килеп керде дә бөтенесе алдында әйберләремне җыеп үземне алып та китте. Ул чагында түшенә бөтен орденнары да беркетелгән капитан формасын киеп йөри иде, шунлыктан аңа каршы килергә кыймадылар. Аның үзенең балалары юк иде. Хатыны Евгения Петровна мәктәптә укытты. Нинди әйбәт кешеләр икәнлеген белсәгез икән! Аларда ике елга якын яшәдем. Аннан соң әткәем белән әнкәем, аның аяк астына егылып, мине кире үзләренә кайтарып бирүен сорап ялвардылар, аллага табынучы кешеләр белән бөтенләй дә аралашмаска сүз бирделәр. Павел Степанович ышанды. Бәлки аның күңелен күз яшьләре кузгаткандыр, аннан соң ул моның закон буенча эшләнмәгәнлеген дә белә иде. Яңадан туган йортымда яши башладым. Болай алар үз сүзләрендә торган кебек тә булдылар, бездә бүтән җыелмадылар да, җырламадылар да. Тик һаман, миңа сиздермәскә тырышып, аллага табынуларын һәм икона алдында бил бөгүләрен дәвам иттеләр. Кайчагында миңа баллы прәннекләр бирәләр, иркәләгән булалар. Менә шулай үстем...

Ул уйланып калды. Өстән-өстән генә сөйләгән булса да, еракта калган балачагының күңелсез хатирәләре яңадан күңелен астын-өскә китереп ташладылар, ахрысы.

Әхмеров Васильеваны ашыктырмады.

— Бу караңгылыктан мин җиденче классны бетергәч кенә котыла алдым,— дип дәвам итте сүзен. Аның тавышы ныгый төште.— Һөнәр училищесына укырга кердем. Токарьлыкка өйрәнгәч, Казагыстанга киттем. Аннан соң Иркутск, Магнитогорск шәһәрләрендә эшләдем. Магнитогорскида кияүгә чыгасы кешемне очраттым. Сергей исемле. Күңеле әйбәт иде, шуңа күрә тартылганмындыр инде үзенә. Физик яктан таза, көчле кешеләр дә ихтыярсыз булгалый икән. Сережа шундыйлардан иде. Мин башта моның никадәр куркыныч икәнлеген аңламаганмын...

Ул эрнеп елмайды, тик үзен кулга алды...

— Гаиләбезгә беренче олы хәсрәт килде — өч яшьлек кызыбыз үлде. Иремнең характер йомшаклыгы шунда күренде. Эчә башлады. Бу юлы безне бер вакыйга коткарып кала алды әле. Әткәйдән хат килде. Әнкәй әлегрәк вафат булган иде, хәзер инде әткәем дә каты чирләп киткән икән. Хатында ул үзен җиргә иңдерер һәм ятим калган мал-мөлкәткә хуҗа булыр өчен дип безне авылга чакырган. Кайттык. Комбайнга утырдым, Сергей ремонт мастерскоена урнашты. Тормыш җайга салына төшкәндәй булды. Әткәй үлгән генә иде, Сергей шуны гына көткән диярсең, шәбрәк яшәү өчен күп акча эшләп кайту турында сөйләнә башлады. Үзе кебек дусларын тапты, машина алырга хыялланды. Тагын бөтенесе бутала башлады...

Әхмеров аны игътибар белән тыңлады. Бу хатынның чибәр йөзендә, кул хәрәкәтләрендә кичергән борчуларның ничек аермачык чагылып китүенә гаҗәпләнеп утырды. Аның һәр буыны, һәрбер нерв җепселе әле әкрен, әле ашыга-ашыга борчылып типкән йөрәгенә буйсыналар кебек иде. Сөйләгәндә ул каршында утырган тикшерүче барлыгын да күрми шикелле...

— Бервакыт Якутиягә җибәрү өчен эшчеләр туплануы турында белдерү басылган газета тотып кайтты бу. Китмә дип шул чаклы үгетләдем, тыңламады. Барып җиткәч, әйбәт кенә урнашуын, акча шәп төшүен хәбәр итте. Аның кайтуын көткән арада, авыл хуҗалыгы техникумына

укырга кердем. Укыгач, вакыт тизрәк үтә бит. Шулай итеп көннәр әкренләп булса да уздылар...

Сөйләүченең авыр сулап куюыннан тикшерүче фаҗигале чишелеш буласын сизенеп, сагайды. Кашларын җыерды. Васильева берьюлы әйтеп бетерим дигәндәй, дәвам итте:

— Сережадан кайтам дигән телеграмма килү белән аны каршы алырга хәзерләнә башладым. Ә икенче көнне бүтән эчтәлекле телеграмма китерделәр. Бусы — Чиләбедән иде. Мине шунда ук прокуратурага чакыртып алдылар. Сережаны юлда үтергәннәр икән. Ресторанга кереп таныш булмаган кеше белән бергә эчкән дә, теле чишелгәч, Якутия турында сөйләгән, үзендәге акчалар белән мактанган. Тегесенең форсатны ычкындырасы килмәгән, фатирына чакырган... Болар барысы да мина куркыныч төш кебек кенә хәзер. Йөрәгемнең ничек чыдаганлыгына аптырыйм. Бераздан соң тормыш әкренләп булса да җайга салына башлады. Техникумны тәмамлагач, Олы Карамалыга күчеп килдем. Авыл советына сайладылар. Менә нибарысы шул, Күргәнегезчә, биографиям әллә нәрсә түгел инде. Кайгы да хәсрәт.

Әхмеров йомшак кына әйтеп куйды:

— Мин болай димәс идем. Биографиягезнең якты битләре дә күп булгандыр. Мәсәлән, миңа берничә ел элек орден белән бүләкләнүегез турында билгеле!

Васильеваның йөзе балкып китте.

— Булган иде шул,— диде ул эчкерсез төстә.— Тик тормыш бер алдын күрсәтсә, биш артын күрсәтә, дигәндәй...

Әхмеров сүзне төп мәсьәләгә күчерде.

— Полина Ивановна, сез Уварова белән күптән таныш идегезме?

Васильева сискәнеп китте.

— Уварова беләнме?— дип сорады ул.— Әйе. Ата-анам кебек үк, ул да аллага табына иде. Өянкеледә яшәгән чагымда тәңре эшләре белән килгәләде. Әткәй үлгәч, килүдән туктады. Олы Карамалыга күчкәч, элекке гадәте буенча, күрәсең, кергәли башлады. Вак-төяк йомыш белән...

Тикшерүчегә ул нидер әйтеп бетермәгән кебек тоелды.

— Аның тарафыннан үзегезгә карата дошманлык яисә яратмау-фәлән кебегрәк нәрсә сизелми идеме?

Васильева, «юк», дигәнне аңлатып, башын чайкады.

— Нигә бүтән нәрсә түгел, нәкъ менә алкалар куярга булган икән соң ул?

Тикшерүче «куярга булган» дип юри әйтте, моның белән ул Васильевага бу сүзне үзенчәрәк аңлап җавап бирергә мөмкинлек тудырырга теләде. Болай итү туры җавап хаҗәт булмаган очракта, әңгәмәдәшне уйландыру һәм хаклыкны эзләп табуда үзенең дә катнашуы кирәклегенә ышандыру өчен кулланыла торган ысулларның берсе иде.

— Белмим,— дип тыенкы гына җавап бирде Васильева, аның күзләре кырысланды, маңгаенда сай гына буразна барлыкка килде.— Бәләкәй чагымда минем бик тә алка киясем килде. Әнкәйдән сорамаган көнем булмагандыр. Ул гел ачулана иде, бервакыт, күңелемне кайтару өчендер инде, теге дөньяда колагын тиштергән кешеләргә генә була торган коточкыч газаплар турында сөйләде. Мин үч итеп икенче көнне үк, елый-елый үтенеп, күрше Серафима түтидән колагымны тиштердем. Әнкәй барыбер тактырмады. Алка киюне ходай тәгалә хупламас дип курыкты. Үзем үсеп, сатып алырга хәлем җитә башлагач та киеп булмады, әле оялдым, әле сайлый белмәдем. Шулай тишек колак белән гомерем үтте.— Ул колак яфракларын тотып карады да көлемсерәде.— Ничектер бу турыда Уваровага сөйләгән идем шул. Менә шулай «куандырмакчы» булгандыр инде...

— Аңлашылды,— диде тикшерүче.— Мин хәзер протокол тутырыйм инде.

Бу эшне бетергәч, Әхмеров икенче биткә чыкты.

— Бердников алып барган сорау алу вакытында сез Уварованың судка берничә көн кала өегезгә керүен әйткән булгансыз икән. Моның турында җентекләбрәк сөйләсәгез иде.

Васильева ничектер бөрешеп китте һәм арыган кыяфәттә күзләрен йомды.

— Хәтерем ялгышмаса, суд булырга ике атналап калгач бугай,— диде ул, авыр сулап.— Үзем генә идем, чоланга он алырга чыктым. Шул чакны Уварова килеп керде. Чолан ишегенең ачык икәнлеген күргәнгәдер бәлки, өйалдыннан гына миңа эндәште. «Женя түти, кирәгез, мин монда!» — дим. Мин он алган арада ул чолан ишеге төбендә басып торды, аннан соң ияреп өйгә керде. Залга чакырдым, тик ул алгы бүлмәдәге урындыкка гына утырды.

— Сандык шунда тора идеме?— дип сорады тикшерүче.

— Әйе. Онны кухняга кертеп чыктым да аның каршындагы сандык читенә утырдым. Уварова милициягә хәбәр иткәнем өчен бәддога укырга, каргыш белән куркытырга тотынды. «Ярар, Полинка,— диде ул, ачуыннан бер бүртенде, бер күз яшьләрен түкте,— иблис котырыгына бирелеп, җаныңа гөнаһ алдың. Син хәзер аңардан арын. Бәләкәйдән үзеңне белүебезне, атаң-анаң белән бер савыттан ашавыбызны исеңә төшер. Буш итмәбез...» Кыскасы, безнең арада күңелсез сөйләшү булды. Әгәр мин, чыгып китәргә кушып, ишеккә күрсәтмәгән булсам, тагын әллә ниләр әйткән булыр иде әле. Уварова мине каһәрли-каһәрли чыгып китте. Аны бүтән күрмәдем.

Тикшерүче, үзе ишеткән һәр сүзне үлчәп карагандай, бераз дәшми утырды. Аннан соң:

— Полина Ивановна, Уварова алгы бүлмәдә утырганда кухняда озак булдыгызмы?— дип сорады.

— Шунда ук кире чыктым.

— Һәм сез, үзегез юктан файдаланып, Уварова алкаларны сандыкка салмагандыр, дип уйлыйсызмы?

— Шулай әлбәттә. Секундлар гына үтте бит. Сандык өстендә футляры белән тегү машинасы тора иде, аны алып куймасаң, капкачны ачып булмый. Алкалар бит анда теләсә ничек кенә куелмаган, әйберләр арасына бик әйбәтләп яшерелгән иде.

— Әйе шул,— дип килеште Әхмеров.— Сез чоланда чагында өй эченә кереп чыгып, әле генә кергәнлеген белдерер өчен эндәшү ихтималы да юк идеме?

— Юк, юк. Мин капка ачылганда эт өргәнен ишеттем.

— Сезнең этегез бармыни?

— Бар. Бонька.

— Бонька? Исеме кызык.

— Карт инде ул. Әткәемнән калган иде.

— Этлеген дә итми, өйне дә каравылламыймыни?— дип көлемсерәде Әхмеров.

— Пенсиягә чыгаруны сорый.— Васильева да аңа каршы елмаеп җавап бирде.— Ә өрүе шәп.. Төннәрен, танымаган очракта, аягыннан эләктереп алырга да күп сорап тормый.

— Бусы аңлашылды. Суд процессына дүрт көн калгач, сез район советы сессиясенә баргансыз, кунып та калгансыз икән.

— Әйе шул. Сессиядән соң миңа кайбер нәрсәләрне хәл итәргә кирәк булды, шунлыктан поездга соңладым.

— Өйгә кайткач шикләнерлек берни дә сизелмәдеме?

— Сез нәрсәне күздә тотасыз?

— Фатирыгызга яшертен генә берәрсе керү ихтималы булгандыр дип уйламадыгызмы?

— Бөтенесе дә тәртиптә иде бугай. Тәрәзә белән ишекләр шул килеш, йозак үз урынында иде. Аннан соң йозакны бүтән кеше ача алмый, аны ирем, без генә ача торган итеп, үзе ясады. Юк, өйгә берәү дә кермәгәндер дип уйлыйм.

Әхмеров, Васильева күрсәтмәләрен протоколга язып алгач, бүгенгә житәр, дип уйлады. Ул Васильеваның менә-менә елап җибәрергә әзер торганлыгын сизде, ә моның алдагы сөйләшүләрнең һәм очрашуларның өзелүенә китерүе мөмкин бит. Үзенә дә ял итеп алырга кирәклеген тойды.

Протоколны Васильева алдына куеп:

— Укып чыгыгыз да менә монда кулыгызны куегыз,— диде.

Рәсми өлешне тәмамлагач, ул кәгазьләрне портфеленә тыгып куйды.

— Бүтән тоткарламыйм инде сезне, Полина Ивановна. Китә аласыз.

Васильева урыныннан кузгалды да әкрен генә атлап ишеккә юнәлде. Чыгар алдыннан кире борылды:

— Юкка гына башламадым микән бу эшне?

— Белмим. Әлегә берни дә әйтә алмыйм,— диде тикшерүче.

Ялгыз калгач, Әхмеров уйга чумды.

Менә аларның беренче очрашуы да тәмам булды. Ул аңа нәрсә бирде соң? Бүген ишеткәннәрнең күбесе бу хатынның намуслы икәнлеген сөйлиләр шикелле. Алкалар турындагы теге эпизодны гына алыйк. Бала чагында төшләренә кереп йөдәткән һәм ахырдан болай да җайга салынмаган тормышына күләгә төшергән. Моны сөйләве аның туры сүзле, саф күңелле булуын күрсәтмимени? Ә Уварованың серле рәвештә өенә килеп керүе? Васильеваның күңелендә әз генә кер булса да, ул аны үз файдасына бора алыр иде. Бердников үзе бит моны җинаять эшен тикшерүне туктатырдай җитди сәбәп итеп санаган. Яки үзе өйдә юк төнне... Әйе, монда әшәке очраклылык турында үзеннән-үзе уйларга туры килә. Әллә минутлык йомшаклыкмы? Көчле ихтыярлы кешеләрне дә тәртәдән чыгара торган кызыгумы бу? Әйе... Әйтик, барысы да урынында калды, ди. Сандык та. Алка да, Уварованың гаризасы да. Барысы да беренче тәэсир генә булды. Кайчакларда шул кадәр алдавыч була торган нәрсә ул беренче тәэсир...

Участковый кабинетында инде ике сәгатьтән артык утырса да, әле бүлмәне әйбәтләп карамаганын уйлап, тикшерүче өстәл артыннан чыкты.

Зур, якты тәрәзәләр. Тәрәзә төпләрендә, стена һәм тәрәзә араларындагы бизәкле савытларга һәм балчык чүлмәкләргә гөлләр утыртылган. Стенаның яртысын карта алып тора, ул үзе хезмәт күрсәтә торган участокныкы булса кирәк. Ә бу нәрсә икән? Әхмеров зур булмаган витринага иелде. Монда игътибар итәрдәй әйберләр бар иде, аңлатмалар да язылган. Укый башлады: «Толкуновның үзе ясаган финкасы»... «Караваевларның сараен ваткан лом». Бер үк төсле ике пуляга игътибар итте — берсен ниндидер Ишмаевтан тапканнар, икенчесен атып үтерелгән поши гәүдәсеннән... Бәләкәй генә музей диярсең.

Әхмеров китапларны карады, суд фотографияләре ябыштырылган калын альбомны актарды. Һәм үзенең бу кечкенә генә сәяхәтеннән канәгать булып, урынына килеп утырды.

Гадәттә, Әхмеров яңа танышларына тиз ияләшеп китә алмый торган иде. Тик бу юлы ул нилектән икәнен белеп җиткермәсә дә, Мироновны шунда ук ошатканлыгын аңлады. Гади. Акыллы. Эчкерсез... Тикшерүче елмайды. Тик менә кичә туры җавап бирмәде. Әллә нинди Ломброзо һәм ниндидер фәлсәфәгә кереп китте. Бу аның бәләкәй генә хәйләсе булгандыр, бәлки. Хәйләкәр булмасаң, нинди участковый ди син!..

Телефон шылтырады. Әхмеров трубканы алды.

— Алексей Михайловичмы?— дип сорады ир кеше әдәпле генә.
— Юк, тикшерүче Әхмеров булам.
— Ә-ә, Әхмәт Шәрипович, исәнмесез! Шамаев борчый иде сезне.— Әхмеров авыл советы председателенең тавышын таныды.
— Исәнмесез, Прохор Ильич! Мин тыңлыйм сезне!
— Эшләр ничегрәк бара? — дип үз иткәндәй сорады председатель.— Йомгаклау сүзегезне тиздән ишетербез микән?
— Барысы да әйбәт кенә әлегә. Ә йомгаклау сүзенә килсәк, иртәрәк бит. Ашыгуның мондый эштә файда китергәне юк.
— Анысы дөрес,— дип килеште Шамаев. Һәм юмакай тавыш белән генә сорады:— Сез үзегез генәме анда?
— Әйе. Нәрсә бар?
— Миңа бер мәсьәлә хакында сөйләшеп алырга кирәк иде. Аның сез тикшергән эшкә турыдан-туры мөнәсәбәте бар.
— Рәхим итеп килегез, Прохор Ильич!
— Яхшы. Мин бер ун минуттан булырмын!
Шамаев, чыннан да, тиз килеп җитте. Кулына матур кара папка тоткан. Чишенеп тә тормыйча түргә үтте, тагын бер тапкыр исәнләште, аннан соң, папкасын өстәл өстенә куеп, урындыкка утырды. Эшләпәсен салды, ашыгып килгәнлектән тирләгән маңгаен кулъяулык белән сөртте.
— Минем сезнең янга килүемне төрлечә фараз кылырга булуын да һәм үз файдама булмаска мөмкинлеген дә әйбәт аңлыйм — диде ул, һәр сүз саен ашыкмый гына тукталыш ясап.— Шулай да килүем намусым кушканга дип ышандырасым килә. Мин Полина Ивановнаны чын күңелдән хөрмәт итәм. Ышаныгыз! Ләкин, борынгылар әйтмешли, хаклык кайчагында дуслыктан кадерлерәк...
Әхмеров аны әңгәмәнең асылына төшенергә тырышып тыңлады. Ниһаять, Шамаев папкасын ачты, аннан ниндидер кәгазьләр чыгарды.
— Менә карагыз әле!
Таушалып беткән ике хат иде бу. Берсеннән — хатынының Уваровадан илле биш сум түләп кофта алганлыгы, ләкин аның үз бәясе утыз сум гына икәнлеге мәгълүм булды, аны артык түләнгән акчасын кайтарып алуда булышуларын үтенеп, Феофанов дигән кеше язган икән. Хатның икенчесе озынрак, кемнән икәнлеге дә билгесез. Ул Уварова һәм аның кызы белән кияве Кожемякинга кагылышлы иде. Хатта аларның бәяләрен арттырып саткан кием-салымнары турында фактлар китерелгән. «Харам мал җыюдан кайчан туктарлар икән болар?»— диелгән иде ахырында. Хатның сул як почмагына тигез матур почерк белән: «Депутат иптәш Хаминовка. Тиз арада тикшерүегезне сорыйм», дип язып куелган. Подпись Васильеваныкы. Ике хат та Уварова һәм аның кияве өстеннән суд процессы башланырга дүрт ай кала язылган.
— Алай...— дип сузды тикшерүче.
— Бу кәгазьләрне мин Васильева өстәлендәге иске документларны актарганда очраклы рәвештә генә таптым,— диде Шамаев.— Аларның кайчан һәм ничек кулына килеп керүен Полина Ивановна үзе генә белә булыр. Һәрхәлдә, мин секретарьдан моны ачыкларлык нәрсә ишетә алмадым.
— Сез аларны кайчанрак таптыгыз соң?
— Кайчан дисезме? — Шамаев буталды.— М-м... Биш-алты көн элек бугай. Ни эшләтергә кирәклеген башта уйлап та җиткермәдем. Аннан инде сез килдегез.
— Аңлавымча, Прохор Ильич, сез бу кәгазьләрне, тикшерәсе эшкә кагылышлы буларак, миңа күрсәтергә булдыгыз, шулай бит?
— Анысын үзегез карагыз инде, Әхмәт Шәрипович,— дип кулларын җәйде Шамаев.— Намусым ничек кушса, шуны гына эшләдем.
— Алайса, мин протокол язарга тиеш.
— Нинди протокол?

— Бу документларны сездән алуым турында. Пүнәтәйләр кирәк булыр.

— Сез нәрсә!— дип хәвефләнеп каршы төште Шамаев.— Берүк алай итә күрмәгез. Полина Ивановнаның, Павел Степанович һәм бүтәннәрнең күзенә ничек күренәсем турында уйлагыз сез. Барысы да, капкын куеп, Полина Ивановнаны авыр хәлдә калдырырга җыенам дип уйларлар.

— Мине дә аңлагыз, Прохор Ильич, бу хатларны язгы ала каргалар алып килде дип әйтә алмыйм бит инде.

— Шулай, әлбәттә,— диде председатель.— Тик бүтәнчәрәк законлаштыру юлы бардыр бит?

Тикшерүче уйланды.

— Ярар, алайса,— диде ул.— Кыска гына аңлатма языгыз. Бу хатларны кайдан табуыгыз һәм ни сәбәпле безгә бирүегезне күрсәтегез.

— Менә бусы ярый,— диде Шамаев тынычланып. Шунда ук папкасыннан чиста кәгазь бите алды, иреннәрен тавышсыз гына кыймылдатакыймылдата яза башлады.

— Тик, серне чишмәгез инде,— диде ул ялагай тон белән.— Югыйсә монда урман ягы, башкисәр халык бит. Борылырга да өлгермәссең, китереп сыларлар.

Ул Әхмеровка ярарга тырышып елмайды.

— Борчылмагыз,— дип җавап бирде тикшерүче.— Сез теләгәнчә булыр. Зур рәхмәт.

«Шушы гына җитмәгән иде», дип уйлады тикшерүче, үзе генә калгач. Әйе, бу очучыларның юлында очрый торган өермә кебек көтелмәгән бер нәрсә иде. Ул өермә сине аска да, өскә дә ыргытып җибәрә, аңардан котылыр өчен элекке биеклекне яңадан яуларга кирәк була.

Ике хат. Бу вакыйганың бөтен серләре аларда яшерелгәнме әллә? Тайга күлен хәтерләткән тирән зәңгәр күзле бу хатын әллә чынлап та...

Ишек әкрен генә ачылып ябылды. Миронов кергән икән.

— Уйланып утыра идеңме?— диде ул, шинелен салып.

— Әйдә, уз, Алексей,— диде Әхмеров куанып. Бу егет белән киңәшеп алу аңа хәзер бик кирәк иде. Туган фикерләр агышын берүзең генә рәткә салып, ерып чыгарлык түгел.

Миронов өстен салды да әле генә Шамаев утырып торган урындыкка килеп утырды.

— Берәр яңа нәрсә килеп чыктымы әллә?— дип сорады ул.

Тикшерүче хатларны аның алдынарак этте.

— Менә кара әле.

Миронов укый башлады. Аның кызларныкы кебек нәфис һәм матур йөзе хәрәкәтсез иде. Тик маңгаенда һәм яңак сөягендәге нечкә тамырлары сизелер-сизелмәс кенә селкенеп куйдылар.

Ниһаять, ул кәгазьләрдән башын күтәрде.

— Алай икән,— диде бераз гаҗәпләнеп.— Монда язылганнан да артыгын әйтеп булмый инде. Әле генә минем каршыга Прохор Ильич очрады. Синнән чыгуы идемени?

— Әйе. Тик хәзергә бу үзебезнең арада гына калсын. Син бу кеше турында ни әйтерсең?

— Шамаевмы? Шәп эшли. Үзен җәлләми. Акыллы. Кайчандыр аспирантурада да укыган бугай. Ә менә күңеленең ничеклегенә килгәндә, төрле кеше төрлечә фикер йөртә...

— Бирегә ниндиерәк уй белән килгәнен әйтә алмассыңмы?

— Миңа калса, үзенә чак кына зыян китерерлек булса, аларны сиңа бирер иде микән? Прохор Ильич үзе турында ныграк кайгырта сыман.

— Син нәрсәне күздә тотып алай дисең?

— Урын... Ул шәпләп утырган урынны...

— Ачыграк әйткәндә?

— Яңа авыл советы башкарма комитеты председателен сайларга кирәк булгач, үз кандидатурасын яклауны сорап, ике тапкыр Зубков янында булган...

— Шулай да булсын, ди. Тик ул хаклыкны эзләүдә ярдәм итәрдәй документларны кулга китереп тоттырды бит.

— Анысы да бик мөмкин. Кара әле, монда исемнәре телгә алынган Феофанов белән Хаминов терәк пункт советы әгъзалары бит. Бүген безнең утырыш була. Катнашасыңмы?

— Әлбәттә... Тик аңарчы Васильева белән тагын бер очрашып сөйләшәсем килә.

...Ул әлегә берни дә белмичә, тагын килде.

Әхмеров, нәрсә аңлатканлыкларын сорап, теге хатларны күрсәткәч, Васильеваның йөзе агарынып китте, мондый борылышны көтмәгән булса кирәк, тикшерүче сулы графинга үрелде. Тик ул сүлпән хәрәкәт белән аны туктатты.

— Юк, юк,— диде, ишетелер-ишетелмәс кенә.— Мин нигә алай эшләгәнемне әйтә алмыйм. Барыбер ышанмассыз. Хәер, аның нинди әһәмияте бар соң?

Ә тикшерүче моны аңлатып бирергә кирәклеген кабат әйтә башлагач, ул:

— Гафу итегез, мин үземне бик начар хис итәм,— диде.

Шуның белән аларның бу очрашулары тәмам булды.

## Алтынчы бүлек

Утырыш сәгать алтыда башланды. Миронов алдан ук Әхмеровка совет әгъзаларының кыскача анкета мәгълүматлары күрсәтелгән исемлек бирде. Шунлыктан ул һәркайсы турында бераз белә иде.

Җыелыш участковый кабинетында үткәрелде.

Совет әгъзалары өстәлнең ике ягына утырыштылар. Алар монда бишәү иде. Алтынчысы — колхоз председателе Зубков — район үзәгеннән кайтып өлгермәгән, аны иртән үк чакыртып алганнар иде.

Сулдагы беренче рәттә җитди кыяфәтле, урта яшьтәге мәктәп директоры Хәлилов, аның янында элеккеге участок инспекторы, шактый өлкән яшьтәге ябык йөзле Хаминов утыра, хәзер ул халык дружинасын җитәкли икән.

Уңдагы рәттә терәк пунктын җитәкләүче пенсионер Феофанов ул элек механик булып эшләгән; участок больницасының баш врачы Бегишаев, ә Миронов белән Әхмеровка каршы яктагы өстәл башына Шамаев утырган. Ул уйчан кыяфәттә, йөзендә борчылу галәмәтләре, әйтерсең, өермә буласын көтә иде.

Башта Миронов урман хуҗалыгына барып кайтуы, анда законсыз рәвештә урман кисү очраклары булгалавы хакында борчылып сөйләде. Кыска гына фикер алышканнан соң, урманда тәртип бозучыларның эзенә басу өчен якын көннәрдә рейд үткәрергә килештеләр.

Бу турыда сүзне бетергәч, участковый Әхмеровның иңенә кагылды.

— Хәзер мин сезне район прокуратурасының тикшерүчесе Әхмеров Әхмәт Шәрипович белән таныштырмакчы булам. Аның да үз мәшәкатьләре бар,— диде.

Әхмеров урыныннан торып басты.

— Мин монда авыл советы башкарма комитетының элеккеге председателе Васильева эше буенча килдем. Сез барыгыз да аны яхшы беләсез булыр,— диде.

Совет әгъзаларының йөзендә аптырашу сизелде. Шамаев кына берни дә аңлатмый торган уйчан кыяфәттә утыруында булды.

— Аның эше бетмәгән идемени әле?— дип сорады баш врач Бегишаев, әллә гаҗәпләнеп, әллә ачуы килебрәк.

— Күргәнегезчә, юк. Дәлилләр җитәрлек булмау аркасында бу эш туктатылган булган,— дип аңлатты Әхмеров.— Полина Ивановна алай гына риза түгел. Аны моның өчен гаепләп булмый. Алкалар тарихы барыгызга да билгеледер инде. Ләкин, мәсьәләгә объективрак килеп караганда, күп нәрсә ачыкланмаган. Минем сезнең белән очрашуым Васильеваның гаепләме-түгелме икәнлеген сорашу өчен түгел. Бөтенләй бүтән төстәге ярдәм кирәк. Шунлыктан, ике арада гына булган сөйләшүне ачып салуым гаҗәпләндермәсен. Миңа, буталчык бер ситуацияне ачыкларга, гомумән, сезнең фикерегезне дә белергә иде...

Әхмеров сумкасыннан Шамаев биргән хатларны алды.

— Уйламаганда, шушы кәгазьләр кулыма килеп эләкте...

Аңа текәлеп торган дүрт пар күз сагайды. Ләкин никадәр генә сиздермәскә тырышса да, Шамаевның күзләрендә куаныч сизелде.

«Аның бая гына нигә күңелсез утырганлыгын аңлый башладым кебек,— дип уйлады Әхмеров.— Үзе турында әйтермен дип борчылгандыр».

Ул сүзен дәвам итте:

— Бу хатларда, аларны гариза дисәк тә ярый, Уварова һәм аның киявенең спекулянтлык эшләре хакында сүз бара. Аларның берсен,— ул Феофановка карады,— сез язгансыз, Михаил Терентьевич. Йон кофта сатып алуыгыз турында... Ул чагында авыл советына мөрәҗәгать иткән булгансыз...

Феофанов борчылып кашларын җыерды, башын артка ташлады һәм исенә төшерергә тырышты.

— Икенче гаризаның кем тарафыннан язылганлыгы безгә мәгълүм түгел, тик аңа салынган резолюциядән күренгәнчә, моны тикшерү вазифасы депутат Хаминовка, яки сезгә, Иван Тимофеевич, йөкләтелгән икән. Теге яки бу гаризаны тикшерү нәтиҗәләре турындагы бер белешмә дә табылмады. Чара да күрелмәгән булса кирәк.

— Юк, алай булмады,— дип, шунда ук урыныннан торып басты Феофанов. Аның сүз тирәнгә киткәнче ачыклык кертәсе килә иде, ахры.— Чара күрелгән иде. Тик менә закон буенча эшләнүе генә... Хәер, моның нәрсәсен сырлап маташырга, тәртибе белән сөйләп биримме әллә?

— Сөйләгез, Михаил Терентьевич.

— Аңлашылмаслык берни дә юк монда. Хатыным беркөнне эштән кайтты да: «Кара әле, Михаил, үземә кофта алдым. Кыйбатрак инде. Илле биш сум тора. Аның каравы, мондыйны каян табасың?» — ди. Чыннан да, әйберсе шәп иде. «Каян алдың соң?» — дип сорыйм. «Евгения Уварованан»,— ди бу. «Анастасиянең ире хатынына алган да, аңа ярамагач, миңа сатты». Ике атнадан соң район үзәгенә баргач, универмагка керсәм — витринага кофта куелган. Нәкъ минем хатын Уваровадан сатып алган кофта инде. Төсе дә, материалы да, фасоны да туры килә. Бәясе генә утыз сум. Өйгә кайткач, моны Галинага әйттем. Ул Евгениягә китте. Тегесе җир йөзендә нинди әшәке сүз бар, шуларны әйтә-әйтә куып чыгарган. Мин шул хәтле гарьләндем, ничек булган — барысын да Полинага кызган шәпкә язып бирдем. Ике-өч көннән соң Уварова җилләнеп килеп кермәсенме. Пычрак галошларын да салып тормыйча түргә узды да, өстәлгә егерме бишлек ыргытты. «Мәгез, тыгыныгыз»,— ди. Җилләнеп чыгып китте. Евгения белән дә, Полина белән дә моның хакында бүтән телгә алмадык.

Феофанов утыручыларга карап алды, сүзләренең чынлыгына шикләнү галәмәтләре сизелмәгәч, картларча хәйләкәрлек белән:

— Чара менә шулай күрелгән иде,— ди.

Әхмеров Феофанов сөйләгәннәрне тагын кабат күңеленнән үт-

кәрде, фактларны логик бер чылбырга тезеп карады, әмма бүтән сүз әйтмәде, элекке участковыйга карап:

— Иван Тимофеевич, сез ни диярсез?— диде.

Хаминов, сорауны ишетмәгәндәй, җавап бирергә ашыкмады. Бераздан соң гына кашларын сикерткәләде, бик тырышып кырылган ябык йөзе белән Әхмеровка таба борылды.

— Мөмкин булса, башта гаризаны укыр идем...

Тикшерүче хатны Мироновка бирде, Миронов исә аны мәктәп директоры аша Хаминовка җибәрде. Ул башта күз йөгертеп кенә чыкты, аннан соң почмактагы язуны игътибар белән карады һәм:

— Менә хәзер исемә төште,— диде.— Дөрестән дә, Полина Ивановна миңа бу гаризаны тикшерергә кушкан иде шул. Тик икенче көнне үк кире алды. Ул үзе Уварова белән сөйләшергә уйлаган иде бугай. Аннан соң мине инфаркт аяктан екты. Калганын үзегез беләсез... больница, санаторийлар... Пенсия билгеләгәнче шулай булды. Бу кәгазьләр кайгысы түгел иде...

— Васильеваның ул хатын белән ни турындарак сөйләшергә теләгәнен хәтерләмисезме?

— Аермачык кына әйтә алмыйм инде, гаризада язылган фактлар хакында кебегрәк хәтердә калган. Васильева беркайчан да кырт кисмәде. Кешегә карата булганда бигрәк тә... ул әңгәмәләр, үгетләүләр, орышулардан башлый иде. Шуңа күрә аңа комачауламадым. Ул үзенчә, ә мин үземчә эшләрбез, дип уйладым. Өлгереп кенә булмады.

Тикшерүче аңа сынап карады.

— Васильеваның сандыгыннан табылган алкаларның моңа кадәр аныкы булмавы, Уварованың күрсәтмәләрендә аларның ышандырырлык итеп тасвирлануы сәер тоелмадымы сезгә?

Моңа каршы элеккеге участковый тыныч кына җавап кайтарды:

— Юк. Беренчедән, Васильеваны әйбәт беләм, Уварованы да шулай ук. Бу хатыннар арасында бернинди алыш-биреш булуы мөмкин түгел. Аннан соң бу вакыйга тарихының логикасы юк. Үзегез уйлагыз әле, Полина Ивановнаны ришвәт алуда гаепләргә тырышу аның эчкерлелеген, баерга омтылуын раслый. Ә монда нәрсә күрәбез? Васильеваның үз йорты, таза хуҗалыгы бар. Атасы белән иреннән әйбәт кенә сумма калды. Үзенең байлыгын бер вак-төяк хисабына арттыру юлына басар иде микән? Намусын бер пар алтын алкага сатармы әллә? Закон ришвәтчелек өчен кулга ала, йорт-җиһазны конфискацияли — Васильева моны белә.— Ул тикшерүчегә гаеп итеп карап алды.— Бәлки милициядә эшләп чыккан кешегә хас булмаганча фикер йөртәмдер, тик бу минем үз фикерем. Аны беркемгә дә көчләп такмыйм.

Моңа кадәр утырышта барган сөйләшүгә игътибар итмәгәндәй, җил искән саен борылган флюгер төсле гомуми настроениегә буйсынып кына утырган кебек күренгән яшь врач сүзгә кушылды:

— Сезнең белән килешәм, Иван Тимофеевич! Мин дә шуны өстәп куйыйм әле: узган ел без көрәшүче Вьетнам файдасына акча җыйган идек. Полина Ивановна ул чагында ике йөз сум бирде. Бу турыда район газетасында да яздылар. Теге алкаларга кызыгырдай булса, ул шул ике йөз сумга сатып алмас идемени?

Мәктәп директоры Хәлилов, мыскыллы елмаебрак сүзгә кушылды:

— Ике йөз сум акча белән гаҗәпләндермәкче буласыз тагын! Полина Ивановнаның аз хезмәт хакы ала торган семьялагы балаларга түләүсез материаль ярдәм күрсәтүе турында әллә ничаклы мисал китерә алам. Шунысын да әйтергә кирәк, бу бер генә тапкыр булмады һәм шактый суммада иде. Мин дә моны яла ягарга маташу дип саныйм.

Әхмеров Мироновка пышылдады:

— Менә хәзер болытлар тарала башлады кебек.

Миронов елмайды.

Васильеваны хөрмәт иткән, шунлыктан аңарга ягылган яланы юк итүләрен чын күңелдән теләүче бу иптәшләрне тыңлаганда Әхмеров үз өстенә алган җаваплылыкның никадәр олы икәнлеген төшенде, хезмәттәшләренең гаепсезлегенә инанган бу капма-каршы холыклы кешеләрнең үз дигәннәрендә нык торулары алдында кыюсызлык сыман хис тойды.

— Аны якларга әзермен...— директор сүзен тәмамлап кына килә иде, көтмәгәндә, бөтенесен дә гаҗәпләндереп, Шамаев кабынып китте.

— Гафу итегез, иптәшләр,— диде, үзенең ярсуын яшермичә.— Сез прокуратура тикшерүчесе белән түгел, ә затлы туташлар институты директоры алдындагы кебек сөйләшәсез. Полина Ивановна әйбәт кеше, без аны ихтирам итәбез. Ләкин минем аңлавымча, Әхмәт Шәриповичка конкрет карар чыгарыр өчен конкрет фактлар кирәк. «Хәлвә, хәлвә!» дип кенә авыздан хәлвә тәме килмәс бит.

Ул үзе әйткән сүзләрнең ничегрәк тәэсир итүен белер өчендер, ахры, тикшерүчегә кызыксынып карады, аның игътибар белән тыңлаганын күргәч, тәкәллефсез генә өстәп тә куйды:

— Төрлечә ярдәм итүләр турында сөйләп кенә Әхмәт Шәриповичны гаҗәпләндерә алмассыз. Аның практикасында җинаять юлы белән табылган акчаларның материаль ярдәм итү максатыннан чыгып туздырылу очраклары аз булмагандыр...

Шамаевның бутарга тырышуы ачык иде. Тик әлегә моны тикшерүче үзе генә сизенде, бәлки Миронов та аңлагандыр. Бүтәннәр исә аны кәефе начар булганлыктан, тотрыксыз табигате яисә бүтән берәр сәбәп аркасында ашыгыбрак нәтиҗә чыгаруыдыр дип аңладылар.

Шулаймы, әллә түгел идеме, әмма әле генә үзен Шамаев бүлдергән мәктәп директоры Хәлилов аңа табан карап, канәгатьсез кәяфәттә әйтте:

— Куегыз әле, Прохор Ильич, үзегезнең шул фараз итүегезне дәвам итмәгез.

Шамаев өстәп тагын нидер әйтмәкче иде, аны баш врач бүлдерде:

— Әхмәт Шәрипович, яшермичә генә әйтегез әле, бу хатынның гөнаһсыз икәнлегенә тулысынча ышансагыз да, Васильеваның өендә ничек итеп алкалар барлыкка килүен ачыклый алырыгызга ышанасызмы соң? Гаепләүче Уварова үзе үлде бит. Вакыт та аз узмады...

Әхмеров күкрәгендә ерып чыгып булмый торган ситуацияләрдә дә ышаныч бирердәй көч өстәлүен сизенеп, уйчан рәвештә чәчләрен сыйпады:

— Булыр дип уйлыйм,— диде.

Әле һаман тынычланып җитә алмаган мәктәп директоры тагын сөйләп китте:

— Нindидер алкалар, үлгән кеше, җинаять юлы белән табылган акчалар турында бәхәс алып барабыз. Ә гомумән алганда, пычрак яла корбаны булмам дип, монда утыручыларның кайсы да булса әйтә аламы? Чыннан да, кая мондый гарантия? Закондамы? Законга мөрәҗәгать итәр өчен, үзеңнең хаклыгыңа ышандыра белергә кирәк. Ә бу, безнең күргәнебезчә, бик җиңел эш түгел икән әле. Яла ягучы бугазыбыздан теләсә кайчан буып ала ала икән! — Ул башын чайкап әрнүле елмайды.— Мин кино караган идем. Анда бер тикшерүчене үзе белән бергә эшләүче дуслары ук рәшәткә артына тыгалар. Ришвәт алуда гаепләп. Аңа да яла ягалар. Онытмасам, фильмның исеме. «Үз кеше» бугай...

Хәлилов биргән сорауларның төгәл адресы юк иде, ләкин бирегә закон тарафыннан — әле яңа гына аңа карата шик белдерелгән закон тарафыннан — җибәрелгән кеше буларак, Әхмеров үзенә җавап бирергә кирәклеген аңлады.

— Яла җәмгыятьтәге бозыклыклар бөтенләй беткәндә генә юкка чыгачак,— диде ул һәм урыныннан торып басты.— Ә җәмгыять дибез икән, ул — без, барыбыз да бит. Инде, килеп җәмгыятьне тәшкил итүче

кешеләр арасында яла дигән нәрсә килеп чыккан икән, өйрәнгән гадәтебез буенча, аның турында гадәти әйбер хакында сүз барган кебек кенә итеп сөйләргә һич тә ярамый. Әйе, яла — ялган ул. Бу ялганны тикшерә башлагач, аның нигезендә еш кына безнең хаталар, ә кайчакларда уйлап житкерми эшләвебез ятканы ачыклана. Әле яңа гына искә алынган фильмдагы тикшерүче дә үзенең ышанучанлыгы һәм уйлап житкермәгән булуы аркасында яла корбаны була бит — гаепләнүчене тентегән чагында табылган акчаларны распискасыз гына туганнарына кире кайтара. Хәер, безгә кинога мөрәжәгать итүнең хаҗәте юк. Шул ук Васильева белән булган хәлне алыйк. Җинаять турында хәбәр иткән язуларны тикшерү органына тапшырырга кирәклеген белмәгәндер дисезме аны? Әлбәттә, белгән! Башта ук шулай иткән булса, шикле алкалар аның өеннән табылмас иде. Болар чүп кенә әле. Яла ягучы яхшылыкны, изгелекне дә үз файдасына кулланудан чирканмый. Шунлыктан законны, куелган тәртипләрне никадәр ныграк сакласак, яла да безгә якын килә алмас дигән нәтиҗә килеп чыга. Беркайчан да хур итәрмәс алар. Берәребезнең капкасы явыз ният белән дегет белән буяп куелган очракта да...

— Анысы шулай да инде, иптәш тикшерүче,— дип картларча мыгырданды Феофанов.— Тик озакка сузылуы әйбәт түгел бит. Салмыш баштан руль артына утырган тракторчыны нинди генә әшәке сүзләр белән сүкмибез. Берәр механик чәчүгә, я урып-җыюга техникасын әзерләмәгән икән, аңа яшәү юк иде. Ә монда елдан артык вакыт узды. Һаман да шул кәгазь туздыру. Берәр ачыклык булырмы-юкмы?

— Гафу итегез, Михаил Терентьевич, мин әле генә шушы сорауга җавап бирдем кебек,— дип картны үпкәләтмәскә тырышып әдәпле генә һәм ихтирам белән әйтте тикшерүче.

Миронов Әхмеровка карады.

— Сүзегез юкмы, Әхмәт Шәрипович?

— Юк. Игътибарыгыз һәм ачыктан-ачык сөйләвегез өчен барыгызга да рәхмәт.

— Минем картлачлар турында ни әйтерсең?— дип сорады Миронов, төн караңгылыгын ерып өйгә кайтканда.

Әхмеров елмайды.

— Картлачлар түгел, ә менә дигән сенат комиссиясе!— диде. Ул бүгенге ыгы-зыгыдан нык кына арыганлыгын сизде.— Минем үземне дә әкрен эш итүдә гаепләп, юкка чыгарып ташламасыннар әле...

— Ничек булыр дип уйлаган идең соң? Дәрәҗәле, мәртәбәле генә киләм дә, мич торбасыннан гүзәл принцессага алтын алкалар ыргыткан явыз сихерче турындагы әкиятне сөйләп, Феникс кошы шикелле йоклатам, аннан соң теге ике серле хатны кирәк кадәр җилпим дә сумкамны болгап китеп барам дипме...

— Ну, үтердең,— диде Әхмеров.— Синдә шул хәтле төртмә тел булыр дип уйламаган идем. Хәер, бу хатларга таянып уңышка ирешермен дип уйлавымны яшереп торасы юк. Ә Феникс кошы турында бераз арттырдың. Я, ярар. Үпкәләмим. Бер акыллы кеше әйткәндәй, дөя дә бүләк, инә дә бүләк.

Әхмеров адымнарын акрынайтты да күкрәген тутырып, рәхәтләнеп сулады.

Салкынча дымлы һава, яка астыннан үтеп кереп йомшак песи баласы шикелле, күкрәкне, колакларны кытыклады.

— Алексей, чыннан да, син мине дөрес башлап җибәрмәде дип уйлыйсыңмы?

— Юк ла. Бөтенесе дә тиешенчә бара. Кулыңа шикле документлар эләккәч, алардан котылу юк...

— Ә бу совет утырышы ничек соң?

— Сиңа аның файдасы тимәдеме әллә? Миңа калса, күп нәрсәне ачыклагансыздыр дип уйлаган идем...

— Аңладым анысы,— дип авыр сулады тикшерүче.— Бу хатынның күңеле саф икәнгә картларның нык ышануларын белдем. Бәлки бу бик тә әйбәттер. Әхлак ягыннан да, юридик мәгънәдән чыгып караганда да. Әмма Шамаев тарафыннан тапшырылган хатлар Васильевага карата шик уята...

— Сиңа аның белән тагын бер тапкыр очрашып, ачыктан-ачык сөйләшергә кирәк,— диде участковый.— Мәсьәләгә формаль яктан килгәндә, Васильева бу гаризаларны яшергән кебек тә. Икенче яктан карасак, гуманлык күрсәткән.

— Син мине гафу ит,— дип күңеле төшкәндәй елмайды Әхмеров.— Болай уйлауның нигезендә иң әйбәт оператив работникларны да хаталандырып куя торган ашыгу ята. Яшертенлек методы кулланылган, күп вакытта тизлек һәм реакция өстенлек иткән оператив эшнең, суд тикшерүенә караганда тизрәк башкарылуын һәм күпкә гадирәк икәнлеген аңла син. Хәер, мин җинаятьне ачыклаганда оператив мәгълүматларның әһәмиятен берничек тә киметмәс идем. Ләкин мин — тикшерүче. Димәк, миңа вак-төяк булып күренгән детальләрне дә җентекләп тикшерергә һәм үзем ясаган нәтиҗәләрне официаль фактлар белән нигезләргә кирәк. Шуңа күрә ашыгырга да, сине алдан куандырырга да хакым юк.

Миронов аңа аз гына да үпкәләмәде, үзенекен дәвам итте:

— Ярар, Әхмәт Шәрипович, гадирәк фикер йөртеп карыйк,— диде ул.— Авыл советына спекуляция турында белгертеп ике гариза кергән. Берсе буенча Васильева практик чара күргән. Икенчесен участковыйга биргән, ләкин, белгәнебезчә, тикшерелмичә калган. Бу кәгазьләр алка бәясе тора микән?— дигән сорау туа.

— Бәлки, кәгазьләр ул бәя тормагандыр да,— дип әйтергә телисезме?

Әхмеровның соравы җавапсыз калды — Миронов яшәгән йорт янына килеп җиткәннәр иде.

Кичке аш әзерләү проблемасы килеп басты, һәркайсы үз шөгыле белән мәшгуль булды, берәү дә берни әйтмәде, берни дә сорашмады. Тиздән өстәлгә кишер, суган, тозлы кәбестәдән ясалган салат, котлетлар куелды.

— Без нидә тукталып калган идек әле, Әхмәт Шәрипович,— дип сүз башлады Миронов, теге сөйләшүгә яңадан кайтырга ниятләп. Тикшерүче үзе дә моны көткән иде, шуңа күрә җавап кайтарырга әзер иде.

— Минемчә, Васильеваның гуманлылыгы аркасында спекулянтлар тиз ышанучан күп кенә кешеләрнең кесәләрен капшауны дәвам иттергәннәр. Аңлавымча, гуманлылык һәрвакытта да әйбәт, гадел башлангыч булырга тиеш. Берәүгә яхшылык итеп, икенче берәүгә яманлык кылырга тиеш түгел ул.

Участковый гаҗәпләнеп кашларын җыерды.

— Ярар инде, Әхмәт Шәрипович, мин адвокат булырга яисә сине нәрсәгә дә булса ышандырырга җыенмадым бит. Дөресен әйткәндә, син бу документлар белән артыграк мавыгып китмәдең микән дигән уй гына туган иде. Ә бәлки мәсьәләгә киңрәк караргадыр? Миңа да нинди дә булса шөгыль килеп чыгар иде. Югыйсә, күңелсез...

— Башта ук шулай дияргә иде аны. Күңелсез, янәсе. Эчең пошарга кайчан өлгерә соң әле. Син бит тынгысыз кеше. Я исерекләр белән эшлисең, я «урман караклары» артыннан чабасың.

— Сиңа үч итеп кенә болар!

Алар бер-берсенә карашып көлештеләр. Күңелләре күтәрелеп китте.

Участковый куе итеп ясалган кайнар чәйне чынаякларга агызды. Хуш исле бал белән эчә башладылар.

— Менә нәрсә, Алексей,— диде тикшерүче.— Син Уварованың кызы белән сөйләшеп кара әле. Үзеннән сорау алган вакытта ул алҗалар турында бер сүз дә әйтмәгән. Белмим һәм — бетте-китте. Бәлки күршеләре, туганнарыннан ни дә булса ишетерсең? Ире белән хат алышуы да ихтимал... Болай ул үзе астыртын хатынга охшаган, тик яңа тикшерүче килүен һәм терәк пунктта булган сөйләшүне кемнән дә булса ишеткән булырга тиеш. Бу аны каушатмый калмас.

Өстәлне җыя гына башлаганнар иде, ишек шакыдылар.

Миронов, чынаякларны кире өстәлгә куеп, чыкты. Алгы бүлмәдән: «Керегез, Павел Степанович, рәхим итегез!» дигәне ишетелде.

Колхоз председателе Зубков икән. Хәл-әхвәл сораша-сораша чишенеп, түргә узды. Нәрсәгәдер борчылган кебек иде. Мироновның өстәлгә чәйнек алып килгәнен күргәч, читкәрәк китеп утырды.

— Мәшәкатьләнмәгез, егетләр. Мин озакка түгел. Яңа гына, өйгә кайтып барган чагында, Феофановны күрдем. Ул миңа бүгенге сөйләшү турында әйтте. Шунлыктан сезгә кагылырга булдым.

— Бер чокыр чәйдән генә баш тартмассыз инде, Павел Степанович,— диде Миронов һәм җавап көтеп тормастан, чәй ясый башлады.

Зубков аны-моны дәшми генә өстәл янына күчеп утырды да чокырдан чәй чөмерә-чөмерә сөйләп китте.

— Дөресен әйткәндә, мин сезнең янга, Әхмәт Шәрипович, Полина Ивановна турында нинди дер шикле кәгазьләргә тап булгансыз дип ишеттем. Аның тарафыннан яшереп калдырылган дип...— ул, сөйләргәмеюкмы дигәндәй, тукталып калды да авыр сулады.— Алайса, мине дә тыңлагыз. Уварованың улы бар. Петр исемле. Диңгезче. Менә дигән егет. Ел саен отпускага кайта. Минем янга да керә. Отставкада булсам да, өченче ранг капитан бит мин...— Ул күңеле әрнеп елмайды.— Соңгы тапкыр керүендә Петя серен ачты. Полина белән яратышалар икән. Чын-чынлап, гомерлеккә... Алар өйләнешергә дә уйлаган булганнар, тик шушы күңелсез хәл килеп чыга. Петр мәсьәләнең асылын аңламыйча кызып китә. Хәзер үкенә үкенүен. Ялгышын аңлаган. Хатларында да шул турыда яза. Тик көймәләре комга терәлгән әлегә. Мәхәббәт ул көзге кебек шул. Ватсаң төзәтүе читен. Анысы үзләренең шәхси эше инде. Ә теге кәгазьләр мәсьәләсендә — уйларга кирәк. Бәлки берәр сере бардыр? Ул хатын-кыз бит!

Зубков чыгып киткәч, Әхмеров уйланып озак утырды. Аннан соң участковыйга эндәште:

— Кара әле, Алексей, иртәгә син миңа Петр Уваровның фоторәсемен табып бирә алмассыңмы?

— Тырышырмын.

## Җиденче бүлек

Участковый сүзендә торган иде.

Әхмеров иртә белән кабинетка керүгә, өстәл өстендә сәүдә флоты капитаны формасы кигән утыз яшьләрендәге ир кеше рәсемен күрде. Күзләре зур, кашлары куе кара, бите киң, кара тутлы. Ияге ике якка аерылыбрак тора. Ягымлы карашы бераз уйчан.

Фоторәсемнең астына басма хәрефләр белән: «Николайга Петрдан. Владивосток. 1969 ел» дип язылган. Миронов аны бүләк ителгән кешесеннән алган булса кирәк.

Фоторәсем белән бергә газетадан кисеп алынган мәкалә бар, анда «Комсомолец» теплоходы капитаны Петр Уваровның ут капкан Канада траулерын коткарудагы батырлыгы турында язылган икән, Петрның матрослар белән кочаклашып төшкән фотосы да бирелгән.

Вак һөнәрче һәм диндар хатынның капитан уллары менә нинди икән! Шуннан соң «алма агачыннан ерак төшми» дигән әйтемгә ышан инде.

Петр Уваровның тынчу өйне саф җилле океан киңлекләре белән алыштыруына гаҗәпләнергә дә кирәк түгелдер бәлки. Һәр заман яңа мәшәкатьләр, яңа омтылышлар уята бит. Әти-әниләре гомерләрен уздырган һәм шунда бертуган апасы да кереп баткан мещанлык ять-мәсеннән ычкынырга менә шулар ярдәм иткәндер.

Әхмеров Васильеваның килүен көтте. Миронов тикшерүченең чакыруын әйтергә аңа кагылырга тиеш иде.

Ул озакламады. Курка-курка гына килеп керде. Кыюсыз гына исәнләшеп, өстәл янына узды, урындыкка утыргач, авыр сулады. Элеккеге кебек үк, йөзенең төсе киткән, күз төпләрендәге күгелҗем күләгәләр каралып тора. Аның бөтен кыяфәтеннән өметсезлек сизелә иде.

Тикшерүче җинаять эше төпләмәсен алдынарак тартып куйды. Васильева килгәнче үк капитанның фотографиясен шунда салып куйган иде, ашыкмыйча актара башлады.

— Үзегезне ничегрәк хис итәсез?— дип сорады ул, башын күтәрмичә.

Васильева тыенкы гына җавап бирде.

— Рәхмәт. Әйбәтрәк шикелле.

— Алайса — ярый. Әйбәт — һәрвакыт әйбәтрәк инде ул!

Шул чак кәгазьләр арасыннан теге фоторәсем өстәлгә шуып төште. Васильева алга таба омтылды һәм, күзләрен зур ачып, тикшерүчегә төбәлде.

— Кем бу?.. Ничек?.. Аның белән бер-бер хәл бармы әллә?— Шунда ук исенә килеп, авызын йомды.

Әхмеров фоторәсемне саклык белән кулына алды да:

— Сез бу кешене беләсезме?— дип сорады.

— Аңа да барып житкәнсең икән,— диде Васильева өметсез рәвештә. Куллары белән битен каплап, елап җибәрде.

Мондый ситуациядә стакан белән су тәкъдим итүнең яисә тынычландыруның файдасы юк, ә туйганчы еларга ирек бирү кирәк иде.

Әхмеров тәрәзә янына килде дә Васильевага аркасы белән борылып, аның тынычланганын көтте. Юл буйларында ерганаклар ага, ә кояш җылыта. Ул күңелле генә челтерәгән ерганаклар, урыны-урыны белән җыелып торган сулар, канаулар аша атлап йөрисен күз алдына китерде дә, шунда ук иркен, якты урамга чыгасы килде.

Елау тавышы әкренләп тынды.

Аның җиңел сулап куйганын ишеткәч, Әхмеров борылды.

— Елап бетердем шикелле хәзер мин,— диде Васильева, газаплы елмаеп һәм гаепле кеше сыман тикшерүчегә карады.— Ни теләсәгез, шуны сорый аласыз хәзер. Миңа барыбер...

Тикшерүче өстәл янына килеп утырды.

— Ярар,— диде ул, эшлекле тонга күчеп.— Бераз тынычланган булсагыз, теге гаризалар турында сөйләгез инде...

— Шамаев китергән гаризалармы?— дип сорады Васильева.— Аның йөзеннән тагын боек елмаю шуып үтте.— Юкка борчыла ул. Анда кабат кайтмыйм инде. Ә гаризалар... Сезгә нәрсә әйтергә соң?..— Ул арыган кыяфәттә битен сыпырып алды, яше дә кибеп бетмәгән күзләрен тикшерүчегә төбәде.— Башта Михаил Терентьевич язды. Бәясен күпкә арттырып саткан нинди дер кофта турында сүз бара иде. Мин Уварованы чакырдым. Ул ялгышканмын, диде. Акчаны кичекмәстән Феофановка кайтарып бирү хакында сөйләштек. Шуның белән бетте. Күп тә үтмәде, тагын бер хат... Анда моннан җитдирәк нәрсәләр турында хәбәр ителгән иде. Кем язганлыгы хәзер исемдә түгел инде, ләкин Уварова белән Кожемякинны спекуляциядә гаепләгәнлекләрен хәтерлим. Минем бик тә ачуым килде. Закон буенча җәза бирсен дип, хатны участковый Хами-

новка тапшырдым. Соңыннан, ашыктык микән әллә, дип уйладым. Элек тә төрле жалобалар язгалыйлар иде, гел дөрес кенә булып та бетми иде. Кыскасы, хатны кире алдым да, Уварованың үзен чакырттым. Карчык, куллары белән селтәнә-селтәнә, бөтенесен дә кире какты, соңыннан елый башлады. Үзенең аллаларын һәм фәрештәләрен исенә төшерде, гафу итүемне сорады. Аның туймый торган комсыз, әшәке күңелле икәнлеген дә белә идем югыйсә. Тик миңа әллә нәрсә булды. Мәрхүм атаң белән анаң хакына, Петякаем хакына дип ялынды. Әйткән сүземнән беркайчан да чыкмас идем дип...

Васильева күзләрен йомды. Аның бөтен кыяфәтеннән боларны искә алуы да авыр икәнлеге, җанын әрнеткәнлеге күренеп тора иде. Ләкин ул тагын сөйләп китте.

— Бу юлы да мин аны гафу иттем. Җәлләдем. Уйламаганда, Хаминов та чирләп китте. Ләкин сәбәп монда гына түгел. Мин башкача булдыра алмадым. Аның исеме дә катнаша иде бит... Соңыннан Уварованың алыш-биреш эшләрен һаман дәвам итүе турындагы сүзләр кабат ишетелә башлагач, хатамны төзәткән дә булдым, белмим тагын, төзәтү булды микән бу?— Ул тикшерүчегә күтәрелеп карады.— Ә алкаларны мин алмадым. Ант итәм, алмадым,— диде.

— Яхшы,— диде Әхмеров.— Миңа сезнең белән тагын очрашырга туры килер әле. Һәм моның тиздән булуы да ихтимал. Китә аласыз, Полина Ивановна.

Нишләргә иде соң аңа? Узган эздән башларгамы? Әле яңа гына тынычлана башлаган бу хатынга мәкерле сораулар бирергәме? Яки ирекле темага күчәргәме? Юк, әңгәмәне дәвам итәргә кирәк түгел иде. Васильева үзе дә моның шулай икәнлеген аңлады булса кирәк, кабинеттан чыкты. «Хушыгыз», дип кенә әйтә алды. Аның тавышында ышаныч сизелгәндәй булды. Димәк, ялган гуманлылык та, баерга теләү комсызлыгы да түгел, ә мәхәббәт икән. Кайчагында закон белән дә исәпләшеп тормый торган, дуамаллык кылып куя торган мәхәббәт...

## Сигезенче бүлек

Көндезге сәгать дүртләрдә терәк пункт янына таныш уазик килеп туктады. Әхмеров тәрәзә аша үзен станциядә каршы алган шоферның, аның артыннан фуражкасын маңгаена төшереп кигән Мироновның машинадан төшкәнен карап торды. Участковый шоферга нидер әйтте, аннан соң тегесе кабинага кабат кереп утырды. Тиздән машина борылып китеп барды.

Бер минуттан тикшерүче белән участковый өстәл артында утыралар һәм күптән күрешмәгән дуслар шикелле сөйләшәләр иде инде.

— Хаминов белән урман хуҗалыгында булдык,— дип сөйләп китте Миронов.— Баруын әйбәт бардык, кайтканда юл боламыкка әйләнгән иде. Сиңа да моннан Мазай бабай көймәсе белән генә чыгарга туры килмәсен дип куркам әле. Аның каравы нинди эш башкардык! Өч авылда булдык. Ә Хаминов, молодец! Кая гына кермәсен, әле генә киселгән бүрәнәләрне күреп ала. Хуҗалары шыр җибәрделәр. Урманчы үзен күтәреп кенә йөртмәде.— Участковый көлде дә кәгазьләр белән шыплап тутырылган планшетын күрсәтте.— Материаллар алып кайттым әле. Бер-икесенә җәза бирергә туры килер. Калганнарына да кайбер чаралар күрергә кирәк.— Ул планшетын читкәрәк куйды.— Үзең ничек соң? Яңалыклар булмадымы? Васильева килдеме?

— Килде...— тикшерүче портфеленнән эш төпләмәсен ашыкмыйча гына ала башлады. Кызыксынучан участковыйның күзләре үзгәрде.

— Я, шуннан?

— Зубков хаклы булган,— диде Әхмеров.— Синең белән Хаминовта да бераз дөреслек бар. Чыннан да бу капитан аның йөрәген белеп ал-

ган. Ул Петр Уваров хакына барысына да әзер. Сүз уңаенда әйтим әле, фоторәсем өчен сиңа рәхмәт. Аның бик тә кирәге булды...

— Син аны каян алганымны беләсеңме?— Участковыйның мактаудан күңеле булган иде.— Монда бик әйбәт кеше бар, Николай Грибоваров исемле. Петр белән аның бабалары бертуган. Фоторәсем сорап кергәч, ул миңа кызыклы бер нәрсә турында сөйләде. Кичә кич, үзенең бер дус тиешле кешесеннән кайтышлый, Анастасия Кожемякинаны очраткан. Тегесе Грибоваров яныннан сиздермичә генә үтеп китәргә теләгән икән, Николай аны дәшеп туктаткан да кая, нигә баруын сораган. Кожемякина: «Николайны алданрак азат итеп булмасмы дип сөйләшергә участковый янына барган идем, тик анда җыелыш бара икән, районнан тикшерүче килгән»,— дип җавап кайтарган.

— Кожемякина нәрсәне дә булса махсус белергә килгәндер дип уйлыйсыңмыни?

— Шулай, билгеле. Тыңлап торган булуы да ихтимал. Ул әнисенә бик тә охшаган бит. Тышкы яктан гына түгел. Алтын алкалар тарихының дәвамы да булмас микән әле. Ә ирен алдан азат итү турында уйлап чыгарган ул, алар бу хакта югары инстанцияләргә әллә кайчан мөрәҗәгать иттеләр, тиешле җавап та алдылар инде.

— Чынлап та кызыклы деталь бу... Кожемякина җыелыш турында каян ишетте микән? Башланган вакытын дим?

— Феофановтан.

Тикшерүче гаҗәпләнүдән иреннәрен кысты.

— Кожемякина белән күршеләр алар. Бүген Михаил Терентьевич белән сөйләшкән идем. Әнисе үлгәч, Анастасия да аңа кергәләп йөри башлаган, син килгәч, мондый визитлар ешаебрак киткән. Михаил Терентьевичның хатыныннан тикшерүченең нигә килгәнлеге турында кызыксынган. Теләсә кайда казна акчасы туздырып йөриләр инде шунда, дип ачуланган да әле. Менә шуларны белеп тор.

Миронов үзен игътибар белән тыңлап утырган тикшерүчегә елмаеп карады.

— Иң әһәмиятлесен әйтмәдем бит әле. Китәр алдыннан ремонт мастерскоена кереп ике кеше белән сөйләштем. Тракторчы Мөбәрәк Исәнаманов Васильева өйдә кунмаган теге көнне этенең бик шикле рәвештә өргәнлеген әйтте. Исәнамановның үзенең дә шиге бар...

— Мөбәрәк Исәнаманов? — дип кабатлап сорады тикшерүче.— Тукта әле!— Әхмеров, җинаять эшен алып, актара башлады.— Нәкъ шулай, Мөбәрәк Исәнаманов Васильеваның күршесе икән... Ул төнтү вакытында пунәтәй дә булган! Кара әле, Алексей, бу кешене ничек табып була?

Миронов, телефонга килеп, трубканы алды.

— Диспетчерны тоташтырыгыз әле... Нина, бу мин, Алексей. Син миңа Исәнамановны ничек табарга кирәклеген әйтмәссеңме? Әйе, Мөбәрәк Исәнамановны! Дүрттә килде. Рәхмәт.

Трубканы элгәч, тикшерүчегә борылды.

— Исәнаманов сәгать дүрттә машина дворына килгән икән. Хәзер ул ремонтчылар бригадасында эшли. Без аны очрата алабыз әле.

— Бик шәп! Машина двороы еракмы?

— Километр ярымлап. Павел Степановичка шалтыратыргамы?

— Юк, юк! Җәяү барыйк. Һава суларбыз.

Колхозның барлык техникасын сыйдырган машина дворы техник станция паркын хәтерләтте. Тегендә дә, монда да кешеләр өелешкән. Кычкырган тавышлар ишетелеп китә.

Кергәч тә сул якта кызыл кирпечтән салынган механика мастерскоеның озынча бинасы сузылган. Уңда, карлыгач оялары кебек, эреле-ваклы складлар китә. Кардан арчылган һәм инде кибеп бетеп килгән мәйданда ремонтланган машиналар тигез бер рәткә тезелгән.

Әхмеров һәм Миронов каравылчы белән исәнләшеп, проходнойдан узгач, мастерскойга таба юнәлделәр. Тар гына баскычтан икенче каттагы мөдир кабинетына менделәр.

Мөдир үзе юк иде. Проходной аша үткәндә үк, сторож аның культиваторлар алыр өчен район үзәгенә киткәнлеген әйтте.

— Син җайлап утыр, Әхмәт Шәрипович,— диде Миронов, бер урындыкны өстәлгә якынрак тартып.— Мин сиңа Исәнамановны эзләп килим әле.

Ул чыгып күп тә үтмәде, кабинетка тәбәнәк кенә буйлы, юантык гәүдәле башкорт килеп керде. Аңа алтмыш яшьләр чамасы инде, тик дала халыкларыныкына тартым түгәрәк һәм яссы йөзе, мут караучы кысык күзләре әле картлыкка бирешергә уйламавы турында сөйлиләр.

— Исәнаманов мин булам. Син чакырдыңмы, юлдаш?— диде ул, кыюсыз гына түргә узып.

— Әйдәгез, әйдә, Мөбәрәк ага. Сезне көтә идем шул,— дип, аның каршысына килде Әхмеров. Картны өстәл янына утыртты.

Исәнаманов бүреген салып, аны тезләренә куйды да, «ни әйтерсез?» дигән кыяфәттә тикшерүчегә карады.

— Эшегездән бүлгәнебез өчен гафу итегез инде, Мөбәрәк ага. Ул сезнең бигрәк тә күптер инде хәзер.

— Ә-ә-ә, юлдаш! Безгә бөтенесенә дә өлгерергә кирәк. Җир сөрү, иген чәчү, аннан соң сабантуйны бәйрәм итү — безнең эш инде алар.

— Барысына да өлгерүегез әйбәт, анысы,— дип, картның үзе кебек җавап бирде Әхмеров.— Күп вакытыгызны алмаска тырышырмын. Сез күршегезне беләсездер инде...

— Полинанымы?— Исәнаманов аңа сүзен дә әйтеп бетерергә ирек бирмәде.— Ничек инде белмәскә! Беләм, әйбәт беләм! Полина — алтын кеше. Саф күңелле бала.

— Мөбәрәк ага, сезгә бер төнне аның ишегалдындагы эте өргән булуы билгеле икән. Ул чакта Полина Ивановна район үзәгенә киткән, икенче көнне иртән генә кайткан. Өч көннән соң суд булган. Шуны хәтерлисезме?

— Хәтерлим, хәтерлим.— Исәнаманов кыска чәчле олы башына уч төбе белән кагылып алды.— Мөбәрәкнең чәче ак булса да, зиһене шәп әле. Мөбәрәк бөтенесен дә әйбәт хәтерли.

— Ничек булганлыгын сөйләгез әле. Бу вакыйга шушы көнгә хәтле ачыкланмаган килеш калган. Бердников сезгә дә чакыру кәгазе җибәргән икән. Менә монда аны алуыгыз турында кул да куелган. Сез анда бармадыгызмыни?

— Ә-ә-ә, юлдаш. Нишләп бармыйм ди? Мөбәрәк андый кеше түгел. Мөбәрәк прокурор белән милицияне һәрвакыт тыңлый. Бердников авылга килгәч, мин санаторийга киттем. Бавырымны дәваларга. Аннан соң чакыру кәгазен алып районга бардым, Бердников үзе больниста ята иде инде. Мин кире кайтып киттем. Бердников бүтән кәгазь җибәрмәде. Ә бу шулай булган иде, юлдаш. Полина район үзәгенә киткәч, энем Салават миңа кунакка килде. Икәүләп сөйләштек, бишбармак ашадык, бераз эчеп тә җибәрдек. Караңгы төшкәч, йокларга яттык. Тыңлыйм: эт өрә. Мин ишегалдына чыктым: «Нигә өрәсең, Бонька?»— дим. Бонька туктады. Мин өйгә кереп, яңадан яттым. Бер минут үтте микән, юк микән, Бонька тагын өрә башлады. Аннан соң йоклап киткәнмен...

Карт менә бөтенесе шул инде дигәндәй, кулларын җәйде.

— Рәхмәт, Мөбәрәк ага,— дип уйчан гына әйтте тикшерүче.— Этнең сәгать ничәләрдә өргәнен генә әйтеп бетермәдегез.

— Ай-яй, зиһен шәп шәбен, тик бусын онытканмын!— карт борчылган кыяфәттә башын чайкады.— Ишегалдыннан кергәч, сәгатькә карадым, шуннан соң гына яттым... Вакыт унны күрсәтә иде кебек, эт шул чакта өрде. Аннан йоклаганмын...

— Элек Бонька төннәрен өрә идеме?— Картның сөйләгәннәре тикшерүчене торган саен ныграк кызыксындырды.

— Юк, Бонька акыллы эт. Бонька аз өрә. Мин керсәм — өрми. Күрше Артем керә — аңа да өрми. Чит кеше керсә, бераз өрә дә туктый. Банька юаш эт, акыллы эт!

Картның һәр сүзен күңеленнән үткәргәннән соң, әлегә ачыкланып житмәгән бу хәл белән Васильеваның өендә булып узган вакыйгаларны берләштереп карарга вакыт житте, дип уйлады тикшерүче.

— Мине тагын бер нәрсә кызыксындыра, Мөбәрәк ага,— диде ул, картка хөрмәт белән карап.— Васильева фатирында тентү уздырылганда сез пүнәтәй итеп чакырылгансыз икән. Алкаларны сандыктан сезнең катнашыгызда тапканнар. Минем бу турыда үзегездән ишетәсем килә иде.

Аның илтифат күрсәтүеннән Исәнамановның күңеле булды. Ләкин тентү һәм алкалар турында исенә төшергәч, ул уңайсызланып иреннәрен чәйни башлады.

— Алкаларның ничек табылуы кәгазьдә язылган,— диде ул, Әхмеров алдында яткан делога ымлап.— Ничек шулай булганлыгын үзем дә белмим. Өйгә ике милиционер килеп керде дә әйтәләр миңа: «Хөрмәтле Мөбәрәк абый, Полинканың өенә барып, әйберләрен карарга кирәк», дип. Чакыргач барырга кирәктер дип уйладым. Полинканың өенә керсәм, ул күңелсез, башын куллары белән тоткан. Күрше Артем да шунда. Милиционерлар шкафтан әйберләрне актара башладылар. Чемоданны карадылар, ящик-тартмаларның барысын да тикшерделәр. Сандыкны ачтылар. Анда ашъяулык, кием-салым бар иде. Шулар арасыннан бәләкәй генә тартма табылды. Эчендә алкалар да бар. Үзе матур, үзе алтын, ә кызыл кашы җем-җем итә. Без барыбыз да ах иттек. Ә Полинка елады. «Минеке түгел, минеке түгел», диде. Белмим, нишләп алай булгандыр, нишләп шулай булгандыр! — Карт авыр сулады, уңайсызланудан бүреген йомарлый башлады.

— Аннан соң милиционер акт төзеде, ишегалдын, өйалдын карады. Полинканың өй рәсемен ясады. Мин дә, күрше Артем да кул куйдык...

— Мөбәрәк ага, сез озак яшәгәнсез, сезне өйрәтеп торасы юк,— дип тикшерүче, әңгәмәдәшен эчкерсез сөйләшүгә тартырга тырышып, картның салпы ягына салам кыстырды.— Полинканы әйбәт кеше, дисез. Сезнең белән бәхәсләшергә җыенмыйм. Тик бу алкалар сандыкка ничек килеп кергәнлеген әйтә алмассызмы?

— Юри куйганнар!— дип кулларын селтәде Исәнаманов.— Начар кешеләрнең кулы уйнаган.

— Өйгә ничек кереп була соң?

— Э-э-э, юлдаш! Тоттың да тәрәзәдән кердең!— диде карт уйлап та тормыйча.

— Тәрәзәләр ябык булган!— дип аңа каршы төште тикшерүче.

— Ишектән кергән!

— Анысы да булмый. Ишектә эленеп торган йозакны чит кеше ача алырлык түгел.

— Барыбер кергән! — диде карт бирешергә теләмичә.— Кеше тычкан белән бер ул.— Теләсә нинди тишектән үтә.

Тикшерүче авыр сулады.

— Мөбәрәк ага, әйдәгез әле тагын уйлабрак карыйк!

Ул җинаять эшен ачып, теге хәвефле көнне тентү үткәргән һәм йорт-каралтыны караган милиционерлар тарафыннан сызылган йорт планын тиз генә эзләп тапкач, Исәнамановка күрсәтте.

— Менә бит, йортның җиде тәрәзәсе бар. Бу икесе — бакча ягына, менә бу өчесе — ишегалдына, ә бу икесе — урамга карыйлар. Васильеваның әйтүенә караганда, барлык тәрәзәләр дә эчтән бикле булганнар.

Тәрәзә төпләрендәге гөлләр дә урыннарыннан кузгалтылмаган. Димәк, өйгә тәрәзә аша кергәндер дигән юебез дөрес түгел.

Карт нәрсәне дә булса хәтеренә төшерергә тырышып, схемага төбәлеп карый иде.

Тикшерүче:

— Ә бу ишек...— дип дәвам итмәкче иде, Исәнаманов аны бүлдерде.

— Тукта, тукта! Нишләп ишектән булсын! Нишләп ишектән булсын!— дип гөрелдәде ул.— Чолан тәрәзәсе кая монда? Тәрәзә кая?

— Ни турыда сөйлисез сез? Нинди тәрәзә?— диде тикшерүче аптырап.— Нәрсәнедер бутыйсыз, Мөбәрәк ага. Чолан дисезме? Ул йортның зурайтылган өлешендәге менә бу почмакка терәп салынган. Тик аның тәрәзәсе юк.

— Нигә юк дисең, юлдаш? Полинканың ире Сережа йортны зурайтырга мине үзе чакырды бит. Ай буенча эшләде. Мин дә булыштым. Чолан да салыштым. Бар чоланда тәрәзә, бар!

— Ничек инде алай ул, Мөбәрәк ага, схемага сез дә кул куйгансыз бит.

Тикшерүче аркасыннан салкын тир бәреп чыгуын тойды. Аның күлмәге тәненә ябышты.

— Әй, юлдаш! Мөбәрәк схеманы карап та тормады. Милиционерлар биргәч, Мөбәрәк кул куйды. Алкаларны табу белән Мөбәрәк чыгып та китте.

— Сез милиция работниклары чоланга кермәгән дип әйтергә телисезмени?

— Кереп тормадылар, әлбәттә, кермәделәр, юлдаш. Сандыктан алка чыккач, чоланга нигә кереп торырга, ди?

— Һм... Ә ул нинди тәрәзә соң, Мөбәрәк ага?

— Гадәти тәрәзә, юлдаш.— Гап-гади. Рамасы бар. Пыяласы бар. Бу якка ачыла, бу якка ябыла торган.

— Ачыла-ябыла торган,— дип кабатлады тикшерүче механик рәвештә.— Туктагыз әле, нәрсә белән бикләнә иде соң ул?

— Менә монысын белмим, юлдаш. Бүтән ул тәрәзәне күрмәдем.— Исәнаманов тикшерүче игътибар итәрдәй хәбәр әйтүеннән үзе дә сөенгән иде, шуңа күрә картларча көлемсерәп, кайнарланмыйча гына сүзен дәвам итте.— Сережаның әлгеч ясарга җыенганын хәтерлим. Тәрәзә турында башта онытканмын, хәзер исемә төште. Баш әйбәт эшли, шулай да кайчагында шаяра, шайтан!

Әхмеров әле һаман да ышанып җитә алмый иде.

— Алай икән... Хәерле булсын! Бик зур рәхмәт, Мөбәрәк ага! Бүтән тоткарламыйм инде сезне. Китәргә ярый. Иртәгә кайсы сменада буласыз?

— Икенче сменада, юлдаш.

— Яхшы. Сезне тагын борчырга туры килсә, ачуланмассыз бит?

— Э-э-э, нинди борчу ди ул? Кунакка кил, юлдаш! Карчык менә дигән итеп бишбармак әзерләр! Минем иң яраткан ризыгым ул. И-и-х!— Исәнаманов әле яңа гына яраткан ризыгын авызына капкан һәм кулыннан аккан майны ялап алырга әзерләнгән кебек хәрәкәт ясап алды.

— Чакыруыгыз өчен рәхмәт, Мөбәрәк ага! — Тикшерүче хөрмәт белән аның кулын кысты.

Карт чыгып киткәч, ул сихерләнгән кебек схемага төбәлде.

Тентү. Тикшерү. Онытылган тәрәзә... Болай булырга мөмкинме? Ә нигә булмасын ди? Хезмәткәрләр яшьләр, тәҗрибәсез булганнар, аларга барысы да гади генә хәл ителгәндәй тоелган. Ни эзләсәләр, шуны тапканнар. Бөтен игътибар шуңарга юнәлгән дә. Бүтән ни кирәк тагын? Нигә әллә нинди кеше ышанмаслык версияләр уйлап маташырга?

Шикләнүләр һәм авыруы аяктан екканга кадәр Бердников та шушы юлдан киткәндер һәм шундый нәтиҗәгә килгәндер. Әхмеров үзе ничек

соң? Бөтенесен дә яңабаштан карап чыкмаса, ул да башка юлны алыр идемени? Әйе... «Акыл теше алтмышта да чыга» дигән мәкальдә хаклык бар.

Ыгы-зыгы дворга чыккач, Әхмеров, участковый юк микән, дип тирәягына каранды. Ләкин Миронов якын-тирәдә күренмәде. Тикшерүче тәгәрмәчле-чылбырлы трактор янына иелгән яшүсмерләрдән — киемнәреннән күренгәнчә, алар профессиональ-техник училищеда укучылар иде булса кирәк:

— Сезнең яннан участковый үтеп китмәдеме, егетләр?— дип сорады.

Тегеләр җавап бирергә дә өлгермәделәр, трактор астыннан аның:

— Әхмәт Шәрипович, мин монда!— дигәне ишетелде.

Шул чагында гына Әхмеров үсмерләрдән берсенең шинель белән фуражка тотып торганлыгына игътибар итте.

Миронов башта күчерелмәле лампаны сузды, аннан соң, мышныйм-мышный, аяклары белән этенә-төртенә, трактор астыннан чыкты. Җитез генә аягына басты, үзен француз докерлар кебек итеп күрсәтүче комбинезон һәм беретканы салып, киемнәрен киде.

— Гафу итегез, Әхмәт Шәрипович,— диде ул, гаепле сыманрак елмаеп.— Тыелып булмады. Ни генә дисәң дә, ике ел танк частенда хезмәт иттем бит. Сагынылган.

Ул трактор янында басып торган үсмерләргә борылды.

— Куркырлык берни дә юк, егетләр. Тормозны гына көйлисе бар.

Машина дворыннан чыккач, алар авылга юл тоттылар. Әхмеров кайтканда участковыйга Исәнаманов белән булган әңгәмә турында сөйләде. Миронов игътибар белән тыңлады. Тикшерүче теге чагында онытылып калган чолан тәрәзәсе һәм бу турыдагы үз уйларын да әйткәч, ул югалып калды, хәтта:

— Кара син аны, ә?.. Гади генә хәл итәргә булган бит... Котлыйм сине, Әхмәт Шәрипович! Ни белән бетәчәген әйтә алмыйм, әле, шулай да, котлыйм, валлаһи!

— Иртә әле, Алексей, иртә! Хаклыкны табарга ерак әле.

— Хәйләләмә!

— Исәнаманов белән сөйләшкәндә безнең янда нигә булырга теләмәдең?

— Беләсеңме,— диде Миронов, адымнарын әкренәйтеп.— Тентү турында сүз буласын белдем. Анда минем хезмәттәшләрем катнашкан бит. Шуңа күрә сезнең белән утырасым килмәде. Үзегезгә дә икәүдән икәү генә әйбәтрәк булыр дип уйладым.

Әхмеров аңа каршы төшмәкче иде, ләкин, ниндидер бер эчке тавыш аны тыеп калды, ул бары тик:

— Алай дисең икән инде... Шулай да вакыйга булган урынны карарга каршы килмәссең бит?— диде.

— Ул турыда сүз булырга да мөмкин түгел. Кайчан? Бүгенме?

— Бүген соң инде. Мондый эштә төн начар киңәшче. Нәрсәне дә булса күреп житкермәвебез ихтимал. Закон да мондый эштә чикләүләр кертә, син беләсең бит...

## Тугызынчы бүлек

Әхмеров участковый белән әз-мәз капкалап алгач, Васильева янына барырга чыкканда, кояш биек агач башлары арасыннан күтәрелеп кенә килә иде әле. Васильеваның йорты аргы башта икән.

Кичәгенәк машина дворыннан кайтышлый алар терәк пунктка да сугылдылар. Участковыйның тикшерү өчен кулланыла торган портфель-комплекты бөтенләй яңа икән. Әхмеров үзе белән гадәт буенча, иске фотоаппарат кына алган иде, шунлыктан бу аның өчен бик тә кулай булды. Күптән онытылырга тиешле вакыйгага башкача юнәлеш алыр дип кем уйлаган? Хәзер аларның эш өчен бөтен кирәк-яраклары да бар иде.

Узган төн тынычсыз булды. Әхмеров йокыга озак китә алмады, әле бер, әле икенче якка әйләнде. Чолан тәрәзәсе аңа тынгылык бирмәде.

Барышлый Исәнамановларга кагылдылар. Аннан соң Миронов пүнәтәйләр чакырды һәм барысы бергәләп Васильевага киттеләр.

Алар биек рус капкадан узып, кары эреп яткан ишегалдына керделәр. Каршыга каяндыр колаклары зур булып асылынган эт йөгереп чыкты. Ул койрыгын болгады да, кирәктән түгел, тиеш булганга гына дигәндәй, теләр-теләмәс кенә өреп маташтты.

— Бонька, азынма!— диде аңа Исәнаманов, иске танышына эндәшкән төсле. Эт, тыңлаучан кыяфәттә башын аска иеп, сарайга таба элдерде.

Әхмеров шунда ук йортның зурайтылган өлешенә игътибар итте, ул йортның өчтән берен диярлек алган һәм бүрәнәләренең яңа булуы белән аерылыбрак тора. Ишегалды эчкә таба, каралты-куралаларга таба авышрак, шунлыктан аның арткы өлеше юан бүрәнәләр өстендә җирдән бераз күтәрелеп тора. Өйгә керә торган якта бизәкләп эшләнгән рамлы олы тәрәзә күренде. Димәк, Исәнаманов сөйләгән тәрәзә кырыйда яисә алма бакчасына каршы якта булырга тиеш.

Хәер, озак уйланып торырга вакыт юк иде. Ишек ачылып китте дә баскыч төбендә хуҗа хатын күренде. Кара свитер белән соры юбка киган. Матур. Төз гәүдәле. Бөтен кыяфәтеннән гадилек бөркелеп тора.

Ул башта гаҗәпләнде, тикшерүчене күреп алгач кына исәнләште:

— Исәнмесез! Сез минем янгамы?

— Иртүк хәбәр итмичә килүебез өчен гафу итегез, Полина Ивановна,— дип аңлатырга ашыкты Әхмеров.— Йортыгызның бер өлешен карап алырга кирәк булды. Сез каршы килми торгансыздыр бит?

— Юк, юк... Рәхим итегез...— диде Васильева елмайган сыман.— Ни теләсәгез, шуны эшли аласыз. Узыгыз...

Ул өйгә таба атлады, ләкин кинәт күзләрен йомып, чайкалып китте. Әхмеров шунда ук аның терсәгеннән тотты.

— Ни булды сезгә?— диде ул борчылып.

— Юк, юк. Болай гына. Борчылмагыз...— Ул башын чайкап алды да, борылып, башкаларга эндәште:— Нишләп торасыз сез? Алексей Иванович, Мөбәрәк агай! Керегез, керегез дим бит.

Барысы да өйалдына узгач, хуҗа хатын утны яндырып, өйгә керә торган ишекне ачты.

— Әйдәгез, рәхим итегез.

— Ашыкмый торыгыз, Полина Ивановна,— дип, туктатты аны Әхмеров.— Башта безгә чоланны карарга кирәк.

— Чоланны?— диде гаҗәпләнеп Васильева.— Менә ул, керегез.

Ул өйалдындагы такта бүлемтек янына килеп, тимер тотканы үзенә таба тартты. Беленер-беленмәс кенә булган ишек ачылып китте. Алар түбәсез бәләкәй генә бүлмәгә килеп керделәр. Он, суган һәм башка ашамлыкларның исе борынга килеп бәрелде. Ике ящик һәм өч бәләкәй тәпән идәндә күп урын алып тормыйлар иде. Стенадагы киштәләргә төрле зурлыктагы тартмалар, пакетлар, төргәкләр куелган иде.

Чоланга дүрт почмаклы бәләкәй тәрәзәдән яктылык төшә. Кичәдән бирле тикшерүчегә тынгы бирмәгән теге тәрәзә инде бу. Ул бүрәнә стенага тишеп ясалган гади форточка гына булып чыкты. Бу урындагы стена буенда әйбер юк, бары тик идәндә тимер тагарак кына бар. Миронов аны аяк астында уралып тормасын өчен читкәрәк этеп куйды.

— Сергей бик ясарга онытткан икән,— дип елмайды Әхмеров, күпне белгән, ләкин тик торуны алтын санап, дәшмәүне әйбәтрәк күргән акыл ияләре шикелле почмакта басып торган Исәнамановка карап.

Әхмеров үрелеп эчкә таба бөгелгән кадакны капшап карады. Ул бик вазифасын үти иде булса кирәк. Шыгырдап кына форточка ачылды. Чоланга саф һава килеп керде.

— Бу әнә теге он тутырылган лардан да җиңелрәк ачыла икән,— дип, канәгать төстә әйтеп куйды тикшерүче.

— Мин сиңа әйтмәдеммени, юлдаш!— диде Исәнаманов, сөенечennән башын чайкап.— Мөбәрәкнең зиһене шәп эшли әле.

— Сезнең белән бәхәсләшеп булмый инде,— диде Әхмеров, үзе участковыйга күзен кысты. Тегесе пырхылдап көлеп җибәрүдән көчкә тыелып калды.

Васильева башын аскарак иеп, кулларын күкрәгенә куйган килеш, ишек янында басып тора бирде. Мондагы вакыйгалар аны әз генә дә кызыксындырмый иде шикелле, шунлыктан ни уйлаганын да белергә мөмкин түгел иде.

Пунәтәй булып кергән ак чәчле, караңгы чырайлы ир кеше һәм мут күзле яшь кенә кыз, сорасалар, барысын да яңадан кабатларга кирәк булган кебек, бер нәрсәне дә күздән ычкындырмаска тырышып, тикшерүченең һәрбер хәрәкәтен бик игътибар белән күзәттеләр.

Әхмеров сумкасыннан үлчәгеч линейка чыгарды да, аяк очларына басып, форточкага үрелде. Озынлыгы кырык, биеклеге егерме алты сантиметр. Олы кеше моннан сыя алмас иде.

— Полина Ивановна, сез бу тәрәзәне гел шулай бикләмичә тотасызмыни?— дип сорады ул.

— Юк, нигә алай булсын? Элек форточка тыгыз итеп ябыла иде һәм ул кадак белән эләктерелгән килеш торды. Сергей бик ясамакчы булып йөрсә дә, соңыннан онытты, ахрысы. Миңа да, якты төшкәч, җиткән иде. Ә бервакытны, бу ирем үлгәч булды, мин керосин түктем. Шуннан соң кадакны борып куйдым да, форточканы ачып, чоланны җилләттем. Шуннан соң кадагын борып еш кына ачкалый башладым. Кайчакларда җиләк, гөмбә киптердем.— Васильева эшнең кая таба барганын сизенгән кебек булды.

— Форточканы ачып яисә бикләмичә калдыруыгыз мөмкин идеме?

— Мөмкин иде. Әле ике атналап элек кенә дә ачкан идем. Өйгә яз исе кертәсем килеп. Күргәнегезчә, кадакны кабат борырга онытканмын.

— Уварованың соңгы килүе алдыннан форточканың шул хәлдә булуы мөмкин идеме?

Ул бары кулларын гына җәйде.

— Каян белим инде...

Миронов, фотоаппаратын әзер тоткан килеш, тынлыктан файдаланып сорады:

— Рәсемгә төшерергә ярыймы, Әхмәт Шәрипович?

— Ярый,— диде тикшерүче.— Детальле рәсемнәр төшерә тор. Без хәзер чыгарбыз.— Ул тагын Васильевага борылды.— Полина Ивановна, шунысын да хәтерли алмассызмы? Зинһар, исегезгә төшерегез әле. Район сессиясенә баруыгыз турында Уваровага әйтмәгән идегезме?

— Юк, мин аңа бу турыда әйтмәдем. Бәлки сез, Уварова минем район үзәгенә барасымны белә идеме дип сорарга теләгәнсездер?

— Әйе шул!

— Белде.— Аның тавышы дулкынланып китте.— Шул көнне район үзәгенә ул да барды бит. Бергә, бер поездда.

— Менә ничек!

— Әйе. Уварованы берничә тапкыр халык судына чакырдылар. Ни... тапшырырга...— ул ничек дип әйтергә белмичә, иренен тешләде.

— Гаепләү нәтиҗәсенме?— дип әйтеп җибәрде тикшерүче.

— Әйе, әйе, гаепләү нәтиҗәсен! Башта Уварова, авыруын сәбәп итеп, баруны гел кичектереп килде. Ул көнне ничек җөръәт иткәндер, белмим...

— Кайсы поездда кайтты соң?

— Кичке беләндер, мөгаен. Көндезге икенче яртыда ул район үзәгендә иде әле. Аны шундагы ашханәдә күрдем.

— Кичке белән...— диде Әхмеров уйланып.— Ялгышмасам, ул соңгы

поезд бит. Сез аңа өлгермәдегез. Өйдә булмасыгызны Уварова белгән булырга тиешле?

— Шулай булып чыга,— диде Васильева хәтере чуалгандай.

Ул арада фотоаппарат «шылт» итте һәм чолан бер мизгелгә ап-якты булып алды. Васильева сискәнеп китте.

— Бу форточканы тышкы яктан да карыйк әле,— диде тикшерүче. Мироновтан кала барысы да чоланнан чыктылар. Җирдән форточкага кадәрге ара метр ярымлап булыр. Монда баскычсыз менеп булмый. Хәер, баскыч та шунда, янәшәдә генә. Ул коймага кырые белән сөяп куйган килеш ята, аскы ягы җиргә береккән, аңардан күптән файдаланганнары юк булса кирәк.

Тикшерүче аны җентекләп карады, берни дә тапмагач, йортның кушып салынган өлешенә килде. Тирә-ягына каранды: алма бакчасында язгы уяну билгеләре сизелми иде әле, күңелсез кыяфәттә каралыбрак тора. Агач ботакларыннан гына боз төймәләр салынып төшкән. Бакча артыннан ук тар гына сукмак еракка сузыла. Сукмак кечкенә елга буена җиткәч, борыла да яр буйлап авыл уртасына таба китә. Увårованың да йорты кайдадыр шул тирәдә...

Әхмеров бакча капкасын, койма буендагы баскычны, сукмакны тагын бер кат күздән кичерде дә, Васильевадан:

— Бу сукмактан сез генә йөрисезме, әллә бүтәннәр дә йөриме?— дип сорады.

— Бөтен кеше йөри. Мин дә, күршеләр дә,— дип, әкрен генә җавап кайтарды Васильева.— Елгасы, бәләкәй булса да тирән. Көр чайкарга да була, эчәргә дә ярый. Кайчагында эшкә дә шуннан барабыз. Тыныч. Машиналар да, тузан да юк.

— Аңлашыла.

Фотоаппарат тоткан Миронов чыкты.

— Бөтенесе тәртиптә, Әхмәт Шәрипович. Барысын да, шул исәптән өйне дә, кирәк кадәр төшердем.— Ул форточкага ымлады.— Бу яктан да кирәкме?

Әхмеров, «төшер» дигәнне аңлатып башын какты.

Участковый фотоаппаратны алмагач ботагына элде дә, баскыч күреп, шуны алырга китте. Исәнаманов аңа ярдәмгә ашыкты. Алар баскычны икәүләп алып килеп форточка турысындагы стенага сөяделәр. Аннан соң Миронов фотоаппарат тотып җәһәт кенә өскә менде. Берике тапкыр рәсемгә төшергәннән соң, форточканың өске өлешенә текәлеп, нәрсәгәдер карап тора башлады.

Тикшерүче, участковыйның нәрсә караганлыгын беләсе килеп, өскә башын сузды.

— Нәрсә бар анда?

— Чүпрәк! — диде Миронов.

— Нәрсә, нәрсә?— Әхмеров берни дә аңламады.

— Ярыкта чүпрәк кисәге бар. Ботакка эләгеп калган. Мин хәзер...— Участковый фотоаппаратны тагын «челт» иттерде. Шуннан соң рам астындагы ярыктан табылдыкны сак кына тартып чыгарды.

— Менә хәзер барысы да ачыкланды инде,— диде ул төшкән чагында.

Чыннан да, бу чүпрәк кисәге иде. Сүтелгән җепләре чукланып торган гади чүпрәк кисәге. Бер ягы уңып бетсә дә, икенче ягы соры төсен үзгәртмәгән иде дияргә.

— Кызык...— Тикшерүче башын күтәрде.— Аны кем калдырган микән анда? — Ул Васильевага таба борылды.— Сез ничек уйлыйсыз, Полина Ивановна?

— Берни дә әйтә алмыйм,— диде ул аптырап.

— Ярар,— диде тикшерүче уйчан гына.— Хәзер мин барыгызның да тагын чоланга керүен сорар идем.

Тикшерүче чоланга үтешли, алгы бүлмәгә күз салды.

— Бу — теге сандыкмы?— дип сорады ул Васильевадан.

Борынгы зур сандык өстенең яртылаш өлешенә кулдан сугылган палас ябылган. Шәлперәйгән агач футляр эчендәге борынгы машина да шунда тора.

— Әйе, мин ата-анамны хәтерләткән бөтен әйберне шушында саклыйм,— дип, уңайсызланып кына җавап кайтарды Васильева, бу нәрсәләрнең үз өендә булуыннан берникадәр кыенсыну кичерде, күрәсең.

— Уварова кергән көнне дә биредәге бөтен әйбер шушы килеш тора идеме?

Васильева алгы бүлмәне җентекләп карап чыкты.

— Шулай бугай. Тик менә монда урындык бар иде. Уварова шунда утырды.

— Алайса, урындыкны ул утырган чагындагы кебек итеп куегыз әле.

Соравы канәгатьләндерелгәч, тикшерүче барысына да чоланга чыгарга кушты.

— Без хәзер кечкенә генә бер тикшерү эксперименты ясап алабыз,— диде.— Ул бик гади. Сезгә, Полина Ивановна, үзегезнең бөтен хәрәкәтләрегезне Уварова алдындагы шикелле кабатларга туры киләчәк.— Әхмеров пүнәтәй кызга таба борылды.— Ә сездән менә нәрсә сорар идем. Полина Ивановна савыт белән он алгач, аның артыннан алгы бүлмәгә кереп, шушы урындыкка утырыгыз. Ул кухняга кереп китү белән, бу шырпы тартмасын әйберләр арасына тыгарсыз.

Моңарчы күзәтеп кенә торган кыз, үзенә дә эш чыгуыннан чамасыз куанды.

— Он алган чагында Уарованың кайда торганын әйтегез әле, Полина Ивановна,— диде тикшерүче.

— Менә хәзер мин басып торган урында,— дип җавап бирде Васильева. Аның да йөзендә кызыксыну галәмәте сизелде.

Тикшерүче, пүнәтәйләргә күрсәтелгән урыннарга басарга кушып, ымлады.

— Форточка кадагының нинди хәлдә торганлыгы әйбәт күренәме?— дип сорады.

— Әйе,— дип шундук җавап кайтарды теге кыз.— Кадак түбәтәе белән аска карап тора.

— Яхшы. Экспериментны башлыйбыз.

Васильева савытына он салды да, чоланнан чыгып, бүлмәгә юнәлде. Кыз аның артыннан кереп, урындыкка утырды. Әхмеров ымлау белән, торып, сандык янына килде, капкачын ача башлады. Моны тиз генә эшләп булмады, тегү машинасы комачаулый иде. Ул аны тиз генә идәнгә алып сандыкка кагылуы булды. Әхмеров: «Тукта!» — дип команда бирде. Васильева кухнядан кире чыгып килә иде.

— Протокол язасы калды,— диде тикшерүче канәгать кыяфәттә.

Протокол язганда сандык читендә уйчан гына утырып торган Васильева, пүнәтәйләр чыгып киткәч, башын күтәрде.

— Сез форточка аша кем дә булса кергән дип уйлыйсызмы?— дип белеште ул сак кына.

— Әйе,— диде Әхмеров.

— Кем булыр икән? Уваровамы?

— Алай димим.

— Олы кешенең моннан сыя алмасын үзегез дә күрәсез бит.

— Моны олы кеше генә эшләргә тиеш дип каян алдыгыз әле сез?— диде Әхмеров.— Форточкадан бала-чага да керергә мөмкин бит.

— Бала-чага? Уйлап әйтәсезме моны? — Васильева торып басты. Ул бераз вакыт катып калгандай булды, кинәт ахылдап куйды һәм куллары белән яңакларын тотты.— Булыр микән? Ходаем...

Миронов белән Әхмеров Васильева ихатасыннан чыккач, әзрәк ял итеп алыр һәм уйларын туплар өчен дип, капка төбендәге эскәмиягә утырдылар.

Икесе дә язгы кояш нурларыннан күзләрен кыскаладылар. Иртәнге тынлыкның эзе дә калмаган, бөтен тирә-якта искитәрлек матур язгы көн тантана итә иде.

— Миңа калса, Әхмәт Шәрипович, синең эшең төгәлләнүгә табан якынлаша,— диде Миронов тикшерүчегә елмаеп карап.

— Теленә төер чыксын! — дип бүлдерде аны Әхмеров ачусыз гына.— Бервакытны шулай явыз ният белән кеше үтерүгә кагылышлы эшне тәмамлап килгәндә, җинаятьчеләрне эзләү бүлеге инспекторы да миңа шулай дигән иде, соңыннан тикшерүне тагын ике ай буена сузарга туры килде.

— Анысы үтереш бит аның, ә монда символик характердагы җинаять. Кан да, качып баручы җинаятьче дә юк.

— Символик дисеңме? Бәлки шулайдыр да. Ләкин күпме кешенең карашы шуңа төбәлгән. Дәүләтбаев үзе генә ни тора! Шулай булгач, вакытны әрәм итмик, участковый иптәш. Авыл уртасына юл тотыйк.

Икесе дә кузгалдылар. Миронов тикшерүченең терсәгенә кагылды.

— Хәзер син күрергә тиеш кешене әйтимме?..

— Нәкъ өстенә бастың, Алексей! Миңа Николай Кожемякинның улы Володяны күрергә кирәк. Уварованың оныгын. Ничәнче класста укый ул, бишенчедәме?

— Бишенчедә. Мәктәпкә киттекме?

Алар берничә адым атларга да өлгермәделәр, кемнеңдер:

— Әхмәт юлдаш! Лешка юлдаш! Кая киттегез! Туктагыз! — дип кычкырганын ишетеп, борылып карадылар.

Кулларын бутый-бутый Исәнаманов йөгерә иде. Килгән шәпкә:

— Ничек уйлыйсың, юлдаш! Полинка тәрәзәсеннән кем кергән булыр микән?— дип сорады.

Карттан яшерүнең кирәге юк иде. Аның үзенең дә моңа карата нидер өстәве мөмкин бит.

— Кожемякиннарның улы булырга тиеш,— диде тикшерүче.

— Әһә!— дип, хәйләкәр елмайды карт.— Мин үзем дә шулай уйлаган идем. Володька шайтан малай. Теге чакта сиңа әйтмәдем генә. Күрмәгәч, нигә әйтергә дип уйладым.

— Моны тикшерәсе бар әле, Мөбәрәк ага. Дөреслек кайчагында син уйлаганнан катлаулырак булып чыга.

Ярдәме өчен картка рәхмәт әйткәч, Әхмеров белән Миронов мәктәпкә киттеләр.

## Унынчы бүлек

Мәктәп директоры Хәлилов аларны коридорда каршы алды. Ачык чырай белән кабинетка чакырды.

Тикшерүче белән участковый аңа үзләренең яңалыкларын сөйләделәр. Васильеваның өен карагач ясалган нәтиҗә турында берни дә яшермичә әйтеп салдылар. Хәлилов аларны башын каккалап, тыныч кына тыңлап утырды, ләкин тәрәзә ярыгына кысылып калган чүпрәк кисәгенә җиткәч һәм бу серле табылдыкка карата үзләренең дә фикерләрен әйткәч, ул сагайды.

— Тукта, тукта! Пиджак яисә чалбар ертылып калгандыр, дисезме? Бервакытны Елизавета Михайловна Володя Кожемякинның мәктәп формасына кагылышлы шуңа охшаш нәрсәдер сөйләгән иде кебек...

— Нинди Елизавета Михайловна?— диде тикшерүче.

— Володяның класс җитәкчесе...— Директор уйланып маңгаен жы-

ерды.— Хәер, нигә баш катырып торырга? Мин хәзер...— Ул телефон трубкасын алды.— Учительскаямы? Елизавета Михайловнаны табыгыз әле?— Аның йөзе яктырып китте.— Елизавета Михайловнамы? Бер генә минутка минем янга кереп чыгыгызчы... Аннан соң...— Ул трубканы читкәрәк алып, Әхмеровтан сорады:— Володя Кожемякинны да чакырыргамы?

Тикшерүче, «әйе» дигәнне аңлатып, баш какты. Хәлилов янадан трубкага дәште:

— Кожемякинны да алып керегез, Елизавета Михайловна. Әйе, Володяны. Көтәбез.

Күп тә үтмәде, коридордан аяк тавышлары һәм, ишек төбенә җиткәч, ягымлы тавышның: «Көтеп тор, мин хәзер», дигәне ишетелде. Ишек ачылды, кабинетка кырыклар тирәсендәге, ябык гәүдәле, өстенә зәңгәр төстәге кримплен костюм кигән уртача буйлы хатын килеп керде. Зур күзлеге астыннан акыллы күзләре карыйлар иде.

— Исәнмесез!

— Узыгыз, Елизавета Михайловна, рәхим итегез.— Хәлилов урындыкны аңа табарак этте.— Таныш булыгыз, бу иптәш — район прокуратурасының тикшерүчесе Әхмеров Әхмәт Шәрипович була. Ул Васильева эше буенча килгән. Алкалар турындагы теге вакыйганы хәтерлисездер әле.

— Тикшерүче... Васильева... алкалар...— Козырева хәтере чуалгандай, директорга аптырап елмайды.— Бу очракта нинди файдам булыр соң минем?

— Әхмәт Шәрипович Володя Кожемякин белән кызыксына, Елизавета Михайловна.

Козырева тагын да ныграк аптырады.

— Кожемякин белә́н? Әлбәттә, мин Володяның класс җитәкчесе, бусы дөрес,— диде ул, борчулы елмаеп.— Ләкин мин бу малай турында сездән артыгын белмим, Әгъзәм Хәлилович.

Козыреваның бөтен кыяфәтеннән, аның үзеннән ярдәм көтеп, тикшерүгә кагылышлы сораулар белән мөрәҗәгать итүләрен өнәп бетермәү сизелә иде.

Каршыда утырып торган Әхмеров, «мәсьәләгә якынрак кил», дигәнне аңлатып, директорга ымлады.

— Шуны ачыклыйсы килә иде, Елизавета Михайловна,— диде аны аңлап алган директор.— Сез миңа Володяның мәктәп формасы белән булган аңлашылмаучылыкны сөйләгән идегез, хәтерлисезме? Узган уку елы башында булган иде кебек, минемчә...

— Хәтерлим, билгеле. Нишләп хәтерләмәскә?— диде Козырева, йөзендәге аптырау юкка чыкты, аны басынкы педагогик таләпчәнлек алмаштырды.

— Менә әйбәт,— дип сүзгә кушылды тикшерүче.— Зинһар өчен шуның турында сөйләгез инде. Мөмкин булса, җентекләбрәк...

— Җентекләбрәк?— Козырева иңнәрен җыерды.— Башта ук сезнең күңелегезне кайтарырга тиеш булам. Миннән алай игътибарны тарта торган нәрсәләр белә алмассыз. Ләкин үземә билгеле булганын сөйләрмен. Әгъзәм Хәлилович хаклы, бу узган уку елы башында булган иде. Укулар башланганчы ук мәктәп формасын мәҗбүри рәвештә киеп йөрү мәсьәләсе буенча педсовет җыелды.— Укытучы директорга карады.— Ул чагында сез, Әгъзәм Хәлилович, дәресләргә мәктәп формасыннан гына йөрергә, дигән идегез. Безнең класста тулы тәртип урнашты. Беркөнне Володя Кожемякин соры төстәге форма пиджагы белән кара чалбар киеп килмәсенме! Билгеле инде, мин нигә алай икәнлеген ачыкларга тырыштым. Володя белән сөйләшеп булмады, ул үзен бик сәер тотты. Сөйләшмәде, борчылды. Шуннан соң аны өенә кайтарып җибәрдем, әбисе белән килергә куштым. Бу көнне ул күренмәде. Икен-

чe көнне, дәресләр башланыр алдыннан әбисе аны минем янга мәктәп формасында алып килде. Ныклап гафу үтенде, уйнаганда чалбарын пычраткан, иртән генә күреп юып куйдым, дип аңлатты. Бу турыда бүтән сүз сөйләшмәдек. Дөрес, соңыннан Володя ике көн буе берәү белән дә сөйләшмәде...

«Бәлки теге чүпрәк кисәген күрсәтергәдер, таныр иде микән?»— дип уйлады тикшерүче, шунда ук башына бүтән төрле фикерләр дә килде.— Ә бу ни бирер соң? Чүпрәк кисәге озак вакытлар буена яңгыр һәм кояш астында торган, төсен үзгәрткән. Теге чалбар үзе булмагач, моның белән ни эшләп була соң? Ашыгырга ярамый».

Әхмеров игътибар белән Козыревага карады.

— Уварованың чалбар турындагы аңлатмасы сезне ышандырдымы?

Бу стандарт сорауны ул хатын-кызларга хас кызыксыну уятуга исәп тотып биргән иде. Ләкин исәбе акланмады. Козырева берни дә аңлатмаган кыяфәттә иңнәрен генә җыерды.

— Яхшы, алайса,— дип, тирәнгә кереп тормады тикшерүче.— Кожемякинны чакырсагыз иде.

Козырева йомшак адымнар белән ишеккә килде.

— Кожемякин! Кер, Володя.

Кабинетка унбер-унике яшьләрендәге ябык кына бер малай килеп керде. Аның тирән кара күзләрендә боеклык чагыла, киң маңгаена кыеграк булып коңгырт чәчләре төшеп тора.

Бу малайда Әхмеров фотодан күреп белгән капитан Уваровны хәтерләткән нәрсәләр бар иде. Тик ул әле бала йөзендә формалашып житмәгән булса кирәк. «Петр белән апасы да бер-берсенә охшаганнардыр»,— дигән нәтиҗәгә килде ул күңеленнән генә.

Козырева шул арада, кайгыртучан рәвештә Володяның аркасыннан сөеп, Әхмеров утырган өстәл каршысына алып килде. Алар янәшә торган урындыкларга утырыштылар.

Малай Әхмеровка карап куйды, авыр гына сулады, бүтән чагында игътибарны тартуы шикле булган өстәл аягына төбәлде.

— Әйдә, танышыйк,— дип, дустанә төстә әйтте Әхмеров.— Мине Әхмәт Шәрипович дип йөртәләр. Прокуратурада тикшерүче булып эшлим. Синең исемеңне дә, кайда укуыңны да беләм инде...

Тикшерүче, әйткәннәрнең мәгънәсен малай үзе аңласын өчен, бераз тынып торды, аннан соң шундый ук тонда дәвам итте:— Кайвакытта кешеләр безнең ярдәмгә бик мохтаҗ булалар, Володя. Аның никадәр үз вакытында һәм файдалы булуы аларның үзләренә, намусларына һәм сүзләренең дөреслегенә бәйле. Шунлыктан, әлек-әлектән үк шундый тәртип килә: безнең алда эчкерсез булырга һәм дөресен генә сөйләргә кирәк.

— Володя намуслы малай. Мин моны ышанып әйтәм. Шулай бит?— диде Елизавета Михайловна, укучысын дәртләндереп җибәрергә тырышып. Тегесе рәхмәт хисе белән башын күтәреп аңа карады.

— Бигрәк әйбәт!— Тикшерүче елмайды.— Безнең дә башкача уйлыйсыбыз килми иде.

Володя, тезләренә агарынган бәләкәй кулларын куйган хәлендә, туры итеп утыра, дулкынланудан бармакларын селеккәли иде. Аның күзләре яшертен курку белән тикшерүчегә карыйлар, шул ук вакытта аларда малайларча кызыксыну да чагыла. Прокуратурадан килгән «ят абый»ның алга таба үзен ничек тотасын белмәсә дә, малай үзенә сорау бирәчәкләрен сизенә кебек иде.

Әхмеров өстәл өстенә кәгазь һәм ручка куеп, үзе якынрак утырды.

— Узган көзне, мәктәптә дәресләр башлангач, чалбарыңны ерткансың, Володя. Хәтерлисеңме? Ничек булганын безгә сөйлә әле.

Малай сискәнде. Йөзе башта агарып китте, аннан соң, салкын җилдә йөргән кебек, кызарынды. Кашлары тартышып, бер кушылдылар,

бер аерылдылар. Нәрсәдер әйтергә җыенды. Уңайсызланып, ярдәм көткәндәй, класс житәкчесенә карады, аннан соң башын аска иеп елап җибәрде.
Әхмеров малайны юатыргамы, әллә мәсьәләне кабыргасы белән куяргамы дип, аптырап калды.
Хәлилов моны сизенде, чыгып торыгыз, дигәнне аңлатып, ишеккә ымлады.
Тикшерүче белән участковый аңа буйсындылар.
Киеренке биш-ун минутлап вакыт үткәч, Козырева ишекне ачып, аларга керергә кушты.
— Володя бераз дулкынланды,— диде ул гаепле төсле.— Хәзер тынычланды инде.
Укытучы Кожемякинның янәшәсенә утырды, тегесе, башын аска игән хәлендә, элеккечә утыруында булды.
— Шулай бит, Володя?— Малай аның сүзен раслап, башын каккач, карашын Әхмеровка күчерде:— Менә күрәсезме. Әйттем бит...
— Хәзер сине тыңлыйк инде, Володя,— диде тикшерүче, яңадан үз урыннарына утыргач.— Тик шулай килешик, син безгә үзең күргән, үзең ишеткән һәм үзең эшләгәнне генә сөйлә. Бернинди арттыру да, фараз итү дә, читләтеп сөйләү дә булмасын. Килештекме?
Малай, ярар, дигәнне аңлатып, тагын башын какты. Тынлык... Ниһаять, ул авырлык белән генә әйтте:
— Чалбарны мин Полина апаның тәрәзәсеннән чыкканда ерткан идем...
— Сөйлә, барысын да ничек булганлыгын сөйлә.— Елизавета Михайловна, укучысының кыюсызлыгын киметергә тырышып, елмайды һәм бу елмаю Володяга да тәэсир итте булса кирәк.
— Әни ул чагында Бакуда иде, ә этиемне милициягә алып киттеләр. Без ул чакта Женя әбием белән икәү генә яшәдек.— Малай, айнып киткәндәй яңакларын көлкеле төстә кабартты, ашыгып һәм дулкынланып сөйләде.— Женя әбекәй районга китте, аннан кичкә таба кайтты. Шунда ук тагын каядыр чыкты, караңгы төшкәч кенә өйгә керде дә: «Үзең белән кесә фонареңны ал әле»,— диде. Мин киенеп аңа ярдем Женя әбекәй ишегалдындагы сарайга кереп, бау алып чыкты, аны миңа бирде. «Тот, кирәге чыгар», диде. Аннан без елга буйлап бардык, каядыр борылдык...
Кожемякин кашларын җыерып, пиджагының төймәсен йолыккалый башлады.
— Сөйлә, сөйлә.— Укытучы аның иңнәренә тагын сак кына кагылды.
— Кая һәм ничек барганыбыз инәсеннән-җебенә хәтле исемдә түгел инде. Караңгы иде. Яшелчә бакчасын, аннан соң кечкенә капканы, аннан йорт белән бакчаны хәтерлим. Мин Женя әбекәйдән: «Кем бакчасы бу?» дип сорадым. «Полинканыкы», диде ул. Үзе миңа бәләкәй генә тартма тоттырды. «Әнә теге бәләкәй тәрәзәне күрәсеңме?» диде. «Сиңа шуннан кереп, чолан аша алгы бүлмәгә үтәргә кирәк. Анда, сул яктагы почмакта сандык тора. Капкачын ач та, тартманы иң эчкә, әйберләр арасына куй. Тәрәзә бикле түгел, син аны эт кенә», диде. Миңа куркыныч булып китте...
Малай күзгә төндәге курыкканнарын яңадан күңеленнән уздырып, куырылып куйды. Укытучысының кулын үз аркасында тойгач кына, тынычланыбрак дәвам итте.
— Мин Женя әбекәйгә әйттем, кеше тәрәзәсеннән керәсем килми, дидем. Ул ачулана башлады. «Эх син, җебегән! Тиздән Полинканың туган көне, мин аңа бүләк бирергә теләгән идем. Ләкин ул белмәслек итеп, яшереп кенә», диде. Аңа ни ясыйсым килә...— Малай тотлыкты.— Ничек дип әйтәләр әле... сюльприз...
— Сюрприз,— дип төзәтте Елизавета Михайловна. Малайның сөй-

ләгәннәре аны борчыган булуы чыраена ук чыкты. Володя аңа рәхмәтле карап алды, дәвам итте:

— Аннан инде мин батырчылык иттем. Женя әбекәй белән койма буенда яткан баскычны алып килеп стенага сөядек. Женя әби мине бау белән бәйләде. Мин тәрәзәдән чоланга төштем, аннан өйалдына чыктым, өйалдыннан алгы бүлмәгә кердем. Фонарь яндырып карагач, почмактагы сандыкны күрдем. Өстендә тегү машинасы тора иде, ул миңа капкачны ачарга комачаулады. Мин барыбер бәләкәй тартманы Женя әбекәй кушканча тыктым. Сандыктан берни дә алмадым. Валлаһи дип әйтәм. Почмакта нәрсәдер кыштырдады. Миңа тагын куркыныч булып китте, чоланга йөгереп кердем. Тәрәзәдән чыккан чагында ишегалдында эт өрә башлады. Мин чак кына аска очмадым. Штаным шунда ертылды. Ярый әле, баскычка тотынып өлгердем, югыйсә егыла идем. Төшкәч, без Женя әби белән баскычны урынына куеп, өйгә кайтып киттек. Эт өреп калды...

Володя, авыр сулап, тынып калды һәм телефон аппаратына төбәлде. Бу сөйләрдәй бүтән сүз калмады дигәнне аңлата иде.

— Чалбарыңны нык ерткан идеңме соң?— дип сорады малай сөйләгәннәрен сүзгә-сүз язып баручы тикшерүче, аның зирәк малай булып чыгуына һәм әйбәт итеп сөйләп бирүенә сөенеп. Малай башын күтәрде.

— Нык,— диде ул.— Әллә нихәтле умырылды.

— Икенче көнне ямап та тормыйча мәктәпкә киеп бардыңмы?

— Юк, мин бүтән чалбар кидем. Аннан соң кайтып киттем.— Ул, өстәп нәрсә әйтергә белмәгәндәй, укытучысына карады.

— Әйе, әйе, мәктәп формасы киеп йөрергә дигән кагыйдәне бозганлыктан, мин Володяны өенә кайтарып җибәрергә мәҗбүр булдым,— диде Елизавета Михайловна, малайны кыен хәлдән чыгарып.

— Менә ничек? Әбиең ыштаның ертылганны белмәдемени соң?— Тикшерүче, юри гаҗәпләнгән булып, Володяга карады.

— Белмәде,— дип, тагын авыр сулады малай.— Мин шунда ук әйтергә курыктым. Елизавета Михайловна өйгә кайтарып җибәргәч кенә моның турында Женя әбекәйгә сөйләп бирдем. Ул мине ачуланды. «Нигә Полинка өе янында чагында ук әйтмәдең», диде. Аннан соң ертык ыштанны мичкә ташлады. «Хәзер мине мәктәпкә кертмиләр инде», дип елап җибәрдем. Женя әбекәй чыгып китте дә яңа чалбар тотып кайтты. Магазиннан алган. Нәкъ элеккесе шикелле...

Әхмеров күзен протоколдан алды. Малайның арыган карашын сизде, мөмкин кадәр йомшаграк итеп сорады:

— Син миңа дөресен генә әйт әле, Володя. Бу хәлдән соң әшәкелек эшләвең турында уйлап карадыңмы? Кеше өенә керү үзе генә дә әйбәт нәрсә түгел бит. Синең абыең Петя Уваров беркайчан да алай итмәс иде!

— Әйе, мин бик начар эшләдем,— дип пышылдады малай, җиңе белән яшьләрен сөртеп.

— Нигә соң син үзеңнең борчуыңны мәктәптәге укытучыларың, дусларың, иптәшләрең белән уртаклашмадың? Болай итеп үзеңә начарлык кылган булыр идеңмени?

— Булдыра алмадым. Мин ант иттем...— диде малай башын иеп.— Өйгә кайткач, Женя әбекәй икона алдына тезләндереп, берәүгә дә бер сүз әйтмәм, дип ант иттерде.

— Син аллага ышанасыңмыни?— Козырева сискәнде. Куркудан һәм аптырап калудан, аның күзләре зур булып ачылдылар.

— Алай ук түгел дә...

Тикшерүче, класс җитәкчесенең кабынып китүен сүндерер өчен:

— Ә ничек?— дип сорады.

— Женя әбекәй эткәйне төрмәгә Поля апа аркасында утырттылар, үзен дә, әнине дә хөкемгә тарттылар, диде.

Тикшерүченең карашында борчылу чагылды.

— Син хәзер дә бөтен бәлаләрегезгә Поля апаң гаепле дип ышанасыңмыни?

— Юк, ышанмыйм. Поля апа әйбәт. Мин моны беләм...

— Теге төндә эшләгәнне син беркайчан да кабатламассыңмы?

— Беркайчан да.

Машина кояш җылытудан изрәгән җирне чәпелдәтеп, колхоз идарәсенә илтә торган каты юлга чыкканчы әкрен генә барды.

Зубков үзендә иде. Шамаев та шунда икән. Терәк пунктта булган бәхәсләшүдән соң Әхмеровның аны күргәне юк иде. Авыл советы председателе керүчеләр белән баш кагып исәнләште. Павел Степанович кочагын җәеп аларга каршы килде, елмайды.

— Узыгыз, уз, егетләр. Күптән көтәм мин сезне.

Ул куанычын яшереп тә тормыйча, аларны урындыкка утыртты, тагын тәрәзә янына килеп, трубкасын кабызды. Картның күзләре сөенечтән елмаялар иде.

— Мин барысын да беләм инде,— диде ул, мыегын селкеткәләп.— Күпме генә яшерергә тырышсалар да, дөреслек өскә калкып чыкты шул. Авыл җирендә хәбәр тиз ишетелә. Дөресен генә әйткәндә, мин моның шулай буласын көткән идем.— Ул уйчан кыяфәттә трубкасына төбәлде.— Алай да бераз шикләнгән идем шикләнүен. Әше бик четерекле иде бит. Хәзер миңа сезгә рәхмәт әйтәсе генә калды. Картларча. Чын күңелдән!

— Рәхмәт сүзләре ишетү һәрвакыт күңелле,— дип елмайды Әхмеров, арыган кыяфәттә.— Уңышка сезнең авыл кешеләренең принципиаль һәм ярдәмчел булулары аркасында ирешелде, Павел Степанович. Ә участковыйга килгәндә,— ул Мироновка борылды,— минем аңа рәхмәтем аеруча зур!

— Булыштыммыни?— Зубков күзләрен хәйләкәр төстә кысып, участковыйга ымлады.

— Булышу гынамы соң! Алексей Николаевич булмаса, кайсы юлдан киткән булыр идем әле,— диде Әхмеров. Миронов оялуыннан кызарды.

— Кара әле, кара, син терәк пункт хисабына гына эшләмисең икән бит.— Колхоз председателе төтенләп торган трубкасы белән Мироновка шаяртып янады.

Өчесе дә көлештеләр. Зубков тикшерүчедән:

— Хәзер нишләргә уйлыйсыз инде?— дип сорады.

— Хәзерме? Әшне туктатабыз да бетте-китте.

— Туктатабыз? — Зубков Әхмеровка шикләнеп карады. Ул Бердниковның карарын хәтерләде, күрәсең.

— Әйе, туктатабыз. Тик бу юлы җинаять составы булмау сәбәпле,— дип аңлатты тикшерүче.

— Ә-ә! Алай булса, Әхмәт Шәрипович, мин сездән бу турыда кәгазь язып бирүегезне сорар идем.— Ул дулкынланып, кабинет буйлап, әрле-бирле йөренде.— Гаепсез бу балага ягылган тапны алып ташларга кирәк бит.

Кайчандыр аның тормышына килеп кереп, яклаучысы булган һәм дөреслекнең ачыклануын түземсезләнеп көткән Зубков киләчәктә Васильева турында берәүдә дә шик калуын теләми иде.

— Яхшы,— диде тикшерүче.— Ике-өч көннән карарның копиясе җибәрелер.

Зубков канәгать төстә мыегын сыпырды, моңа кадәр бер сүз дә дәшми утырган авыл советы председателенә таба борылып, горурланып әйтте:

— Ә егетләр булдырды бит! Молодцы! Шушындый төенне чишәргә кирәк бит! Ну и ну!

Зубков башлаган сүзен әйтеп бетерә алмады, көтмәгәндә ишек шакыдылар. Ул иңнәрен турайтты, галстугын тартып куйды һәм колхоз председателенә хас мәһабәт кыяфәткә кереп:

— Керегез!— диде.

Кулына калын дәфтәр тоткан матур кыз, ашыгудан тыны бетеп, кабинетка очынып керде, председатель утырып өлгергән өстәл янына килде, дәфтәр арасыннан зәңгәр төстәге кәгазь кисәге алып, аңа сузды һәм кыю тавыш белән:

— Сезгә телеграмма, Павел Степанович. Рәхим итеп, менә монда кулыгызны куегыз,— диде.

Зубков кул кую белән, кыз кабаланып чыгып та китте.

Телеграмманы укыгач, Зубковның күзләрендә сөенеч балкыды.

— Петькадан, бу Петькадан бит! Димәк, диңгездән кайткан.— Ул дулкынланудан калтыранган куллары белән Әхмеровка телеграмманы сузды.— Моряк нәрсә язган, Әхмәт Шәрипович, укыгыз әле.

Тикшерүче телеграммага күзләрен йөртеп чыкты: «Иртәгә юлга чыгам. Әзер булып тор».— Гафу итегез, нәрсәне аңлата соң бу?

— Петр Уваров монда кайтып, зәңгәр күкле, акчарлаклы дулкыннар чайкалган якка безнең Полинканы алып китә дигән сүз бу, кадерлекәем.

Шамаев сискәнеп куйды, сизелер-сизелмәс кенә елмайды. Ул урыныннан кузгалды, сәгатенә караган булып, үзенекенә бөтенләй дә охшамаган карлыккан тавыш белән:

— Гафу итегез, депутатлар белән очрашу билгеләнгән иде, каршы килмәсәгез, китәр идем,— диде.— Хәерле юл сезгә, Әхмәт Шәрипович.

— Хушыгыз, Прохор Ильич. Уңышлар сезгә...

Шамаевны калырга берәү дә кыстамады, артыннан ишек ябылгач кына, Зубков борчылып әйтте:

— Акылсыз да түгел кебек, тик шул кадәр шикләнүчән һәм шома кеше...

Бергәләп, кояш нурларында коенган урамга чыктылар.

Павел Степанович Әхмеров белән аталарча ягымлы итеп һәм тыйнак кына саубуллашты. Мироновның хушлашырга чират көтеп торуын күреп, шоферга таба китте.

Тикшерүче участковыйдан:

— Ну, бүген ни белән шөгыльләнергә уйлыйсың,— дип сорады. Гүя алтын алкалар тарихының тәмамлануы белән, участковыйның да авыр һәм көн дә дәвам итә торган эшләре барын оныткан иде. Әле кичә генә бөтенләй ят булган, бүген инде якын кешегә әверелергә өлгергән бу егет белән саубуллашуы кыен иде аңа.

— Машина дворына барам,— дип, күзләрен кыскалады Миронов һәм беркатлы елмайды.— Анда кичәгенәк тракторның релесен салдырып алганнар иде.

— Район үзәгенә кайчан киләсең?

— Берсекөнгә. Актив җыелышында буласым бар.

— Минем янга кагылырсың бит?

— Әлбәттә!

...Автомашина, тизлеген арттырып, авылдан ераклашты. Председатель белән участковый һаман да калкулык башында басып торалар һәм аңа кул болгыйлар иде. Алар янына бер хатын-кыз килеп басты. Әхмеров аны таныды. Бу — Васильева иде.

Хуш, Полина Ивановна! Хуш, Павел Степанович! Сау булып тор, участковый дустым!

# Эдуард Мостафин

## Туган якка кайтып барышлый

Чит җирләрдән туган оясына
Очкан коштай, кайтып барышым.
Якташларым мине көтеп тормый
Урып-суккан бодай, арышын.
Җиләкләрен җыйган чиләк-чиләк,
Мәтрүшкәсен элгән чормага.
Җил талаган борчак басуында
Нәрсә калган ялгыз торнага?!
Торна китәр, ә мин кайтам гына
Ояларның буш кочагына.
Туган якның төсле «Әлифба»сын
Өр-яңадан мин ачам гына.
Бик таныш бу көзнең «Әлифба»сы,
Куралар да җирдә, камыллар.
Чабып-урган инде, ә шулай да
Киселмичә кала тамырлар...

Тәлгәшендә яшеренеп калган
Миләш, баланнары алланып,
Өзеп алыр өчен кул бармады —
Песнәк карады күк ялварып.
Пошиларга әле үләннәр бар,
Тиеннәргә җитә чикләвек.
Мин соңарып кайткан нәфесемдә
Шигырь белән калам чикләнеп.
Чикләнәмме, әллә ачыламмы,
Бер чынлыгын тоям сагышның —
Балачактай ачык, әчкерсез шул,
Монда килгән уйлар агышы:
Табигатьнең үз күзләре белән
Очраштым мин — вакыт сынаша.
Әйтерсең лә, бүген чынбарлыкның
Үзәгенә төштем көз аша.

## Фикер

Җыела фикер —
яуган кардан, тамган тамчылардан,
искән җилдән, давыл-дулкыннардан,
җыела ул яшен-камчылардан.
Я мәхәббәт, яки нәфрәт булып
җыела да актарылып чыга
язгы ташу, аккан бозлар булып.
Чаптар аттай ыргып-ыргып чаба,
канат җәеп оча еракларга,
Йолдыз булып яна күк түрендә,
диңгез булып шаулый колакларда.
Тәмам ныгып, тыгыз җисем булып
кереп ята кәгазь битләренә.
Ул фикерне кемдер серле күреп
ачкыч эзли башлый бикләренә.
Биген ачса, анда тамчы тама,
җилләр иссә — кайный атомнар да.
Шул ук хәләт-тормыш башлангычы —
Бала-чага таган атынганда...

## Мәхәббәт — иҗат

Мәхәббәт — иҗат, мәңгелек иҗат.
Иҗат итә аны ике йөрәк.
Иҗат итә җил-давыллар кичеп,
Яки тып-тын, яки янып-көйрәп.
Иҗат итә ана бала сөеп,
Кер чайкаган хәлдә иҗат итә,
Иҗат итә токмач кискән чакта,
Ә мәхәббәт, азсынгандай, көтә.
Иҗат итә ата балта чабып,
Буразнада чакта иҗат итә,
Иҗат итә диңгезләрне кичеп,
Ә мәхәббәт, азсынгандай, көтә.
Аңа нидер җитми, әллә яңгыр,
Әллә кармы бик тә көткән чакта.
Онытылган бер елмаю әллә,
Бер яфракмы җитми туган якта.
Мәхәббәткә нидер җитми кала,
Бер йолдызмы янмый күкләрендә,
Бер чәчәкме үсми болынында,
Бер сулышмы җитми күкрәгендә.
Җавап көтәм шактый сорауларга,
Күзләреңә багып җавап эзлим.
Шул ук вакыт — балачагым, яшь-
лек,
Атам йорты белән арам өзмим.
Күңелеңне, уйларыңны тыңлап
Гомер буе иҗат итәм аны.
Белмим: кайда аның башлангычы,
Кайда бетә мәхәббәт ватаны...

## Ут. Кәгазь. Каләм.

Ут яктысы көчен белəм;
Ак кәгазь ята алда,
Башта бер-ике фикер бар,
Түземсез каләм кулда.
Кәгазь — шигырь, әнигә хат,
Бер яла була ала.
Кәгазь — кичелмәгән диңгез,
Кәгазь — күп, чиксез дала.
Ә ут яна, сихри бер көч,
Янар ул таңга кадәр.
Туасы көн өчен кәгазь
Җиткерер нинди хәбәр?
Үткәннәр турында язсам,
Кемнең юк соң үткәне,
Үпкәннәр турында язсам,
Кемнең юк соң үпкәне.
Шундый халәт — ут яктысы.
Кәгазь — сорау билгесе.
Ут, кәгазь, каләмем белән
Дөньяны билгелисе.

## Ике тәрәзә

Бер йортта, ике тәрәздә,
Төн буена ут яна.
Бер бүлмәдә ялгыз ата,
Икенчесендә — ана.
Зур шәһәрнең ике күзе —
Ике тәрәзә — төндә
Ачылган яра шикелле
Бер наз күрмәгән тәндә.
Шул төндә ачылды микән
Күңелләрендә яра?
Ник хәлләрен белешмиләр,
Күрше булып, үзара?
Миңа билгесез уйлары,
Мин бары тик ут күрәм.
Ике ялгызга кушылып
Үз төнемне үткәрәм.
Ике тәрәздә ике ут —
Төнгә кадалган пычак.
Сине шул вакытта вөҗдан
Йолкып уяткан бер чак.
Изәме төн, газаплыймы
Тумый калган баладай...
Вөҗданың йокламый икән,
Язмышың — киң даладай.

# Әмир Мәхмүдов

## ЯШӘЕШ УТЫ

Тарих уты сыный безне,
Гүзәл кешем, бул түземле!—
Чибәр кызлар карашы күк
Яндыра бит ул күңелне.
Сөя белгән йөрәкләргә
Җылылык та уттан күчкән,
Саф мәхәббәт ширбәтләрен
Сөя белгән генә эчкән.
Пыскып янган утын түгел,
Күңел уты — яз, кыш уты...
Язлар килер мизгел җиткәч,
Уттай очып, ак кыш үтә.
Дөньяның иң чибәрен дә
Сөендерә язмыш уты...
Кавышмаган йөрәкләрдән
Китә белми сагыш уты...
Зур галәмнең үз җыры бар,
Моңын бик тиз булмый отып.
Киң җиһанда очучының
Күңелен ялмый язмыш уты.
Яшәешнең җаныдыр ут,
Иң мөһиме — сак эш итү!

Сөймәс йөрәкләрнең уты —
Утларның да иң кырысы.
Ул чакта ут бозларга тиң,
Утлы бозлар ник эресен?..
Кояш — утның иң нурлысы,
Кеше өчен иң җылысы.
Нурларыннан кыллар ясап
Уйныйсы да тик уйныйсы!

Күз яшен дә ут киптерә,
Гүзәл кызый, ник елыйсың?!
Йөз мең төскә керәсең, ут,
Кешегә бик кирәксең, ут,
Янган офык төслесең, син.
Яшеннәрдә — ямь-яшелсең.
Яфрагында ут-гөлләрнең —
Иренедәй гүзәлләрнең.
Алсу алмаларда да ут,
Ялкынланып кайный бит сут,
Салкын кар бөртекләрендә
Җем-җем килеп яна ул ут!
Һич тынмый ут-сандугачым
Тугайларда сайрар әле,
Кешеләрнең йөрәгендә
Уятып ут дәрьяларын...

Минем якты хыялымда
Ут, нишләптер, син — гел төссез...
Ут булса да, сиздермә, йот,
Яшәү мөмкин түгел хиссез.
Томаннарда ул — ак, зәңгәр,
Әмма беләм: утта — куәт,
Ут барысын да ялмап үтә,
Анда — дәрман, анда — хәтәр!
Туганнар каберлегендә
Кешелекнең кайнар хисе —
Кайгы төсе янган утта
Төп юлдашы айның төсе!
Галәмнең падишаһыдыр,
Яшәешнең җаныдыр ут.
Бу дөньяның үзе кебек
Җанлыдыр ут, җанлыдыр ут!
Калса да ул, кинәт, телсез,
Ут — үлемсез, ут — үлемсез!

## Гарифҗан Мөхәммәтшин

# ДҮРТ ЮЛЛЫК ХИС

●

Гөрселдәде шартлау. Ваттыралар
Елгадагы бозны.
Сискәнүдән тетрәп куйды җаным,
Ваттылар дип... Язны.

●

Юллар мине нык иттереп
Менә шуңа төшендерде:
Юллар узганда ачыла
Кешеләрнең кешелеге.

●

Туган Җирне күпме гиздем,
Кая барма — Җәлил эзе!
Гел ак булыр Җәлилләрне
Тудыралган халык үзе.

●

Апрель җитсә үтә борчулы мин,
Үтә сизгер күңелем бу айны:
Шушы айда халкым бәгыреннән
Өзеп алган язмыш Тукайны.

●

Басып китсә җанны кайвакытта
Гамьсезлек һәм ваклык юшкыны,
Алам да мин, кабат укып чыгам
Туфанымны, Тукай, Пушкинны.

●

Кыш көннәре әле яңа гына
Язга таба бара авышып,
Ә күңелем күптән ишетә инде
Тезелеп кайтыр кошлар тавышын...

●

Август. Таңда тәүге кырау,
Күктә тынмас яңгырау,
Берөзлексез чыңлый гүя
Сихри көмеш кыңгырау.

●

Моңланганда, җырлар татар
«Иске кара урман»ын —
Тыңла бер, аңларсың шундук
Аның рыясыз җанын!

●

Тын кысыла. Салкын.
Һава чатнап тора.
Шул салкында нәни бөре
Яшәү өчен саклап тора!

●

«Тук» та «тук» — яңгырый урман,
Балта авазы.
«Тукта!», «Тукта!» дип кисәтә
Кайтавазы.

●

Бер җансыз җан телеп киткән
Ак каенның кайрысын.
Болай да җитәрлек ләса
Каеннарның кайгысы!

●

Зәңгәр күлдә аккош кагына
Су чәчрәтеп тирә-ягына,
Кавышу юлысыман, канатына
Салават күпере сарыла.

●

Май кояшы көлеп яшь кызларның
Алсу битен үпкән шикелле,
Гашыйк таллар сары яфрак сипкән,—
Күзгә күл өсте дә сипкелле.

●

Дулкыннар ярга сыенмый
Кемгә барып сыенсын?
Сыенып ярың булмаса
Җирдә яшәү кыен соң!

●

Әйтерсең лә гашыйк бер Мәҗнүн ул —
Ярын күрү өчен ашыккан —
Караңгы да җиргә таралмаган,
Күктә инде моңсу ай чыккан!

●

Кайтам яшьлегемә хыял көймәсендә
Сагышлы елларны — дулкыннарны ярып,
Чакырып тора яшьлек ярларында
Синең күзләр, янып.

●

Якты бер йолдыз атылды
Кемнеңдер кочагына.
Теләп калдым, юлыкма, дип
Хыянәт учагына.

●

Моңсу гына күзгә бакты
Соңлап чәчәк аткан бер гөл —
Искә төште соңгы кабат
Синең йөзең күргән мизгел.

Тукайның 100 еллыгына

# КАЗАНДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ

**Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул;**
**Алга барганнарга тик табла табылса: алла ул.**

Г. Тукай. «Давылга», 1913.



Элекке «Амур» номерлары (хәзерге Киров урамы, 70 йорт). 1912 ел ахырларыннан 1913 елның мартына кадәр (Клячкин больницасына кергәнче) Тукай шунда яши.

Татьяна Зуева рәсеме.

Казан утлары АЭС әдәби пост

## Марат Әмирханов

# АЭС КЫЗЛАРЫ

Иң башта алар уналтау булалар. Моннан җиде-сигез ай элек Брежнев шәһәрендәге профессиональ-техник училищены тәмамлап, Кама Аланына энергетиклар шәһәре төзергә килгән кызлар алар. Кызарып пешкән алма кебек тулы, матур чаклары. Көчләре дә ташып тора, бәдәннәре дә нык. Кызларга карата болай әйтү, ихтимал, килешеп тә бетмидер. Әмма шәһәр төзү уен эш түгел: көч-куәт тә, ныклык та, күңел киңлеге дә кирәк моның өчен. Шәһәр киләчәк өчен салына. Киләчәкнең исә таләпләре зурдан. Шуның белән бергә, яшьлеккә кырыс имтихан да ул шәһәр кору. Кызганычка каршы, бу имтиханны барысы да уңышлы тота алмый. Шушы кечкенә коллективта сынатучысы да табыла.

...Кызларны вагоннарга урнаштыралар. Брежневтагы якты, биек, иркен тулай торактан соң бернинди уңайлыклары да булмаган вагонда яшәү, билгеле, җиңел түгел. Тик кызлар әле моңа әллә ни игътибар итми. Ниһаять, алар мөстәкыйль! Монысын болай ит, тегесе ярамый, дип өстә торучы юк... Тик бу мөстәкыйльлекнең кыен яклары да күп икән. Бик рәхәт булган икән дә училищеда, ничек кайгыртканнар икән укытучылар алар турында!

Кызлар бик тиз җылы бөркеп торган мәктәпләрен, укытучыларын сагына, юксына башлыйлар. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, көннәрдән бер көнне М. ның әнисе килеп төшмәсенме?! Әни кеше төзелеш белән, андагы эш шартлары белән танышып йөри. Хәер, моңа күп вакыт кирәкми. Кама Аланында нибары биш-алты йорт та, актарылып ташланган тау-тау балчык өемнәре! Барысы да уч төбендәгедәй күренеп тора. Ана:

— Шушындый ташландык җирдә эшләү өчен унбер ел укытмадым мин сине!— дип, кызын төзелештән алып китә.

Өеренче югалту. Уйлап карасаң, аларны соң атом электр станциясе төзелешенә берәү дә көчләп китермәде. Укыганда ук яңа төзелешләргә бару, тормыш юлын бер кешегә аркаланмый, үзләренчә башлап җибәрү турында күпме хыялланганнар иде. Н. Островскийның «Корыч ничек чыныкты», В. Катаевның «Вакыт, алга!» әсәрләрен кат-кат укыдылар, диспутлар оештырып тамаклары карлыкканчы бәхәсләштеләр. Данлы комсомол традицияләренә сүнмәс ялкын өстәгән КамАЗ баһадирны коручылар, чирәм җирләрне үзләштерүчеләр, БАМ юлларын сузучыларның батырлыгы ничек ашкындыра иде аларны.

Һәм менә алар өлешенә төшкән көмеш — Татарстан атом электр станциясе! Мәйданга чык, бил алыш, комсомол дигән олы исемне эшең белән исбатла!

Мастер апалары Роза Галимҗанова укучыларының теләгән чын күңеленнән хуплый.

— Рәхмәт, кызлар, сездән башканы көтмәгән идем,— ди ул шатланып.

...Кама Аланында кызларны чәчәк бәйләмнәре белән каршы алалар, берсеннән-берсе матур теләкләр телиләр. Кызларның бәхете ташый. Шулай булмыйча, әнә ничек хөрмәтлиләр аларны. КамАЗ батыры, идарә начальнигы Рәис Сәлахович Сәлахов кул астында эш башлау үзе ни тора!

Шуңа күрә кызлар төзелештән киткән әлеге кызны гафу итә алмыйлар, бу хакта

хәтта искә төшергәнне дә әнәп җиткермиләр. Нишлисең, яшьлек шундый инде ул. Алай дисәң, икенче «югалтуга» мөнәсәбәт бөтенләй башка. Чөнки анысы гаилә кору белән бәйле, кем әйтмешли, объектив сәбәп.

Хәзер алар ундүртәү. Иртә таңнан кыр казларыдай тезелешеп, уйнаша-көлешә эшкә ашыгалар. Шаяннар, тапкырлар һәм үтә дә нечкә күңелләләр... Сания Мифтахова бер вакыйганы искә төшерде:

— Шулай бер көнне,— дип сөйләп китте ул,— Рәис Сәлахович чакыртып алды. Подъездларны, тәрәзә төпләрен чистартыгыз, тәртипкә китерегез, йортны комиссиягә тапшырырга әзерлибез, ди бу. Ашыктырыпмы ашыктыра. Шул кызулык белән мин дә кызларны боргычлап эшкә куштым. Бераздан урап килсәм, ни күрим, утырганнар да рәхәтләнеп ял итәләр.

— Их, оятсызлар,— дип орышырга тотындым боларны.

— Кузгалдык, кызлар,— диде Флера исемлесе. Миңа ник кайтарып сүз әйтсеннәр: әллә мин бар аларга, әллә — юк. Яннарында сырпаланып та йөреп карыйм, ярарга тырышып мәзәк сүзләр дә кыстырып җибәрәм. Ачылмыйлар.

Бер җаен чыгарып Флераны читкәрәк чакырып алдым да:

— Ни булды, нигә үпкәләдегез? — дидем.

— Сез безне бала-чагага саныйсыз, Сания Нуриевна,— ди бу.

— Ничек инде?..

— Сез килгәнче бертуктамый ике сәгать эшләгән идек инде без, арыттык. Оятсызлар, дип әрләдегез...

Күзләрен чекерәйтеп карап тора миңа, иреннәре мелт-мелт килә үзенең. Бик кыен булып китте, тамакка ниндидер кайнар төер утырды, уйлап карасаң, улым яшендә генә бит әле алар. Рамилем унынчыда укыса да, ул миңа һаман сабый кебек кенә. Ә бу кызлар әнә нинди зур эшкә алынганнар.

Флераны кочаклап алдым. Гафу үтендем кызлардан, килештек...

Еш кына без хәзерге балаларның «туганда ук унны бетереп туулары» хакында сөйләргә яратабыз. Тик унбиш-уналтыда ук ике метр буй үстергән бу балалар табигатьләре белән моннан илле-алтмыш ел элеккege яшьтәшләреннән әллә ни аерылмыйлардыр. Өлкәннәр белән яшьләр арасындагы кайбер аңлашылмаучылыкның нигезендә «буйга карап» фикер йөртү ятмыймы икән әле? Мәктәптә, училищеларда тәрбия эшен азмы-күпме бу үзенчәлекне искә алып оештырырга тырышалар. Хезмәт коллективларында хәл башкачарак. Ярый ла Сания Нуриевна хәлне тиз төшенеп алган. Җитәкче өчен һава кебек кирәкле сыйфат ул сизгерлек. Һай, ничек җитми ул кайчакта безгә!

Төзелештә гел яшьләр. Утыздан узганнарны сирәк очратасың. Бу — заманның иң катлаулы корылмаларыннан берсе булган атом электр станциясен, энергетиклар шәһәрен яшьләр күтәрә дигән сүз.

Эшләр монда җитәрлек. Быел, әйтик, 25 мең квадрат метр мәйданлы торак йортлар төзү каралган. Алдагы ике елда гомуми мәйданы 32,5 мең квадрат метр булган торак төзелүен исәпкә алсак, бу — шактый зур бурыч. Шундагы буяу эшләрен идарәдәге С. Мифтахова җитәкчелегендәге бердәнбер бригада башкарачак. Менә нинди ул безнең буяучы кызлар!

Бригадада алар ундүртәү...

## Флера

Кызлар фоторәсемгә төшәргә ярата инде ул. «Казан утлары» журналыннан язучылар килгәч тә алар бик теләп объектив алдына бастылар. Чәчләрен шома итеп тарап җибәргән, кечерәк буйлы тиктормас бу кыз шунда ук күзгә чалынды.

— Истәлек була ул,— дип сөйләнә-сөйләнә башкаларны кысрыклап иң алга килеп тә басты. Аннан соң фотографка карап шаян гына әйтеп куйды: аппаратыңда пленка бармы соң?

Юл буена бер кәлимә сүз әйтмәгән, җитди фотограф та елмаегандай итте хәтта. Ә кызларга көләргә генә булсын. Бер тын чыр-чу килеп алдылар.

— Һи, кычыткан чыпчыклары, сез җыенгалаганчы караңгы төшә бит инде,— дип идарәнең баш инженеры кызларны ашыктырып та карады.

— Караңгыдан куркасызмыни, абый?

Янә көлешү. Флера башын артка чөеп нидер әйтте, шунда гына тындылар.

Флера белән тулай торакта да, эш урынында да очрашырга туры килде. Дәрт ташып тора бу бөтерчектәй кыздан. Ул, я әңгәмә, мае беткән лампа кебек инде сүнәм, инде өзеләм дип торганда, иң кирәкле сүзне кыстырып, аны җанландырып җибәрә, я күз карашы белән генә сер ачарга җыенучыны туктатып кала. Иптәшләрен үз тирәсенә туплый ала, үз ихтыярына буйсындыра белә Флера Нургалиева. Ул һәрвакыт — кешеләр арасында. Дуслары да, иптәшләре дә күп аның. Бөтен группа белән атом электр станциясе төзелешенә киту турындагы фикерне дә беренче булып ул әйтә.

— Училищедан кызларны озата килгән Роза Галимҗанова, теге яки бу мәсьәләне хәл иткәнче иң элек Флера белән сөйләш, дип киңәш бирде,— ди бригадир,— мин бу киңәшне тотам.

Бервакыт мастер Фәридә белән Валентинаның эшен кабул итми. Квартираны яңабаштан буярга, обойларга туры килә. Ә кабат эшләүнең зыяны зур: беренчедән, материал күп тотыла, икенчедән, җитештерүчәнлеккә суга. Мондый шартларда хезмәт җитештерүчәнлеген планнан тыш бер процентка күтәрү, үзкыйммәтне ярты процентка киметү турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Йөкләмәдә исә бу беренче һәм төп пункт итеп язылган. Бригадирның ачуы килә, әлбәттә. Үз башыма бәла алдым бу өйрәнчекләр белән дип тә уйлап куя. Бригада советы җыеп, хәлне уртага салып тикшерергә, дигән карарга килә ул, премияләрен кисәргә, гел-гел ташлама ясап барсаң, башыңа менеп утырырга да күп сорамаслар.

Флера бригадирның уйларын сизеп торган, күрәсең. Төш вакытында Сания апасы янына килә дә, аны култыклап ала.

— Нигә әле хәйләкәр мәче кебек бик сырпаланасың, кызый?— ди бригадир битараф кыяфәт белән.

— Сер бар, Сания апа,— ди Флера пышылдап кына.

— Нинди сер ул тагын?

— Валентиналарга каты бәрелмик әле бу юлы.

— Юк инде, наным, гел сезнең көйне көйләп булмас. Узган айда да план үтәлмәде.

— Анысын аңлыйм мин... Күңелсез хат алдылар алар.

— Нурзидәнең дә әнисе авырып ята, аңа карап эшенә зыян китерми, барыгыздан да уздыра.

— Кайгыны төрле кеше төрлечә кичерә, Сания апа.

— Комсорг белән дә киңәшегез,— ди бригадир бераз уйланып торганнан соң,— ишетсен колагың, монысы соңгы ташлама.

— Сания апа, нел әле, битеңдә тап бар,— ди Флера һәм бригадирның битеннән үбеп ала да чырык-чырык көлеп китеп тә бара.

Әйе, бер үк училищеда укысалар да, осталык төрлесенеке төрлечә шул. Флера, әнә, дүртенче разряд белән чыккан, башкаларныкы түбәнрәк. Хикмәт разрядта гына да түгел, күнекмә җитми, тизлек. Өйрәтергә дә өйрәтергә әле.

Бригадир бу хакта еш уйлана һәм көннәрдән бер көнне идарә начальнигы алдында кичке укулар оештыру мәсьәләсен куя. Фикерне хуплыйлар. Өйрәнүнең — зарары, осталыкның чиге юк.

Кайгыртучанлык — һәр кешене бизи торган матур сыйфатларның берсе. Ләкин ул бар кешегә дә бердәй бирелми. Моның өчен яшьтән үк ниндидер шартлар булуы зарурдыр, мөгаен. Бу шарт — Флера өчен, безгә калса, ул туып үскән гаиләнең ишлелеге. Сигез бала үсәләр алар. Ул — өченче. Аңа, билгеле, үзе турында гына түгел, кече туганнары турында да кайгыртырга туры килә. Киң күңеллелек менә шуннан киләдер дә инде. Әтисе Ярулла Аксубай районының «Большевик» колхозында тракторчы булып эшли, әнисе Нурфиәл дә балалары күплеккә сылтау итми, кулыннан килгәнчә, колхозга булыша. Ә алма агачыннан ерак төшми диләр.

Флера хәзер институтка әзерләнә. Теләге — төзүче-инженер булу.

## Гөлсинә

Миңа Кама Аланында шактый вакыт яшәргә туры килде. Фатир хуҗасы, төзелә торган атом электр станциясенең директор урынбасары Леонид Григорьевич Чащин

командировкада иде. Шуңа күрә комсомол-яшьләр бригадасының эшен җентекләп, иркенләп өйрәнергә мөмкинлек булды. Түшәмнәргә буяу тигез төшкән, обойлар матур итеп ябыштырылган, гомумән, пөхтәлек менә мин дип тора. Тик су гына өзек-өзек килә, җылысы да чамалырак.

Бу хакта мин әңгәмәдәшем Минзәлә кызы Гөлсинә Сәлаховага да әйттем. Ул зур зәңгәр күзләрен каймалаган озын-озын керфекләрен сирпеп бер карады да, оялчан гына елмаеп:

— Суы-җылысы безгә кагылмый инде, абый, без буяучылар бит,— диде.

— Комсомоллардыр бит сез?..

Әлбәттә, су, җылылык мәсьәләләре бригада комсоргы очлап чыга торган нәрсәләр түгел. Аның белән шактый югарыдагы җитәкчеләр шөгыльләнсә дә таманга туры килә әле, дәгъва барыбер бетми. Әлеге сүзләр исә күбрәк Гөлсинәне «кузгатып» җибәрү өчен әйтелде.

Флераны башлап йөрүче дигән идек. Бу дөрес. Аны коллективта хөрмәт итәләр, тыңлыйлар. Шулай да комсорг итеп характеры белән Флерадан шактый аерылып торган Гөлсинәне сайлаганнар. Сәбәп нәрсәдә?

— Гөлсинә тыйнак кыз, юкка-барга тузынмас,— диде Валентина.

— Гадел ул Гөлсинә,— дип өстәде Рәхимә,— тотнаклы.

— Сүзендә дә тора бит,— Монысын Нурзидә Сәмигуллина әйтте.

Күрәсең, кызлар әнә нинди сыйфатларны да алга куялар. Кайчак шулай да була, кайбер «активистлар» үз мәнфәгатьләренә туры килә торган, үз шәхесләрен күтәрүче «күтемле» эшләр белән генә мавыгалар. Беркем белән дә конфликтка кермәүче мондый эшкуарлар, яшерен-батырын түгел, кайчак тамырларын шактый киң җибәрәләр. Гөлсинәгә андый гадәт ят тоела. Ул беренче планга коллектив мәнфәгатьләрен куеп эш итә.

...Төзелешкә килгән чаклары гына була кызларның. Нәкъ шул вакытта биш катлы бер торак йортны тапшырырга әзерлиләр. Төзүчеләр ашыга, чөнки унлаган-йөзләгән кеше фатир көтә. Фатир булмау аркасында күп кенә кешеләр көн саен Түбән Кама, Зәй, Брежнев шәһәрләренә кайтып-китеп йөрергә мәҗбүр.

— Шимбә өмәләре үткәрсәк ничек булыр икән, кызлар,— дип киңәш итә комсорг.

— Авылга кайтасы бар.

— Мунча кереп килергә кирәк, кер юылмаган.

Сүз дә юк, сәбәп нигезле. Чөнки әлеге поселокта яшәү өчен шартлар бик тә чамалы. Әмма комсоргның чигенәсе килми.

— Җәй көне ләбаса,— ди ул,— кичен Кама буена төшәргә мөмкин...

— Ял көне ял өчен бирелә.

— Шул да булдымы комсомол сүзе. Корчагиннар, Космодемьянскаялар турында лаф орырга яратабыз, эшкә килсәк, башкача сайрыйбыз...

Икенче көнне Гөлсинәнең шатлыгы эченә сыймый: тыңлаганнар, күңелен аңлаганнар!

Абруй үзеннән-үзе генә килми, аны эшең, кылган гамәлләрең, хаклыгың белән яуларга кирәк. Ул бөртекләп, айлар-еллар дәвамында җыела. Гөлсинә Сәлахова әле бу юлның башында гына тора. Бүгенге омтылышларына карaганда, өметле күренә яшь комсорг. Тик шунысы борчый: төзелештә әлегә Гөлсинә кебекләргә ярдәм җитәрлек түгел. Брежнев йортлар төзү комбинаты комсомол оешмасы, ВЛКСМның Түбән Кама комитеты, шулай ук ВЛКСМ өлкә комитеты бу мөһим төзелешкә игътибарны арттырсыннар иде. Монда килеп чыгучылар исә хәзергә план үтәлү белән кызыксынудан ары узмыйлар. Планнарны үтәргә генә түгел, арттырып та үтәргә кирәк. Әмма бурычлар үтәлешен таләп иткәндә КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре К. У. Черненконың сайлаучылар алдында сөйләгән речендә әйтелгәнчә, кешеләрнең белемнәренең, интересларының, кәефләренең әһәмияте һич тә кимемәскә тиеш.

— Ничек төзүче булып киттең?— дип сорадым Гөлсинәдән.

— Безнең Күзкәй мәктәбендә җәй саен укучылардан төзүчеләр бригадасы оештырыла иде. Ике ел мөгезле эре терлекләр комплексы коруда катнаштым. Ошады миңа бу һөнәр. Укып бетергәч туры училищега килдем.

Гөлсинә, аңлашылганча, һөнәрен очраклы рәвештә, кем әйтмешли, күз йомып

сайламаган. Бу бик мөһим. Чөнки үз һөнәрен яраткан кеше аңа беркайчан да хыянәт итми. Бу уңайдан игътибарга лаек тагын бер нәрсә бар, ул да булса мәктәптә профессиональ ориентация эшенең куелышы. Авыл мәктәбендә тәзүче һөнәренә тәпле мәхәббәт уяту аеруча мактаулы күренеш. Ишәйсеннәр иде андый мәктәпләр. Авылның үзе өчен дә әзерләсеннәр иде Гөлсинә Сәлахова кебек төзүчеләрне.

## Гөлшат

Төзелешкә килеп озак та тормыйча комсомол җыелышында Гөлшат Солтанованың тәртибен тикшерделәр.

— Ничек алай килеп чыкты соң?

Кызның озынчарак ябык бите буйлап ниндидер шаян дулкын йөгереп узды, кыйгач кара кашлары астына яшеренгән күзләреннән зур булып очкын сибелде. Күрептөрам, Гөлшатның пырхылдап көлеп җибәрәсе килә, әмма чыдый, тырышып-тырмашып булса да чыдый. Сабак алмаган ахрысы бу кыз әлеге тикшерүдән, дип уйлап алдым. Чөнки, җыелышка куеп тикшерерлек булгач, хәл җитдигә охшый. Ә ул авыз ера.

— Ничек дип, кем белә инде аны, абый,— диде кыз, ниһаять.

— Ул көнне йокыдан торганда ук бик ашкынып, җилкенеп торган иде Гөлшат,— дип искә алды бүлмәдәш иптәше Фәридә,— әле Алла Пугачева тавышына охшатып җырлап җибәрә, әле биеп китә, көлә-көлә арып беттек үзеннән.

Баксаң, күңеленә ятышлы төш күргән икән Гөлшат. Имеш, үзләренең Югары Галим (Зәй районы) авылында сабан туе, ә алар, дус кызлары белән, ап-ак күлмәктән, кулларында аллы-гөлле кыр чәчәкләре. Ул җыр, ул уен-көлке...

— Тавык төшенә тары керә,— дип котырта аны бүлмәдәшләре.

Гөлшат дөрестән дә биергә ярата икән. Дискотека булган көнне аны клубтан бульдозер белән эттереп тә чыгарып булмый, дип шаярталар кызлар.

Зифа буе, бераз чандыррак җиңел гәүдәсе, озын төз аяклары биергә ясап куйган кебек инде. Шулай да фикерне бүлеп булса да әйтик, кайчандыр 200—300 кешеле авыл өчен җиткерелгән клуб, әлбәттә, яшьләрнең таләпләрен канәгатьләндерә алмый. Акчаны аз эшләми кызлар, киемнең дә ниндиен алырга беләләр. Клубта исә, күлмәкчән утырып булмый, салкын, тешләр тешкә бәрелә. Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Инде хәзер үк Кама Аланында 2660 кеше яши, киләсе ел башына халык саны 7 меңгә җитәр, дип көтелә. Ләкин хәзергә әле культура йорты салу турында сүз дә ишетелми. Өстәвенә, клуб хезмәткәрләре искечә, «авылча» эшләүләрен дәвам иттерәләр. Көн саен кино карау, һичшиксез, яшьләрне ялыктыра торгандыр. Гөлшатларга, ышанып әйтергә була, бу гына җитми. Яшьлек, шартлар юк, дип тормый, ул ярларына сыеша алмый аккан язгы елга кебек ашкына, болгана, бөтерелә. Бу агымга без дөрес юнәлеш бирергә тиешбез...

Шулай да ни булган соң теге көнне?

...Кызлар, көндәгечә, эшкә тотыналар. Кызганычка каршы, измә бетә. Менә-менә китереп җиткерергә тиешләр икән. Брежнев шәһәреннән измә ташу да җиңел түгел, ара йөз чакрым чамасы бит. Хәер, бу вакытлы кыенлык. Измә заводлары салынып ята. Әмма кызып кына эшләгәндә кинәт тукталып калу барыбер ачуны кабарта.

Кызларның авыз-борыннары салына, аптыраганнан кайсы кая барып сөялә. Ә урамда — җәй. Кама ягыннан йомшак җил исә. Күктә кояш балкый.

— Кызлар, әйдәгез су коенырга!— ди Гөлшат.— Барыбер тик утырабыз.

— Бирермен мин сезгә тик утыруны!

Барысының да башлары тавыш килгән якка борыла. Сания апалары икән. Их, бу тишек авыз Гөлшатны!?

— Подъездны чистартыгыз, чүпләрне түгегез, идәннәрне себерегез,— ди бригадир каршы сүз әйтергә урын калдырмыйча. Аның да хәлен аңларга кирәк. Булмаганда эш табу ифрат авыр нәрсә ул. Кызлар да төшеп калганнардан түгел шул.

— Без буяучылар, чүп түгүчеләр түгел,— дип җибәрә Гөлшат.

Башкалар аңа кушылуларын сиздереп сүзсез генә баш ияләр. Бригадир измә

артыннан китә. Чөнки күз-колак була алмасаң, үзеңә үпкәлә, аны сылаучылар эләргә генә тора.

Кызларның вак-төяк эш белән шөгыльләнәсе килми, әлбәттә. Нишлисең, бригадир кушкач тыңламый булмый. Гөлшат иреннәрен турсайтып ачык тәрәзә янына килеп баса. Аста мастер белән бригадир сөйләшеп тора. Нәрсә турындадыр кычкырышып-кычкырышып бәхәсләшәләр. Мастер Сания апаларына очып кунарга әзер, мин сиңа әйтим. Гөлшат моңа түзеп тора аламы соң? Тота да идәндә аунап яткан бер уч чүпне мастер ягына тондыра...

Әле ярый мастерга эләкми... Монда комсомолларны иң борчыганы шул була, Гөлшат мин түгел, дип, кылган эшеннән танып маташа. Монысы инде чыннан да уйландырырлык.

Нык эләгә кызга, утлы табага бастыралар үзен...

— Гөлшат катлаулы, авыр эшләрне ярата,— ди бригадир,— мин аңа гел шундыйларны кушарга тырышам. Стеналарны, түшәмне шомартырга, почмакларны бик тигез итәргә оста ул. Бу эшләр көч, җитезлек кенә түгел, нәфисләкне тоемлау да таләп итә. Куллар мастерок аша изманең ничек ятуын сиземләргә тиеш.

Гөлшат беренче шомарткан түшәмен әле булса хәтерендә саклый. Югыйсә, тырышкан да иде инде. Очынып эшләде. Авыр, авыр дигән булалар, ние бар соң моның?! Әнә шундый үз-үзеннән канәгатьләнү хисе дә кереп оялаган иде күңеленә.

— Гөлшат, түшәмгә география картасы төшерәсеңме әллә? — дип бу уйларын бик тиз таратты Нурзидә. Ул күрше бүлмәдә эшли иде.

Баскычтан төшеп, түшәмгә караган иде, чак авып китмәде: сылангач урыннар кәрмәле дә чыкмалы, үзләре сызыклы, әйтерсең лә, өсләреннән суалчан кәтүе узган.

Кыз үкси-үкси елаган иде. Осталык җиңел генә бирелми икән. Тик эшкә тешә-тырнагы белән ябышкан кеше барыбер үзенекен итмичә калмый. Гөлшатка хәзер күз тимәсен! Озак та үтмәс, ул яшьләргә үз һөнәренең серләрен төшендерә башлар.

* * *

Бригадада алар ундүрт кыз: Флера, Гөлсинә, Гөлшат, Нурзидә, Рәхимә, Фәридә, Валентина...

Тыныч, матур кичләрдә кызлар биек тау башына менәргә, анда килеш йолдызлар атылганын күзәтеп торырга яраталар. Якты эзләр белән тулы күк йөзе әкияттәге сихри дөньяны хәтерләтә. Күңелләр дә сафланып киткәндәй була, гел яхшылык кына эшлисе килә. Хәер, кызлар болай да бик изге эш башкаралар, хезмәтләре җирдә йолдызлар кебек кабынып кала. Бу инде — зур бәхет!

## Касыйм Хәмзин

# БЕЗНЕҢ БАБАЙЛАР

### Хәбибулла

Бездә, «Җиде бабаңны беләсеңме?» — дигән сорау йөри. Бу инде туган-үскән җиреңне, аның кешеләрен беләсеңме, дигән сүздер. Яшь чакта барысын да белгән кебек тә буласың. Тик, картая төшкәч, хәйран каласың: тәкәбберләнелгән генә икән...

Кайтыр алдыннан авылымның бер егете турында укыдым. Ул миңа бик нык тәэсир итте. Сүз Коры Көрнәле егете, Хәйрулла бабай оныгы Хәбибулла турында иде.

1942 елны Хәбибуллага унсигез яшь тула. Кай арада бу яшүсмер егет булып өлгергән соң?! Әле бит күптән түгел, ул Бабай күленнән кызыл канатлар сөзеп йөри иде. Эте Актырнакны ияртеп, Поместа урманы буенда куян, төлке ауларга да ярата иде Хәбибулла.

Сабан туйларында Хәбибулла үзе шикелле үсмерләр белән көрәшә. Җиңсә, бүләк ала, җиңелсә, коры кала. Боларның бакча артында калын әянке үсә, малай шуның төбенә утырып, скрипка ясап карый. Бер көн, биш көн, ун көн утыра. Скрипка юк.

— Нәстә улым, барып чыкмыймы әллә?

— Юк, әти, пәке белән генә булмый икән.

— Шулай улым, һәр эштә корал кирәк. Теге, беренче Герман сугышында, ике солдатка бер мылтык иде, чүт кенә җиңелми калдык, революция генә коткарды. Ташла, гармун алып бирермен.

Болары — малай-шалайларга хас мавыгулар гына булып кала. Үсмер Хәбибулла, авыл мәктәбен тәмамлагач, 1938—39 еллар тирәсендә Спасстагы (хәзерге Куйбышев районы) тракторчылар курсына укырга бара. Алмыйлар. «Соңга калдың, яренгә кил, иптәш Хәйруллин»,— диләр.

— Иптәш директор, кырык чакрым җәяү килдем, алыгыз инде!

— Булмый. Программаның шактыен үттеләр, каулап җитәлмисең.

— Җитәм. Мин математиканы бишкә генә укыдым.

Барыбер алмыйлар.

Хәбибулла колхозына кайта. Диплом сорамый торган эшләр башкара: салам китерә, тирес чыгара, көз көннәрендә Чистайга, Алексеевскига ашлык ташый, атлар карый, нинди кара эш бар — бөтенесенә өлгерә.

Үсмерлеккә — үсмер, әтисенә караганда, буйчанрак, җилкә дә киңрәк. Ләкин аз сүзле, йомыграк, әйтерсең, ниндидер авыр хисап чыгара.

Еллар йөгереп үтәләр. 1941 ел. Көтелмәгән хәл: сугыш. Менә сиңа — Спасс, менә сиңа тракторчылар мәктәбе.

— Улым, мин сугышка киттем. Әй, колхоз синең җилкәдә кала, сынатма.

— Ярый, әти, исән йөреп, сау кайт, ...ат яз, әти, хат яз!

1942 елны яшь-яшь егет Хәбибулла да, берникадәр сугыш һөнәрен үзләштергәч, артиллерист булып, Сталинград фронтына юнәлә.

— 1945 ел. Кыш. Тымызык салкын. Зур кибәндәй олы кояш кызарып чыкканда, кинәт таулар актарылгандай була. Тирә-як тетри, озын телле ялкын күккә сузыла. Фашистлар йөзләгән орудиедән коточкыч ут ачалар. Дошман һөҗүм башлый. Өлкән сержант Хәбибулла — үзенең пушкасы белән ничәмә танк каршында. Аның орудиесе һәр секунд диярлек утлы туп очыра. Өзлексез улау-гөрселдәү арасында бер генә боерык: «Огонь! Огонь!..» Уң якта безнекеләр чигенәләр: ротамы, взводмы чигенә. Полк җиргә сыена. Менә тагын бер танк аның өстенә килә. Ләкин, килеп җиттем, дигәндә, бер урында ике тапкыр әйләнә дә, кара төтен чыгарып яна башлый.

— Старший сержант Хәйруллин! Прямой наводкой!!

— Есть, прямой наводкой!

Тиңдәшсез көрәш ничә сәгать дәвам иткәндер. Аның алдында фашист мәетләре, җимерек танклар, үзйөрешле пушкалар. Дошман — Хәбибулла сызыгын үтә алмый. Кара дулкын булып ябырыла да, корыч кыяга бәрелгәндәй, чәлпәрәмә килә. Егетнең гимнастеркасы тозлы суга манып алган кебек. Соңгы туп — ут уйнаткан орудие тынып кала. Фашистлар канатланалар. Аларга юл ачыла. Ләкин егет бер-бер артлы гранаталар очыра. Бара-бара граната әрҗәләре дә бушап кала. Кискен минутлар, фаҗигале секундлар. Чигенергә? Бирелергә? Әсир төшәргә? Юк! Юк!! «В рукопашную!!!» Хәбибулла бу әмерне үзенә һәм ярдәмчесенә бирә. Ул автоматта калган соңгы патроннарны, кыеклап сиптерә-сиптерә алга атлый: орудие көпшәсе алдына, дошман каршына, атакага!

Ул өзлексез сөйләнә... юк, совет солдаты бирелми. В атаку! Түтә белән! Зубами! Урааа!! За родину!.. Кинәт, җир эченнән, үзәннәрдән меңләгән «ура!» яңгырый. Бу нәрсә?

Кайтавазмы? Юк. Бу — чын «ура!» Полк һөҗүмгә күчә. Хәрби подразделениеләр, тимер ташкыны булып, алга ыргылалар. Хәбибулла уртада кала. Кыскасы солдатлар, офицерлар егетне үтеп-үтеп китәләр. Нидер эндәшеп, өлкән сержант җилкәсенә кулларын тидереп алалар. «Молодец! Молодец!» — диләр.

Хәбибулла орудие көпшәсенә таянып биш кенә минут хәл җыеп ала. Аннан Берлинга юл тота. Рейхстагка барып җитәргә санаулы көннәр генә кала.

Сугыш кырында адашып очкан пулялар күп. Шуларның берсе өлкән сержант Хәбибуллага тия...

Менә шулай минем күңелдә егетнең тәрҗемәи хәле яңарды.

Кул чемоданы тотып, елга портына төштем. Билет алдым. Ярты сәгать үтмәде, зур көпчәкле пароходка утырдым. Идел тын. Җил юк. Су өсте тип-тигез. Пароход бер алга, бер артка селкенеп, чылбырларын дөбердәтеп алды. «Сау булыгыз! Без китәбез, сез каласыз!» — дигән сыман, ике мәртәбә моңсу гудок бирде һәм зур көпчәкләрен «шап-шап» бәреп, китеп тә барды. Биек биналар минут саен ераклашты. Ак Кремль дә, Сөембикә манарасы да күздән югалды.

Пароход Кама Тамагында озак тормады, Лаешка бөтенләй туктамады. Озын-озын ике мәртәбә сызгыртып, Мурзиха пристанена элмәкле аркан ташлады. Элек заманда монда биек яр иде. Яр өстендә балык, ак күмәч, крендель кибетләре, агач чиркәү, зур трактир-чәйханә һәм яр буйлап сузылган икмәк амбарлары, Мурзиха авылы җәелеп ята иде. Хәзер боларның берсе дә юк. Су да су, су да су... Тиз-тиз атлап корыга чыктым һәм, үтеп баручы машинага утырып, Көрнәлегә юнәлдем.

Авыл. Килгәннең икенче көнендә урамга чыктым. Тыкрыкларны әйләндем. Сулары шактый кимегән инеш-күлләргә карый-карый, авыл уртасындагы таш һәйкәл янына барып тукталдым. Һәйкәлне ал, зәңгәр чәчәкләр бизәгән. Бронза йөгертеп, алтын төс биреп, бер генә җөмлә язылган.

«Советлар Союзы Герое Хәбибулла Нәбиулла улы Хәйруллин һәм Ватан сугышында корбан булган җитмеш авылдашыбыз истәлегенә».

Озак кына шул чәчәкләргә карап тордым һәм төрле уйларга чумып: «Каһарманның әтисен күреп сөйләшим әле!» — дип, урам буйлап киттем. Юлда, күпер янында Кадыйр бабай очрады.

Исәнлек-саулык алышкач, геройның әтисе Нәбиулла абзый янына баруымны әйттем.

— Соңга калгансың, үткән ел без аны җирләдек, сиксән бер яшендә вафат булды, — диде карт.

## Нәбиулла

Шулай, килде-китте сөйләшеп, аның өенә таба атладык.

Кадыйр бабай:

— Хәбибулланың әтисе Нәбиулланы миннән дә яхшы белүче юк, — диде.

Кама елгасы буенда атаклы Ләбәдин Болыны бар. Болын зур, киң. Үлән — билдән, төнбоек яфраклары каплаган кечкенә күлләр, ермаклар күп. Кыр үрдәкләре, урман тавыклары, төрле кошлар өчен — җәннәт. Кызу печән өстендә бу гүзәл болын яшь кызлар, киленнәр, егетләр шау-шуыннан гөрләп тора. Көрнәлеләр шунда печән чабалар. Зур-зур кибәннәр куялар. Чана юлы төшкәч, көрпәк кар өстеннән үрәчәле чана белән ташыйлар. 20 яшьлек Нәбиулла кайвакытларда, керәшен татары Иван дәдәйләргә кереп, атын ял иттереп чыга. Күз ачкысыз буранлы кичләрдә кунып та калгалый. Шулай кереп-чыгып йөри-йөри Иван дәдәйнең 18 яшьлек кызы Анфиса белән таныша.

Егет тәвәккәл.

— Анфиса, әгәр дә миңа кияүгә чыгарга теләсәң, өч тапкыр вәгъдә бир! — ди.

Кыз: «Вәгъдә! Вәгъдә! Вәгъдә! Вәгъдә!» — дип, дүрт мәртәбә әйтә. Егет сүз арасында гына: «Башлы-күзле буласы иде. Мәнә без, Анфиса белән, Иван дәдәй, әйе...» — дип, кызның әтисе янында да тел тибрәтә башлый.

— Без, Нәбиулла, каршы түгел, чиркәүдә поп ни дияр...

— Алла сакласын, тәүбә, тәүбә, Иван дәдәй, мин нишләп чиркәүгә барыйм?!

— Без — христианнар шул, Нәбиулла.

— Булмагае. Чиркәүгә бармыйм. Совет власте дә көләр, авылдашлар да күз ачырмаслар. Юк, булмый.

— Нишләргә соң?

— Ир — кая, хатын — шунда. Безнең өйдә генә туй ясарбыз, бер дога укытырбыз: берәү дә сизми калыр, бетте-китте, Иван дәдәй!

— Хатын күнмәс бит.

— Күнәр, хатын-кызга ирнең бер карашы җитә. Бөереңә йодрыгыңны терәп каршына бассаң...

— Анысы шулай, ну, синең мәһәрең бармы соң?

— Әй, бабай, Нәбиулла мәһәрсез кыз сорап йөриме? Чүпрәк-чапрак бер сандык тулы.

— Нәбиулла, карале, хатыннар нәфесле була. Минем хатын дүрт аяклы хайван сораячак.

— Кәҗә бар, Иван дәдәй, менә диген кәҗә!

— Кәҗә — мәһәр малы түгел. Хатын тана сорар.

— Тана күп булыр, Иван дәдәй, мине аяктан егу булыр ул, син ирләрчә, акаебрак карап, кәҗәгә күндер үзен.

Керәшен татарларының тагын бер гадәтләре бар икән. Әгәр дә кияү ягы кодакодачаларга бүләкне саран бирсә, түр башыннан төшми, кияү ягын хурлап такмак әйтеп утырачаклар икән.

— Озак утыралармы, Иван дәдәй.

— Бер тәүлек. Кисәү агачы белән дә кузгатып булмаячак.

— Уйлашырбыз, Иван дәдәй...

Бер кичне көтмәгәндә егетнең тәрәзә яңагын кемдер шакый. Егет, кына гөлләрен читкәрәк этәреп, тәрәзәне ача. Авыл советы дежурные икән.

— Нәбиулла энем, бик тиз кәнсәләргә. Авыл советы чакыра.

Авыл урамнары кыска. Ике-өч сикердең — кирәк җиргә барып та җитәсең.

— Ни бар, Җәлал абзый?

— Мәнә нәстә, Нәбиулла. Военкоматтан повестка килде. Син, Вәгыйз улы Кадыйр — икәү волостька, каралырга барасыз.

— Нәстә, Җәлал абзый, әллә хафалы хәбәрләр бармы?

— Бар энем. Аклар Казан каласына якынлаша икән.

Каралырга гына киткән Нәбиулланы шул ук көнне Казанга ук озаталар. Кабан күле тирәсендә атна чамасы кыр тузаннарын кагалар. Мылтык тотарга, атарга өйрәнәләр һәм Вятка шәһәренә алып китәләр.

Менә шунда латыш егете Азинның атлы батальонына элгә Нәбиулла. Нарат кебек зифа буйлы Нәбиулланы иртәдән кичкә кадәр сугышырга өйрәтәләр. «Направо руби! Налево руби! Прямо коли!..»

Нәбиулла сугыш хезмәтенә өйрәнгән чакта аклар Казанга кергәннәр. Мәскәүдән катгый боерык: «Казан каласын кайтарып алырга!»

Арчаны аклардан чистарту Азин батальонына йөкләнә. Атлы батальон юлда. Привал. Азин эскадрон командирларын җыя... «Сугыш хәйләсез булмый» — ди ул. Һәм Ижевск шәһәреннән ак гарнизонга ярдәмгә килгән ак отряд булып Арчага керәләр.

Кояш баер алдыннан, кичкенә шәһәрнең каралтылары сөремләнеп күренә. Кич. Эңгер-меңгер. Ак гарнизон үз хатасын соң сизә. Нәбиулланың кылычы ялтырап-ялтырап китә.

«Яшәсен Совет власте!» Бу аның тавышы. Аңа Кадыйр егет кушыла. «Үлем — акларгааа!!»

Кайдандыр «урааа!» яңгырый. Тимер юл станциясе, почта алынган. Гөрселдәү сирәгәя, бара-бара бөтенләй тына. Төн. Зур бина түбәсенә озын колга белән кызыл әләм элеләр...

Бер генә көнгә, каралырга гына киткән Нәбиулла частьтан частька күчеп, дөнья гизеп, Арча, Казан, Богырыслан, Бузулык, Җаек шәһәрләрен азат итеп, өч ел үткәч кенә авылына кайта. Анфиса көтмәгән. Кияүгә чыккан. «Вот кызларның вәгъдәсенә ышан...» — диде Кадыйр бабай.

Нәбиулла егетнең өе Яңарәт урамында, Бакай күленә каршы. Аккош атавына төшә торган тыкрык чатында. Урыс капка, калын бүрәнәле, биш-алты тәрәзәле, калай түбәле, таза өй. Сугыш елларын исәпкә алмасаң, егет бөтен гомерен шул авылда, шул нигездә үткәргән...

1922 елны игеннәр шашып үстеләр. Арышлар шундый биек, кыңгыраулы кара дугаларның түбәләре генә күренеп-күренеп ала. Бодай сабагы үзенең эре башагын күтәрә алмый җиргә иелде. Мәрҗән-мәрҗән тары тасмалары, алкалы солылар, боркчак кузаклары, барысы да Көрнәле игенчеләрен чиксез шатландырды. Нәбиулла җиң сызганып эшкә керешә. Тик ялгызлык комачаулый. Кул арасына керергә сөйгән яр кирәк. Димче карчыклар алтын акча кебек ялтырап торган кызыл кавалеристны еракган күреп алалар. Кызлар сиртмәле кое тирәсендә моңа каш сикертәләр. Чия кебекләр дә, йөзек кашы кебекләр дә исәпсез-хисапсыз. Ә егет сырлана, сайлый. «... Инде, Нәбиулла, бәхетле буласың килсә, уңга да, сулга да карама. Безнең авылда Миңлебанаттан да чибәр, кура җиләге кебек мөлдерәп пешкән кызны, көндез уникеле лампа тотып эзләсәң дә, табалмассың. Уңганлыгы дисәң — бер хәйран. Бер көлтәгә — биш көлтә урып та, бәйләп тә өлгертә. Үзе инсафлы, мәнфәгатьле, олыны — олы, кечене кече итә, ирне дә ир итәр. Синең сүзең Миңлебанатның түбәсе өстендә булыр! Үзе дә сине өзелеп ярата. Атасы-анасы дисәң — әүлияләр инде...»

Шулкадәр гүзәл кыз алдында бер кызыл кавалерист кына түгел, биш Нәбиулла да эрер иде. Әби-бабай, мәһәр, дип тә тормыйлар. «Бергә тора башлагач, барысын да үзегез карарсыз, шул үзе мәһәр булыр», — диләр.

Шул ук елны Нәбиулла өйләнә. Башлы-күзле була. «Килен рәхәте татый алмый үләм инде»,— дип зарланган әнкәсе дә килен күрә.

Бер ел да үтми, булачак герой Хәбибулла дөньяга килә.

— Менә шулай узды Нәбиулла кордашның егет чагы. Хәзер юк шул инде, җирләдек, — диде бабай. — Улының һәйкәле генә калды...

## Илдар Низамов

# КИТАП! КИТАП? КИТАП

КИТАП УКУЧЫГА АЧЫК ХАТ

Хөрмәтле Зыя абый, исәнмесез!

Сораган китабыгызны («Илдә мин дә сандугач») җибәреп, калган сорауларыгызга җавапны матбугат аша җиткерергә Сездән ризалык алганга да, берничә ай үтеп китте. Гафу итегез! Тоткарлануым гамьсезлектән түгел. Уйланырга, әзерләнергә кирәк иде. Китап кадәр китап турында, ачык хат язу җиңел түгел икән.

Әмма язарга кирәктер дим, чөнки китапны иҗат итү, аны бастырып чыгару, укучыга җиткерүгә бәйле, Сезне борчыган сораулар миндә дә, мин эшләгән Татарстан китап нәшриятында, газета-журнал редакцияләрендә дә, язучы һәм журналистларда да бар.

Бу рәвешле җавап бирергә мин хаклымы соң? Хаклымындыр дим, чөнки минем төп вазифам — китап язу, аны бастырып чыгару. Андый кеше китапны сәүдә һәм китапханәләр аша укучыга җиткерү мәсьәләләре белән дә таныш була.

Барыннан да бигрәк, мин — китапны укучы. Китап ата-бабаларыма да, үземә дә, балаларыма да тел ачкычы, белем чыганагы, җан азыгы, киңәшче һәм дус булды. Китапны олылаганга күрә аны тагын да күбрәк белергә, файдасын бүтәннәргә дә җиткерәсе килгәнгәдер инде, аңарга бәйле эшне гомерлеккә сайлаганмын; китап сөючеләр җәмгыятенә дә, ул оешуга ук, бик теләп кердем. Болар барысы да, китап укучы иптәшләремә мөрәҗәгать итеп, фикерләремне уртаклашырга хокук бирәдер дим.

Ачык хатның кемгә адреслануын да төгәлрәк тәгаенләп китик. Китап укучыга, дидек тә, ә кем ул китап укучы? Үпкәләмәгез, Зыя абый, хәзерге заманда «китап сатып алучы» һәм «китап укучы» төшенчәләре һәр очракта тәңгәл килми. Әйтеп ышанмаслык хәл: китапны матди байлык, йорт җиһазы итеп алучылар ишәйде. Зарары нидәме? Иң беренчесе: әхлакый түбәнлек — замана мещаны «культурный» булып, икейөзлеләнә, китапка таянып, дус-иш, туган-тумача алдында дәрәҗәсен күтәрә, аңа сыенып, үзенә кирәкле кешеләр җайлый. Андый кешеләрне үгетләргә җыенмыйм, теләгем дә юк, ачу-нәфрәтем дә җитми, кулым да бармый. Алар безнең журналны барыбер укымый да. Әмма, бөкрене гүр турайтыр дип, кул селтәргә дә хакыбыз юк. Алар бит күпме китапны — җан азыгын — зинданнарга ябып тоталар. Бу бит кешелек тәҗрибәсен, зиһенен, акылын үзләрендә туплаган дөнья бәясе кешеләрне тереләй күмү белән бер. Ярамый!..

Безгә рухи азыкны мещаннарга бирмәс өчен житди чаралар күрергә кирәк. Моңа партия, дәүләт күләмендәге эш дип карау сорала. Нинди чаралар икәнен, бәлки, журнал битләрендә киләчәктә бергәләп ачыкларгадыр, уртага салып фикерләшергә, киңәшергә? Китап чын-чыннан рухи ихтыяҗдан чыгып кулланучыларга ирешер-

га тиеш. Мондый чара әхлак тәрбиясенә дә уңай йогынты ясар иде. Югыйсә, бу алдагы әхлакый түбәнлек, әйтергә дә оят, китап спекуляциясе, китап урлау төшенчәләрен барлыкка китерде.

Безгә дә: «Нәшрият тирәсендә эшлисең, юньлерәк китаплар табыш әле»,— дип килүчеләр очрый. «Нинди була ул юньле китап, кайсы язучыныкы, нинди әсәре кирәк!» дип төпчене башласаң, алар сиңа марсианга караган кебек аптырап карыйлар. Китапның ни нәрсә икәнен төшендерә башласаң, үпкәлиләр.

Әлбәттә ки, өенә китап сатып алып кайтырга теләгән һәр кешенең юлына каршы төшәргә димим. Шәхси китапханә булдыру — изге эш. Белемгә, культурага омтылган меңнәрнең хыялы иде ул. Аны тормышка ашырыр өчен хәзер шәһәрдә дә, авылда да һәр гаиләнең диярлек мөмкинлеге бар. Безнең илдәге шәхси китапханәләрдә 40 миллиардтан артык китап тупланган. Күмәк куллану фондларыннан берничә мәртәбә күбрәк. Искиткеч байлык! Социализмның олы җиңүе, казанышы. Социалистик яшәү рәвешенең күркәм бер сыйфаты.

Шәхси китапханә турында үзенә бер гәп корырга ярар иде: ул нинди булырга тиеш, аннан ничек файдаланырга?

Минемчә, шәхси китапханә ул аның хуҗасының рухи йөзен чагылдыра. Аннан шөгыленне, холкыңны, хәтта өметеңне, хыялларыңны күреп була.

Әлбәттә, кешенең белем дәрәҗәсе, холкы, шөгыле нинди генә булмасын, китапханәдә кешелек культурасының, әхлагының нигезен тәшкил иткән, сине дә, мине дә кешечә тәрбияләгән һәм тәрбияләүче классик әсәрләр һичшиксез булырга тиеш. Культура, әдәбият әһелләре, педагог, психологлар әйтүенчә, андыйлар — «йөз том» тирәсе. Болардан тыш үзеңнең, гаиләңнең зәвыгына, гадәтләренә аеруча туры килгән, яраткан язучылар, әдәбият жанрлары, сәнгать төрләре булырга мөмкин (без, мәсәлән, гаиләбез, нәселебез белән — табигать сөючеләр). Эшеңә, мавыгуларыңа бәйле әдәбият та кирәк. Өйдә шулай ук политик, аң-белемеңне чарлап, дөнья хәлләреннән хәбәрдар тору өчен актуаль әдәбият, брошюралар да, өй, хуҗалык, көнкүреш, бала тәрбияләү өчен кулланмалар, сүзлекләр, атлас, альбомнар була.

Нигә кирәклеге ачык булмаган китапның киштәмдә торуын күз алдына да китерә алмыйм. Китап — дус, дибез икән, китапханәңдә үзеңә таныш түгел «ят»ны тотарга ярыймы соң!? Кемнең кем икәне эштә, хәрәкәттә генә белене. Китапка да тузан кунмаска, ул гел хәрәкәттә булырга тиеш. Бу — өй китапханәсенең иң беренче мөһим шарты. В. И. Ленинның китапка биргән билгеләмәсен искә төшерик: китап ул — искиткеч зур көч, аны хәрәкәтчән, «күчеп йөри торган» итәргә кирәк. Ә Тукай ни диген: китап укып, дәртләремә дәрман алам. Без исә, китап хуҗасы булып, дәртебезне басып куябыз да, аңардан дәрман алырга, ягъни аны укырга ашыкмыйбыз.

Арабызда өй китапханәсен: «Ичмасам бездән балаларга мирас калсын, бәлки, пенсиягә чыккач, үзебез дә укырбыз», дип, бүтәннәрдән калышмаска теләп җыючылар да аз түгел. Юк, андый китапханә үз хуҗасының йөзен дөрес күрсәтә алмый.

Шәхси китапханәле кешеләр белән кызыксынгач, бер авылда җитәкчеләр мине бик мул яшәүче гаиләгә җибәрделәр. Чыннан да аның ялтыравыклы серванты эчендә, савыт-сабалар арасына калын-калын китаплар да тезелгән иде. Хуҗа кеше белән иркенләп гәпләшергә генә торганда, табынга чәй әзерли башладылар. Түгәрәк өстәл селкенә икән. Шуны сизеп, хуҗа дөрес хәзерләп утырган малаеның китаплары арасыннан берсен алды да өстәл тәпие астына кыстырды да куйды. Тәлсез калдым. Сервантта эшсез тилмереп утырганнары өчен дә җаным әрнеде: сайгаклар какшый башласа, алар шунда кыстырылмаслар дип кем ышандыра ала, ә!?

«Пенсиягә чыккач укырбыз», дип, китапларны зинданда тоту — кысыр өмет. Пушкин яисә Тукай иҗаты белән бүген танышу ихтыяҗы тумаган икән, андый теләк, пенсиягә чыккач кына тумас.

Инде балаларга мирас калдыруга килсәк, минем хәтердә бер ханымның журналда басылган хаты яңара. Ул аны елый-елый язгандыр. Бердәнбер кызыма дип, ул чамадан тыш зур китапханә җыя. Аны әллә нинди махсус йозаклар белән бикләп тота. Ниһаять, кызы буйга үсеп, аңа тантаналы рәвештә шушы байлыкны тапшырыр минут та җитә. Ана дулкынлана, ә кыз — битараф. «Нигә кирәк миңа ул китапханә?

Шундый шыксыз, шундый салкын, син аның янында кабер янында торган кебек торасың», ди.

Күрәсезме, Зыя абый: «китап сатып алучы» белән «китап укучы» арасындагы аерманы ачыклап, Сезнең «Ни өчен китап җитми?»— дигән төп соравыгызга да берникадәр җавап бирдек шикелле. Чыннан да, бездә әле, тулаем алганда, китап җитмәүчелек күренешләре (кибетләрдә «яхшы» китапларга чират була, кергән кибетеңдә кирәк китабыңны таба алмыйсың һ. б.) бар икән, бу, беренчедән, китапның чын хуҗасына эләкмәвеннән, икенчедән, җәмәгать һәм шәхси китапханәләрдә хәрәкәтсез ятуыннан килә. Икесе дә — зур, әле хәл итеп бетерелмәгән проблема, болар хакында да журнал битләрендә уртага салып сөйләшеп алырга ярар иде. Бүген исә без сәбәпләрнең башка берсенә тукталмакчы булабыз.

Кызык хәл: китап җитми, шул ук вакытта кибетләрдә шүрлекләр тулы. Озак еллар сатылмыйча, база, складларны тутырып яткан, хәтта бер тапкыр да ачылмыйча, макулатурага тапшырылган китаплар да була. Мондый хәл сәүдәдәге китапның башка товарлардан нык аерылуын, үзенә аерым бер товар булуын сөйли. Аңа «Ни өчен фәлән әйбер җитми?» дигән сорау да урынлы түгел. «Кемгә һәм нинди китап җитми?» дигән сорау кирәктер. Әйтик, менә Сез, Зыя абый, ни өчен теге китапны ике ел эзләп тә кибетләрдән таба алмагансыз, авторына һәм нәшриятка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булгансыз? Сез юкка миннән кат-кат гафу үтенәсез, андый гозерләр еш була, һәм без аларны кулдан килгәнчә канәгатьләндерергә тырышабыз. Бу инде үзенә нәрсә кирәк икәнен дә белмәгән кешенең «әйбәт китап» соравы түгел. Сез бит нәкъ шул китапны эзлисез, аның үзегезгә ни өчен кирәк икәнен беләсез.

Андый очраклар еш була, дидем. Шушы хатны язганда, ягъни кичәле-бүгенле генә дә бер-бер артлы булган ике мисалны теркәп китим. Редакциягә башта Киевтән бер иптәш килеп керде. Генерал Сафиуллин китапларын эзли икән. Әтисе турында да язылган булган. Аңа бердәнбер юлны — китапханә юлын өйрәтеп, озатып җибәргә, телефон шылтырады да, авылдан килгән бер абзый: «Гомер бер генә» дигән китапны Казанда да таба алмадым, сездә юкмы?» дип сорады. Татарстан китап торгыннан белешергә киңәш бирдек.

Ярый инде, генерал Сафиуллинның русча китаплары моннан җиде-сигез ел элек чыгып, сатылып беткән дә булсын ди, ә «Гомер бер генә»нең басылганына ике ай да юк. Шул арада сатылып бетәргә ул бүлмә бизәр өчен яраклы калын китаплардан түгел. Юка гына. Йомшак тышлы. Темасы да бөтен кеше ташлана торган аш-су, дару үләннәре, бакча эшләре түгел. Аңа партиянең XXVI съезды күрсәткән кимчелекләр, аларны бетерү юллары турындагы язмалар тупланган. Көн үзәгендәге темага язылып, бик вакытлы дөнья күргән китап лабаса, нигә җитәрлек чыкмаган соң?

Тиражын, ягъни китапның ничә данә басылуын, карыйк: 4 мең икән. Нәшрият исә аны 10 мең басарга планлаштырган булган. Аңлашылды! Тукта, миңа аңлашылды да, ә бүтәннәргә? Арабызда китап тотмаган кеше юк диярлек, әмма күпләр аның туу, укучыга килү юлын күз алдына китереп бетерми. Тәртип мондый: китапның тиражын автор да, аны бастырып чыгаручы нәшрият та үзләре генә билгеләми, алар шулай ук китапны тарату белән дә шөгыльләнмиләр, аларда китап булмый, кирәккәндә, үзләре кибеттән сатып алалар. Китап сәүдәсе белән республикада Татарстан китап торгы (Таткниготорг) һәм Татпотребсоюзның китап бүлеге шөгыльләнә.

Тираж болай билгеләнә. Нәшрият үзенең планын ике ел алдан төзи. Әйтик, 1985 елда чыгачак китаплар планын без 1983 елның сентябрь аенда югары оешмаларга җиткереп, ноябрь аенда раслатып алдык. Шуннан соң план, аерым китап итеп типографиядә бастырыла да, май аенда сәүдә оешмаларына җибәрелә.

Авыл һәм шәһәрләрдәге китап сатуга бәйле һәр коллектив, товароведлар җитәкчелегендә, әлеге тематик планны төпченеп өйрәнергә, хезмәт коллективларында, уку йортларында, халык арасында пропагандалауны да оештырырга бурычлылар. Бу эш турындагы «Положение»да «Товаровед китап сәүдәсе ассортиментын республика (край, өлкә) сатып алучыларының һәм китапханәләренең ихтыяҗын җентекле өйрәнү нигезендә формалаштыра»,— дигән сүзләр бар.

Димәк, китапның тиражы аңа булган ихтыяҗны җентекләп өйрәнүгә бәйле. Кибетнең киләчәккә акча-финанс планы да, укучыларның рухи азык белән тәэмин ителү

мөмкинлеге дә сәүдә хезмәткәрләре тарафыннан, менә шушы, заказ җыю көннәрендә (май-август) хәл кылына. Чыннан да, бик җаваплы чор бит!

Авыр чор — үзәк нәшриятларның (алар 30 дан күбрәк) да тематик планнары шушы көннәрдә килеп төшә, берьюлы 16—17 мең чамасы китапның кыскача эчтәлеген, җисемен өйрәнеп чыгарга кирәк. Бу көннәрдә сәүдәчеләр урындагы хезмәт коллективларының китап сөючеләрнең ярдәменә бик тә мохтаҗ.

Эшнең күплеге, әлбәттә, аның ярым-йорты үтәлүенә сәбәп булмаска тиеш. Тематик планнар белән күпчелек укучыларны таныштырганда гына, аларның игътибарын басылачак һәр китапка юнәлткәндә генә сәүдә хезмәткәрләренең киләчәккә ышанычлары нык була ала.

Һәр китапка! дип басым ясыйбыз, чөнки сәүдәгә тәкъдим ителгән китапны башка товарлар кебек, «фәлән сорт» дип, «уптым» санау мөмкин түгел. Һәр китап — мөстәкыйль берәмлек. Тематик планнарда «матур әдәбият», «масса-политик әдәбият» дип, төркемнәргә бүленсә дә, укучылардан заказ җыйганда, тираж билгеләгәндә шул гомуми төшенчәләр белән генә эш итәргә ярамый. Һәрбер китапка булган ихтыяҗ аерым ачыкланырга тиеш. Мисалга, Татарстан китап нәшриятының 1985 ел планына күз салыйк. Иң беренче бүлеге: «Масса-политик әдәбият». Игътибар белән карыйк. Анда бит иллеләп исемдә китап, брошюра.

Һәркайсының үз авторы, исеме, темасы, жанры, үз проблемасы бар. Арада марксизм-ленинизм классикларының хезмәтләре, алар турында әсәрләр дә, партия, хөкүмәт карарлары да, төрле тарихи вакыйгаларга, шәхесләргә багышланган әсәрләр, партия-оештыру, идеология һәм тәрбия эшенең бүгенге актуаль мәсьәләләренә багышланган китап, брошюралар, яшьләр тормышын, әхлак хәлләрен яктырткан әсәрләр, юридик киңәшләр, рәсми белешмәләр... Әйтик, «В. И. Ленин, КПСС экономия һәм сакчыллык турында (мәкаләләр, документлар җыентыгы)», Е. А. Степанованың «Карл Маркс. Кыскача биографик очерк» китабы; «Әйдә халыкка хезмәткә!» дигән җыентыкка күренекле татар публицистлары К. Насыйри, Х. Ямашев, Г. Тукай, Г. Коләхметов, М. Гафури, Г. Ибраһимов һ. б. турында очерклар тупланган. С. Шакирның «Мәңгелек исемлектә» китабы Татарстан улларының Бөек Ватан сугышындагы батырлыкларын тасвирлый...

Матур әдәбият, балалар һәм яшьләр өчен әдәбият, производство-техник, авыл хуҗалыгы, туган якны өйрәнү, уку-укыту һәм башка әдәбият бүлекләренең һәркайсы менә шушылай, һәрберсенең үз йөзе булган, конкрет катлам укучыга аталып тәкъдим ителгән китап, брошюра, альбом, буклет, нота, календарь һәм башкалардан тора. Татарстан китап нәшриятында гына да аларның еллык саны 340—350 гә җитә.

Һәрберсе — иҗат җимеше, күмәк хезмәт казанышы. Бер генә китап та планга очраклы керми. План күп санлы укучыларның, җәмәгать оешмаларының, иҗади көчләрнең фикер-теләкләренә таянып, аларның хатларында, очрашуларда, «түгәрәк өстәл» яннарында әйтелгәннәрен дә истә тотып төзелә. Анда Язучылар союзы, Журналистлар союзы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты кебек иҗади һәм фәнни оешмаларның тәкъдимнәре чагылыш таба. Шуны гамәлгә ашырырга республиканың һәм илнең иң оста, тәҗрибәле иҗатчылары — язучылар, журналистлар, партия һәм совет эшлеклеләре, эшче, колхозчылар, галим, белгечләр тартыла. Укучы кулына килеп кергәнче китапка нәшриятта да, типографиядә дә әле бик күп көч салына, зур чыгымнар тотыла. Инде нәшрият планында билгеләнгән һәр берәмлекнең үз хуҗасын табуы һәм аның теләгән һәр кешегә җитәрлек булуы мөһим. Дәүләткүләм әһәмиятле бу бурыч, әйткәнебезчә, асылда, сәүдә эшчеләренә йөкләнгән. Менә шушы җәйге өч-дүрт ай эчендә алар тематик планнардагы китапларга заказ җыялар. Җентекләп, берәмтекләп тупланган бу мәгълүматлар Татарстан китап торгында һәм Татпотребсоюзда гомумиләштерелә.

Көз көне, планда каралган китапларны типографиядә баса башлар вакыт якынайгач, тираж комиссиясе җыела. Утырышта нәшрият, К. Якуб исемендәге полиграфия комбинаты, Татарстан китап торгы, Татпотребсоюз, бибколлектор, «Союзпечать», китап сөючеләр җәмгыяте, иҗат союзлары вәкилләре катнаша. Комиссия һәр китапның тиражын билгели. Бу, үзенә күрә, ярминкә. Утырыш кызыклы, шау-шулы, хисле үтә. Анда сөенәсең дә, борчыласың да...

1984 елда басылачак китапларның тиражын билгеләгән утырыш әле дә истә. Тәэсирләрне, Зыя абый, Сезнең белән дә уртаклашасы килә. Шунысы кызык, баягы «Гомер бер генә» анда кабат телгә алынды. Менә нинди уңайдан. 1984 елга нәшрият «Җир. Икмәк. Кеше» дигән җыентык әзерләде. Анда Азык-төлек программасын үтәү барышында туган кыенлыклар, аларны җиңү юллары турында бүгенге авыл хәлләрен төпле белеп, аларның асылына төшеп, тәэсирләнерлек итеп яза торган әдипләребезнең очерк һәм публицистик мәкаләләре тупланды. Тиражы 10 мең дип тәкъдим ителде.

Мондый тираж менә нәрсәгә нигезләнде. Татар язучыларының проза әсәрләре күпләп тарала. 50—100 мең тираж белән чыкканнары да аз түгел. Шулай да кәгазьнең чикләнгән булуын, полиграфия мөмкинлекләрен исәпкә алып, гадәттә мондый китаплар уртача 15 мең тираж белән басыла. Әлеге очракта исә, темасының һәм публицистик язмаларның вакыт чикләре таррак булуын искә алып, тираж бераз киметелә.

Нәшрият тәкъдименә сәүдә оешмалары нинди җавап бирде дисезме? Әйтергә дә оят: заказ 1 мең данә җыелган! 6317 мең татарның Татарстанда яшәүче, туган теле татар теле дип санаучы миллион ярымының өчтән бере генә (500 мең) китап укый дисәк тә, аларның өчтән бере генә (166 мең) авыл хәлләре белән кызыксына дисәк тә, шуларның өчтән бере генә (55 мең) татар язучыларының проза әсәрләрен укый дисәк тә, анда да өчтән бере генә (18 мең) публицистика белән мавыга дисәк тә...

Юк, бу заказда бернинди дә логика да, арифметика да юк иде. Шуңа күрә нәшрият, Язучылар союзы вәкилләре дәшми кала алмады. «Гомер бер генә» дә шунда искә төшерелде: аңа 4 мең биргән булгансыз, ә ул чыга-чыгышка сатылып беткән, «Җир. Икмәк. Кеше.» дә шуңа охшаш бит, диделәр.

Әмма сәүдә вәкилләре сүзләреннән кире кайтмады. «Заказ шул чаклы җыелган. Андый төр әдәбият укылмый», диделәр. Язучы Гариф Ахунов нык офтанып, «Боларны бер нәрсә белән дә кузгата алмассың!» диде. Офтанырсыз да, язучы бит, китапка, балага караган кебек үк, дөньяда бердәнбер, андый бүтән юк, була да алмый, дип карарга күнеккән.

«Ярминкә» дәвам итә. Повесть, романнарга, аеруча, рус, чит ил классикларының калын әсәрләренә, файдалы киңәшләр, бакча эшләре, дару үләннәре китапларына җиткәч, тиражлар 100, 200, 300 мең ява башлады.

Менә «Татар әдәбияты тарихы»ның 1 томы игълан ителә. Бу — Татарстанның күп санлы күренекле әдәбият, мәдәният эшлеклеләре озак еллар күп көч салып башкарган 6 томлык җитди хезмәтнең беренче карлыгачы. Республикабыз тормышында зур вакыйга. Аны күптән көтәләр, ул бүген дә киләсә буын кешеләренә дә кирәк булыр.

Ләкин... Аңа да 1 мең (!) бирделәр. Аптыраудан телсез калган комиссия членнарына китап торгы директоры: «Заказ шулай гына җыелды. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» дә әле сатылып бетмичә ята», диде.

Әлеге дә баягы барлык китапларны товар итеп бер бүлек астында, бер чыбыктан сөрү бәласе. Сүзлекнең яңа кулланучыларны көтеп берничә ел кибеттә ятуыннан ни зыян, андый хезмәтне кабат-кабат чыгаруы — кыен эш. Ашамлык түгел, бозылмый, костюм түгел, модадан чыкмый. Заманында җитәрлек тираж бирелмәгәнгә күрә, алмаслар, дип, курыкканга күрә, бүген кибетләрдә татарча-русча, русча-татарча сүзлекләрне табып булмый.

Шушы мисаллардан да, Зыя абый, мәсьәлә шактый ачыклана шикелле: сәүдә оешмаларына тиз сатылып бетеп, күп керем бирә торган кыйбатлы китаплар кирәк. Дөрес, аларның да хәлләренә кермичә ярамый — эш нәтиҗәләре, шәһрәт, премияләр, нинди китап сатудан түгел, тулаем керем алудан килә. Димәк, ни генә әйтмә, китап сәүдә оешмалары өчен башка әйберләр кебек үк, гап-гади товар булып кала.

Сүз дә юк, тираж комиссиясе укучылар мәнфәгатен күздә тотарга тырыша. Шулай тиеш тә, беребезнең дә китапның, иң беренче чиратта, идеология коралы, рухи азык икәнен беркайчан да онытырга хакыбыз юк. Шулай да бу теләкне гамәлгә ашыру шактый авыр, чөнки китап сәүдәсе системасы башка товарлар сәүдәсенекеннән

элла ни аерылмый. һәм бу хәл хәзер күпләрне борчый. Китап сәүдәсен, үзенчәлеген исәп тотып, камиллаштерү, тормышчан итү турында сөйләшү, уйлану, тәкъдимнәр матбугат битләрендә дә, җыелыш, киңәшмәләрдә дә әледән-әле кабынып, дөрләп алгалый. Китап сатуны бер генә оешмага, Татарстанда, мәсәлән, китап торгына тапшыру кирәклеге күптән әйтелә. Чыннан да, кайсы гына районы алсак та, аның товар әйләнеше суммасында китаптан килгән керем бер процентка да җитми. Димәк, бу «товарга» игътибар да шундый гына. Махсус оешма булганда, хәл шактый үзгәрер иде. Балтик буе республикаларында, Молдавиядә һәм башка кайбер өлкәләрдә нәкъ шул юнәлештә уңышлы гына сынаулар бара.

Китап сату оешмасының план күрсәткече дә нинди тәрдә, ничә исемдә китап сатылудан чыгып бәяләнергә тиеш. Әйтик, бу бишьеллыкта һәр нәшриятның тулай продукциясендә масса-политик әдәбият 8,8 процент тәшкил итә. Сәүдә планында да бу нисбәт саклансын иде! Кибетләрнең акча-финанс планы алар җыйган заказларга да бәйле булырга тиеш. Әйтик, нәшриятлар авыл хуҗалыгы әдәбиятын чыгаруны арттыралар икән, бу яңалык райполар планында да чагылсын!

Киләчәктә, мөгаен, шулай булыр. Илебезнең алдынгы сәүдә оешмалары тынгысыз, иҗади эзләнүләрен дәвам иттерәләр. һәм идеология, тәрбия эшенең мөһим бер өлешен тәшкил итүче китап сәүдәсе һәр укучы белән, һәр китап белән аерым, индивидуаль эш алып бара башлар.

Китап сатучы — пропагандист. Бүген дә, киләчәктә дә китап сәүдәсен — пропаганда, рекламадан башка күз алдына да китереп булмый.

Дөресен әйткәндә, Зыя абый, хәзергә кайбер укучылар — кирәкле китабын, ә кайбер китап — укучысын табыша алмый интегә. Кемгәдер ниндидер китап җитми икән, моны иң башта китаплар турында мәгълүмат тарату эшенең канәгатьләнерлек булмавыннан күрергә кирәк. Дөрес, нәшриятлар да, иҗат союзлары да, китап сөючеләр җәмгыяте дә, китапханәләр һәм сәүдә оешмалары да моның белән шөгыльләнәләр. Әмма һәркайсы — аерым-аерым. Аларның тырышлыгын бер үзәккә җыючы юк. 1979 елда ук әле китап сөючеләр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе нәтиҗәле бер система булдыру кирәк, дип язып чыккан иде. Система исә әле дә юк.

Китап пропагандасы өчен иң җаваплысы — сәүдә оешмасы, чөнки китапны сатучыдан таләп итәләр, тәкъдим-фикерләрен, теләкләрен дә аңа әйтәләр. «Китап сатучы ул — пропагандист»,— дибез икән, массалар белән турыдан-туры аралашып эшләүдән дә үтемлерәк, тәэсирлерәк тагын нинди пропаганда бар!?

Китапны пропагандалау тәҗрибәсе нәшриятларда да, Язучылар союзында да еллар буе бөртекләп җыелган. Китап сөючеләр җәмгыяте дә (аның хәзер 120 меңгә якын члены бар — нинди көч!) бу юнәлештә ышанычлы адымнар атлый. Андый тәҗрибә, әлбәттә, сәүдә оешмаларында да бар. Алдынгы сатучылар күргәзмәләр оештыралар, витриналарны яңартып торалар, радиода, матбугатта, стена газеталарында белдерүләр бирәләр, киңәшмә, җыелышларда игълан, информацияләр ясыйлар. Басу фермаларда, мәктәп, клубларда китап сату оештыралар. Китап алучыларны авторлар белән очраштыралар...

Ләкин оешмаларда тупланган мондый тәҗрибә үрнәкләре, ком арасында ышенгән алтын бөртекләре кебек, чәчелеп ята, аларны җыясы, өйрәнәсе, бергә туплыйсы бар. Моның өчен Татарстан китап торгында пропаганда-реклама бүлеге булдыру кирәк. Кайбер алдынгы торгларда андый бүлекләр бар инде. Бу оешма — тираж комиссиясе җитәкчелегендә, аның тәкъдим, күрсәтмәләренә таянып эшләр иде. Бу партия Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумы карарларын үтәүгә эш белән җавап бирү булыр иде. РСФСР нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетында, Пленум карарларын үтәү бурычлары турында сөйләгәндә: «...китап сәүдәсе оешмалары сатып алучылар ихтыяҗын начар өйрәнәләр; нәшриятларның тематик планнарына аз тәэсир итәләр; әдәбиятны белер-белмәс пропагандалыйлар», дип, шактый җитди әйтелде. Шул уңайдан комитет буенча чыккан приказда: «...әдәбият пропагандалауның, басылып чыккан һәм чыгачак китаплар турында информация бирүнең төгәл системасын булдырырга» диген юллар бар. (Ассызык безнеке.— Н. И.).

«Чыгачак китап»ны аерып күрсәтү китап тарату алдында торган икенче зур бурычка бәйле. Без хәзергәчә, гади генә әйткәндә, кибеттә алынмыйча ята торган ки-

тапларга хуҗа табу өчен тырышабыз. Ә төп максат — халык массаларын марксизм-ленинизм идеяләре рухында тәрбияләү өчен, һәр кешегә кирәкле рухи азыкны билгеләргә ярдәм итү, китапның аны укырга теләгән һәр кешегә барып җитүенә ирешү. Бу бурыч, иң беренче чиратта, тематик планнарны өйрәнеп, китапларга заказ бирү чорында хәл ителә. Китапны пропагандалауның иң кызган чагы — җәйге мәлдер. Бу чорда сәүдә оешмалары ярдәмгә авторларны да, нәшрият, китапханә вәкилләрен дә, китап сөючеләрне дә дәшәргә, аларның эшчәнлеген берләштерергә бурычлы. Китап сәүдәсендә бу — чәчү өсте. һәр сатучы, аеруча һәр товаровед, бер яктан, нәшриятлар тәкъдим иткән һәр китапны төпченеп өйрәнә. Икенче яктан, бүгенге һәм булачак укучыларын ачыклый, аларның ихтыяҗын өйрәнә. Моның өчен аңардан үз төбәген яхшы белү, аның бүгенгесен генә түгел, киләчәген дә тоемлау сорала. Әйтик, бер елдан соң беренче класска ничә бала керәчәген төгәл белеп булса да, ничә бала туасын чамалау шактый кыен. Әмма аны ничек тә ачыкларга кирәк, чөнки нәшрият, мәсәлән, бер яшькә кадәрге баланы тәрбияләү турында брошюра тәкъдим итә һәм аны яшь аналар бер елдан, һичшиксез, бик теләп сатып алачаклар.

Алда телгә алынган «Положение»дә дә товаровед үз эшен «шушы районның географик-экономик, культура һәм милли үзенчәлекләрен искә алып оештыра» диелгән. Кызганычка каршы, татарча китаплар чыгаручы Татарстан китап нәшриятының тематик планын ачып та карамаган товароведларны очратырга туры килде. Хәер, эчтәлеге, җисеме белән кызыксынмагач, ачып караудан гына ни файда! Зеленодольск районыннан Г. Ахуновның «Без бит Арча яклары...» китабының җитмәвенә зарланып хатлар килгәч, товароведтан белешкән идек, «Ул бит Арча районы турында», диде. Менә сиңа җавап! «Арча ягы» әдәбияты, «Идел аръягы әдәбияты» бар диярсең...

Әйткәнебезчә, бу көннәрдә дә, китапны пропагандалауда гомумән дә, сәүдә хезмәткәрләренең иң ышанычлы таянычлары — партия оешмалары һәм башка җәмәгать оешмалары. Район күләмендә күргәзмәләр, китап укучылар конференцияләре, язучылар, нәшрият вәкилләре катнашында тематик планнарны тикшерүләр һәм башка чаралар үткәрелә.

Шул ук вакытта әлеге оешмалар үзләренә кирәкле әдәбият турында да кайгыртып калалар. Ләкин чынбарлыкта күп кенә җәмәгать оешмалары тематик планнарга шактый гамьсез, җавапсыз карыйлар. Соңгы өч-дүрт елда Татарстан китап нәшрияты Арча, Актаныш, Балтач, Брежнев, Мамадыш, Түбән Кама һәм башка район, шәһәрләр тормышыннан китап, брошюралар чыгарды. Алар бик тиз сатылып бетеп, шул төбәкләрдәге укучыларга җитми дә калды. Бактың исә, җитәкче оешмалар бу хакта белмәгәннәр дә икән. Заказ бланкларын тутырганда товароведлар алар белән киңәшмәгән. Дөрес, нәшрият үзенең планын партиянең район комитетларына да җибәрә. Димәк, анда да игътибар итмәгәннәр.

Зыя абый, без күбрәк төрле оешмалар хәл итәсе мәсьәләләргә тукталдык. Китап бит безгә, укучыларга кирәк. Шулай булгач, без кемнеңдер план белән таныштырганын, үгетләвен көтеп ятарга тиеш түгел. Китап сәүдәсе барыбызның да игътибар үзәгендә булсын иде.

Китап сөюче дигән югары исемне йөртәбез икән, димәк, безгә китапны хөрмәтләргә, аның язмышы өчен бернинди мәшәкатьтән дә курыкмаска кирәк.

Беркөнне чүп әрҗәләре янында, яралы кош кебек, канат-битләрен җилдә кагып яткан китапны иелеп алдым. «Корыч ничек чыныкты». Бар дөньяда бәгырьсез кешеләр! Инде матур тышлылар кысрыклап чыгарган икән, күрше-күлән балаларына бирергә дә күңел киңлегең җитмәгән икән, букинистларга сатар идең, һич югы макулатурага тапшырыр идең!

Шөкер, мондый вәхшилек еш очрамый. Әмма «бәгырьсезлекнең» зурраклары, рәсмиләштерелгәннәре дә очрый әле. Быел Ширәмәт кибете складында макулатурага тапшырырга бәйләп ташланган өр-яңа китапларга юлыктык. Бер күч. Йөзләрчә китап. Бер кеше кулы тиеп карамаган. Инструкцияләр белән нигезләнгән, рәсмиләштерелгән вәхшилек! Сатылмавының сәбәбен «Алмыйлар»,— дип аңлаттылар. Менә шул. Нигә алмыйлар? Җавап юк. Төшенмәкче булабыз. Кайберләре төрле дата, бәйрәмнәргә багышланган булган. «Искергән», диләр. Әлбәттә, нәкъ көнендә сатарга кирәкле китаплар да була. Әмма алар барыбер искермиләр, китапларның тарихи әһәмияте кимеми. һич югы, аларны бушка бирү бер дә гөнаһ булмаган адреслар

бар: Совет Армиясе частьлары, зур төзелешләрнең китапханәләре, балалар йортлары һәм башкалар.

«Үтмәс товар» булып калганнарның күпчелеге — бирегә ялгыш килгәннәр. Ширәмәттә шахта, урман кисү, автомат системалар бармы? Кибет заказны җитәрлек җыймагач, боларын өстәп җибәргәннәр. Хәлбуки, уйлап бетермәгәннәр. Ул китапларны да кемнәрдер эзләгәндер, бәлки, бүген дә эзлидер.

Безне тәти шкаф-зинданнарга бикләнгән китаплар язмышы борчый, ә инде яндырырга яисә макулатурага хөкем ителгән, «үлем алдындагы» китап безнең җаннарны тетрәтә, нәфрәтебезне кузгата. Китап үлә торган хәзинә түгел! Беренче бөтендөнья күргәзмәсенең «Сокланргыч язмышлы китаплар» бүлегендә күргәннәр һаман күз алдында. Атакага ташланган совет солдатының рюкзагында — йөрәге белән бергә пуля тишеп чыккан китап; Блокададагы Ленинградның бер йорты чардагында — дошман снарядын үз эченә алып, аны шартлатмый калдырган, әле дә шул снаряд уемтыгыннан каралып торган китап; СК-065 торпеда катерында — ничәмә-ничә мәртәбә экипаж белән бергә үлемнән котылып калган «Корыч ничек чыныкты»...

Ачык хатны шушында очлап, Зыя абый, мин сезгә җан азыгы булырдай яңаданяңа китаплар белән дуслашу бәхетен телим. Биредә язылганнарга Сезнең һәм башка укучыларның фикер-тәкъдимнәрен көтеп калам. Соңгы сүз итеп шуны әйтәсем килә: китап ул — мәңгелек! Кулымнан килсә, мин һәр китапның титул битенә күренекле язучыбыз Ибраһим Газиның шушы сүзләрен бастырыр идем: «Дәүләтләр яшәгән — беткән, халыклар яшәгән — сөяге дә калмаган. Ай калган, кояш калган да китап калган... Китап безгә бөек революционерлар Маркс, Энгельс тәгълиматын алып килгән, китап безгә Ленин идеалларын бөтен дөньяга таратырга ярдәм итә... Китапны бүгенге көндә берни дә алыштыра алмый».

библио графия

# СЕЗ БУ ХАТНЫ МИНЕМ УКЫГАНДА...

## ҺАДИ ТАКТАШ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ЯҢА БАСМАСЫ ТУРЫНДА

Такташның өч томлык җыелмасын басу тәгәлләнде. Беренче том — 1980, икенчесе 1981 елны дөнья күргән иде. Ә 1983 елда Татарстан китап нәшрияты укучыларга шагыйрьнең өченче томын тәкъдим итте.

Шагыйрьнең әсәрләре аерым китап рәвешендә 1923 елдан башлап басылып килә. Үзе исән чакта аның барлыгы 13 китабы чыккан булса (гомуми тиражы 50 мең чамасы), Такташ үлгәннән соң аның җыентыклары татар телендә генә дә 35 мәртәбә басылды. Аларның гомуми тиражы 350 меңнән артты. Әмма моңа кадәр аның әсәрләре аерым җыентыклар һәм бер томлыклар итеп кенә басыла килде. Күпчелек китаплары киң масса укучыларны күздә тотып, популяр характерда чыгарыла иде. Аңлашыла ки, алардан тулылыкны да, фәнни төгәллекне дә таләп итеп булмый иде.

Такташ әсәрләрен фәнни басма рәвешендә әзерләү илленче елларда башланды. Бу эштә әдәбиятчы галим Хатип Госман роле аеруча зур булды. Бу вакытта Такташ иҗатына багышланган шактый җитди һәм төпле хезмәтләр чыккан иде инде (Г. Нигъмәти, Г. Гали, М. Мамин, Х. Хәйри һ. б. хезмәтләре). Шуларга таянып, Х. Госман шагыйрьнең поэтик әсәрләрен туплап, фәнни яктан тикшереп, аңлатма һәм комментарийлар белән бастырып чыгарды. Үз чоры өчен бу иң тулы һәм фәнни яктан иң төгәл эшләнгән басма иде. Һәм ул хаклы рәвештә 50 нче еллар текстологиясенең җитди казанышы булып исәпләнә.

Еллар үтү белән Такташны өйрәнү фәне яңа уңышларга иреште. Аның тормышы һәм иҗаты турында Х. Госман, Г. Халит, Н. Юзиев хезмәтләре чыкты. Такташ әсәрләренең шактый тулы библиографиясе тезелде. 1970 елда шагыйрьнең архивы Татарстан дәүләт музеена тапшырылды. Бу исә аның кульязмаларын барлау, җентекләп танышу һәм басылган әсәрләр белән чагыштыру өчен яңа мөмкинлекләр ачты. Шулар нигезендә Такташның тагы да тулырак һәм фәнни яктан чор таләпләренә җавап бирә торган әсәрләр җыелмасын хәзерләү бурычы көн тәртибенә килеп басты. Бу эшкә Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторы алынды. 70 нче еллар уртасында ук башланган эш Татарстан дәүләт музее һәм китап нәшрияты белән иҗади хезмәттәшлектә алып барылды. Томнарны әзерләүдә филология фәннәре докторы Нил Юзиев җитәкчелегендә зур фәнни коллектив катнашты. Редколлегия әгъзаларыннан әдәбият белгечләре Хатип Госман һәм Гали Халит, Татарстан дәүләт музее хезмәткәре Дания Баһаветдинова һәм шагыйрь Шәүкәт Галиев игелекле эш башкардылар.

Бу басма моңа кадәр дөнья күргән җыентыклардан кайсы яклары белән аерылып тора соң? Шагыйрьнең иҗади йөзен ачуга һәм аның биографиясенә нинди яңалыклар өсти?

Беренче томда[1] Такташның шигырьләре һәм поэмалары урын алган. Аларның күпчелеге укучыларга яхшы таныш булса да, басманы әзерләгәндә һәрбер шигырь юлы Татарстан дәүләт музеенда саклаган архивлардагы кульязмалар яисә Такташ үзе исән чакта чыккан басмалар белән чагыштырылган. Хәреф, пунктуация хаталары,

[1] Һади Такташ. Әсәрләр. Өч томда. I том. Шигырьләр һәм поэмалар. Татарстан китап нәшрияты. 1980. Томны төзүче, текст һәм искәрмәләрне хәзерләүче Нажия Садыйкова. Томның фәнни редакторы Нил Юзиев. Нәшрият редакторы Равил Кукушкин.

урынсыз кыскартулар, сүзләрне алмаштыру, башка төрле бозулар төзәтелгән. Шуның нәтиҗәсендә безгә күптән таныш булган кайбер шигъри юллар да бөтенләй башкача яңгырый башлаган. Бер генә мисал китереп узыйк. 1981 елда язылган «Мин дезертир бугай, командир!» шигыре әлегәчә чыккан җыентыкларда болай басылып килде:

*Күптән инде шулай бер аякка*
*йөрегән юк,—*
*Бүген беләсең...*
*Тьфу!*
*Тагын ялгыш качкан суккин сынны*
*Тотып алып килгән шикелле...*[1]

Җентеклəбрәк укысаң, бу юлларда күп нәрсә аңлашылмый. Ничек итеп «ялгыш» качарга мөмкин? Рифмасы да бик «хөрти» («беләсең — шикелле»)— бер дә Такташныкына охшамаган. Тәзүче Н. Садыйкова, кульязмалар һәм беренче басмалар белән чагыштыргач, шигырьдәге ике юлның 1931 елгы басмадан соң «төшеп калуын» ачыклый. Соңгы ике юл урынына оригиналда дүрт юл булган икән:

*Тагын ялгыш атлап куйдым,*
*Оныта башлаганмын, күрәсең...*
*Постын ташлап качкан суккин сынны*
*Тотып алып килгән шикелле...*

Күрәсең, бу механик рәвештә эшләнгән хата булгандыр. Андыйлар аз түгел. Алар белән беррәттән редакторлар тарафыннан «аңлы рәвештә» махсус «бозылган», кыскартылган, ә кайбер очракта өстәлгән урыннар да шактый. Мәсәлән, «Пи-би-би-бип» шигырендә моңача чыккан җыентыкларда Такташның Кави Нәҗмигә якын итеп, дусларча «Кави» дип эндәшеп язылган бөтен бер строфасын төшереп калдырган булганнар. «Съезд ачылды» шигырендә ТатЦИК председателе Моратхуҗин турындагы юллар төшеп калган. Мондый хаталар яңа басмада барысы да диярлек төзәтелгән.

«Диярлек» сүзен юкка кулланмадым. Кайбер тупас хаталар яңа басмада да калган. Әйтик, «Чигенү» шигырендә түбәндәге юллар бар:

*Сөю —*
*Әгәр авыру өчен булса,*
*Ташла, парикмахер!*

«Сөю — әгәр авыру өчен»... Сәер яңгырый, аңлашылмый. 1981 елның гыйнварында булган фәнни конференция вакытында ясалган докладында Н. Садыйкова бу шигырьнең ялгыш басылып килүен, кемнеңдер хатасы аркасында «уен» сүзе «өчен» сүзе белән алмаштырылганын әйткән иде. Чыннан да «уен» сүзе монда нәкъ үз урынында һәм ул шигырь дәвамында «уйнала» да («Гаилә дә уен өчен түгел», «Мәхәббәттә булган уенда» һ. б.) Әмма шул ук Н. Садыйкова төзегән беренче томда шигырь элеккечә, хата белән басылган.

Беренче том башка басмалардан үзенең тулылыгы белән дә аерылып тора. Аңа бүгенге көнгә Такташныкы икәнлеге расланган барлык шигырьләр дә кергән дияргә була. Алар арасында моңарча шагыйрьнең бер җыентыгына да кермәгән, фәнни яктан беренче кат тикшерелеп басылган шигырьләр дә бар. Кыскача шигырьләрне һәм дүртьюллыкларны да санаганда, алар егермедән артып китә. Аларның күпчелеге заманында псевдоним белән яисә имзасыз басылып, вакытлы матбугат битләрендә чәчелеп-югалып калган. Төзүче Н. Садыйкова Татарстан дәүләт музеенда сакланган Такташ архивына таянып һәм музей хезмәткәрләре белән бергәләп эш иткән. Архивта шагыйрьнең төгәлләнмәгән әсәрләренең кульязмалары арасында ниндидер бөтенлеккә ия булган шигъри өзекләрнең булуын ачыклап, аларны да беренче томга тәкъдим иткән.

Әлбәттә, яңа табылган шигъри әсәрләр Такташның поэтик йөзенә принципиаль үзгәрешләр кертми, шулай да ниндидер яңалык алып килә. Менә «Мәчеләр күз яше» шигыре. 1928 елда ул «Шефыгыз Такташ» имзасы белән «Чаян» да басылып, әлегә хәтле Такташның бер җыентыгына да кертелмәгән. Шигырь Такташның Тукайга карата мөнәсәбәтен ачыклау өчен бик мөһим. Кайбер чыганакларда бу мөнәсәбәт берьяклырак, Тукай иҗатын инкарь итү, аның шигырь системасын кабул итмәү, җимерү итеп күрсәтеп киленде. Әмма бу шигырьдә Такташ Тукайны зур ихтирам, чын сөю белән телгә ала бит. «Мәрсия»гне без укып яшьләр түгебез, әй Тукай!» «Яшь түгебез кан катыш, Тукай, сине без уйлагач...» шигырен ул Тукай сүзләре белән башлап җибәрә, хәтта ритмикасы да Тукай рухында.

Такташның кульязмалары арасында табылган һәм шулай ук беренче тапкыр басылган «Кырым матур диләр» исемле өзек шагыйрьнең Галимҗан Ибраһимовка карата булган олы ихтирамын, алай гына да түгел, җылы дуслык хисләрен күрсәтә: «Син, Галим[illegible]ан абый, у[illegible]лама, Такташ сине артык сагына, тик баралмый гына яныңа...»

[1] Һ. Такташ. Сайланма әсәрләр. Казан. Таткнигоиздат, 1952, 159 б.

(Шигырь Г. Ибраһимов Кырымда дәваланып яткан чагында язылган.)

Хәсән Туфанның Такташка багышланган шигырьләр циклы безгә яхшы мәгълүм. Алар эчкерсез, саф дуслык хисләре белән сугарылган. Әмма Такташның Туфанга багышлап язылган шигырьләре моңарчы билгеле түгел иде. Шуңа күрә: «Бу дуслык берьяклы гына булмады микән?» дигән сорау туу табигый иде. «Туфан йоклый» исемле яңа табылган өзек Такташның да дустына карата шундый ук җылы, самими хисләр кичерүен исбатлый.

Яңа тәкъдим ителгән шигырьләрнең күпчелеге заманында «Чаян» битләрендә басылган («Чаян»ның хайванат бакчасы», «Чаян» уклары» һ. б. рубрикалар астында). Бу шигырьләр әдипнең иҗат йөзен шулай ук шактый тулыландыралар. Без Такташны шашкын хисле романтик шагыйрь итеп кенә күз алдына китерергә күнеккәнбез. Ә бит ул искиткеч оста, усал телле сатирик һәм юморист шагыйрь дә булган. Аның ярты гасыр элек конкрет кешеләрне яисә кимчелекләрне фаш итеп язылган сатирик парчаларының күбесе әле бүген дә искермәгән. Аларны укыганда рәхәтләнеп көләсең, эстетик ләззәт табасың. Бик җитди политик мәсьәләләр турында да шагыйрь шаян тонда, көлкеле һәм шул ук вакытта бик үтемле итеп яза белгән.

Томда беренче тапкыр урнаштырылган шигырьләр Такташның поэзиядә ялкынлы публицист, агымдагы халыкара мәсьәләләргә үз карашын ачык итеп белдерә торган шагыйрь икәнен дә күрсәтә («Кутепов кайда?», «Удар артыннан удар» һ. б.)

Архивта сакланган шигъри өзекләр Такташның шактый авыр шартларда, РАПП позициясендәге тәнкыйтьчеләр тарафыннан ничек кыйналып-сүгелеп яшәвен дә искәртәләр:

*Һәр өйрәнчек тәнкыйть язучылар*
*Һ. Такташны мишень итәләр.*
*Өйрәнчек яшь хирурглар кебек*
*Минем әсәрләрдә «опыт» ясап,*
*Үтмәс пычак белән кисәләр...*
*Неужели үтерүдән курыкмыйлар?*

Шуның өчен ачынып, өзгәләнеп язылган юлларны Такташның хатларында да еш очратырга була.

Томда Такташ әсәрләренең вариантлары аерым бүлек итеп урнаштырылган. «Мәхәббәт тәүбәсе», «Үтеп барышлый», «Мокамай», «Алсу», «Киләчәккә хатлар» һәм башка әсәрләренең вариантлары Такташның иҗат процессын тулырак күзалларга мөмкинлек бирә. Чагыштырып карап, шагыйрьнең нинди үзгәрешләр кичерүен күрер өчен, әдәби осталыкка өйрәнү өчен дә алар шактый гыйбрәтле.

Әлбәттә, бу әле Такташның иҗатын барлау юнәлешендә барысы да эшләнгән дигән сүз түгел. Әле бүген дә Такташның барлык псевдонимнары ачыкланып бетмәгән. Шуңа күрә аның кайбер шигырьләре газета-журнал битләрендә кала бирә. Шагыйрьнең кулъязмалары да тулысынча тупланып җитмәгән. Димәк, киләчәк өчен дә эшләр җитәрлек әле.

Икенче томга[1] Такташның драма һәм проза әсәрләре тупланган. Моңача әдипнең хикәяләре һәм пьесалары аерым җыентык булып бер генә мәртәбә, 1953 елны, Хатип Госман тарафыннан җыелып басылган иде. Әлеге җыентык белән чагыштырганда, икенче том икеләтә калынрак. Димәк, томның яртысын моңарчы басылмаган, киң даирәгә билгеле булмаган әсәрләр тәшкил итә. Мәсәлән, «Сәхнә әсәрләре» бүлегендә укучыга таныш булган «Камил» пьесасы белән бергә әлегәчә томнарга кермәгән «Күмелгән кораллар» һәм «Югалган матурлык» пьесалары да басылган. Заманында бу пьесалар, сәхнәдә куелып та, әллә ни киң яңгыраш ала алмаганнар. «Югалган матурлык» пьесасы исә кискен тәнкыйть утына эләккән. Кайбер тәнкыйтьчеләр аңарда хәтта «чит идеология» чагылышын күргәннәр. Бу пьесаларны бүгенге таләпләр югарылыгыннан яңадан укып чыккач, бер әйбергә инанасың: әйе, пьесаларның заманында аңлашылмавы табигый. Ләкин Таактašның монда бер гаебе дә юк — ул үз заманы таләпләреннән шактый алга киткән. Бәлки, әлеге пьесаларны нәкъ менә бүген яңа күздән укып, яңача сәхнәдә куярга вакыт җиткәндер.

Күп актлы драмалар белән беррәттән, Такташ бер актлы, агитка формасында язылган пьесалар да иҗат иткән (шундыйлардан «Өйләнделәр» пьесасы томда беренче мәртәбә басыла). Бу әсәрләр хәзерге таләпләргә җавап бирмәсәләр дә, Такташның иҗат биографиясен тулырак итеп күз алдына китерү өчен мөһим.

Татар язучыларыннан беренче буларак, Такташ кино сәнгатенә дә ниндидер өлеш керткән. Томга аның архивта табылган

[1] Һади Такташ. Әсәрләр. Өч томда. II том. Драматургия һәм проза. Татарстан китап нәшрияты. 1981. Томның драматургия өлешен төзүче, искәрмәләрен хәзерләүче Марсель Әхмәтҗанов. Проза бүлеген төзүче һәм искәрмәләрен хәзерләүче Лена Гайнанова.

«Камил» пьесасы буенча эшләнгән киносценарие кертелгән. Кызганычка каршы, бу сценарий, заманы өчен шактый оста язылган һәм «Востоккино» киностудиясе тарафыннан кабул ителгән булуына карамастан, куелмыйча кала.

Шул ук пьеса буенча шагыйрь «Камил» исемле опера либреттосын да язарга тотынган. Томда либреттоның тәмамланып җитмәгән планы басылган (ул Татарстан дәүләт музеендагы архивта саклана). Кайбер истәлекләргә караганда, бу эшкә Такташны композитор Салих Сәйдәшев күндергән, либретто өстендә дә алар бергәләп эшли башлаганнар. Әмма шагыйрьнең вакытсыз үлеме бу планнарны өзә.

Проза бүлегендә Такташның «Таң җиле» исемле тәмамланмаган романы, нәсерләр, хикәяләр урын алган. Алар арасында үз вакытында газета-журналларда гына басылып, моңарчы җыентыкларга кермәгәннәре дә бар («Иркә солдат», «Сез икегез дә гаепле»). Бу әсәрләр белән танышкач, Такташта талантлы прозаик «оеткысы» булганын күрәсең. Дөрес, иҗатның бу ягы җитәрлек дәрәҗәдә ачылып өлгерми (чын прозаик утыз яшьтән соң гына башлана диләр бит), әмма басылган өзекләрдә без аны шактый оста хикәяче, уңышлы детальләр таба белә торган персонажларның сөйләме аша аларның характерларын ачып бирә ала торган язучы итеп күрәбез.

«Таң җиле» романы үзенең автобиографик характерда булуы белән дә кызыклы. Төп герой Рөстәм образында без яшь Һадиның үзенә хас булган күп сыйфатларын күрәбез. Аларның биографияләре дә, торган урыннары да, кылган эшләре дә тәңгәл килә дип әйтергә була.

Томга шулай ук шагыйрьнең язарга ниятләп йөргән әсәрләренең план-сызымнары, тәмамланмаган проза һәм драма әсәрләренең вариантлары урнаштырылган. Шулай итеп, икенче томда да Такташның иҗади мирасын тулыландыруга шактый зур өлеш кертә.

Өченче том да[1] шушы ук фикерне куәтли. Ул тулысынча диярлек яңа материаллардан төзелгән. Моңа кадәр шагыйрьнең публицистикасы бергә җыелып, хатлары һәм башка төрле биографик материаллары китапка тупланып укучыга тәкъдим ителгәне юк иде. Бу томда шагыйрь укучы алдында эшлекле журналист, ялкынлы публицист, таләпчән тәнкыйтьче буларак ачыла.

Билгеле булганча, Такташ матбугатта беренче тапкыр шигырьләре белән түгел, ә мәкалә-хәбәрләре белән күренә. 1917 елның 23 августында «Олуг Төркстан» газетасында 16 яшьлек әдипнең «Бохарада уку һәм укыту эшләре» исемле мәкаләсе басыла. Шул чыгышыннан башлап, шагыйрь гомере буе журналистикадан аерылмый. 1919 елдан Оренбургтагы «Юксыллар сүзе» газетасыда штаттагы әдәби хезмәткәр, аннары җаваплы секретарь һәм вакытлыча редактор булып эшли. 1921-1923 еллар арасында Ташкентка күчеп, «Белем йорты» журналында җаваплы секретарь вазифасын үти. Казанга күчеп килгәч, «Чаян», «Октябрь яшьләре», аның дәвамы булган «Авыл яшьләре», «Азат хатын», аннары яңадан «Чаян» редакцияләрендә җаваплы секретарь булып эшли. Башка газета һәм журналларда да үзенең шигырьләре белән генә түгел, чәчмә әсәрләре, мәкаләләре, кыска хәбәрләре белән актив катнашып тора.

Өченче томның төп өлешен нәкъ шушы, кайчандыр вакытлы матбугат битләрендә урын алган, хәзерге укучыларга аз билгеле булган публицистика һәм тәнкыйть жанрындагы әсәрләр тәшкил итә. Аларны туплау өчен төзүче Л. Гайнановага шактый көч сарыф итәргә туры килгән. Әлек, мәсәлән, Такташның «Чаян»да басылган бары дүрт фельетоны аерым җыентыкка керсә, хәзер аларның саны кырыкка җитә. Такташның яңа псевдонимнары ачыкланууын да уңыш буларак билгеләргә кирәк.

Бу чорда хәзерлекле журналистлар аз булганга, Такташка редакциядәге бөтен эшләрне үз җилкәсендә сөйрәп барырга, журналларны да күп вакытта тулысынча диярлек үз материаллары белән «тутырып» барырга туры килгән. Әйтик, «Чаян»ның кайбер саннарында шагыйрь бишәр-алтышар, хәтта җидешәр-сигезәр мәкалә-фельетон бастырган. (Шуңа күрә аңа яңадан-яңа псевдонимнар кирәк булып торган да.)

Әдипнең журналистик хезмәте искиткеч бай һәм күпкырлы. Әдәбият мәсьәләләренә караган яки үзенең эстетик карашларын чагылдырган мәкалә-рецензияләр белән бергә, язучы бик күп башка темаларны да күтәрә, тормышның агымдагы көн кадагына суга торган тәэсирле публи-

---

[1] Һади Такташ. Әсәрләр. Өч томда. III том. Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, публицистика, биографик материаллар, хатлар. Татарстан китап нәшрияты. 1983. Томның әдәбият-сәнгать тәнкыйте, публицистика өлешен төзүче, текст һәм искәрмәләрен хәзерләүче Лена Гайнанова. Биографик материаллар, хатлар өлешен төзүче, текст һәм искәрмәләрен хәзерләүче Марсель Әхмәтҗанов. Томның фәнни редакторлары Рашат Гайнанов һәм Нил Юзиев.

цистик мәкаләләр яза. Алай гына да түгел, газета һәм журналларда язышучы белгечләрнең аз булуын искә алып, ул агрономия һәм җир эшләре, радиотехника һәм гигиена, педагогика һәм башка шуныңише махсус белем таләп итә торган мәсьәләләр турында яза. (Өченче томда андый рухтагы материаллар да урын алган.)

Әлеге том, Такташның иҗат йөзен тулыландыру белән бергә, аның журналистика һәм публицистика өлкәсендәге хезмәтләре аша поэзиясенә дә яңа караш ташларга мөмкинлек бирә, чөнки шигърияттә дә, журналистик эшчәнлегендә дә шагыйрьне бер үк мәсьәләләр борчый, ул аларга үз карашын белдермичә кала алмый.

Аерым бүлектә урнаштырылган тәнкыйть мәкаләләре Такташның эстетик карашлары һәм әдәби зәвыгы ничек үскәнен күзәтергә мөмкинлек бирә. Әгәр иҗатның башлангыч чорында ул Ф. Бурнашны «идеалистик карашларда» гаепләсә («Оҗмах кошы»на рецензия), күренекле татар драматургларының әсәрләрен берьяклырак бәяләсә («Оперетта каһарманнары»), ахырга таба без әдип фикерләренең елдан-ел төплерәк, дәлиллерәк була баруын күрәбез.

Әлбәттә, бу өлкәдә дә эшләнәсе эшләр байтак әле. Мәсәлән, Ташкентта чыккан «Олуг Төркстан» һәм аның дәвамы булган «Кызыл байрак» газеталарының тулы җыелмалары әлегә кадәр табылмаган. «Юксыллар сүзе» газетасының да китапханәләрдә аерым саннары гына сакланган. Ә аларда Такташның әлегәчә безгә билгесез булган материаллары һичшиксез булырга тиеш.

Такташның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү буенча безнең әдәбият галимнәребез шактый зур эш башкарды. Г. Нигъмәти, Г. Гали, М. Мамин, Х. Хәйри, Х. Госман, Г. Халит һ. б. лар шагыйрь турында төпле, җитди хезмәтләр бастырдылар. Татар шагыйрьләреннән бик азы гына мондый игътибарга лаек булды. Әмма өченче томда басылган хатлар белән танышкач, шагыйрьнең иҗади йөзе тулы булмаганын, тормышында да күп нәрсәләр әлегәчә ачык түгеллеген, кайбер очракларда аның биографиясенә конкретлык җитмәгән күрәсең. М. Әхмәтҗанов тарафыннан табылган яңа чыганаклар мондый «ак таплар»ны тутырырга мөмкинлек бирә.

Такташ хатларының бер өлеше моңарчы да басылган иде. Әмма кайберәүләре аерым кешеләр кулында сакланганга, кайберәүләре яңарак табылып, җитди тикшерелмәгәнгә күрә, аның иҗатын һәм биографиясен өйрәнүчеләр өчен билгесез материал булып кала бирде. Өченче томны хәзерләгәндә М. Әхмәтҗанов Такташның барлык хатларын барлап, фәнни яктан тикшереп чыга. Бүгенге көнгә Такташның сиксәннән артык хаты билгеле. Шуларның 69 ы өченче томга кергән. Аларның яртысы — әлегәчә матбугатка чыкмаган, беренче мәртәбә басыла торган хатлар.

Такташ хатлары аның иҗатын өйрәнүчеләргә искиткеч бай материал бирә. Әйтик: шагыйрьнең М. Гафурига язган хаты ике әдип арасындагы иҗади дуслык һәм бер-беренә тирән ихтирам хакында сөйли (моңарчы Такташның Гафурига язган бер генә хаты да билгеле түгел иде). Күп хатларда шагыйрьнең биографиясендәге билгеле булмаган фактлар чагыла. Бу хатлар һәм гомумән өчтомлыкка кергән яңа бай материал Такташны өйрәнүдә яңа бурычлар куярга, шул исәптән аның фәнни биографиясен төзергә мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, өч томлык материаллары китапларның бүгенге көнгә Такташның иң тулы басмасы икәнлеген ачык раслый. Бу бигрәк тә икенче, өченче томнарга кергән һәм укучыларга беренче тапкыр тәкъдим ителгән драма һәм проза әсәрләре, публицистик һәм тәнкыйть мәкаләләренә карый. Такташ бу томнарда укучы алдында бөтенләй яңа яклары белән ачыла, аның иҗат йөзе шактый тулылана, фигурасы тагы да калку булып күз алдына килеп баса.

Өч томлыкның фәнни аппараты турында берничә сүз.

Тулаем алганда, яңа томнар — текстологик яктан да Такташның иң тәгәл, фәнни басмаларның төп таләпләренә җавап бирә торган басмасы. Томнардагы һәр әсәргә хәзерге текстология фәненең таләпләреннән чыгып шактый тулы һәм тәгәл искәрмәләр бирелгән (аеруча икенче, өченче томнарда). Искәрмәләрдә теге яки бу әсәрнең кайчан, кайда, нинди шартларда һәм нинди вакыйгага уңае белән язылуы ачыклана, беренче булып кайда басылуы һәм том өчен кайдан алынуы турында мәгълүмат бирелә. Тарихи шәхесләргә, текстта телгә алынган кайбер вакыйгаларга шулай ук кыска, әмма тәгәл аңлатма китерелә. Моңарчы комментарийларның Такташның фәкать шигырьләренә генә бирелүен һәм аларның да шактый кыска һәм берьяклы булуын искә алсак, бу эш-

нең ни дәрәҗәдә житди һәм авыр булуын аңлавы кыен түгел.

Әмма шул ук вакытта фәнни аппаратның кайбер җитди кимчелекләргә дә күз йомып булмый. Иң элек өч томлыкның аңлатмаларында әзлеклелек принцибының тиешенчә сакланмавы күзгә ташлана. Әйтик, икенче, өченче томнардагы искәрмәләрдә Такташның ачык имзалары (һади Такташ, һ. Такташ, Такташ) күрсәтелми, яшерен имзалары (псевдонимнары) гына бирелә. Бик дөрес һәм текстология фәнендә күптән кабул ителгән принцип. Әмма беренче томда ул ни өчендер сакланмый. Мәсәлән, 347 биттәге «Яңа лордлар, перлый сортлар» шигыренә язылган искәрмәдә шигырьнең «һади Такташ имзасы белән басылган»лыгы әйтелә. Шундый ук искәрмәләр 272, 300, 304, 351 һ. б. битләрдә дә бирелгән. Ә шулар янәшәсендә булган һәм шулай ук Такташның ачык имзасы белән басылган шигырьләргә мондый комментарийлар бирелми. һәм, киресенчә, кайбер вакытта яшерен имза яки имзасыз басылган шигырьләргә бернинди дә аңлатма күрмибез. (Мәсәлән, 361 биткә язылган искәрмәне кара.) «Безнең теләк», «Фаҗигале хәл» һ. б. кайбер шигырьләрне Такташ заманында имзасыз бастырган, әмма аңлатмада бу хакта бер сүз дә әйтелми.

Мондый буталчыклык фәнни басма өчен һич тә килешми. Ул шагыйрьнең кайсы очракта һәм ни өчен яшерен имза куллануын ачыкларга да мөмкинлек бирми.

Гадәттә, фәнни басмаларны әзерләгәндә, әсәр томнарга беренче тапкыр кертелсә, бу хакта махсус искәрмә бирелә. Өч томлыкның икенче, өченче томнарында бу нәкъ шулай эшләнгән дә. Әмма беренче томны әзерләүче һәм төзүче ни өчендер әлеге принципны эзлекле рәвештә сакламаган. Кайбер очракта андый искәрмә бирелә (мәсәлән, 400 нче биттә), әмма күпчелек очракта бу хакта бер сүз дә әйтелми (300, 349, 358, 352 һ. б. битләргә искәрмәләр). Шуңа күрә гади укучыга гына түгел, белгечкә дә томга беренче мәртәбә урнаштырган әсәрләрне ачыклавы шактый читен.

Кайбер аңлатмаларның укучыны саташтыруы мөмкин. Әйтик, 273 биттәге «Ләйлә» шигыренә язылган аңлатмада «Текст «Азат хатын»нан алынды», дип әйтелә. Моны укыганнан соң укучының бу шигырь Такташның бер җыентыгына да кермәгән икән, дип уйлавы мөмкин. Әмма «Ләйлә» шигыре шагыйрьнең элекке, төп вариантын тапкандыр? Алай дисәң, шигырьнең бер сүзе дә элекке басмалардан аерылмый.

Фәнни басмадагы комментарийларны хәзерләү төзүчедән аеруча саклык таләп итә, чөнки мондагы мәгълүматлар башка фәнни хезмәтләргә, мәкаләләргә, рецензияләргә күчеп, кабатланып, хакыйкатькә әйләнүе ихтимал. Укучы да аларга тулысынча ышана. Шуңа күрә комментарийлардагы кечкенә генә төгәлсезлек тә «ЧП» буларак кабул ителергә тиеш.

Беренче томның 491 битендә урнаштырылган аңлатмада Такташның «Үтеп барышлый» шигыре беренче мәртәбә 1928 елның 28 августында басылган, ә шул шигырь уңае белән язылган «Сагынылган җирләрдә» исемле мәкаләсе 1928 елның 18 августында чыккан дип әйтелә. Ә өченче томның 413 битендә урнаштырылган аңлатма буенча шул ук шигырь 1928 елның 18 августында дөнья күргән булып чыга (дөресе — 28 август), мәкалә исә 1928 елның 29 июнендә басылган, диелә (соңгысы дөрес). Бер ук басмадагы мондый «кычкырып торган» каршылыкларга фәнни редакторлар да, нәшрият редакторлары да игътибар итмәгән, күрәсең.

Очраклымы бу хаталар? Әлбәттә, бик төгәл басмада да аерым төгәлсезлекләр булуы ихтимал. Аларны булдырмау өчен, бүгенге текстология таләпләре буенча, вакытлы матбугатта басылган әсәргә бирелгән аңлатмада газетаның датасы белән бергә санын да күрсәтергә кирәк булгандыр. Икенче, өченче томнарда бу шулай эшләнгән дә. (Әйтик, «Сагынылган җирләрдә» мәкаләсенең «Кызыл Татарстан»ның 148 санында басылганлыгы әйтелә.) Болай эшләгәндә төп чыганакны табып, чагыштырып карау әллә ни читен түгел. Әмма беренче томда газеталарның саннары бер кайда да күрсәтелмәгән.

Текстология таләпләре буенча, теге яки бу матбугат органы комментарийларда беренче мәртәбә телгә алынганда, аңа аңлатма бирелергә тиеш. Әмма өч томлыкта бу принцип та эзлекле сакланмаган. Беренче томның 461, 473, 481 битләрендә, мәсәлән, «Эшче», «Кызыл яшьләр» газеталары һәм «Азат хатын» журналы аңлатмасыз калган. Шул ук китапның 477 битендә «Казан утлары»ның 1956 елгы 7 санына искәрмә бирелгән. Ләкин 1956 елны журнал «Совет әдәбияты» исемен йөртә.

Югарыда китерелгән фактларга таянып, шундый нәтиҗәгә килергә мөмкин: берен-

че томның фәнни аппараты җитәрлек дәрәҗәдә эшләнеп бетмәгән. Шуның аркасында төрле томнарга бирелгән комментарийлар арасында башка җитди каршылыклар да очрый. Әйтик, беренче томның 477 битендә урнаштырылган аңлатма буенча шагыйрьнең сеңлесе Хәнифә Такташева 1903 елда туган, медицина техникумында укыган, соңыннан укытучы булып эшләгән. Ә өченче томның 437 битендә урнаштырылган аңлатмада аның 1908 елны туганлыгы, педагогия техникумында укуы, соңыннан Казанның төрле предприятиеләрендә эшләве бәян ителә. Боларның кайсысына ышанырга соң? Махсус тикшергәннән соң гына соңгысы дөрес икәнлеге ачыклана.

Яки менә беренче томның 474 битендә урнаштырылган «Нәни разбойник» шигыренә язылган аңлатманы алып карыйк. Төзүчегә ышансак, Такташ Г. Нигъмәтинең «Имзасыз һәм җавапсыз мәкалә турында» исемле язмасына ишарә ясый, шунда әйтелгән фикергә каршы чыга. Ләкин Г. Нигъмәти әлеге мәкаләсендә, киресенчә, Такташны яклап чыга. Шагыйрь исә тәнкыйтьченең бөтенләй башка, «Нәни разбойник», хатынсыз ай һәм бераз гына мужик фәлсәфәсе турында» исемле мәкаләсен күздә тота. Бу хакта да өченче томга бирелгән искәрмәләрдә (389 битне кара) ачык һәм дөрес итеп әйтелә.

Беренче томның 190 битенә язылган аңлатмада Такташның «Карт артист» исемле мәкаләсе телгә алына. Ләкин шагыйрь шул исемдәге шигырь язып бастыра, мәкаләсе исә «Кари кичәсе» дип атала (III томның 377 битендә урнаштырылган аңлатманы кара).

Мондый каршылыклар җитди басмаларның бизәми, әлбәттә. Текстология фәнендә вак нәрсә юк, кечкенә генә төгәлсезлек тә, башка хезмәтләрдә кабатланып, шактый зур зарар китерүе мөмкин.

Шулай да, җитешмәгән яклары булуга карамастан, өч томлыкны Такташны өйрәнүдә тагын бер, зур, яңа адым дип бәяләргә мөмкин.

*Сез бу хатны минем укыганда*
*Мин бик күптән үлгән булырмын.*
*Еллар бер-бер артлы үткән булыр,*
*Исмем сезгә җитмәс — онытылыр,*

— дип язган иде Такташ үзенең «Киләчәккә хатлар»ында.

Нинди генә бөек зат булмасын, бу мәсьәләдә Такташ ялгышкан (ә бәлки артык тыйнаклык күрсәткәндер). Юк, аның исеме онытылмады, киресенчә, елдан-ел яңа яклары белән безнең чор укучылары алдында ачыла бара. Аның үлмәс әсәрләре безнең заманнарга җитеп, изге теләкләре безнең кырларда чәчәк аттылар.

**Рафаэль МОСТАФИН.**

# ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ

*Чакыручы чаң шикелле*
*яңгырый иде*
*Халыкның шат һәм кайгылы*
*көннәрендә...*

М. Ю. Лермонтов.

Шушы елның октябрь аенда бөек рус шагыйре М. Ю. Лермонтовның тууына 170 ел тула.

Илебез халыкларының зур казанышы булган рус классик әдәбиятының бай мирасында М. Ю. Лермонтов исеме А. С. Пушкинның мәңгелек исеме белән янәшә тора.

Аларның замандашы, Пушкинның бөеклегенә беренче булып бәя биргән В. Г. Белинский Лермонтов әсәрләренең дөньяга чыгуын сокланып каршы ала. «Руста яңа көчле талант туды», «Пушкин үлсә дә, дәвамчысы калды», дип яза ул.

В. Г. Белинский фикерләренең дөреслеген тарих раслады. Лермонтов иҗаты күптән инде дөнья күләмдә танылды. Аның иҗат мирасы Пушкинныкы кебек үк илебезнең барлык язучылары өчен осталык мәктәбе һәм олы горурлык.

М. Ю. Лермонтов 1814 елның 3 октябрендә Мәскәүдә дөньяга килә. Михаилга өч яшь тулар-тулмас аның әнисе үлеп китә. Шагыйрьнең балалык еллары Пенза губернасында, әбисе Елизавета Алексеевна Арсеньеваның Тархан имениесендә уза. Бөлгенлеккә төшкән әтисе белән бай һәм власть сөючән әбисе арасында низаглар көчәя. Әбисе малайны үзе тәрбияләргә тели. Гаиләдәге ызгыш-талашлар, шагыйрьнең башлангыч иҗатына тәэсир итми калмыйлар, әлбәттә. «Ата белән улга җирдә ни авыр аерым яшәп, ялгызлыкта үлүдән...»,— дип яза уналты яшьлек шагыйрь.

Шуңа бәйләп кайбер галимнәр һәм шагыйрьнең биографиясен өйрәнүчеләр аның шәхси тормыш фактларының иҗатка йогынтысын арттырып күрсәтергә тырыштылар. Бу исә шагыйрь иҗатының социаль әһәмиятен кечерәйтүгә, аның крепостной Россиягә каршы мөнәсәбәтен тәртипсез гаилә шартларында формалашкан авыр холкына гына бәйләп калдыруга китерә иде.

Лермонтов яшьтән үк искиткеч сәләтле була. Бала вакыттан ук француз, немец, инглиз телләрен үзләштерә, соңрак төрки телләрне өйрәнә. (Ул вакытта төрки телләр татар теле дип аталган.) Рәсем ясау белән мавыга, фортепьяно һәм скрипкада уйный. Бик яшьли әдәби әсәрләр дә яза.

Булачак шагыйрь 1830—1832 елларда Мәскәү университетында укый, соңрак, 1834 елда Петербургта гвардия подпрапорщиклары һәм кавалерия юнкерлары мәктәбен тәмамлый. Беренчеләрдән булган «Яз» шигыре 1830 елда «Атеней» журналында басылып чыга. Шагыйрьнең В. Г. Белинский тарафыннан югары бәя алган тугыз әсәрләр җыентыгы исә 1840 елда дөнья күрә.

Пушкинның үлеме Лермонтовны аеруча тетрәндерә. Ул җавап йөзеннән «Шагыйрьнең үлеме» дигән шигырен яза. Үзенең даныи шагыйрь нәкъ менә шушы шигырь белән казана да... Әсәренең югары катлау вәкилләре ачуына дучар булуын белгәч, ул аңа тагын уналты юл өсти:

Әле Россия моңа кадәр шундый социаль-политик, эмоциональ көчле шигырь барлыгын белмәгән була. Бу шигырь кулдан күчерелеп меңнәрчә данә таратыла. Заманның алдынгы кешеләре шигырьне үз хисләре һәм карашлары чагылышы, ә шагыйрьнең үзен Пушкинның дәвамчысы итеп кабул итәләр. Җәмгыятьнең реакцион даирәләре шигырьне кыргый усаллык белән каршылый. Шагыйрьне эзәрлекләү башлана. Патша кушуы буенча Лермонтов Кавказга, хәрәкәттәге армиягә сөрелә.

Бары тик әбисенең ныклап кайгыртуы нәтиҗәсендә һәм Жуковский ярдәме белән генә 1837 елның көзендә шагыйрь Новгородка, ә 1838 елның язында Петербургка күчерелә.

1840 елда ул яңадан Кавказга сөрелә. Бу юлы инде Франция илчесе де Барантның руслар турында мыскыллау сүзләре әйткән улы белән дуэльдә булуы өчен.

Хәрәкәттәге армиягә җибәреп, патша һәм аның иярченнәре Лермонтовның үлемен өметләнәләр. Югары сыйныфлар моннан башка чаралар да күрәләр, билгеле. Николай I, мәсәлән, шундый боерык җибәрә: «Поручик Лермонтов фронтта гел күз алдында булырга тиеш һәм начальство аны һичбернинди сылтау белән дә үз полкындагы фронт хезмәтеннән ераклаштырырга батырчылык итмәскә тиеш». Күрсәткән батырлыгы, кыюлыгы өчен Лермонтов бүләкләнергә тиешле кешеләр исемлегенә кертелсә дә, Петербургта аны бүләкләү турындагы үтенечләрне кире кагалар.

1841 елның июлендә Пятигорскида Лермонтов белән аның күптәнге танышы Н. Мартынов арасында кечкенә низаг булып ала. Мартынов, патша ялчыларының котыртуы буенча, юк-бар сылтау белән шагыйрьне дуэльгә чакыра. Дуэль Машук тавы итәгендә оештырыла. Шагыйрь бер атуда ук үтерелә — пуля аның күкрәген тишеп уза.

Төрле чорның күп кенә әдәбият белгечләре һәм шагыйрь биографиясен өйрәнүчеләр тарафыннан шагыйрьнең үлеме властьлар катнашы белән оештырылган дигән фикер әйтелгән. Лермонтов тирәлегендәге киеренке хәлләрне тудыруда өстен катлауларның катнашы булу Г. Блюминның «Пятигорскидагы ату сере» [1] исемле мәкаләсендә дә күрсәтелә. Ул, чыннан да Пушкин кебек үк, крепостной Россия тормышының корбаны иде.

Лермонтов үзенең кыска гомеренең ахырына кадәр Пушкинны бик ихтирам итә. Аның башлангыч чор иҗаты да Пушкин әсәрләре тәэсирендә байый.

*Син җырладың һәм бар илеңдә*
*Бер аңлаучы җырны синең дә,*

— дигән юллар белән белдерә ул үз остазына мөнәсәбәтен.

Яшь Лермонтовка кайвакыт Пушкин дөнья белән килешә, үзенә күрсәткән рәсми зурлауларны чынлап кабул итә кебек тоела һәм ул 1830 елда түбәндәге юлларны яза:

*Җитәр гафу итү азгынлыкны!*
*Порфира[2] соң явыз җаннарга*
*Калканмыни?— җырлап мактау җыры,*
*Табына бирсен ахмак аларга.*
*Ә син, җырчы, тукта: алтын таҗ*
*Кияр өчен түгел синең баш.*

Бу шигъри юллар Пушкинга багышланган дигән фикерне беренче булып М. Горький әйтә. Ул Лермонтов иҗатын бик яхшы белә һәм гомер буе аңа соклана.

Күп кенә тәнкыйтьчеләр, бигрәк тә консерватив һәм либераль лагерь вәкилләре, шагыйрьне «байронизм бөркәнчеге бөркәнергә тырыша» һәм Байрон кебек бу-

[1] «Советская Татария», 1983, 19 октябрь.
[2] Порфира — патшалар киеме.

дырга тели дип уйлыйлар. XIX гасыр башында иҗат иткән бөек Байрон, әлбәттә, Пушкин һәм Лермонтовка йогынты ясамый калмагандыр. Аеруча иҗатларының башлангыч чорында. Әмма бу ике рус даһиеның таланты рус җирлегендә туып үсте, аларны рус культурасы өлгертте. Лермонтов яшь чагында ук үзен «байроннистлар» рәтенә кертүчеләргә җавап итеп:

*Юк, мин Байрон түгел, мин бары*
*Әле беленмәгән бер җырчы,*
*Аның төсле үк сөрелер узгынчы*
*Ләкин җаным минем рус җаны.*

— дигән юлларны яза.

«М. Лермонтов шигырьләре» исемле мәкаләсендә Белинский: «Хәзергә без аны Байрон, Гете, Пушкин... дип тә атамыйбыз, аннан беренчесе дә, икенчесе дә, өченчесе дә чыкмас, әмма аннан Лермонтов чыгар», дип бик дөрес язды.

Шагыйрь яшь чагында да, соңрак та үткәннәргә һәм үз чорына мөрәҗәгать итеп тиранлыкка каршы чыга. «Новгород» шигыре әнә шундыйлардан:

*Кар уллары, әй сез, славяннар,*
*Рух төшәрлек нәрсә бар анда?*
*Беткән төсле башка тираннар,*
*Бетәчәк бит сезнең тиран да!*

Бу шигырь цензурадан яшертен формада Себергә куылган декабристларга багышланган дип күрсәтә И. Андроников. «Дума» (1838) шигырендә Лермонтов ачыктан-ачык һәм кыю рәвештә үз чоры буынын тәнкыйть итә. Белинский бу шигырьне «...шигырьнең алмаз крепосте, җанландыруның күкрәү көче, тирән сагыш»[1] белән аерылып тора дип бәяли.

Иҗат эшчәнлеге кыска гомерле булганлыктан, М. Ю. Лермонтов тулысынча ачылырга, бөек художник булып өлгерергә, иҗтимагый фикерләрен ныгытырга да өлгерә алмый кала. Ләкин ул тудырган иҗат үзенең эчтәлеге һәм әһәмияте белән бер чорда да кыйммәтен югалтмый. Аның мирасы күпләгән шигырь, поэма, роман, повесть һәм драмалардан гыйбарәт. «Безнең заман герое» романын һәм дөнья әдәбияты җәүһәрләреннән берсе булган «Демон» поэмасын аеруча билгеләп үтәргә кирәк. Поэманың сюжеты — фантастик. Грузин кызы Тамара, сөйгән ярын югалткач, монастырьга китәргә карар итә. Аңа явыз рух Демон гашыйк була. Демон кайчандыр фәрештә булган, ләкин ул алла белән килешә алмый, баш күтәргән. Поэманың төрле редакцияләрендә вакыйгалар төрлечә үрелә, ләкин ахырда алла тарафыннан җибәрелгән фәрештә барыбер Тамараның җанын саклап кала. («Кочагында ул гөнаһлы җанны илтә иде күккә дөньядан»). Сөрелгән Демон Тамараның мәхәббәте ярдәмендә яңадан туу турындагы «үзенең акылсыз хыялларын» каргый:

*Элеккедәй калды беркемсез,*
*Мәгърур карап, сөю, өметсез!..*

Бу мифологик сюжет авторга күктәге генә түгел, җирдәге тәртипләргә дә үзенең кискен каршы мөнәсәбәтен белдерергә мөмкинлек бирә. Шуңа күрә Лермонтов исән вакытта цензура поэманы тыя.

Консерватив һәм тар карашлы әдәбиятчылар шагыйрьнең күк эшләренә катнашуына, үз әсәренең персонажлары итеп фәрештә һәм шайтанны алуына нәфрәт белдерәләр. Тасвирланган вакыйгаларда өстен көчләр һәрвакытта җиңүгә ирешмәү дә аларга охшамый.

Әсәрне тәнкыйтьләүчеләрдән берәү: «Кемнең кемне тудыруын берничек тә аңлый алмыйм: ул рухны Лермонтов тудырганмы, әллә Лермонтов үзе шул явыз рухтан туганмы?» — ди.

Шагыйрьне әзәрлекләүчеләр төп мәсьәләдә ялгышмыйлар. «Демон», чынлап та,

---

[1] Белинский В. Г. Избр. произведения. М. Л., Худ. лит. 1949, 210 б.

өстенлек итүче гореф-гадәтләргә, шул чор тәртипләренә, моралена каршы протест белдерә. Реакцион тәнкыйтьчеләр поэманы халык интересларыннан ерак, аңлаешсыз, аңа чит күренеш һ. б. диләр. Ә М. Горький үзенең повестенда икона ясау мастерскоенда эшчеләргә «Демон»ны укуы, поэманың аларны дулкынландыруы, аны зур игътибар белән һәм сокланып тыңлаулары, әсәрнең хаким сыйныфларга каршы юнәлгәнлеген аңлаулары турында яза.

«Безнең заман герое» яшьләрнең иң күп һәм яратып укый торган әсәренә әверелде. Роман барлык СССР халыклары һәм күп кенә дөнья халыклары теленә тәрҗемә ителгән.

Әсәрнең төп герое Печорин образында язучы яңа заман шартларына туры килә торган «артык кеше» тибын чагылдыра. Ул акыллы, энергияле яшь кеше. Ләкин яшәп килгән социаль шартларда үз көчен файдаланырлык урын тапмый һәм гадәттән тыш мөмкинлекләрен, көчен вак-төяк эшкә сарыф итә. Бу, үз чиратында, әдәбиятта «артык кеше» тибы үсешенең чираттагы этабы иде. Белинский: «Печорин — ул бүгенге Онегин» дип язды.

Лермонтов күп кенә әсәрләрендә — «Кавказга», «Валерик», «Бәхәс», «Терек бүләкләре» һ. б. ларда — сугыш, кан коюның кешелек табигатенә никадәр ят икәнен күрсәтте. Шагыйрь әсәрләрендә чагылыш тапкан төрле халыкларның дуслыгы идеясе бүген дә яңгырашын югалтмый.

Лермонтов лирикасы — рус һәм дөнья лирикасының югары баскычларыннан берсе. «Мин ялгызым чыгам юлга», «Мин моңсу, чөнки сине яратам» һ. б. шундый күп шигырьләре бүген дә безгә зур эстетик ләззәт бирәләр.

«Мцыри» трагик поэмасында (Мцыри — грузинча монастырьга ябылып, монах булырга хәзерләнүче кеше) көчле, ирек сөюче, бунтарь малай образы сурәтләнә. Малай, уңышсыз качуыннан соң, барс белән көрәшеп, үлгәндә бик аз гына булса да ирек һавасын сулап калуы белән, үзен бәхетле саный. Ирек өчен ул тормышын да аямый. Йөрәкләргә үтеп керә торган бу поэманың нигезенә грузин халык легендасы салынган. Төп эчтәлеге — шәхесне һәртөрле изүгә протест.

Замандашларын тетрәндергән «Шагыйрьнең үлеме» шигыре Пушкинның үлеменә тирән кайгы белән ачылып, үтерүчеләргә нәфрәтләнеп язылган. Шигырьнең һәр юлында Пушкинның дуслары көткән хакыйкать әйтелә. (Бу шигырьне беренче мәртәбә татар теленә Мәхмүт Галәү тәрҗемә итә һәм 1908 елда «Шура» журналында бастыра. Татар укучылары шигырьне бик яратып каршы алалар).

Лермонтовның проза әсәрләре дә фикер тирәнлеге һәм форма төзеклеге белән аерылып торалар. Алар — рус прозасы һәм теле үсешендә бер адым алга китеш. Н. В. Гоголь «Аңарчы әле беркем дә аныкы шикелле дөрес, гүзәл һәм хуш исле проза белән язганы юк иде» [1], ди. Ярты гасыр үткәч А. П. Чехов: «Мин Лермонтов теленнән дә яхшы телне белмим... Мин болай эшләр идем — хикәясен алып, мәктәптәге кебек җөмләләргә, җөмлә кисәкләренә аерып чыгар идем. Язарга шулай өйрәнер идем» [2] — ди. Стиле, теле ягыннан «Тамань» повесте аерым игътибарга лаек. Аны бик күп күренекле проза осталары, шул исәптән Л. Н. Толстой да, үрнәк итеп куя. Белинский исә, югары дәрәҗәдәге поэтик хикәя дип атый.

Лермонтов Владимир Ильичның иң яраткан язучыларыннан берсе була. Бу турыда Н. К. Крупская Пятигорскидагы «Лермонтов өе» музеена җибәргән хатында болай дип яза: «Владимир Ильич Лермонтовны ярата иде. Безне Лермонтовта хиснең шундый калку итеп бирелүе һәм кыюлыгы үзенә тартты» [3]. В. И. Ленин Лермонтов әсәрләреннән шигъри юлларны цитата формасында бик еш куллана. А. М. Горький, шагыйрьнең лирикасын югары бәяләп, аны Пушкинның лаеклы дәвамчысы дип атый һәм: «Лермонтов шигырьләрендә Пушкинда бөтенләй диярлек күренмәгән ноталар — ашкынып эш, хәрәкәт теләү, тормышка актив катнашырга теләү ноталары яңгырый» [4],— ди.

Лермонтовның әдәби мирасы М. Горький иҗатына, аеруча азатлык рухы, революцион романтизм белән сугарылган, «Изергиль карчык», «Лачын турында җыр», «Давыл хәбәрчесе турында җыр» әсәрләренә әһәмиятле йогынты ясый.

---

[1] Гоголь Н. В. Собр. сочин. М., Гослитиздат, 1947, 6 т., 468 бит.
[2] А. П. Чехов в воспоминаниях современников. М., 1960, 463 бит.
[3] Ленин В. И. О литературе и искусстве. М., 1967, 636 б.
[4] Горький М. История русской литературы. М., 1939, 160, 165 бб.

1906 елда язган «Авыр вакыт» мәкаләсендә А. Блок ике «демон»ның — Лермонтов һәм Гогольнең — үзләренә өченче «демон»ны — Достоевскийны иярткүләре һәм аны крепостной чынбарлыкның әшәкелекләренә карата килешеп булмый торган зур социаль масштабта фикер йөртергә өйрәтүләре турында яза. Болардан тыш бирелә Лермонтов — XIX гасыр рус әдәбиятында психологик анализга нигез салучыларның берсе дигән фикер дә үткәрелә. Аның иҗаты йогынтысын кичермәгән Россия шагыйренең исемен атау да кыен.

Чыннан да, бу бөек әдипнең әчтәлек тирәнлеге һәм форма камиллеге белән таң калдырган иҗаты бүген дә рус әдәбиятына уңай йогынты ясый.

Шагыйрьнең лирикасы илебез халыкларының иң талантлы шагыйрьләрендә дә олы хөрмәт һәм мәхәббәт казанды.

Лермонтов, Пушкин белән бергә, бөек татар шагыйре Габдулла Тукай йөрәгендә һәм иҗатында зур урын алып тора. Г. Тукай мирасында Лермонтовтан тәрҗемәләр дә, аңа охшатып язылган, аның иҗаты белән өртелгән, аның турында сокланып әйтелгән әсәрләр дә шактый.

Шулай да, татар укучыларының Лермонтов белән тәүге танышуы иртәрәк, XIX гасыр азагында була. 1898 елда шагыйрьнең «Гашыйк Кариб» әкияте татар телендә аерым басма булып дөнья күрә. XX гасыр башында инде аның иҗаты күп кенә талантлы татар әдипләрен үзенә җәлеп итә. Шулай да аның иң зур тәэсире Г. Тукай иҗатында чагыла.

Лермонтов һәм Пушкин, шагыйрьдән йөз ел алда яшәсәләр дә, Г. Тукайның авыр, әмма данлы юлында чын мәгънәсендә остаз булдылар. Тукайның Лермонтовтан тәрҗемәләре, аның иҗаты белән сугарылган, аңа охшатып язылган шигырьләре арасыннан «Шагыйрьгә», «Вәгазь», «Охшату», «Алдандым», «Соңра», «Пигамбәр», «...га (И матур! Иренмәче...)» кебекләрне күрсәтергә мөмкин.

Тукайга да туган якның табигате, матурлыгы гына түгел, аның кайгы-хәсрәтләре дә якын. «Туган илемә» дигән шигырендә ул, мәсәлән:

*Җөмләтән изге икән ич: инешең, чишмәң, кырың,*
*Юлларың, авыл, әвен, кибәннәрең дә ындырың;*
*. . . . . . . . . . . . . . . . . .*
*Яхшыдыр барлык яманың, бар минемчә юкларың*[1],

— дип, туган җиренә булган чиксез яратуын белдерә.

Тукайдагы халыкка хезмәт итүне изге бурыч дип карау да Пушкин һәм Лермонтовтагыча.

*Тик фәкать милләткә хезмәткә мәхәббәт бәндә бар,—*
*Бәнчә, бунда ямь дә бар, ләззәт тә бардыр, тәм дә бар!*
*(«Ләззәт вә тәм нәрсәдә?» 1907.)*

Тукай буржуаз җәмгыять тәртипләренә, гореф-гадәтләренә каршы баш күтәрә. Тукай белән Лермонтовны тема һәм рух бердәмлеге дә якынайта.

«Яшьләр» (1910) шигырендә Тукай яшь буынны җәмгыять тормышына салкын, пассив булулары өчен шелтәләп «аңарда бөртек тә кыюлык, тамчы да дәрт юк» дип яза. Аның бу шигыре Лермонтовның «Дума»сы белән авазлаш.

«Шүрәле»не язганда шагыйрь Пушкин белән Лермонтовның халык әкиятләре сюжетларын эшкәртү тәҗрибәсен дә оста файдалангандыр.

Тукай, Лермонтов кебек үк, бик аз — 27 ел гына яшәп кала. Әмма аның халык культурасында калдырган эзе Лермонтовныкы кебек үк. Тукай түбәндәге юлларны бик хаклы әйткән:

*Шигъре Лермонтов вә Пушкин — олуг саф диңгез ул,*
*Хәзрәте Пушкин вә Лермонтов, Тукай — өч йолдыз ул.*
*(«Җавап», 1911.)*

Профессор М. Х. Гайнуллин «Лермонтов энциклопедиясе»ндә басылган «Татар әдәбияты» исемле мәкаләсендә: «1905—1907 елгы революция җиңелгәннән соң

[1] Тукай Г. Шигырьләр һәм поэмалар. Татарстан китап нәшрияты, 1968, 64 бит.

Лермонтовның политик лирикасы киң яңгыраш ала»[1],— дип яза. «Безнең заман герое»ннан өзек, байтак шигырьләр, татар шагыйре С. Рәмиевнең аңа охшатып язган «Пәйгамбәр» шигыре нәкъ әнә шул елларда дөнья күрәләр. Революциягә кадәр басылган Лермонтов турындагы татарча язмалардан М. Х. Гайнуллин «Бөек рус шагыйре» («Аң» журналы, 1914 ел, № 17) һәм Ф. Әмирханның «Олуг милләтнең олуг шагыйре» («Кояш» газетасы, 1914, 2 октябрь) исемле мәкаләләрен күрсәтә. Ф. Әмирхан «Лермонтовның матурлык вә үзенә бер төрле нәфасәт белән тулы шигырьләре рус милләте тарафыннан гына түгел, бәлки рус теле белә торган бөтен милләтләр тарафыннан хосусый бер мәхәббәт белән укыладыр»[2],— ди.

Лермонтов әсәрләре Совет власте елларында илебездә киң таралды. Алар барлык СССР халыклары телләрендә моңа кадәр күрелмәгән тиражда дөнья күрәләр. Лермонтовның иҗаты патриотизм, халыкка мәхәббәт, иптәшлек, чын гүзәллекне аңлау хисләренең үсешенә уңай йогынты ясый. Илебез шагыйрьләре, язучылары аның әсәрләреннән осталыкка өйрәнәләр.

Шагыйрьнең әсәрләре татар телендә дә күп меңләгән тиражда таратыла. Шигъри тәрҗемәләрдән тыш, утызынчы елларда татар телендә аның зур әсәрләре дә дөнья күрә. К. Басыйров тәрҗемәсендә «Безнең заман герое» (1937), шагыйрьнең биографик очеркы белән сайланма әсәрләре (1938) басылып чыга. Г. Кутуй (1939), Ф. Хөсни (1941), Ә. Давыдов (1964) һәм башкаларның мәкаләләре М. Ю. Лермонтов иҗатына, шагыйрьнең истәлекле даталарына багышланганнар. 1956 елда Татарстан китап нәшрияты әдипнең сайланма әсәрләрен бастырып таратты. Лермонтов әсәрләрен тәрҗемә итүдә Ә. Исхак, Ш. Маннур, К. Нәҗми, Ә. Фәйзи, Ә. Ерикәй, Ә. Давыдов, С. Баттал, З. Нури һ. б. зур көч куйганнар һәм куялар.

Күп санлы тикшеренүләрдә Лермонтов иҗатының татар әдәбиятына йогынтысы турында әйтелә. Аерым алганда, «Татар совет әдәбияты тарихы»нда күрсәтелгәнчә, романтизм тенденциясе Байрон, Гейне, Пушкин, Лермонтов традицияләре белән үрелеп, Тукай, Гафури иҗатында, шулай ук С. Рәмиевнең башлангыч чор шигырьләрендә киң чагылыш таба һәм яңа чор татар язучыларында нык сизелә.

Лермонтов иҗатының татар әдәбияты үсешенә тәэсире поэзиядәге прогрессив романтизм, халыкчанлык, гуманизм, лиризм, бигрәк тә политик лирика (Тукайның «Китмибез» шигыре сыман) юнәлешләрендә аеруча ачык күренә. Лермонтовның иҗаты һәм аның үзенчәлекле яклары Тукай буыныннан бүгенге көн шагыйрьләренә — Ә. Давыдов, С. Хәким, З. Нури, И. Юзеев, Р. Харис, М. Шабаев, Р. Әхмәтҗанов һ. б. ларга күчкән.

Шагыйрьнең тууына 150 ел тулу уңаеннан «Совет әдәбияты» журналында чыккан мәкаләдә: «...безнең хәзерге яшь буын аның алдында баш ия, ...аның актив иҗат йогынтысы дәвам итә»[3] диелә.

Шагыйрь үлеменең 140 еллыгына туры китереп 1981 елда чыгарылган «Лермонтов энциклопедиясе» — М. Ю. Лермонтовка бик зур һәйкәл. Бу бер әдипкә багышланган беренче энциклопедия. Ул Лермонтовны өйрәнүчеләргә, күп санлы укучыларга һәм, гомумән, Лермонтов иҗатын яратучыларга гаять кадерле бүләк булды.

Әйе, бөек шагыйрь иҗаты каршында вакыт агышы көчсез. М. Ю. Лермонтов әсәрләре бүген дә бик яратып укыла. Ул безнең иң сөекле шагыйрьләребездән берсе!

**Мария ПОПОВА,**
**Казан дәүләт культура институты доценты.**

[1] Лермонтов энциклопедиясе, 382 б.
[2] Лермонтов энциклопедиясе, 382 б.
[3] «Совет әдәбияты», 1964, № 10.

**Әмирхан Еники**

# АНЫҢ ЙӨГЕ — ИЛ МИЛКЕ

Картлык мине һәрвакытта уйландыра. Адәм баласының бу нинди чагы, күпмегә сузыла ул картлык дигән нәрсә? Сәләт, дәрман, хәтер, зиһен кайчанга чаклы саклана? Билгеле инде, картлык — кеше гомеренең соңгы чиге, күпме генә сузылса да — ахыры бер... Мин моны белеп торам. (Шөкер, үзем дә җитмештән узган кеше.) Әмма мине бик гаҗәпләндергән һәм сокландырган якын картларым бар. Аларның икесе Казанда, берсе Уфада: Болар — Бакый Урманче белән Нәкый Исәнбәт абзыйлар һәм Сәйфи ага Кудаш!.. һәркайсына туксаныньчы яшь, ә Сәйфи ага тиздән бу чикне дә атлап узачак!.. Инде игътибар итегез: алар мәктәп яшеннән алып, шушы яшьләренә чаклы өзлексез акыл хезмәте белән



*Рәсемдә: Сәйфи Кудаш, (сулда) Хәсән Туфан, Мостай Кәрим.*

шөгыльләнгән кешеләр. Билгеле, әкренләп тузганнар, авырулар кичергәннәр, ниһаять, картайганнар, әмма нинди дер кодрәт аркасында рух, дәрт, сәләт, теләкләре картая да, туза да белмәгән. Хәзер дә әле аларның бу авыр-тынгысыз акыл һәм йөрәк эшеннән бер генә көн дә тукталып торганнары юк. Һәм йөзгә җитсәләр дә туктый белмәсләр кебек... Әйе, безнең халыктан чыккан шушы олы затларга карап: «Бәрәкалла, нинди кешеләребез бар бит әле!» — дип чын ихластан сөенмичә мөмкин түгел.

Сәйфи аганы мин бик күптән, мәктәпкә йөргән чагымнан ук инде шигырьләрен

укып белә идем. Аның исеме минем аңыма Шәехзадә Бабич, Давыт Юлтый, Гариф Гомәр кебек Уфа шагыйрьләренең исемнәре белән бергә кереп калды. Әмма ләкин очрашып, танышып китүебез шактый соң булды. Ялгышмасам, 1954 елны Татарстан язучыларының сугыштан соңгы беренче съездына Уфадан Сәйфи ага да килгән иде. Беренче мәртәбә кул биреп күрешүебез менә шул чакта булган иде.

Шуннан соң Казанда да, Уфада да очрашуларыбыз еш кына кабатланып торды, һәм без, әлектән үк бер-беребезне яхшы белгәндәй, җиңел генә уртак тел дә таптык. Уфага кайткан саен Сәйфи агай янына бару минем өчен ничектер бер күңел ихтыяҗына, зарурияткә әйләнде дисәм дә һич арттыру булмас. Җәй көннәрендә ул Юматауда торган чагында да мин я үзем генә, я язучы дусларның берәрсе белән аның дачасына бармыйча калмый идем. Ике тапкыр андагы санаторийда ял иткән вакытымда Сәйфи агай белән көн аралаш диярлек очрашып тордым. Кыскасы, яшел бакча түрендәге җыйнак кына агач йортта күп булдым, мәрхүмә Мәгъфүрә апаның сыйларын, аңардан соң Сәйфи агайның үзе пешергән ашларын күп ашадым.

Кайткан саен болай барып йөрүнең бер сәбәбе карт шагыйрьгә ихтирам йөзеннән булса, икенче иң мөһим сәбәбе аның белән, борынгыча әйтсәк, мөсахәбә кылып утыруның гаять кызыклы булуында иде. Сез беләсез инде, Сәйфи агай — бик мөлаем кеше, шуның өстенә сүзгә юмарт бик оста сөйләүче дә. Хәтере — яшьләрнекедәй, зиһене — көзгедәй ачык. Ә аның узган гасырдан башлап бүгенге көнгә килеп җиткән тормыш юлы?! Туксан ел эчендә кеше ниләр генә күрмәгәндер дә ниләр генә кичермәгәндер. Һәм бу үзе бер гасырга якын гомер нинди заманнар, вакытлар, вакыйгалар аша гына үтмәгән!.. Әйе, бик күпне белә агаем!..

Әлбәттә, бик күпләрне кызыксындыра торгандыр аның белгәннәре... Минем үземне, мәсәлән, Уфа тормышының революция алдыннан булып узган чоры бик кызыксындыра. Мәгълүм булганча, гасыр башында, бигрәк тә 1905 ел революциясеннән соң, Уфада тормыш бик тиз җанлана, халыкта фикер уяна — эзләнү башлана, азатлыкка омтылыш көчәя, мәгърифәт һәм мәдәният эшләре елдан-ел ныграк үсә-җәелә бара, «Госмания» һәм бөтен Россиягә даны таралган «Галия» мәдрәсәләре ачыла, вакытлы матбугат һәм яңа әдәбият басыла башлый, профессионал театр труппасы оеша — кыскасы, әнә шул дәвердә Уфа татар һәм башкор дөньясында иң күренекле урын тоткан аң-белем һәм демократик хәрәкәт учагына әверелә. Сез Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр»ен генә алып карагыз. Бу романда бит нәкъ Уфа тормышы, Уфаның беренче революция чорында тынгысыз, кайнар көннәре мавыктыргыч тулы итеп сурәтләнә дә инде... Ниһаять, биек тау өстендәге шушы чиста һәм пөхтә калада Мәҗит Гафури, шул ук Галимҗан Ибраһимов, Шәехзадә Бабич, Сәгыйть Рәмиев, Сәгыйть Сүнчәләй кебек әдип һәм шагыйрьләр яшәгәннәр, эшләгәннәр, иҗат иткәннәр... (Мин монда искә төшкәннәрен генә әйтеп узам.) Әйе, күп хәлләр, күп вакыйгалар белән тулы, күп шәхесләрнең язмышлары белән бәйле революция алды елларындагы Уфа тормышы. Сәйфи ага — менә шуларның җанлы бер шаһиты. Уфаның байларын да, җәмәгать хадимнәрен дә, зыялыларын да, шәкертләрен дә, революционерларын да белә, күргән, аралашып йөргән. Бер генә сүз белән әйткәндә — аяклы тарих!

Һәм иң куандырганы — Сәйфи агай сөйләргә ярата. Кемнәрне генә исенә төшерми дә нинди генә вакыйгаларны күз алдыннан кичерми ул!.. Ерак яшьлегендәге «Галия»сен еш кына сагынып телгә ала — бу мәдрәсә аңа бик күпне биргән булырга тиеш. Кайчандыр халкыбызның бердәнбер мәгърифәт учагы булган мәдрәсәләргә хөрмәт саклау, минемчә, бик күркәм эш, чөнки шул мәдрәсәләрдән чыккан безнең Тукаебыз да, Гафуриебыз да. (Һәм тагын бик күп горурланырлык зур шәхесләребез!)

Мин бу ихлас сөйләшүләр вакытында бер нәрсәне сизәм кебек: Сәйфи ага үзе күргән, үзе белгәннәрне бүгенге олы яше һәм бай тәҗрибәсе югарылыгыннан торып яңадан аңларга, иске хаталарны төзәтергә, үзенчә дөрес дип тапкан хакыйкатьне әйтеп калырга тели һәм шушы юнәлештә даими уйланып, эзләнеп, борчылып, тизрәк барсын да кәгазьгә төшерергә ашкынып яши. Аңа сокланмыйча, аңа теләктәшлек белдермичә мөмкин түгел, чөнки аның эше үзе өчен дә, безнең өчен дә бик әһәмиятле.

1981 елның җәендә, Уфага китәр алдыннан, Хәсән Туфан янына баргач, ул миңа бердәнбер теләге итеп Сәйфи агайның хәлен белеп кайтырга кушты. Үзе дә хәл эчендә яткан авыру шагыйрьнең күптәнге замандашы һәм якын дусты өчен борчылуы бик аңлашыла иде — ул бит белеп тора аның нинди уй-теләкләр белән янып яшәвен! Сәй-

фи авырмыймы, эше алга барамы, берәр төрле комачаулык күрмиме — менә ниләр борчыган булса кирәк Хәсән абзыйны. Тик менә Хәсән абзыйның кушканын үтәп кайтуымны, зур кызганычка каршы, аның үзенә сөйләргә генә өлгерә алмадым.

Сәйфи ага — барысыннан элек шагыйрь, әлбәттә! Шагыйрь булып туган ул, шагыйрь булып яшәде һәм шагыйрь булып картайды да. Аның шигърияте Тукай, Гафурилар заманыннан ук башланып килә. Һәм бу шигъриятне калын урманнар аша, биек тауларны кисеп, киң тугайлар буйлап аккан озын елгага да охшатырга мөмкин булыр иде. Беләсез инде, башта ашыгып аккан тар елгачык үзенең ахырына җитәрәк салмак агымлы киң, тирән, тын елгага әйләнә. Шуның шикелле, туксанга якынлашып килгән кешенең эчке дөньясы да отыры нечкәрә, тирәнәя бара торгандыр дип уйлыйм. Күпме йокысыз уйланулар, иска төшерүләр, сагынулар, нәрсәнедер башкача аңлаулар, нәрсәдәндер ваз кичүләр, хәтта ирексездән үкенүләр дә шагыйрь күңеле аша узып, әнә шул тын-тирән елгадай аккан шигъриятендә үзенең чагылышын тапмыйча калмый торгандыр... Әгәр шулай икән, карт шагыйрьнең рухи халәте өчен бу бик тә табигый хәл. Моңа һич тә гаҗәпләнергә туры килми, минемчә...

Сәйфи агай үзе миңа бүләк иткән китабына: «Карт бакчаның соңгы чәчәкләре...» дигән сүзләрне дә язган иде. Әйе, дөрес, күкрәп үскән карт бакча, әмма аның чәчәкләре ел саен атып торырга тиеш әле. Шулай да китап эчендәге бер шигырьнең менә бу хикмәтле сүзләре мине әеруча гаҗәпләндергән һәм сөендергән иде:

*Күргәс минем арбамдагы,*
*Аркамдагы таудай йөкте,*
*Уйламагыз: «Комһоз икән,*
*Бөтәһен дә алып китте!»*

*Юк, мин алыр өсен түгел,*
*Бәлки бирер өсен килдем.*
*Алып китәргә ил милкен*
*Юк хокугы һис бер кемдең!*

Хак сүз, бик урынлы әйтелгән! Әйе, аның таудай йөге — ил милке... Ул шуны безгә биреп калдырырга тели. Моның өчен нәрсә кирәк? Билгеле инде, вакыт һәм тазалык! Менә безнең бердәнбер иң ихлас теләгебез дә аңа — тазалык белән вакыт!

*1983 ел*

## Сәйфи Кудаш,

*Башкортстанның халык шагыйре*

# ХӘСӘН ТУФАНГА ШИГЪРИ ХАТЛАР

## Чакыру

Кайсы бер чак якын иптәшеңне
Көтмәгәндә каршы аласың.
Күргәч аны, әйтер сүзләреңне
Әйтә алмый телсез каласың...

Шундый хәлдә калдым, беләсеңме,
Утырган чак альбом актарып,
Кулга алдым, табып сурәтеңне,
Үзеңне күргәндәй шатланып...

Әллә картлык, әллә сагыну шулай,
Әйтүе дә кыен кырт кына.
Шатлыгы да хәзер, кайгысы да
Еш кына балавыз сыктыра...

Уйлый күрмә, онытkандыр диеп,
Безнең Уфа үзенең Туфанын.
Бардыр әле синең йөрәктә дә
Сагындырган җире Уфаның...

Шул хисләрең тыя алмаслык булып
Көчәйсеннәр иде тагы да.
Кыстасыннар иде ярсындырып,
Юл чыгарга Уфа ягына...

Самолет та килә Уфага,
Пароход та килә Уфага.
Кайсысы ошаса үзеңә,
Утырып кил шуның түренә.

Сыйлар идек тәкә симертеп,
Тустакларда кымыз күпертеп.
Өйне шигырь белән тутырып,
Бер сайрашыр идек утырып!..

*1957*

## Гөлләрнең дә теле бар икән

*Әй, кыюлар,*
*Мәгез, газизләрем,*
*Бу гөлләрне миннән алыгыз,*
*Үзегезнең гөлләрне дә өстәп,*
*Туганыма алып барыгыз!*

Хәсән Туфан

Гөлләрнең дә телләре бар икән [1],
Сөйләшәләр икән чәчкәләр.
Сүзлексез дә аңлап була икән,
Гөлләр сиңа өзелеп әйтсәләр.

Әлсерәшеп килеп кергәч бүген
«Аккош күле»нең юлчы гөлләре,
Саулыкларын сорашудан алда,
Суын суздым ашыгып әлгәре.

Дим гөлләре торган вазаларга
Утырткач иркәләп үзләрен,
Күтәрелде тылсымлы керфекләр,
Ачты кунак гөлләр күзләрен.

Башкорт белән татар кебек икән
Бакчада үскән гөлләр дә.
Теләкләрең бер төсле булсалар,
Аңлашыла икән телләр дә...

Кайнар көйгә килде сәламнәрең,
Гөлләреңнең телен төшендем.
Чәчкәләр дә сөйли белә икән
Хәлен бик сагынган кешеңнең.

*1968*

---

[1] Бу шигырь Мостай Кәрим Х. Туфанның «Аккош күле»ндәге дачасыннан кыңгырау чәчкәләр алып кайтып биргәч язылган иде. (Автор.)

Шулай итеп китәр чаклар
Җитте дә мени әле?
Үтмәс тоелган минутлар
Үтте дә мени әле?

Егерме елдан соң гына
Килеп күрешкән идек.
Сулкылдатып иреннәрне
Җылап үбешкән идек...

Күреп туймады күзләрем,
Хушлашыр минут җитә.
Бетмәде сөйләр сүзләрем,
Пароход хәзер китә.

Аерылышудан соң һәрчак
Кавышу йөрсен иде.
Сагынганнарыңны көтми
Өйләргә керсен иде!..

*1977*

## Сагынып килдем

Мин Казанда, синең Казаныңда,
Тагын килдем сагынып, Туфан-җан.
Бер самолет мәхәббәт китердем
Яшьлек эзең калган Уфаңнан.

Самолетка утырган чагында
Чемоданнарыңны үлчиләр.
Әле дә яхшы,—безнең йөрәкләрне
Үлчәү чараларын белмиләр...

Син беләсең, безнең йөрәкләрдә
Илдән яшрен серләр-керләр юк.
Тик шулай да безнең мәхәббәтне
Үлчи ала торган герләр юк!

Алып килдем мәхәббәтнең шундый,
Үлчәүләргә сыймый торганын...
Картлыкка җиңелми, үлемгә бирешми,
Һәрвакыт илаһи булганын!

*1980, декабрь*

## Сәйфи Кудаш

# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КАҺАРМАН БЕР КЫЗЫ

*Баллы Багъбостан ханым,*
*Мәктәп тотып ускән ханым.*

Ш. Бабич.



Шагыйрь Шәехзадә Бабич үзенең бу эпиграммасын язган көннәргә инде хәзер алтмыш сигез ел гомер узып киткән. Бабич тарафыннан шулай атаклы кешеләр рәтенә куеп эпиграмма язарлык игътибарга лаек булган бу Багъбостан ханым кем соң?

Багъбостан Вилдан кызы Мөэминова 1884 елда Минзәлә өязенең Мәндәй (хәзерге Татарстан АССР Азнакай районы) авылында ярлы крестьян гаиләсендә дөньяга килгән. Бишенче бала булып туган Багъбостанга өч яшь тулган чакта, анық әтисе үлеп китә. Әнисе Гафифә апа, бәләкәй арба сөйрәп, биш баласын ияртә дә, Оренбург ягына таба бәхет эзләп китәргә мәҗбүр була. Бер ай дигәндә Гафифә апа балалары белән Оренбургка килеп җитә һәм үзе дә шунда эшкә керә. Аннан соң иң кечкенә Багъбостаннан башка кызларын төрле кешеләргә асраулыкка бирә. Шулай итеп аларның шәһәрдәге авыр тормышлары башланып китә.

Бәләкәйдән үк бик зирәк булгач, Багъбостанны яңа тәртип белән укытыла торган кызлар мәктәбенә бирәләр. Ул бик тизлек белән тегү-чигү эшләренә дә өйрәнеп, калфаклар эшли башлый. Багъбостан кыш көне укый, җәйге айларда йон фабрикаларында булышып, үзен-үзе карый башлый. Унбиш яшь тулган чакта ул җидееллык кызлар мәктәбен тәмамлап, хосусый рәвештә физика, математика һәм география фәннәрен өйрәнергә керешә. Ул куркып һәм шикләнеп тормый, монастырь эргәсендәге кул эшләре түгәрәгенә йөри, үзенең тегү-чигү осталыгын да камилләштерә.

1905 елгы Беренче рус революциясен Багъбостан менә шундый грамоталы, төрле фәннәрдән башлангыч белем белән коралланган һәм тегү-чигү эшләренә остарып, буйга җиткән бер кыз булып каршылый. Шуңа күрә дә, революциядән соң чыга башлаган газета-журналлар Багъбостанның җитлеккән канатларын очарлык бер хәлгә ки-

терел җиткерәләр. Электән үк мөселман хатын-кызларының наданлыгы, хокуксызлыгы белән риза булмаган Багъбостанга революция киң эш мәйданы барлыкка китерә. Реакцион муллаларның һәм фанатик динчеләрнең каршылыкларына карамастан, ул зур дәрт белән хатын-кызларны укыту һәм тегү-чигү түгәрәкләре оештыру эшенә бирелеп китә. Тора-бара бу түгәрәкләр зураеп, җидееллык кызлар мәктәбенә әйләнә. Менә шуннан соң инде «Багъбостан мәктәбе» дип аталган мәшһүр кызлар мәктәбе барлыкка килә.

Багъбостанның шундый эшләре белән танышканнан соң Н. Г. Чернышевскийның «Нәрсә эшләргә?» дигән атаклы романының төп герое, хатын-кызларының яңа бер образын гәүдәләндергән Вера Павловна хәтергә төшә, күз алдына килә һәм синдә Багъбостан белән кызыксыну тагы да арта. Татар романнарының берсендә әллә кайчан ук героиня булып тасвирланырга хаклы булган бу ханым, әлбәттә, онытылмаска тиеш.

Багъбостан мәктәбенең даны бик тиз тарала. Россиянең төрле якларыннан белемгә сусаган татар, башкорт, казах-кыргыз һәм үзбәк кызлары шушы мәктәп яктылыгына карап юлга чыгалар. Бу мәктәпнең даны арткан саен «Дин вә мәгыйшәт»че реакцион динчеләрнең искелек сарулары да көчлерәк кайный башлый. «Дин вә мәгыйшәт» журналының һәр санында дип әйтерлек, бу мәктәпкә һәм аның җитәкчесе Багъбостан ханымга карата яла ягылган материаллар бастырып чыгаралар. Шул сәбәпле мәктәптә еш кына тентүләр була. Берничә тапкыр шулай тентеп, мәктәп китапханәсенең астын өскә китерәләр.

Шундый юллар белән мәктәпне ябтыра алмагач, Багъбостан ханымга: «Укытучылык итәргә хокукың юк, әгәр дә Диния назарәтендә имтихан тотып мөгаллимәлеккә хокук алмасаң, мәктәбеңне ябып куячакбыз»,— дип ультиматум куялар. Шуннан ул, хатын-кызлардан тарихта беренче тапкыр буларак, үзен имтихан кылуны сорап, Диния назарәтенә барырга мәҗбүр була. Ләкин әлегә чаклы ирләргә генә муллалык һәм мөгаллимлек хокукы бирү эшләре белән шөгыльләнгән бу оешманың кешеләре, үзләренә шундый бер кыю ханым килеп кергәч, аптырашып калалар һәм: «Бездә хатын-кызларны имтихан кыла торган бүлек юк», дип аның теләген кире кагалар.

Ул арада Багъбостан ханымның шулай аяусызланып һәм юл ярып йөрүен газеталар бик тиз эләктереп алалар. Вакытлы матбугат бертавыштан шауларга керешә. Шуннан соң мөселман депутатлары бу мәсьәләне Дәүләт думасына кертәләр һәм Диния назарәтендә хатын-кызларны имтихан кылып мөгаллимәлек хокукы бирү бүлеген ачтыруга ирешәләр. Шулай итеп Багъбостан ханым 1913 елда имтихан тотып, мөгаллимәлек хокукы ала. Ул чактагы шартлардан чыгып караганда хатын-кызларның бу көчкенә җиңүләре аларны ирләр белән бер хокукка кую өчен алып барылган көрәшнең бер нәтиҗәсе булып тора.

Шуның өстенә Багъбостан ханым 1916 елдан алып, кызлар мәктәбендә укытырга мөгаллимәләр хәзерләр өчен кыска вакытлы педагогик курслар оештырып җибәрә. Ун ел вакыт эчендә аның төп мәктәбендә барлыгы 1212 кыз укып белем ала. Шулардан 149 кеше мәктәпне тәмамлап, мөгаллимә булып чыккан. Тагын ике ел дәвам иткән кыска вакытлы курста укып, махсус комиссия алдында имтихан тоткан, 198 кеше мөгаллимәлек хокукы алган. Шулай итеп, Багъбостан ханым кызлар мәктәбендә һәм педагогик курсларда барлыгы 347 укытучы хәзерләп чыгарган. Бөек Октябрь революциясеннән соң Багъбостан ханымның мәктәбе бөтенләй хөкүмәт карамагына күчкән.

Кызлар мәктәбен тоту өчен Багъбостан ханым ун ел эчендә барлыгы 25 мең 461 сум акча чыгарган. Бу акчаның, уку хакы рәвешендә балалардан алына торган бер өлешеннән башкасы, бөтенесе дә Багъбостан ханымның үз тырышлыгы белән табылган. Бу яктан ул, «Галия» мәдрәсәсен яшәткән Зыя Камалигә бик нык охшый. Шагыйрь Шәехзадә Бабич үзенең «Бер тамсия» исемле шигырендә «Галия» мәдрәсәсен умартага, ә Зыя Камалине корт анасына охшатып тасвирлый һәм:

*Ни курсә аңа барып кадала ул;*
*Сыгып-суырып булса да бал ала ул;*
*Шул көйгә азапланып җыя торгач,*
*Берәр ел яшәр кадәр хәл ала ул,*

— дип яза.

Багъбостан ханым да үзенең мәктәбен яшәтер өчен әнә шулай төрле юллар белән мөмкинлек табарга тырышкан. Шуңа күрә дә Бабичның «Галия» мәдрәсәсе җитәкчелегенә биргән характеристикасы Багъбостан ханымга да бик туры килә. Бу акчаларны төрле миллә кешеләре, замәнасының мәгърифәтчелек яклы булган алдынгы кешеләре, ярдәм итеп биргәннәр. Бу эштә, әлбәттә, Багъбостан ханым ялгыз булмаган. Иң беренче нәүбәттә аңа тормыш иптәше һәм заманында физика, табигать белеме фәннәре буенча дәреслекләр, «мәктәп өчен шигырьләр» китабы бастырып чыгарган алдынгы укытучы-мәгърифәтчеләрдән Гобәйдулла Рдуди өзлексез рәвештә бик зур ярдәм күрсәткән.

Оренбургтагы язучы, укымышлы һәм педагоглар Фатих Кәрими, Кәбир Бәкер, Борһан Шәрәф, Нургали Надиев, Сәнгатулла Бикбулат, Риза Фәхретдинев, Ибраһим Бикчәнтәй, Ибраһим Терегулов һәм Шәриф Манатов кебек затлар турыдан-туры аның мәктәбендә яки курсларында укытучылык итәләр. Үзләренең киңәшләре белән Багъбостан ханымга мораль ярдәм кулы сузалар.

Багъбостан ханым мәктәбендә һәм педагогик курсларында укып белем алган хатын-кызлар, Октябрь революциясеннән соң совет мәктәпләренең беренче укытучылары булдылар һәм ирләр белән кулга-кул тотынышып, яшь совет властен ныгыту юлында җиң сызганып хезмәт иттеләр. Соңыннан аларның байтагы совет югары уку йортларында да белем алып, хатын-кызлардан беренче совет врачлары, агрономнары һәм журналистлары булып чыктылар. Ә кайсыберләре партия хезмәткәрләре булдылар.

Әгәр дә бу эшләрнең барысы да Оренбургка бәхет эзләп килгән ятим бер татар кызы тарафыннан эшләнгәнлеген игътибарга алсаң, Багъбостанның батырлыгына сокланмаска һәм хәйран калмаска мөмкин түгел. Шәехзадә Бабич аның бу хезмәтен шул чакта ук бик тирән аңлаган һәм югары бәяләгән иде.

1917 елның җәендә Шәехзадә Бабич Оренбургта чыга торган «Кармак» журналына секретарь булып эшкә керә.

Бу елларда Багъбостан ханымның өе, гомумән, Оренбургтагы татар һәм башкорт интеллигенциясенең еш очраша торган бер урыны булган. Шул елның көзендә Багъбостан ханым өендә булганнан соң Бабич үзенең «Багъбостанда» исемле түбәндәге бер шигырен яза:

*И илаһи, килде дә керде борынга тәмле ис,*
*И газиз кич, ямьле кич һәм җанлы кич, илһамлы кич.*
*Ямьле өстәл җәйгән матур ак эскәтер.*
*Эскәтер өстендә коймаклар нәфис ис искәтер.*

*Эч, кунаклар!— дип самавыр шатланып җырлап тора,*
*Һәм дә Багъбостан үзе илһамлы ай кук яктыра.*

*Алдыбызда май белән баллар торалар: кап! диеп,*
*Һәм Бабич та кычкыра: «Ныграк аша, Исхак!» — диеп.*

*Ул матур кыз Суфия каймак ташый да, чәй ясый,*
*Кып-кызыл алма кебек пешкән аның бит алмасы.*

Бабичның бу шигыре беренче тапкыр 1922 елда Казанда Галимҗан Ибраһимов редакциясендә чыккан җыентыгында игълан ителде.

1962 елның башларында Сәгыйт Агиш белән әдәбият тарихы, әдәби мирас һәм әдәби вакыйгалар турында истәлекләр язуга бәйләнешле хәлләр хакында фикер алышып утырган чакта, мин аңа:

— Безнең совет әдәбияты тормышында булган мөһим вакыйгалар турында, шул эшләрдә актив катнашучыларның үз каләмнәре белән дөрес итеп язылган истәлекләр юк,— дидем.

Фикеремне дәресләр өчен үзебезнең тормыштан бик күп мисаллар китердем. Азактан Бабичның өстәлемдә яткан җыентыгын алып ачтым да, аның шушы «Багъбостанда» исемле шигырен укыды[illegible] [illegible]м.

— Миңа синң конкрет бер мисал. Бу шигырь кайчан һәм нинди вакыйгага уңаеннан язылган? Шигырьдә Багъбостаннан башка ик[illegible] кешенең исеме телгә алына. Боларның

Исхакы кем дә, Суфиясы кем? Аерым шагыйрьләрнең иҗатларын һәм тормыш юлларын өйрәнүче галимнәр боларның барысын да белергә тиешләр бит,— дидем.

Сәгыйть Агиш, әлбәттә, минем сүзләремә баштанаяк кушылды. Сүз уңаенда үзенең Шәриф Камал, Муса Җәлил кебек язучылар хакындагы истәлекләрен сөйләп алып китте. Сүзенең азагында ул мин куйган сорауларга җавап рәвешендә:

— Әле менә Бабичның Сез әйткән шигырендә телгә алынган Исхакны, мәрхүм шагыйрь-артист Исхак Зәйни: «Ул бит мин» дип сөйли торган иде. Теге Суфиясы Оренбургта безнең белән бергә педтехникумда укыды, фамилиясе Шәрипова»,— диде.

Шуңа ялгап Сәгыйть Агиш Багъбостан ханымның шушы көндә Уфада яшәвен, аның өендә булганлыгын да сөйләде.

Шушы сөйләшүләрдән соң миндә Багъбостан ханым белән хат аркылы гына булса да танышу һәм бәйләнешкә керү теләге туды. Шуннан соң мин Багъбостан ханым белән таныш булган берничә иптәшкә мөрәҗәгать итеп, алардан бу ханымның Шәехзадә Бабич һәм Газиз Әлмөхәммәтов турындагы истәлекләрен язып алуларын үтенеп карадым. Ләкин бу иптәшләрнең барысы да төрле сәбәпләр табып, нигәдер, бу эштән баш тарттылар. Шулай да мин Багъбостан ханым белән очрашу уеннан ваз кичмәдем һәм 1962 елның март азакларында теләгемә ирештем.

Багъбостан ханым бик кыска вакытлы һәм беренче тапкыр очрашу минутларында гына әлегә чаклы билгесез булган әр-яңа һәм бик әһәмиятле хәбәрләр сөйли алмады, әлбәттә. Чөнки сиксән яшькә җитеп барган, шуның өстенә сәламәтлеге дә нык какшаган, әзлексез ютәлләп торуы аңа сөйләшергә нык уңайсызлый иде. Бу мине бик уңайсыз хәлдә калдырды. Багъбостан ханым үзенең авыруын белдермәскә тырышса да, аны борчып йөрүем өчен үкенә башладым.

Шул хәлдә булуына да карамастан, Багъбостан ханым бик күп мәсьәләләр һәм кешеләр хакында сөйләде һәм Бабичны да читләтеп үтмәде. Чөнки Бабичның Оренбургтагы язмышы һәм алып барган эшләре, теләсә-теләмәсә дә аны кайсыбер чакларда Багъбостан ханымга килергә, аңа мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр иткәннәр. Торабара Багъбостанның өе Бабич килеп сыена торган бер ышанычлы өйгә әйләнеп киткән.

1917 елның көзендә Бабич вакытның бик тыгыз һәм көннәрнең бик киеренке булуына карамастан, Багъбостан ханым мәктәбендә укучы кызлардан хор оештырган һәм декабрь аенда зур әдәби-музыкаль кичә уздырган. Кичәнең җитәкчесе һәм дирижеры Бабич үзе булган. Шул кичәдән соң Бабич Уфа якларына командировкага киткән.

Багъбостан ханым Бабичның шаянлыклары турында да берничә вакыйга хәтеренә алып китте. Азактан үзенең сүзләренә йомгак ясаган кебек итеп:

— Бабичка шаянлык табигать тарафыннан бүләк ителгән иде. Ул, нинди генә көлке нәрсәләрне сөйләгән чакларда да, бик җитди кыяфәт һәм тон белән, үзе һичбер көлмичә сөйли ала торган бер көчле кеше иде. Шунлыктан бу сыйфат аңа бик килешеп тора иде. Ул гына да түгел, хәтта кайсыбер артыграк булып күренгән шаярулар да, аңа килешеп, ярашып тора торган иде. Чөнки ул көчәнеп шаяртмый, бәлки бу шаянлыклар аның табигатеннән шулай килеп чыга иде. Шуңа күрә дә бу шаянлыклар кешеләрне Бабичтан биздермиләр, киресенчә, аны яраттыралар гына иде. Әле менә кайсыберәүләр Бабичка нәреп шаярып карасалар да, нигәдер, барып чыкмый торган иде. Ясалма булганга күрә шулай булгандыр, күрәсең.

Сөйләшеп утырган чакта Багъбостан ханым үзенең 8 дәфтәрдән торган көндәлекләре барлыгын әйтте. Бу көндәлекләрдә Бабич белән халык җырчысы Газиз Әлмөхәммәтовларның Оренбургтагы тормышлары турында күп мәгълүматлар барлыгын белдерде. Кабаттан тагын бер тапкыр карап чыккач, ул бу көндәлекләрне миңа күрсәтергә вәгъдә бирде. Мин аңа көндәлекләрне болай яткырмаска, югалмасын өчен, аларны Тарих, тел һәм әдәбият институтына тапшырырга киңәш бирдем.

Бу очрашу азагында Багъбостан ханым тиз генә кузгалып, үзенең кәгазьләре арасыннан 1914 елда Төркиядә чыккан «Фикер» исемле газетаны китереп тоттырды, андагы бер мәкаләне тартып күрсәтте һәм кызлар мәдрәсәләрендә укыту-уку эшләре белән танышу өчен үзенең Төркиягә баруын сөйләп китте.

Багъбостан ханымның Төркиягә баруы төрек хөкүмәте мәҗлесенең (парламентының — С. К.) утыру көннәренә туры килгән. Ул мәҗлес утырышына бара һәм керергә

рөхсәт сорый. Фәкать ирләрдән генә торган, һичкайчан хатын-кыз аяк басмаган бу мәҗлескә аның килеп керүе бик гаҗәп хәл булып чыккан. Шуның өстенә ул чыгыш ясарга рөхсәт сораган, төрек телендә чыгыш та ясаган — үзенең Оренбург шәһәрендә хатын-кызлар мәдрәсәсенең җитәкчесе булуын әйткән, эше белән таныштырган. Икенче көнне иртәнге газеталарда «Хөкүмәт мәҗлесендә беренче мөселман ханымы» дигән исем астында мәкалә басылып чыккан булган икән.

Хушлашкан чагында Багъбостан ханым миңа кызлар мәдрәсәсенең ун еллык бәйрәменә карата «Кызлар җәмгыяте» тарафыннан төзелеп чыгарылган «Ун еллык гыйльми хезмәт» дигән кечкенә бер китапны, үзенең рәсемен һәм үзенең тормыш иптәше, укытучы Гобәйдулла Рдуҗинең «Мәктәп өчен шигырьләр» исемле җыентыгын истәлеккә бүләк итте.

Шуннан соң минем Багъбостан ханымны кабат борчырга батырчылыгым җитә алмады. Көндәлек дәфтәрләре турысында үзем сүз кузгатуны килештермәдем. Апрельнең беренче атнасында инде мин Акманай күле буена җәйләүгә кайтып киттем. Шуннан соң безнең бәйләнешләр беразга өзелеп торды. Көз көне мин авылдан авырып кайттым һәм бертоташтан ике айдан артык түшәктә ятып авырдым. Шулай булса да үземнең хәлемне аңлатып, Багъбостан ханымга хат яздым. Бу хатка җавап буларак декабрьның 23 ендә мин аңардан: «...Менә Сезгә дәфтәрнең өчесен карап чыгар өчен биреп җибәрдем. Миндә калганнары белән барысы да Сезгә багышланган бүләк булса да, миңа кире кайтарырсыз. Кеше җибәреп алдырырмын. Көннәр озыная төшкәч, саулык булса, бергәләп карарбыз һәм тәртипләп тәмамларбыз»,— дигән хат һәм көндәлекләрнең карап чыгылган өч дәфтәрен алдым.

Ләкин мин бу дәфтәрләрне тиешенчә файдалана алмадым, бәлки яткан җирдән генә күз йөгертеп чыктым. Калган дәфтәрләрне каравы да бик озакка сузылды. Җитмәсә тагы, Багъбостан ханым, нәрсә уйлаптыр, миндәге ике данә «Сөембикә» журналы белән теге өч дәфтәрне дә бик ашыгыч рәвештә кире соратып алды.

Мин еш кына Багъбостан ханымның төрле вакытларда «Сөембикә» журналында басылган юл истәлекләреннән торган очеркларын һәм гаиләнең иҗтимагый тормышта тоткан урыны турындагы кайсыбер мәкаләләрен искә төшерәм. Бу истәлекләр, очерк һәм мәкаләләр Багъбостан ханымның заманында үз карашлы, бик шома каләмле һәм югары культуралы журналист булганлыгын раслап торалар. Бер яктан ул укымышлы педагог, икенче яктан язучы-журналист. Менә ул 1912 елда иҗтимагый тормышта һәм гаиләдә хатын-кызларның тоткан урыннары турында нинди фикерләр яза: «...Хатын мөкатдәс һәм мөхтәрәм. Иҗтимагый хәятнең иң мөһим, иң кирәкле әгъзасыдыр. Ул — сәгадәт, бәхет чыганагы. Хатын-кызны аның гыйффәте-сафлыгы бәхетле ясар. Гаилә төзүнең нигезендә табигый һәм иҗтимагый идеяләр ятарга тиеш. Өйләнү — сәүдә эше түгел. Аның белән сату итәргә ярамый. Өйләнүдән — рухи бәхет һәм иҗтимагый максаттан башка файда көтү урынсыз. Гаилә коруның нигезендә — иҗтимагый тормышка хезмәт итү идеясе ятарга тиеш. Болай булмаганда гаилә тормышыннан рухи һәм физик бәхет көтү — урынсыз. Тормышта кара тап калдырмау — гаилә тормышына керәчәк җегет һәм кызларның бурычлары булырга тиеш. Тормыш сәхифәләре керләнгән кызлар һәм җегетләр бәхетле яши алмаслар. Сафлык — бәя җитми торган бер җәүһәрдер!..»

Моннан 72 ел элек гади бер мөгаллимә тарафыннан әйтелгән бу сүзләр, мәкалә иясенең нинди карашта һәм нинди культура югарылыгында торганлыгын бик ачык күрсәтеп торалар. Шуның белән бергә бу сүзләр бүген дә актуаль яңгырыйлар һәм һичбер аңлатмага мохтаҗ түгелләр.

Багъбостан ханым, әгәр дә сәламәтлеге һәм гомере рөхсәт итсә, Шәехзадә Бабич турында иркенләбрәк һәм мөмкин чаклы тулы итеп, истәлекләр язарга булган иде. Азакта, миңа язган бер хатында ул бик кыска гына план сымаграк итеп, бер нәрсә дә сызгалап җибәргән иде. Менә ул язмадан өземтәләр:

— Ай күрде, кояш алды,— дигән сыман, Бабич 1917 елның азакларында, 1918 елның беренче яртысында, искелек белән яңалык бугазга бугаз килеп көрәшкән көннәрдә, халыкның көндез утырып ашарга, төнлә ятып йокларга вакыты да булмаган бер вакытта, балкып узган бер йолдыз кебек булып, Оренбургта күренеп кенә калды. Бу чакларда Бабич үз эше белән, мин мәктәбем белән үтә мәшгуль булганга кү-

рә, безгә сирәк бик киеренке шартларда гына очрашырга туры килә иде. Шулай булса да, йөз мәртәбә ишетүгә караганда, бер тапкыр күрү артыграк, диләр бит. Шәехзадә Бабич төскә-сынга сылу кеше түгел иде. Ләкин ул, үзенең характеры һәм холыгы белән моңа капма-каршы булуына да карамастан, беренче очрашуда ук, бик җылы тәэсир калдырды. Үзенең гадилеге, тормышында тыйнаклыгы һәм әдәплелеге белән минем мәхәббәтемне яулап алды. Бабич хезмәт сөючә, саф күңелле бер җегет иде. Мин бөек Тукайны күрү бәхетенә ирешә алмадым. Бабич мин күреп белгән шагыйрьләр арасында иң талантлыларыннан иде. Чөнки ул дөньяга сирәк килә торган талантларның берсе булды. Шуңа күрә дә аның бик кыска гына бер иҗади гомер эчендә һәм буталчык шартларда бөтен язганнары, бу зур талантның башлангыч адымнары гына булып калдылар. Без аның кадерен белергә дә өлгерә алмадык. Чөнки: «Без аны кайдан белик, мескен үлеп аңлатмагач?»— дип, Тукай сүзләре белән тәмамлаган ул үзенең язмаларын.

Багъбостан ханым, бәлки, бу карашларын һәм уйларын очрашу минутларында булган сөйләшүләрне хәтерли-хәтерли яза да башлаган булыр иде. Бәлки язып тәмам да иткәндер. Ләкин, хәзергә болар билгесез әле. Чөнки Багъбостан ханым, мин шушы истәлекләрне язып яткан көннәрдә, 1963 елның тугызынчы мартында вафат булган. Аның беркемгә дә бик тиз генә күрсәтеп һәм биреп бармый торган архивы, теге сигез дәфтәр көндәлекләрен һәм бик күп хатлары салынган кәгазь тартманы, үзе үлгәч, ниндидер бер хатын килеп, алып чыгып киткән.

Әгәр дә ул кеше Багъбостан ханымны чын күңелдән ихтирам итә торган бер зат булса һәм бу архивның әһәмиятен аңларлык югарылыкта торса, мәрхүмәнең истәлекләрен, әлбәттә, югалтмас дип ышанырга кирәк.

Әгәр дә Багъбостан ханымның мәгърифәтчелек өлкәсендәге ун еллык хезмәтен йомгаклаган хисап китабы, журналларда басылып чыккан мәкаләләре һәм замандашларының истәлекләре белән бергә кушып дөньяга чыгарылса, бу аның өчен гомерлек бер һәйкәл булыр иде.

*1963—1984 еллар.*

# РЕВОЛЮЦИОНЕР ҺӘМ ЖУРНАЛИСТ

*Вәли Шәфигуллинның тууына 90 ел*

Владимир Ильич Ленин 1921 елда РКП(б)ның X съезды барган чакта Казаннан килгән делегатларның бер төркеме белән очраша. Башка күп мәсьәләләр белән беррәттән, ул республикада матбугатның ничек үсүе, аның тиражы, полиграфия базасының нинди хәлдә булуы белән кызыксына, җирле матбугатта милли интеллигенциянең ничек катнашуы турында сораша.

Шушы әңгәмәдә катнашкан, ул вакытта Казанда чыгып килгән «Известия ТатЦИКа» дигән республика газетасының редакторы, соңрак күренекле совет язучысы В. М. Бахметьев искә алганча, делегатларның берсе болай ди:

«— Владимир Ильич, казанлылар үткән ел ук гомуми редакция астында татар һәм рус телендә бер газета чыгарырга карар бирделәр.— Ул кулы белән минем якка күрсәтте.— Аны рус теле буенча редактор итеп һәм Казанның яшь бер журналистын...

— Шәфигуллинны,— дип әйтеп куйдым мин.

— Әйе, Шәфигуллинны — татар теле буенча редактор итеп куйдылар.

Владимир Ильич безне хуплап баш селекте...» [1]

Заманында исеме бөек юлбашчыга билгеле булган, республикабызның күренекле партия эшлеклесе, журналист һәм әдип Вәли Сәлимулла улы Шәфигуллинның тууына быел 90 ел тула. Ул 1894 елның 4 (16) августында элекке Тәтеш өязенең Борнаш авылында (хәзерге Апас районы) туа [2]. Аның әтисе Сәлимулла Шәфигулла улы һәм әнисе Газизә Миңнегали кызы урта хәлле крестьяннар булалар.

Башка яшьтәшләре кебек Вәлигә дә яшьтән үк крестьян тормышының ачысын-төчесен татырга туры килә. Шуның өстенә аңа 11 яшь тулганда әтисе үлеп китеп ятимлек кайгысы да өстәлә.

Рус-япон сугышыннан соң крестьянның хәле бигрәк тә мөшкелләнә. Вәлине Урта Азиядәге читек-кәвеш сатучы туганнарына асрамага биреп җибәрәләр. Авыл мәдрәсәсендә Шәрәфетдин мулла карамагында өч ел укып хәреф-язуга өйрәнгән малайга анда күзләрен ачу өчен уңай шартлар туа: аны Ташкентта башлангыч училищега бирәләр. Ике ел русча уку Вәлинең карашлары киңәюгә ярдәм итә.

16 яшь тулганда Вәли Шәфигуллин «Азия» товариществосы литографиясенә хисапчы булып эшкә урнаша, үз көнен үзе күрә башлый. Аннан соңгы елларда Киснер типографиясендә заказлар җыю агенты, «Кюммене» акционерлык җәмгыятенең кәгазь складында күпләп сатучы, «Садаи Төркестан» исемле демократик юнәлештәге үзбәк газетасы редакциясендә өлкән экспедитор булып эшли.

Күрәсез, Вәли Шәфигуллин торган саен матбугат эшенә ныграк якыная. Бу чорда ул, матбугат таратучы буларак, рус, татар, үзбәк телләрендә (ул өч телне дә яхшы белә) [3] чыга торган газета-журналларны зур кызыксыну белән укып бара, әледән-әле революцион карашлы яшьләр белән очраша. Болар Вәлинең гомуми белем һәм культура дәрәҗәсе үсүгә, революцион карашлары формалашуга уңай йогынты яса-

[1] Ленин и Татария. Казань, 1970, 360 бит.
[2] Татарстан АССР Министрлар Советының архив бүлеге һәм Татарстан АССР Үзәк дәүләт архивының 1964 ел 13 августында 12241 номерлы җавабы.
[3] КПССның Татарстан өлкә комитеты партия архивы. 15 фонд. 380 эш, 267 бит.

гый калмый, әлбәттә. Шул елларда матбугат битләрендә аның зур булмаган беренче мәкаләләре басыла башлый.

Урта Азия халыклары тормышына шактый күнексә дә, туган як Вәлине торган саен үзенә ныграк тарта. Егетнең күңеле Идел буйларына ашкына. һәм ул 1915 ел башында Казанга кайтып төшә. Тик биредә матбугат, типография тирәсендә эш таба алмый. Аңа Мусин аяк киеме фабрикасында бухгалтер булып эшләргә тәкъдим итәләр.

Монда сәүдәгәрләр һәм приказчиклар, фабрикант һәм эшчеләр арасында каршылыклар үсүен, беренче бөтендөнья сугышы Казан эшчеләре, приказчиклары, ярлылары тормышын тагын да авырайтуын күрә. Ул тормыштагы гаделсезлекләр турында уйлана, күңелендә туган сорауларга җавап эзли. һәм шундый вакытта тормыш давылы аның үзен дә патша армиясенә хезмәткә алып китә. Тик фронтның алгы сызыгында түгел, Сембердә урнашкан пехота полкында, аннары — Казанда. Резервта торган полкларда, яшьләр белән беррәттән, сугышның әчесен-төчесен үз җилкәләрендә татыган солдатлар да, империалистик сугышның төп максатларын аңлаучы большевиклар да була. Вәли алар белән аралаша, үзендә туган сорауларга җавапларны алардан ала. Февраль буржуаз демократик революциясе җиңгәндә Шәфигуллин большевиклар, революцион рухтагы сугышчылар арасында була.

Әмма бу революция болай да чуалчык тормышны тагын да чуалта төшә. Буржуаз Вакытлы хөкүмәт күпмилләтле Россия халкы зарыгып көткән тынычлык, җир һәм милли мәсьәләләрне чишәргә ашыкмый. Империалистик сугыш тукталмый, алпавыт җирләрен конфискацияләү сузыла, милләтләргә үзбилгеләнү хокукы бирелми. Патша заманындагы кебек үк шовинистик һәм колонизаторлык политикасы үткәрелә. Урыннарда җирле милләтчелек көчәя.

Мондый шартларда хезмәт ияләрен социалистик революция җиңүенә туплау өчен милләтчел буржуазиягә каршы көрәшне бик нык көчәйтергә кирәк була. Большевиклар, социалистик революция җиңүе өчен көрәшүчеләр үзләренең революцион оешмаларын, газеталарын булдыруга керешәләр. Күренекле революционер-интернационалист Мулланур Вахитов, беренче татар большевикларыннан Галимҗан Сәйфетдинов инициативасы белән 1917 елның язында Казанда Мөселман социалистлар комитеты барлыкка килә. Бу хакта В. Шәфигуллин «Казан Мөселман социалистлар комитеты» дигән мәкаләсендә болай искә ала:

«1917 елның март урталарында Казан Мөселман социалистлар комитетын оештыру эшенә керешелде. Бу комитетны оештыру өчен... Мулланур Вахитов һәм Галимҗан Сәйфетдинов иптәшләр тарафыннан март урталарында бер-ике-өч кешелек аерым киңәш мәҗелесе җыелды.

17 мартларда инде Панаевское подворье номерларында М. Вахитовның кечкенә бүлмәсендә берничә мәртәбә киңрәк җыелыш ясалды. Бу җыелышка Мулланур һәм Сәйфетдиновларның үзләренең карашлары буенча бергәрәк эшләрдәй кешеләрнең барысы да чакырылганнар иде. Яңлышмасам ул мәҗлестә: Мулланур, Галимҗан Сәйфетдинов, Вәли Шәфигуллин, Каюм Саттаров, Ибраһим Кулиев, Гимад Нугайбек, Габдулла (мәрхүм) Кариев, Хатип (мәрхүм) Мөхетдинов, Нәҗип Халфин, Хәнәфи Кайбышевлар бар иде. Алар янына мәҗлеснең ахырынарак «Мөхәммәдия» мәдрәсәсеннән ике укытучы килеп керделәр (хәтеремдә Богданов һәм Шиһабетдинов булып калганнар).

Бу мәҗлестә татарлардан шул партия әгъзалары булган иптәшләрне берләштереп татар эшчеләренә сыйнфый аң бирү, солдат һәм крестьяннар арасында сәяси эш алып бару һәм Мөселман комитеты белән көрәшү өчен бер комитет (социалистик — Т. Н.) төзү мәсьәләсе каралды» [1].

Истәлектән һәм башка документлардан күренгәнчә, Вәли Шәфигуллин Мөселман социалистлар комитеты (МСК) оештыруда актив катнаша. М. Вахитов — комитетның председателе, В. Шәфигуллин — секретаре булып сайлана. Бу хакта аларның имзалары белән расланган, Татарстан дәүләт музеенда саклана торган МСК члены, соңыннан күренекле врач, галим Ф. Г. Мөхәммәдьяровның шәхси карточкасы да ачык

[1] «Кызыл Татарстан», 4 ноябрь 1927 ел. Х. Кайбышев 1917 елның 15 апрелендә, царизм вакытында провокатор булганы өчен төрмәгә ябыла.

сөйли. 1917 елның апрелендә В. С. Шәфигуллин Казан шәһәре комитеты тарафыннан большевиклар партиясенә кабул ителә [1].

1917 елның июнендә Мөселман социалистлар комитеты М. Вахитов редакторлыгында «Кызыл байрак» исемле газета чыгара башлый. Ул газетада В. Шәфигуллин «Вәли», «В. Сәлим» псевдонимнары белән революцион рухтагы мәкаләләр бастыра.

РСДРП(б)ның Казан комитеты белән тыгыз мөнәсәбәттә булган Мөселман социалистлары комитеты, бигрәк тә аның Г. Сәйфетдинов, В. Шәфигуллин, К. Сатаров, К. Якубов кебек көрәшчеләрдән торган большевистик фракциясе, милләтчел буржуазиянең мәкерле планнарын фаш итү, татар хезмәт ияләрен социалистик революция җиңүенә туплау буенча киң аңлату эшләре алып баралар. Мәсәлән, солдат-артиллерист Бикеев истәлекләрендә, В. Шәфигуллин, К. Якубов, Х. Әхтәмовның һәм МСКның башка членнарының 95-полкта даими рәвештә агитация эше алып барулары әйтелә [2].

Октябрь урталарында Казанда революцион көчләрнең демонстрациясе була. Сафларда Мөселман социалистлар комитетындагы большевиклар һәм сул социалистлар җитәкчелегендәге 5 мөселман ротасы солдатлары да була. Аннан соң үткәрелгән татар солдатлары митингысында К. Якубов, Я. Чанышев, В. Шәфигуллин социалистик революциянең максатларын аңлатып чыгыш ясыйлар [3].

Большевикларның тырышлыгы үзенең гүзәл җимешләрен бирә. Илебезнең бик күп шәһәрләрендәге кебек, Казанда да эшчеләр һәм солдатлар Октябрь кораллы восстаниесенә күтәрелә. Коммунист Вәли Шәфигуллин восстаниечеләрнең алгы сафында. Ул эшчеләрнең һәм солдатларның үз кешесе, җитәкчесе. Совет власте җиңгәч аны Казан хәрби-революцион комитеты составына сайлыйлар.

Коралы восстание җиңү белән генә көрәш бетми әле. Яшь Совет дәүләтен, эшче крестьян властен ныгытырга, татар хезмәт ияләрен алдап революциядән читләштерергә маташучы буржуаз милләтчеләрне фаш итәргә кирәк. Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә Мөселман социалистлар комитеты членнары белән бергәләп, Вәли Шәфигуллин үзенең бөтен көчен буржуазиянең мәкерле ниятләрен халык алдында ачып салуга юнәлдерә.

Аның эшчәнлеге мөселманнарның 2 нче Бөтенроссия хәрби съездына хәзерләнү һәм аны үткәрү чорында аеруча киң колач ала. Буржуаз милләтчеләр шушы съезд трибунасын үз максатларына файдаланырга тырышканда Камил Якуб, Сәхипгәрәй Сәетгалиев, Хәсән Урманов, Латыйф Гомәров һәм башка большевиклар белән берлектә Вәли Шәфигуллин аларның явыз ниятләрен татар солдатларына һәм хезмәт ияләренә төшендерү буенча актив эш алып бара.

1918 елның феврале бу көрәшнең иң кызган көннәре була. Большевистик фракция, шул исәптән Вәли Шәфигуллин да, контрреволюционерлар хәрби съездын ташлап чыга һәм, партиянең Казан комитеты тәкъдиме белән, Казан шәһәр Советы каршында мөселман комиссариаты оештыралар. Вәли Шәфигуллин комиссариатның финанс бүлегендә эшли башлый. Озакламый ул, Х. Урманов һәм К. Каспранский белән бергә, Казанда чыга башлаган татар телендәге беренче совет газетасы «Эш»нең (хәзерге «Социалистик Татарстан»ның башлангычы) редколлегия члены итеп раслана.

1918 елның җәендә Казан өчен зур куркыныч — фетнәче чехлар һәм ак гвардиячеләр басып керү куркынычы туа. Шәһәрне дошманнан саклау, көн тәртибендәге иң мөһим бурыч була.

Бу эштә актив катнашу өчен августның 5 ләрендә Ленин мандаты белән, махсус отряд алып, Мулланур Вахитов та килә. Нәкъ шул көннәрдә Вәли Шәфигуллин татар эшчеләреннән коралы отряд оештыру белән шөгыльләнә. Әмма оборонаны ныгытып өлгергәнче, хыянәтчеләр булышлыгы белән, дошман Казанга бәреп керә. Шәһәрдә канлы террор башлана. Күп кенә большевик-революционерлар белән бергә М. Вахитов та һәлак була. Остазын һәм көрәштәшен югалтуны В. Шәфигуллин авыр кичерә. Ул аның якты истәлеген күңелендә изге итеп саклый. М. Вахитовның үлү еллыкларына багышлап газеталарда истәлекләр яза [4].

---

[1] КПССның Татарстан өлкә комитеты партархивы. 15 фонд, 380 эш, 266 бит.
[2] КПССның Татарстан өлкә комитеты партархивы. 7080 фонд, 11 эш, IX том, 52 бит.
[3] Ионенко И., Таһиров И. Октябрь Казанда. Казан, 1971, 191 бит.
[4] «Эш», 1919 ел, 19 август; «Эшче», 1920 ел, 18 август.

1918 елның сентябрендә Казанны ак чехлардан азат иткәч, В. Шәфигуллин яңадан оештырылган «Эш» газетасының баш редакторы итеп билгеләнә. Аның җитәкчелегендә бу газета тиз арада партия һәм Совет хөкүмәте уздыра торган политиканы халыкка җиткерүче, хезмәт ияләрен интервентларга каршы көрәшкә һәм социализм төзүгә рухландыручы матбугат органына әверелә.

Вәли Шәфигуллин — партия солдаты. Партия кая кушса, ул шунда эшли. Моннан соңгы аның бөтен тормышы шул турыда сөйли. Совет властеның беренче елларында партия матбугатын җайга салу белән бер үк вакытта нәшрият эшләрен дә юлга салу мөһим бурыч булып тора. РКП(б)ның Казан губерна комитеты карары белән Казанда нәшрият коллегиясе төзелә һәм 1919 елның апрелендә Вәли Шәфигуллин шушы коллегиянең члены итеп билгеләнә.

Шул ук елның азагында Вәли Шәфигуллин мөселман коммунистларының II Бөтенроссия съездында катнаша һәм барлык делегатлар белән бергә, В. И. Ленинның съездда ясаган речен тыңлый. Биредә аны РКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы члены, аннары бу бюроның басма органнары — «Эшче» газетасы һәм «Кызыл Шәрык» журналы баш редакторы итеп раслыйлар.

1920 елда, Татарстан автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелү уңае белән, күренекле большевик-журналист Вәли Шәфигуллинны РКП(б)ның Казан губерна комитеты «Татарстан хәбәрләре» дигән республика газетасының баш редакторы итеп билгели. В. И. Ленин белән очрашуда Владимир Бахметьев Вәли Шәфигуллинның шушы газетада редактор булып эшләве турында әйтә. Бу чорда Вәли Сәлимулла улы Татарстан Үзәк Башкарма Комитетының беренче составы члены буларак совет эшләрендә дә актив катнаша. 1921 елда аны «Мәгариф» (хәзерге «Совет мәктәбе») журналының баш редакторы итеп билгелиләр.

1925 елның азагында РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты карары белән Вәли Шәфигуллин матбугат комбинаты директоры, соңрак Татиздат управляющие урынбасары булып эшли. В. Шәфигуллин 1929 елда Мәскәүгә ВКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы марксизм-ленинизм курсларына укырга җибәрелә. Ләкин тынгысыз журналист, белемен күтәрү белән бер үк вакытта, Мәскәүдә чыга торган «Эшче» газетасы редакторы да булып эшли.

1931—1933 елларда ул яңадан Казанда. Бу чорда аны ВКП(б) өлкә комитетының матбугат бүлеге мөдире һәм Татгосиздатның партия әдәбияты бүлегенең баш редакторы буларак хәтерлиләр.

Вәли Шәфигуллин журналистика һәм тарих-әдәбият өлкәсендә кыйммәтле мирас калдырды. «Кызыл байрак», «Эш», «Эшче», «Кызыл Армия», «Татарстан хәбәрләре», «Татарстан», «Кызыл Татарстан», «Известия ТатЦИКа» газеталары, «Кызыл шәрык», «Мәгариф» һәм «Җитәкче» журналлары битләрендә аның күп санлы мәкаләләре басылып чыккан. Алар арасында: «Февраль революциясе һәм татар пролетариаты», «Моннан ун ел элек Казанда 1 Май», «Казан мөселман социалистлары комитеты», «Казанда Октябрь көрәшләре», «Казан Октябре», «Татар җөмһүрияте», «Мәгариф эшчеләре ачлык белән көрәштә», Мулланур Вахитов, Камил Якубов турындагы һәм башка мәкаләләрне, истәлекләрне күрсәтергә була. Күренекле большевик, журналист В. Шәфигуллинның бу язмалары Татарстанда революцион көрәш һәм беренче социалистик төзелеш адымнары тарихын өйрәнүдә, һичшиксез, әһәмиятле чыганак булып торалар.

Күп санлы публицистик мәкаләләрдән тыш, Вәли Шәфигуллин шигырьләр, сатирик памфлетлар да яза. 1917 елның урталарыннан ук инде татар әдәбияты классикларының берсе булган Галиәсгар Камал белән аның арасында ныклы иҗади элемтә урнашкан була. «Әүлия» һәм аның компаниясе» псевдонимы белән аларның бергәләп язган, революция дошманнарын кискен чыбыркылый торган әсәрләре матбугатта әледән-әле басылып килә («Әүлия» — В. Шәфигуллин псевдонимы).

Революционер-большевик, күренекле татар совет журналисты Вәли Шәфигуллинның тормыш юлы Коммунистлар партиясе эшенә намуслы һәм фидакарь хезмәт итү үрнәге булып тора.

Талгат НАСЫЙРОВ,
тарих фәннәре кандидаты.

# МӘГЪРИФӘТЧЕ ШИҺАП ӘХМЕРОВ

Мәгърифәтче дигәч, культурабыз тарихында аерым дәверләр тәшкил иткән Хәлфиннәр династиясе, Каюм Насыйрилар күз алдына килеп баса. Бездә исемнәре әле киң катлау укучыларга яхшы билгеле булмаган, халык мәгърифәте, мәктәп-мәдрәсә, китап-журнал, театр өлкәсендә җиң сызганып эшләп килгән зыялылар аз түгел. Татар мәгърифәтчелегенә багышланган хезмәтләрдә, күп очракта, халык мәгарифенә зур өлеш керткән кешеләрне искә алып үтү белән чикләнәләр, аларның шәхес буларак тормышы һәм эшчәнлеге турында җәелеп тормыйлар. Ә бит фәннең, сәнгатьнең, әдәбиятның, шул исәптән мәгърифәтчелекнең һәр өлкәсендә теге яки бу уңышлар аерым шәхесләр эшчәнлегенә барып тоташа. Шуңа күрә теге яки бу шәхеснең, тормышын, иҗатын, аны тәрбияләп үстергән мохитнең аның формалашуындагы ролен өйрәнү — шул өлкәнең тарихын өйрәнү булып саналырга тиеш.

Биредә сүз исеме югарыда искә алынган, киң катлау укучыларга аз билгеле булган, культурабызның төрле өлкәләрендә эшләп килгән Шиһап Әхмеров турында. Шиһабетдин Шәрәфетдин улы Әхмеров 1882 елның 30 декабрендә элеккеге Сембер губернасы Буа өязе, Чүпрәле волосте Яңа Задур авылында крестьян гаиләсендә туган. (Вафаты Казанда, 1966 елның 30 апрелендә.)

Шиһап Буа мәдрәсәсендә укып белем ала. Ул шәхес буларак XIX йөзнең ахыры һәм XX йөз башында, илдә, шулай ук татар тормышында зур үзгәрешләр барган елларда формалаша. XIX йөз ахырында мәгърифәтчелек идеяләре үтеп керә башлаган Буа мәдрәсәсендә уку елларында ук Шиһап Әхмеровта халыкка хезмәт итү юлына керешү хисләре туа. Беренче рус революциясе, илдә барган революцион-демократик хәрәкәт, милли азатлык өчен көрәш идеяләре көчәйгән иҗтимагый шартлар аны мәгърифәтчелек өлкәсенә алып кереп китә.

Мәдрәсәне тәмамлаган яшь Шиһап мәгърифәткә хезмәт итү юлын Әлмәттә укытучы булудан башлап җибәрә. Биредә схоластик тәртипләргә корылган мәктәп-мәдрәсәләрнең нәрсәгә китерүен тагын да тирәнрәк аңлый башлагач, ул дөньяви юлга корылган мәктәпләргә юл ачу өчен дөньяви фәннәр буенча уку китаплары, дәреслекләр җитештерү кирәклеген бик яхшы төшенә. Дөрес, татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен дөньяви дәреслекләр инде XIX гасырның икенче яртысында, бигрәк тә аның соңгы чирегендә шактый басыла башлаган була. Ләкин андый дәреслекләр әле җитәрлек түгел, күп кенә фәннәрдән исә әле бөтенләй булмаган. Менә шушы нәрсә Ш. Әхмеровта үзе дә дәреслекләр язып карау хисе тудыра, шул өлкәдә беренче тапкыр тәҗрибә дә ясап карый. Һәм аның «Мөнтәхиб әлифба» дигән ике кисәктән торган хезмәте 1908 һәм 1909 елларда аерым китап булып басылып та чыга.

1908 елны Ш. Әхмеров Әлмәттән Казанга килә. Мәктәп-мәдрәсәләр өчен уку китаплары басу белән шөгыльләнә торган «Сабах» кәтепханәсе дигән нәшриятта эшли башлый. 1902 елда бертуган Габделвәли һәм Мөхәммәтгали Әхмәдуллиннар тарафыннан оештырылган, вакытында «Кәтепханәи иптидаия» исеме белән билгеле булган бу нәшриятның төп максаты дәреслек китаплары басу була. Ш. Әхмеров «Сабах» нәшриятының китап кибетендә эшли, шул ук вакытта мәктәп-мәдрәсәләр өчен дәреслекләр һәм матур әдәбият авторлары белән элемтәгә керү, алар язган әсәрләрне сайлау, типографиядә бастыру эшләре тулысынча аңа йөкләтелгән була. Ш. Әхмеровның турыдан-туры катнашы белән «Сабах» нәшрияты 1912 елның 21 июнендә үзенә типо-

графия ача, соңыннан бу типографиягә И. Н. Харитонов типографиясе дә кушыла. Татар китаплары басу буенча бу типография Казанда иң алдынгы басмаханәгә әйләнә.

Бу типографиядә Октябрь революциясенә хәтле миллион ярым тираж белән 400 дән артык татар китабы басылып чыга. Аларның төп өлешен татар мәктәпләре өчен басылган китаплар тәшкил итә. Бу дәреслекләрнең авторлары арасында без күренекле татар әдипләре, галимнәре, педагогларының хезмәтләрен күрәбез. Алар Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, М. Корбангалиев, Н. Думави, М. Галәү (М. Мәрҗани), Г. Алпар һәм башкалар. «Сабах» нәшрияты чыгарган мәктәп китаплары арасында рус педагоглары дәреслекләре дә аз түгел.

Ш. Әхмеров инициативасы белән «Өмед» нәшриятында да күп кенә башка татар язучыларының китаплары — Г. Камал, М. Фәйзи, Ш. Әхмәдиев, Ф. Кәримов һәм башка әдипләрнең әсәрләре дөнья күрә. Татар укучыларын башка халыклар әдәбиятлары белән таныштыру йөзеннән татар теленә тәрҗемә ителеп Л. Толстой, И. Куприн, Г. Гейне кебек классикларның хикәя, повесть, шигырьләре басыла. Нәшриятның репертуарында киң халык массаларына адресланган фәнни-популяр характердагы, шул исәптән авыл хуҗалыгына караган басмалар да очрый. Бу басмалар нәшриятының халыкка дөньяви белем тарату буенча да эшләгәнлеген күрсәтә. Китап репертуарының халык мәгърифәтенә буйсындырылуы Шиһап Әхмеровның эшчәнлегенә турыдан-туры бәйләнгән дияргә була. Ул нәшриятка килгәч берадәрән Әхмәдуллиннар нигездә типография осталары буларак кына эшли башлыйлар дип әйтергә мөмкин, китап басу өчен әсәрләр сайлау, аларны чыгару юлларын таптау Ш. Әхмеров җилкәсенә төшкән.

Нәшрият тарафыннан мәктәпләр өчен дөньяви дәреслекләр, төрле өлкәләргә караган фәнни-популяр хезмәтләр, прогрессив язучыларның әсәрләре бастырылып килүе — нәшриятның һәм аның басмаханәсенең мәгърифәтчелек позицияләреннән чыгып эшләвенә тагын бер дәлил булып тора.

Китап дөньясына килеп кергән Ш. Әхмеров басмачылык тарихы белән дә кызыксына. Бу кызыксынуның нәтиҗәсе буларак аның «Матбагачылык тарихы» дигән китабы дөнья күрә. Бу хезмәт авторның матбагачылык тарихы буенча заманы өчен зур эрудицияле зыялы булуын күрсәтә. Бу хезмәт татар китабы тарихы буенча язылган иң беренче зур хезмәт буларак та үзенең тарихи әһәмиятен әле дә югалтмаган. Анда төрле вакытта эшләп килгән, татар телендә китап басу белән шөгыльләнгән һәр басмаханәнең диярлек кыскача тарихы яктыртылган. Татарларда басмачылык эшенең тарихын өйрәнү шушы хезмәттән башлана дияргә була. Дөрес, бу темага Риза Фәхретдинев язган хезмәтләрне дә кертергә кирәк, ләкин алар икенче планда язылганнар.

Менә бу фактлар Ш. Әхмеровның китапчы гына түгел, шул ук вакытта китап тарихы, басмачылык тарихы буенча да белгеч булуын күрсәтәләр.

Татар китабының үсешендә зур роль уйнаган рус типографы И. Н. Харитонов исеме китап белгечләренә яхшы билгеле. Ул, бертуган Әхмәдуллиннар белән университет типографиясендә бергә эшләп үскән полиграфист, шул ук вакытта Ш. Әхмеровның да дусты булган. Бертуган Әхмәдуллиннар инициативасы белән үзләренең дусты И. Н. Харитонов турында язылган бер китап дөнья күрә. Аның авторы күрсәтелми. Бу хезмәтнең авторы Ш. Әхмеров булу мөмкинлеген әйтми үтеп булмый. Моның шулай булуын күп нәрсәләргә таянып якларга була, бу урында без шул гипотезаны кую белән генә чикләнәбез.

Шиһап Әхмеров күренекле редактор, журналист та иде. Ул 1913 елда Казанда татар телендә чыга башлаган беренче педагогик журнал «Мәктәп»нең редакторы була. Әхмәдуллиннар хисабына чыга башлаган бу журналны оештыруда иң актив катнашкан кеше дә Шиһап Әхмеров булуына шикләнер урын юк.

Бу журналның дөньяга килү тарихы гомумән өйрәнелмәгән. Шул уңайдан без биредә кайбер фактларга игътибар итеп үтәргә булдык. Билгеле булганча, журналның беренче саны бөек шагыйребез Габдулла Тукайның шигыре белән ачылып китә. Менә шушы факт журналны оештыруда Г. Тукайның да катнашы булуы мөмкинлеген күрсәтә. Бу фикерне куәтләүче башка дәлилләр дә китереп булыр иде. Мәсәлән, 1912 елда 15 декабрьдә чыга башлаган «Аң» журналының беренче саны да Г. Тукай шигыре белән ачыла. Архив документларыннан күренгәнчә, бу журналны оештыруда да Г. Тукай актив катнашкан. Аның нәшире һәм редакторы Әхмәтгәрәй Хәсәни белән

дус булган, аралашкан, киңәшләшкән Тукай, күп тапкырлар редакциягә, Ә. Хәсәни янына килеп йөргән.

Шиһап Әхмеров та, Әхмәтгәрәй Хәсәни дә — Габдулла Тукайның дуслары. 1908 елдан башлап әдипнең вафатына хәтле аның белән аралашып, фикерләшеп, чәйләшеп, көн саен диярлек очрашып яшәгән. Ш. Әхмеров белән Г. Тукайның күп теләк, уйлары, хыяллары бер булган дип әйтергә була. Алар бер чорда, бер шәһәрдә генә түгел, бер кунак йортында, «Болгар» номерларында (хәзерге Татарстан белән Киров урамнары чатындагы бина) бергә яшәгәннәр. Әнә шунда яшәү елларында алар нык дуслашканнар. Ш. Әхмеров өйләнгәч, «Болгар»дан квартирага китә. «Болгар» номерларында торып калган Тукай шуннан соң да Әхмеровлар гаиләсендә еш була. Менә шул киңәшүләр, халык мәгърифәте турындагы бәхәсләрдә педагогик журнал оештыру мәсьәләсе, һичшиксез, күп тапкырлар кузгатылган булырга тиеш. Ш. Әхмеровның педагогия өлкәсендәге эшчәнлеге турында сүз барганда, ул редакцияләгән «Мәктәп» журналы турында да бер-нике сүз әйтми үтү мөмкин түгел, чөнки ул журнал Ш. Әхмеров эшчәнлегенең көзгесе бит. Журналның программасы гаять киң була. Бу журнал чыгаруның максатын тулырак күз алдына китерү өчен әнә шул программа белән бераз танышып үтик.

Ул программа 28 бүлектән тора. Анда педагогик тәрбия мәсьәләләре, урта һәм түбән классларда укытыла торган фәннәрне укыту методикасы, мәктәп-мәдрәсәләргә карата руханилар һәм җәмәгатьчелекнең тоткан урыны, аларда гомуми белем бирү һәм аны дәүләт гимназиясе программасына яраштыру, мөселманнарга техник белем бирү, мөселман балаларына мәҗбүри башлангыч белем бирү, хатын-кызларны укыту кебек пунктларны күрәбез. Алардан тыш «Мәктәп» журналының программасы буенча журналда аерым фәннәр буенча лекцияләр, мәкаләләр, авыл хуҗалыгына караган яңалыклар, татар мәктәпләренең үткәне, хәзергесе һәм киләчәге, татарларда башлангыч белемнең торышы, татар мәктәпләре системасы, мәктәп-мәдрәсәләр өчен мөгаллим һәм мөгаллимәләр хәзерләү, татар уку йортлары һәм аңа хөкүмәтнең карашы кебек темалар яктыртылырга уйланыла. Болардан тыш программа буенча журнал битләрендә хөкүмәт уку йортларында укучы татар яшьләренә туган телне, татар әдәбиятын һәм тарихын өйрәтү, мәктәп-мәдрәсәләрнең материаль ягын ничек кайгырту, шул исәптән бу мәсьәләдә җирле властьлар һәм земство, мәктәп-мәдрәсәләргә карата хөкүмәтнең рәсми боерык һәм күрсәтмәләре дә чагылырга тиеш була. Шул ук вакытта журнал мәктәп-мәдрәсәләр, педагогия, методика буенча төрле телләрдә чыккан хезмәтләр турында рецензияләр, күзәтүләр, күренекле педагог, укытучылар турында очерклар басуны һ. б. шундый күп нәрсәләрне яктырту бурычын алган [1]. Бу программа һичшиксез Ш. Әхмеровның актив катнашында төзелгән, чөнки ул алдан ук журналның җаваплы редакторы булу вазифасын үз өстенә алганда аның программасын белмичә, бу эшкә алынмас иде. Дөрес, журналны чыгару өчен үтенеч белән губернаторга инде әйтеп үтелгән Әхмәдуллиннар, дөресрәге Габделвәли мөрәҗәгать итә. Югарыда билгеләп үтелгәнчә, алар нәширлек эше белән түгел, полиграфия эше белән шөгыльләнгән затлар. Прогрессив карашлы, татар китабы үсешенә зур өлеш керткән Әхмәдуллиннар журнал чыгарырга рөхсәт сорап Ш. Әхмеров һәм аның якыннары үтенече белән мөрәҗәгать иткәннәр. Алар арасында Г. Тукай да булган дип уйлый алабыз.

Бу журнал озын гомерле булмады. Беренче империалистик сугыш башлангач, 1914 елның көзендә басылудан туктады. Үз алдына куйган зур программасын тулысынча үтәп чыгып җитә алмады. Бу журналда татар мәктәбе, мәдрәсә турында, аны заманча оештыру турында һ. б. күп кенә мәкаләләр басылып чыкты. Анда басылган мәкаләләрнең авторлары арасында без атаклы педагог, галим М. Корбангалиев, язучы һәм педагог Н. Думави, тарихчы галим Г. Гобәйдуллин, язучы һәм педагог Ф. Сәйфи-Казанлы һәм башкаларны күрәбез. Шул ук вакытта Ш. Әхмеров үзе дә, редактор буларак кына түгел, автор буларак та журналда катнаша башлый, аның татар хатын-кызларына гимназия ачу кирәклеге турында мәкаләсе шунда дөнья күрә. Журналда әдәбият, сәнгать мәсьәләләренә караган материаллар да күренгәле башлый, атаклы артист Г. Кариевның да мәкаләсе басылып чыга. Г. Тукай вафат булгач журналның бер саны аңа багышланып чыгарыла.

[1] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 420 фонд, 1 тасвирлама, 241 эш, 2 бит.

Татар иҗтимагый тормышында иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булган һәм иң зур бәхәсләр барган өлкә — «мәктәп-мәдрәсә» мәсьәләсе. Әнә шул катлаулы мәсьәләдә арадашчылык ролен алган журнал редакторы булу заманы өчен гаять җаваплы эш булган. Ш. Әхмәровның культурабыз, мәгърифәтчелек өлкәсендә эшчәнлеге турында сүз алып барганда без моны онытмаска тиешбез.

Ш. Әхмәров Октябрь революциясеннән соң да журналистлык эшен ташламады. Аның Габдулла Тукай, Салих Сәйдәшев турында язган истәлекләре әнә шуны сөйли. Салих Сәйдәшев исемен искә алгач, тагын бер нәрсәне әйтергә кирәк. Кечкенәдән ятим калган Салихны Ш. Әхмәров үз улы итеп тәрбиягә ала. Салих Әминә ханымның — Ш. Әхмәровның хатынының — бертуган энесе була. Шиһап Әхмәров малайның гадәти булмаган бай, нечкә күңелен, музыкага сәләтен һәм омтылышын бик тиз сизеп ала һәм аңа төрлечә ярдәм итәргә тырыша. Шул максат белән ул Салих өчен музыка укытучысы чакыра. Сәйдәшнең бәхетенә каршы, бу укытучы татар халкының беренче халык композиторы Заһидулла Яруллин була. Салих Сәйдәшевнең композитор булып формалашуына Әхмәровлар гаиләсе игелекле йогынты ясый. Инде танылган композитор булгач та Салих Сәйдәшев Шиһап ага Әхмәровны үз әтисе кебек хөрмәт итә, олылый.

1908 елдан башлап Г. Тукай белән аралашып килгән, аның соңгы минутларында янында булган кеше буларак та Ш. Әхмәров шәхесе кызыксыну уятыр иде. Чит кешеләр белән тиз якыная алмый торган Тукайның якын дусты булу үзе генә дә аның шәхес буларак киң күңелле, чын кеше булуын сөйли. Үлем түшәгендә яткан шагыйрьнең соңгы рәсемен алдыручы да ул булган.

Халкыбызның ике гиганты — бөек Г. Тукай белән киләчәктә шулай ук бөек композитор булачак Салих Сәйдәшевне үзара таныштырган кеше дә — Шиһап Әхмәров.

Ш. Әхмәровны күреп белүчеләр һәм аралашкан кешеләр аның кече күңелле, гаять кешелекле, ярдәмчел булуын хөрмәт белән искә алалар. Бу Ш. Әхмәровның тумыштан ук педагоглык таланты булуыннан килә. Аның өчен кешенең бәхете — кешегә яхшылык эшләүдә, ярдәм итүдә, кешенең бөтен зурлыгы хезмәттә, халкына хезмәт итүдә. Аның аңлавы буенча, Г. Тукай әйтмешли, «Әйдә халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә» — кеше тормышының мәгънәсе шунда. Шул ук вакытта Әхмәровлар гаиләсе гаять кунакчыл да булган. Алар квартирасына күренекле кешеләр еш килеп йөргәннәр. Алар арасында артистлар да, язучылар да, педагоглар да булган. Г. Тукайдан башка алар торган йортның сукмагын Фатих Әмирхан, артист Г. Кариев, язучы һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе, революционер Г. Ибраһимов, шагыйрьләо Ш. Бабич, Ф. Бурнаш, педагог М. Корбангалиев, рәссам Әхмәт Урманчеев һәм башкалар яхшы белгәннәр. Әхмәровлар фатирында яңа шигырьләр укыйлар, яңа пьесаларны тыңлыйлар, укыту-тәрбия, мәктәп-мәдрәсә, музыка, театр турында әңгәмәләр, бәхәсләр еш булып тора. Болар үз чиратында эзләнүләргә, халыкның культурасы һәм мәгърифәте турында уйлануларга, шул өлкәдә эшләү өчен дәрт һәм дәрман бирә. Менә шундый кичәләр оештырылган Ш. Әхмәров квартирасы һәм аның хуҗасы ни өчен полиция күзәтүе астында торган дигән сорауга җавап булып тора.

Пәһлеван гәүдәле, мөлаем дә, җитди дә карашлы, һәр сүзен уйлап кенә әйтүче, һәр хәрәкәтендә тормыш һәм иҗат дәрте кайнап торган бу куркәм кеше — үзенең китаплары, чыгарган журналлары, мәкаләләре белән генә түгел, халык мәгърифәте өчен көрәшүе белән дә, халык тудырган педагогик алымнарны оста файдаланучы, аны киләсе буыннарга җиткерү өчен көрәшүче педагог буларак та үзенчәлекле шәхес.

Зур эрудицияле, тумыштан педагог җанлы Ш. Әхмәров, күреп үткәнчә, үзенең хезмәтләре белән Каюм Насыйрилар күтәреп чыккан мәгърифәтчелек идеяләрен практик рәвештә тормышка ашыручылар отрядының күренекле вәкиле.

Без еш кына традицияләргә караш, педагогикада халык традицияләренең уңай якларын өйрәнү һәм яшь буынны тәрбияләүдә аларны куллану турында сөйлибез. Шул ук вакытта халык педагогикасенең бер өлеше булган, махсус белемнәр алмыйча практикада үзен зур педагог итеп күрсәткән шәхесләрнең тормышына һәм иҗатына һәрвакытта тиешле әһәмият бирмибез. Без моны Ш. Әхмәров тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә карата да әйтә алабыз.

Шиһап Әхмеровның хезмәте уп тәрбияләгән Салих Сәйдәшев иҗатында, аның рухи тәрбиясе астында үскән балаларында, оныкларында да чагыла. Алар әтисеннән мирас итеп аның хезмәт сөючәнлеген, туган илгә, халыкка хезмәт итү, ярдәмчел, көчле күңелле булуны алганнар. Ш. Әхмеровның олы улы Үзбәк Шиһапович Мәскәү транспорт инженерлары институтын уңышлы тәмамлый, аннары берничә ел буе заводта инженер-конструктор булып эшли. Хезмәт ияләре арасында яшәп, эшчә сыйныфының төп әхлакый һәм этик нормаларын үзләштерә. Булган сәләтен тагын да киңрәк кулланып кешеләргә күбрәк файда китерү нияте белән Казан медицина институтын тәмамлый. Медик буларак Казан ГИДУВында уналты ел авырулар дәвалый. Медицина фәннәре кандидаты, аннары биология буенча доктор Үзбәк Әхмеровны фәннең яңа тармагы — бионика үзенә тарта. Ул илебездә беренче буларак Казан университетында ачылган бионика фәнни лабораториясен оештыра. Ул теоретик эзләнүләр белән беррәттән бионика фәненең уңышларын тормышта куллану буенча да зур эшләр алып бара. Аның магнитлы суларны промышленностьта куллану, Татарстан халык хуҗалыгына керткән практик тәкъдимнәре әнә шул турыда сөйли. Аның тормыш девизы — кеше өчен яшәү, кешеләргә ярдәмчел булу. Бу максатны тормышка ашыруда, әлбәттә, аның медик булуы, Гиппократча фикер йөртүе дә ярдәм итә. Болар барысы да — совет мәгариф системасы һәм, һичшиксез, демократ педагог, халык өчен янып яшәгән әтисенең йогынтысы нәтиҗәсе.

Казан дәүләт университеты профессоры Ү. Ш. Әхмеровның өлкән улы да — шул рухта тәрбияләнгән кеше. Ул — Татарстан буйлап санитар самолетларда очып, аерата авыр хәлгә калган кешеләргә ярдәм күрсәтүче табиб. Нияз Үзбәк улы Әхмеров Казан медицина институтын тәмамлый, соңыннан университетта укып белем ала. Хәзер медицина фәннәре кандидаты, кешеләрнең сәламәтлеген саклау юлында яңа ысуллар эзли.

Шиһап Әхмеровның икенче улы Җанбәк Бөек Ватан сугышыннан яраланып, инвалид булып кайта. Әтисендә булган фәнгә, белемгә җитди караш аның да күңеленә сеңгән. Сугыштан кайткач, Җанбәк ветеринария институтын тәмамлый, аннан озак еллар ветврач булып «Красный ключ» совхозында эшли. Җанбәк, әтисе кебек үк, хезмәткә бирелгән, кешеләргә һәрвакыт яхшылык эшләргә әзер торучы кеше. Торабара ул, үзенең практик эштә җыйган тәҗрибәләренә таянып, кандидатлык, аннан ветеринария фәннәре буенча докторлык диссертациясе яклый.

Үзбәк һәм Җанбәк Әхмеровларның кызлары һәм уллары бабаларның һәм аталарның гүзәл сыйфатларын дәвам итәләр.

Бөек Октябрьның беренче көннәреннән үк илебездә культура революциясе үткәрү өчен зур көрәш башланды. Хәзер без — нык үскән социалистик җәмгыятьне камилләштерү өчен көрәшәбез. Партиябез күрсәткәнчә, беренче максатларның берсе булып барлык кешеләрдә дә югары дәрәҗәдә әдәп-әхлак тәрбияләү алда тора. Бу уңайдан без фәнгә генә түгел — халык педагогиясенең уңай традицияләрен безнең көннәргә хәтле китереп җиткергән аерым шәхесләрнең педагогик мирасларына да таянабыз. Бу бай мирас, кешелек җәмгыятенең язылмаган кагыйдә-кануннары формасында безнең тормышыбызда, эшебездә яшәп килә. Хезмәт халкы арасында гаилә тәрбиясенең уңай традицияләре яшь буынны тормышка, коммунизм төзүгә хәзерләүнең нигезен тәшкил итә.

Бүген партия һәм хөкүмәтебез яшьләрне әхлакый яктан тәрбияләүгә дә зур игътибар бирә икән, моның өчен барлык резервларны: педагогик мирасны, халыкның интеллектуаль мөмкинлекләрен киңрәк файдаланырга кирәк.

Хезмәт кешесе — безнең җәмгыятьнең нигезе. Без эшчеләр династияләре хасил булуы һәм үсүе белән горурланабыз. Шулай ук совет заманында барлыкка килгән эшче-крестьян интеллигенциясе династияләре үсүе дә безнең җәмгыятьнең зур казанышы. Әнә шул династиянең бер буыны булган Әхмеровлар нәселе моңа ачык мисал.

Әгәр безнең әдәбиятыбыз, сәнгатебез XX йөз башында ук көр тавыш белән башлаган икән, мәгърифәтчеләр кабызып җибәргән чаткы ялкынга әйләнә башлаган икән, татар мәктәпләрендә дөньяви белемнәр бирү өскә чыга башлаган икән — монда Шиһап Әхмеров һәм киң масса укучыларга аз билгеле булган икенче буын мәгърифәтчеләрнең хезмәте аз булмаган.

Укытучы, педагог, журналист, китапчы, матбага тарихы белгече, Г. Тукайның якын дусты, С. Сәйдәшевнең тәрбиячесе Шиһап ага Әхмеровның исемен һәм хезмәтен зур ихтирам белән искә алабыз. Ул Тукайлар, Сәйдәшләр кебек кешеләрне тудырган иҗтимагый-мәдәни мохитнең аерылгысыз өлеше, бөек мәгърифәтчеләребезнең максатларын тормышка ашыруда җиң сызганып эшләгән зыялы буларак та безгә кадерле, безгә газиз.

**Мирза МӘХМҮТОВ,**
СССР Педагогия фәннәре академиясенең академигы.
**Әбрар КӘРИМУЛЛИН,**
филология фәннәре докторы.

# ГАЛИ МӘХМҮДОВ—ХАТТАТ

Гали Мәхмүдов культурабыз тарихында зур һәм үзенчәлекле роль уйнаган шәхес. Аның тормыш юлы һәм эшчәнлеге моңарчы күп кенә тикшеренүче дикъкатен җәлеп иткән. Мәхмүдов хакында язылган мәкалә-очерклар да байтак. Ләкин шуны әйтергә кирәк: болар аның эшчәнлеген берьяклырак яктырта, тәгәлрәк әйткәндә, нигездә педагогик һәм тел өлкәсендәге эшенә кагыла. Шул ук вакытта, бу затның гарәп-төрки каллиграфия сәнгате мәйданындагы гамәле һәм казанышлары һаман да игътибардан читтәрәк кала килде. Шушыларны исәпкә алганда, Г. Мәхмүдовның хаттат[1] һәм каллиграф-педагог сыйфатлары белән беркадәр таныштыруның хаҗәте бәхәссездер.

Гали (Мөхәммәтгали) Мәхмүдов 1824 елда Казан өязе Мәмдәл волосте (хәзерге Биектау районы) Сәләнгер авылында дөньяга килә. Башта шунда башлангыч белем ала, соңра Казанның бер мәдрәсәсендә укый. 1842 елдан башлап гарәп каллиграфиясе укытучысы буларак Казан университетында эшли, бер үк вакытта шәһәрнең беренче гимназиясендә дә укыта. Биредә ул 1868 елга кадәр дәрес бирә. 1876—1881 елларда Казандагы Татарская учительская школаның инспекторы вазифасын башкара. Г. Мәхмүдов 1891 елда вафат була.

Гали Мәхмүдовның исеме иң беренче нәүбәттә нәкъ менә каллиграфия сәнгате, аерым алганда ул сәнгатьнең казан татарлары мохитендә үсеше белән бәйләнгән. Бу үсешнең сызыгы исә IX—X гасырларга барып тоташа. Гарәп язуын куллана башлау белән болгар халкы эчендә, табигый, аның осталары да барлыкка килгән. XIII йөз ахыры — XX йөз башы дәвер эчендә иҗат ителеп дөньяга килгән төрле характердагы күп кенә язма ядкарьләр — безнең карамагыбызда. Алар язма культурабызның иң югары дәрәҗәгә ирешкәнен раслый торган бәһасез истәлекләр.

Халкыбыз тарихын гарәп язуыннан башка күз алдына китерү мөмкин булмаган шикелле, ул язуны аның каллиграфик төрләреннән аерып булмый. Культурабыз тарихында Г. Мәхмүдов тоткан урынны дөрес ачыклау өчен без нәкъ шушы факторны истән чыгармаска тиешбез. Дөнья күләмендә танылган каллиграфик сәнгать гарәп язулы халыкларда бүгенге көндә дә туктаусыз үсеш юлында. Совет галиме Б. В. Веймарн бу җәһәттән болай дип яза: «Эстетик әһәмият һәм сәнгатьчә эшләнеше ягыннан дөньяның бер әлифбасы да... гарәп язуы дәрәҗәсенә ирешмәде»[2]. Гарәп каллиграфиясенең мондый, башка бер милли язуда да күрелмәгән үсүе нәрсә белән

[1] Мөселман Көнчыгышында матур язу осталарын шулай атыйлар.
[2] Веймарн Б. В. Искусство арабских стран и Ирана. М., 1974, 25 б.

аңлатыла соң? Билгеле булганча, мөселманнарда язу изге эшләрнең берсе санала, язу осталары нык ихтирам ителә. Шул ук вакытта сәнгатьнең мөһим төре — сурәтчелек, ягъни кеше рәсемен ясау ислам тарафыннан мәҗүсилек һәм христиан дине белән бәйләп каралган, шуларны тарату, пропагандалау чарасы исәпләнгән. Башлыча әнә шул сәбәпле сынлы сәнгать мөселман илләрендә (Иранны беркадәр кагыйдәдән чыгарма итеп караганда) ныклап тамыр җәя алмаган. О. Г. Большаков язганча, «ислам дине баштан ук үз идеяләрен пропагандалауда сынлы сәнгать булышлыгыннан баш тарткан...» [1]. Ләкин, гүзәл язу бары тик сынлы сәнгать урынын биләү бәрабәренә үскән дисәк, хата булыр. Мәсьәләнең тагы бер ягы бар һәм ул әһәмияте буенча югарыда күрсәтелгән сәбәптән һич калышмый. Сүз гарәп язуының табигый сыйфатлары: хәрефләрнең үзгә формалары, сызыкларның сыгылмалылыгы, хәреф элементларының үзара ярашып торуы һ. б. турында. Бу үзенчәлекләр сәнгатьчә иҗат өчен чиксез мөмкинлекләр тудыра.





*Г. Мәхмүдов хатыны һәм кызы белән. 1870 еллар.*

*Г. Мәхмүдов язмаларыннан бер үрнәк.*

Гарәп язу төрләренең иң борынгы ике төре — нәсех белән куфи. Соңгысы гарәпләрдә ислам дине кергәнче үк кулланылган. Соңрак, X гасырда, «хотуты ситтә» ягъни «алты язу» дип исемләнгән төп язулар төркеме барлыкка килә. Болар эченә нәсех белән бергә сөлес, мохаккак, рәйхани, тәукыйгъ һәм рикъка керә. Шуннан соңгы чорда иҗат ителгән язу өслүбләре теге яки бу дәрәҗәдә әлеге «алтылыкка» барып тоташа.

Гарәп язуы каллиграфиясен яхшылап белмичә торып, Шәрык дөньясын, мөселман халыклары мәдәниятын тулысынча аңлау мөмкин түгел. XIX йөздә Казан университетында эшләгән ориенталист галимнәр шушы хакыйкатьтән яхшы хәбәрдар булып, Көнчыгыш телләр бүлегендә укучы студентларны гарәп-төрки каллиграфиясенә өйрәтү кирәклеген белгәннәр. 1843 елда төрки телләр белгече профессор А. К. Ка-

[1] Большаков О. Г. Ислам и изобразительное искусство. Труды Государственного Эрмитажа, т. X. Культура и искусство народов Востока. Л., 1969, 152 б.

зем-Бек киңәше нигезендә Казан уку округы попечителе М. Н. Мусин-Пушкин университет советына махсус хат яза. Аннан мондый сүзләрне укырга мөмкин: «Гарәп, фарсы һәм төрек-татар каллиграфиясе үзенә бер төрле сәнгать тәшкил итә. Анда кулланылган язу ысулларының күптөрлелеге һәм нәфислеге махсус өйрәнүгә лаек»[1].

Шулай итеп, Г. Мәхмүдовның Казан университеты мөгаллиме булып китүе дә бу уку йортының гарәп каллиграфиясе укытучысына мохтаҗ булуы белән бәйле.

Хаттат гүзәл язу кагыйдәләрен балачагында ук өйрәнә башлаган. «Мөселман җирендә хөрмәт ителгән каллиграфия сәнгате белән мин кече яшемнән бирле шөгыльләндем»,— дип яза ул Казан уку округы попечителенә тапшырган гаризасында[2]. Мәдрәсәдә укыган елларда ук инде Г. Мәхмүдов оста һәм килешле язган. А. К. Казем-Бек аның маһирлыгына игътибар итеп, соңыннан талантлы шәкертне каллиграфия укытучысы сыйфатында Көнчыгыш телләр бүлегенә тәкъдим итә.

Мәхмүдовның дәрес бирү структурасы ориенталист студентларга каллиграфия теориясеннән төпле мәгълүмат үзләштерергә, язуның гамәли күнекмәләрен алырга тулы мөмкинлекләр биргән. Мәхмүдов үз эшен яратып башкарган, аңа ихлас күңелдән бирелгән кеше булган. Бер генә фактны искә алыйк. Каллиграфик язу белән шөгыльләнүнең төп шарты — очы кагыйдә буенча киселгән каләм, шомартылган кәгазь һәм махсус әзерләнгән кара булдыру. Менә шул әсбапларны җитештерү мәшәкатен үз өстенә алып, мөгаллим, Казем-Бек Н. И. Лобачевскийга хәбәр иткәнчә, «зур булмаган хезмәт хакының бер өлеше исәбеннән»[3] алты ел буена студентларны каләм-кара белән тәэмин итеп торган.

Г. Мәхмүдовның каллиграфик мирасына килгәндә, шуны истә тотарга кирәк: кызганычка каршы, хаттат кулы белән күчерелгән китаплар, язылган «кыйтгалар»ның (язу үрнәкләре) зур өлеше 1902 елда янгын вакытында көлгә әйләнгән. Ләкин безнең көннәргәчә сакланган кадәресе дә хаттатның сокландыргыч маһирлыгы хакында сөйли.

Останың безгә билгеле булган тәүге язу үрнәкләренә күз салыйк[4]. Ул аларны гариза белән бергә попечительгә тапшырган булган. Шушы дүрт кыйтгада ук инде унсигез яшьлек каллиграф үзен гүзәл язу сәнгатенең асыл кагыйдәләреннән тулысынча хәбәрдар икәнен күрсәтә. Шулай ук тәҗрибәнең әле бигүк җитәрлек булмавы кайбер хәрефләрне төзәткән җиреннән чамалана.

Кыйтгаларның беренчесендә пөхтә, бик җыйнак «нәстәгъликъ-и-хафи» (вак нәстәгъликъ) ысулы белән бер фарсы шигыреннән өзек язылган. Нәстәгъликъ теренең нигез принципларыннан берсе — язуда калын сызыкларның нечкәләре белән чиратлашып килүен төгәл күрсәтү. Шушы, хаттаттан югары осталык өстенә, нечкә зәвыклы булуын сораган алымны Мәхмүдов бөтен күркәмлеге белән башкара.

Икенче үрнәк эре нәстәгъликъ (нәстәгъликъ-и-җәли») стилендә язылган. Монысы композиция ягыннан аерылып тора. Кайбер очракта каллиграф, аерым сүз язылышы белән канәгатьләнмичә, аны төзәтеп, гомуми композицион тукымага ярашлырак, ятышлырак иттереп, бүтәнчә рәвештә урнаштырган. Гомумән, нәстәгъликъ белән язылган бу ике кыйтга XIV йөз ахырында Иранда барлыкка килгән стильнең бөтен гүзәллеген һәм җиңеллеген туплаган дип әйтергә була.

Янә бер үрнәк. Монысында «нәсех» язуы кулланылган. Күренекле сәнгать белгече П. М. Дульский үзенең 1930 елда чыккан мәкаләсендә бу өзекне «элеккесе (нәстәгъликъ белән язылганы — Р. К.) кебек ачык язылмаган» дип бәяли[5]. Ләкин бу фикер белән килешеп булмый. Нәсехне Мәхмүдов башка язу төрләрен өйрәнгән дәрәҗәдә үк яхшы үзләштергән. Әлеге кыйтгада яшь оста язу ритмын төгәл саклый. Әледән-әле хәрефләрнең горизонталь өлешләрен сузып җибәрүе (бу алым хаттатлар телендә «ирсал» дип атала) нәсех стиленең асылын ачып салуда ярдәм итә. Ирсал алымын систематик рәвештә һәм урынлы куллану билгеле дәрәҗәдә «саллы» булган нәсехне җиңеләйтергә, алга омтылышлы итеп күрсәтергә мөмкинлек тудыра.

---

[1] ТАССР Үзәк Дәүләт архивы, 977 фонд, «Совет» тасв., 2649 эш, 1 б.
[2] ТАССР Үзәк Дәүләт архивы, 92 фонд, 1 тасв., 5319 эш, 1 б.
[3] ТАССР Үзәк Дәүләт архивы, 92 фонд, 1 тасв., 5319 эш, 31 б.
[4] ТАССР Үзәк Дәүләт архивы, 997 фонд, «Совет» тасв., 2649 эш, 3, 4, 5 битләр
[5] Дульский П. М. Казанский каллиграф Али Махмудов. Казань, 1930, 6 б.

Ниһаять, уку өчен шактый авыр дүртенче каллиграфик язу үрнәге. Бередә кул ланылган ысул — «шикәстә» [1]. Тышкы күренеше талымлы, катлаулы бизәкне хәтерләтә Бу ысул белән яхшы яза алу каллиграфлар каршында гомуми осталыкның бер кри терие саналган.

Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең сирәк китап һәм кульязмалар бүлегендә Г. Мәхмүдов кулы белән күчереп язылган китапларның берничәсе саклана. Мондый зур күләмле әсәрләр күчерү каллиграф өчен һәрчак җитди сынау була. Аларны хаттат урта яшьләрдә чакта язган. Җитлеккән талант, күпкырлы тәҗрибә бу кульязмаларда үзләрен бөтен көче-куәте белән сиздерә. Мәсәлән, Мәхмүдов күчергән фарсы авторы Һатифиның «һәфте манзар» («Җиде күзәтү») исемле шигъри әсәр язуының нәфислеге, нәзакәтлелеге белән сокландыра. Китапта башлыча «нәстәгъликъ» стиле кулланылып, декоратив «сөлес» язуы да урын алган, атап әйткәндә, аның белән бүлек исемнәре язылган. Хәрефләрне салмак, талгын рәвештә тезеп бару осталыгы, язуның гомуми ятышлылыгы — һәммәсе дә әйбәт тәэсир калдыра.

Шулай ук «нәстәгъликъ» язулы, 250 биттән дә ким түгел, «Тәзкирә эш-шөгара» әсәренең күчермәсе каллиграфның иҗади уңышы булып тора. Китапка үткән заман гарәп шагыйрьләре, шул җөмләдән, мәшһүр Әбү әл-Галя әл-Мәгари тормышы һәм иҗатыннан күп мәгълүмат тупланган. Текстны күчергәндә Мәхмүдов кара һәм кызыл төсләге карадан файдалана. Бередә язу төрләре кулланылышындагы бик характерлы бер үзенчәлек белән очрашасың: текстның фарсы телендәге өлешләре «нәстәгъликъ», гарәпчә шигъри парчалар исә «нәсех» язылышында бирелгән. Бу күренеш билгеле төр язуның башлыча билгеле бер географик өлкәдә, мәгълүм бер халык тарафыннан кулланылу традициясе белән аңлатыла.

Күргәнебезчә, Г. Мәхмүдов гарәп язу стильләренең байтагын камил үзләштереп, алар белән бердәй дәрәҗәдә оста эш иткән.

Элек-электән, профессиональ язу техникасы кагыйдәләрен бик яхшы белү белән бергә, хаттатлардан югары әхлак сыйфатларына ия булу таләп ителгән. Бу таләпне үтәү осталыкның иң биек дәрәҗәсенә ирешүнең зарури шарты итеп каралган. Иранның мәшһүр хаттаты, «нәстәгъликъ» остасы Солтан Гали Мәшһәди әлеге принципны кыска һәм төгәл рәвештә болай аңлаткан: «Язу сафлыгы — күңел сафлыгыннан». Мәхмүдовның каллиграфия өлкәсендәге казанышлары, шиксез, шушы асыл принципка һәрдаим йөз тотуы белән дә бәйле.

Г. Мәхмүдовның безгә мәгълүм фоторәсемнәре бик аз. Күптән түгел хаттат төшкән тагын берәү булуы ачыкланды. Ул күп еллардан бирле Мәхмүдов оныклары — аның кызы, татар хатын-кызлары арасында демократик хәрәкәтнең күренекле вәкиле Гайшә һәм танылган юрист, җәмәгать эшлеклесе Ибраһим Терегуловларның балалары — Мәдинә апа Кәримова белән Хәлимә апа Булатованың шәхси архивында саклана.

Чама белән 1870 еллар башында төшерелгән фотода без Гали Мәхмүдовның үзен, хатыны Гөлчирә һәм олы кызлары Гайшәне күрәбез.

Үткән гасыр җәмгыятебез культура эшлеклеләре сафында сәнгать кешесе һәм галим Гали Мәхмүдов чордашлары Ш. Мәрҗани, К. Насыйри кебек олы затлар белән беррәттән милли мәдәниятыбызның горурлыгы булып тора.

**Рәшит КАДЫЙРОВ**

---

[1] XVIII йөздә Иранда барлыкка килгән «шикәстә» («сынык» дигән мәгънәне белдергән фарсы сүзе) XVIII—XIX гасырларда Казан татарлары арасында киң таралган булган. Көндәлек тормышта аның шактый гадиләштерелгән варианты кулланылган.

# «ЯШЬ ЛЕНИНЧЫ»ГА 60 ЕЛ

1924 ел. Бер көнне язучы Афзал Шамовны комсомол өлкә комитетында комсомол егет Шәһит Шаммазов туктата:

— Афзал абый, татар балаларының хәзер үз газеталары булачак! Меңләгән сан белән, бөтен илгә таралырлык.

— Ә исеме?

— «Яшь ленинчы»...

Бу шатлыклы сөйләшүдән соң күп тә үтми, яңгырлы салкын көннәрнең берендә Афзал агайның өй ишеген шакыйлар.

— Ачыгыз әле, Афзал абый, бу мин — Шаммазов.

Шәһитнең өсте юеш, куллары өшегән, салкыннан калтырана, әмма күзләре янып тора. Кесәсеннән бер төргәк кәгазь чыгарып:

— Афзал абый, менә бу «Яшь ленинчы»ның беренче саны өчен материаллар. Эшләргә булышыгыз әле?! — ди.

— Ә редакциягез кайда?

— Хәзергә менә минем кесәдә,— ди ул сөенеп.

Афзал агаларның өендә таңга кадәр ут яна.

Моннан 60 ел элек «Яшь ленинчы» газетасының беренче саны әнә шулай туа. Ике саны 1500 данә булса, инде өченче саны 2 мең данәгә җитә.

1924 елның январе бөтен совет халкы өчен кайгылы ай булды. Сөекле юлбашчыбызның үлеме Ильич эшенең мәңгелеген раслау өчен бердәм сафка басу кирәклеген хәбәр итте сыман. Ильич исеме, аның уйлары, фикерләре белән сугарылган пионерлар оешмасына шул елны юлбашчыбыз В. И. Ленин исеме бирелде.

Шул ук елны Татарстанда оештырылган балалар газетасының да «Яшь ленинчы» исеме белән аталуы очраклы түгел.

Газетабызны беренче адымнарыннан ук житәкләп олы юлга чыгаруда татар совет язучылары зур тырышлык күрсәтәләр. Почетлы пионер Шамил Усманов, Госман Бакир, Ибраһим Гази кебек язучылар газетаның беренче саннарында ук катнашалар. Киләчәктә күренекле әдәбият галиме булачак 13 яшьлек Хатип Госман Пермь шәһәреннән беренче хикәяләрен җибәрә. Казанның 13 нче мәктәбеннән Габделхак Галиуллин беренче хәбәрләрен китерә. Безнең көннәрдә ул — профессор, техник фәннәр докторы, Мәскәүдәге Патрис Лумумба исемендәге Халыклар дуслыгы университетының кафедра мөдире булыр. Шул ук мәктәптән газета битләрендә беренче рәсемнәрен бастырган Яңа Бистәнең Харис атлы малае, киләчәктә СССРның халык художнигы булып, Харис Якупов исеме белән бөтен илгә танылды. «Диңгез ярында» исемле хикәясе белән газетада катнашкан Мәхмүт Зарипов — бүгенге көннәрдә физика-математика фәннәре докторы, Казан дәүләт педагогия институтының кафедра мөдире. «Канлы юллар» хикәясен язган Лотфулла Фәттахов соңыннан рәссам, РСФСРның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Болар — «Яшь ленинчы» газетасында тәрбияләнеп үскән беренче буын пионерлар.

Татарстан язучыларының беренче съезды делегаты (ул чакта мәктәп укучысы), бүгенге көндә һәммәбезгә таныш балалар язучысы Гарәфи Хәсәновның истәлегенә караганда, ул еллар — газетаның үзенә бер рухи күтәренкелек заманы. Редакция каршындагы әдәби түгәрәккә композитор Җәүдәт Фәйзи килеп йөри, халык көйләрен уйнап күрсәтә, соңыннан сихри музыка дөньясының һәрбер һөнәр иясенә үз максатына җитәргә ярдәм итүчәге хакында лекция укый. Бәлки әнә шуңа күрәдер дә, Җәүдәт абый соңгы көнгә кадәр бала җанлы булып калды. Балаларга музыка кораллары, музыка дөньясы хакында шигъри китап язып калдыруы шул хакта сөйли. Әдәби түгәрәктә Фатих Хөсни иң беренче мәртәбә (бүгенге көндә дәреслекләргә кергән) әнисе йомышка җибәргәч, табаны алып кайту урынына аның белән тау шуып йөргән малай хакындагы хикәясен укый. Атаклы артист Зәйни Солтанов — Тукайны күреп, якыннан аралашып яшәгән кеше. Аның белән булган очрашулар да газетабыз битләрендә үзенә бер сәхифә булып калган.

Газетабызның ул чорын укып тәрбия-

ләнгән кешеләр өчен вакытсыз вафат булган Галимҗан Мөхәммәтшин исеме бик тә кадерле. Ихлас күңелле, трибун, балаларның да, өлкәннәрнең дә яраткан шагыйре. Әле үзе дә балалыктан чыгып җитмәгән сыман. Ялкынланып яна. Яшь кенә булса да, газетабызның җаваплы эшләрен алып бара. «Йөрәк яна» дип яза ул. Аңа җавап итеп Хәсән абыйсы Туфан шигырь юллый:

*Безнең йөрәкләр дә яна, дисең, энем,*
*Яна икән, әйдә янсыннар!*
*Әмма алар утызынчы еллар*
*«Алсу»ларын тудыра алсыннар!*

Абдулла Алишның бер тоташтан командировкаларга йөрүе аркасында әдәби түгәрәкнең эшен ул юкта Галимҗан Мөхәммәтшин алып барган.

Ләбиб Гыйльми, Ибраһим Сәлахов, Шамил Гәрәй төрле елларда үзләре редакциядә эшләгәннәр.

Авыр фронт юлларын үтеп, исән кайтып безгә бик күп матур әсәрләр бүләк иткән шагыйрьләр, язучылар Сибгат Хәким, Мөхәммәт Садри, Шәрәф Мөдәррис, Гали Хуҗи, Абдулла Әхмәт, Нури Арсланов, Нәби Дәүли, Зәки Нури, сугыш кырларыннан кайтмый калган Мифтах Вәдүт, Мансур Гаяз, Мөхәммәт Әхмәтгалиев... «Яшь ленинчы»да беренче шигырьләрен бастырган, шунда тәрбияләнеп үскән шагыйрь Шәрәф Мөдәррис бу буын хакында соңыннан болай дип яза: Без «Яшь ленинчы»ны зарыгып көтеп ала идек, ярыша-ярыша аңа подпискалар җыя идек. Ул безне, яшь алмашчыларны, укуга һәм хезмәткә рухландырды, Ватан намусы, халык бәхете өчен киләчәк көрәшләргә рухландырды, чыныктырды. 1941 елда инде элекке пионерлар 20—22 яшьлек егетләр иде. Алар ут-су кичеп Рейхстаг гөмбәзенә җиңү байрагы кададылар».

Газетабыз тарихында Муса Җәлил, Абдулла Алиш үзенә бер аерым урын алып торалар. Абдулла Алиш 1933 нче елдан сугыш башланганга кадәр «Техника», «Пионер каләме» журналларында эшли. Әмма шуның өстенә безнең газетада дистәләгән әкиятләр, хикәяләр, очерклар, язмалар белән катнаша. Редакция каршында әдәби түгәрәк оештыра һәм аның белән җитәкчелек итә. Бүгенге көндә газетабыз каршында эшләп килгән республика әдәби иҗат берләшмәсе лаеклы рәвештә моннан 50 ел элек әдәби түгәрәкне башлап җибәргән язучының исемен йөртә.

Өлкән буын кешеләре — әтиләр, аналар Алишның хикәяләрен, әкиятләрен генә түгел, бәлки аның балалар турында даими кайгыртып яшәгәнен онытмаганнардыр. 1934 елда аның газетада «Балалар тапшыруының сыйфатын күтәрик» (11 январь), «Совет әдәбияты тудыру юлында» (22 июнь) кебек зур проблемалар күтәргән, җитди мәкаләләре басыла. Алиш «Яшь ленинчы» белән берлектә яшь буынны тәрбияләү турында кайгыртучанлык күрсәтеп яши, үзе актив эшли, башкаларны да оештыра.

Алиш һәм Муса Җәлил. Бу исемнәрни өчендер үзеннән-үзе «Яшь ленинчы» белән «Октябрь баласы» журналының, Мәскәү белән Казан матбугатының тыгыз бәйләнеш символы булып хәтергә сеңеп кала. «Октябрь баласы» (хәзер «Ялкын») ул чакта Мәскәүдә басыла. Ә «Октябрь баласы»нда эшләүче Муса Җәлилгә Казанның ярдәме бик кирәк. «Яшь ленинчы» белән журнал бүгенге көндә дә сокланып искә алырлык, тапкыр бер аралашу ысулы табалар. «Октябрь баласы» чыга башлаганга ярты ел вакыт үткәч, газетаның бер санында «Беренче марттан суд башлана» дигән белдерү бирелә. «Мәскәүдә чыга торган «Октябрь баласы» журналына суд башлыйбыз. Аның нинди җитешмәгән яклары, кимчелекләре бар, вакытында чыгамы, балалар тормышын ничек бирә? Журналны яхшыртуда нинди теләкләрегез бар?».

Шулай итеп, «Яшь ленинчы», беренчедән, укучы балаларның игътибарын Мәскәү журналына юнәлтә, икенчедән, үзенең күп санлы хәбәрчеләре, укучылары ярдәмендә аны эчтәлекле, кызыклы, кыскасы, Муса Җәлил теләгәнчә, «җанлы боевой әдәби журнал» итү өчен зур эш башкара. Бу «суд», ягъни «Октябрь баласы» журналы хакында фикер алышу биш ай дәвам итә, барлыгы 14 утырыш булып, журнал редакциясенең зур җавабын урнаштыру белән тәмамлана. Әлеге җавап — газетада Җәлил авазы, аның «Яшь ленинчы»га рәхмәте. Журнал газета булышлыгы белән тиз арада Татарстанда да популярлашып өлгерә, аңарда кызыклы яңа бүлекләр ачыла, аның тиражы күтәрелә, Татарстаннан хәбәрчеләре ишәя.

«Танылган шагыйрь Муса Җәлил та-

тар балалар әдәбиятын тудыру һәм аны үстерүдә иң күп эшләгән язучы» (1939 ел, 27 июнь). Газета Җәлилне рәсеме һәм яңа әсәрләре белән укучыларына менә шулай тәкъдим итә. Әйе, чыннан да «иң күп эшләгән». Безнең газетага Җәлил музыка дөньясын алып килә. Беренче мәртәбә Хәсән Туфан белән берлектә тәрҗемә итеп, ул чакта иң таралган балалар җыры булган «Таулар, диңгезләр артында» җырын бирә. Уртак максат олы шәхесләрне үзеннән-үзе бергә туплый. Күренекле композиторлар Латиф Хәмиди, Җәүдәт Фәйзи исемнәре Җәлил белән бергә балалар дөньясына килеп керәләр. «Яшь ленинчы»да чыккан иң беренче җырлар аларның исеме белән бәйле.

«Без барыбыз да җыр яратабыз. Йөрәгебездәге тойгыларны дәртле һәм күңелле музыка аркылы җырлап аңлату — безнең иң сөйгән эшебез. Демонстрацияләрдә, лагерьда, мәктәптә, ял сәгатьләрендә бергә төрле көйләрдә җырлар җырлыйбыз». 1939 елда Җәлил «Беренче татар операсы» исемле мәкаләсен әнә шулай башлап китә. Балаларга: «Бу — бөтен халкыбыз өчен зур бәйрәм» — дип мөрәҗәгать итә.

Фатих Кәрим — газетабызның тагын бер якты сәхифәсе. «Яшь ленинчы»ның иң беренче саннарында ук «Урыс ашы», «Балык тәмле булдымы, чыбыкмы?» хикәяләрен, «Төнге урам баласы», «Урман» кебек шигырьләрен бастырган чорда кечкенә Фатих кызыл галстук тагып редакциягә килеп йөри. (Соңыннан балаларга язылган әсәрләре иң беренче мәртәбә «Яшь ленинчы» аша дөнья күрә. «Аучылар» поэмасы, «Улак белән ерак» кебек зур күләмле чәчмә әсәре дә газетада берничә саннар дәвамында бара. Балалар әдәбияты хакында редакциянең Татарстан пролетариат язучыларына мөрәҗәгать хаты басылып чыккач (1933, 5 апрель) Фатих Кәрим иң беренчеләрдән булып җавабын бастыра. «Мин бу чакыруны зур җаваплылык белән каршы алам. Бу эшкә керешүне — миллионлаган хезмәт иясе балаларына коммунистларча һәм коммунизм төзү эшенә чыныккан көрәшчеләр итеп тәрбияләү эшен — зур, авыр, ләкин бик кирәк эш дип таныйм». Газетаның язучыларга бу мөрәҗәгате киң яклау таба. Кави Нәҗми, Ибраһим Гази, Мирсәй Әмир, Фатих Кәримнең балалар өчен язылган яңа әсәрләре туа.

1974 елны пионерлар Фатих Кәрим турында «Аның башлангыч җыры без идек» дип язып чыктылар. Бу сүзләрне Галимҗан Мөхәммәтшин, Абдулла Әхмәт, Зәки Нури, Әминә Бикчәнтәева, Гариф Галиев, Мәхмүт Хөсәен, Гариф Гобәй кебек аның үзен күреп, аның мәктәбеннән дәрес алып калган шәкертләре дә кабатладылар һәм кабатлыйлар. Әнә шундый балаларга булган ягымлы мөнәсәбәт традициясе буыннан-буынга күчеп дәвам итеп килгән. 1961 елны газета яңадан чыга башлагач, Марс Шабаев, Венера Ихсанова, Зоммер Гыйлаҗев, Хәмзә Зарипов, Әнәс Сәләхетдинов, Саимә Ибраһимова, Хәкимҗан Халиковлар бу традицияләрне дәвам итеп алып киттеләр.

Газетаның баш очында бишек җырын җырлаган Афзал Шамов, Һ. Такташ, Ш. Камал, Х. Туфан, К. Нәҗмиләр булды.

«Яшь ленинчы» алардан соң Кутуй, Нур Баян, Шәйхи Маннур абыйларын саный. Һәм 1929 елның март санында бирелгән махсус кушымтада рәсемнәрен бирел әсәрләрен бастыра.

«Яшь иптәшләр! Минем бүген сезнең белән сөйләшә торган нәрсәм — китап турында, китапны ничек уку турында булыр. Без һәрбер эштә тәртипле булырга тиеш. Тәртип иң авыр хезмәтне дә җиңеләйтә. Китап — кешенең иң якын дусты. Дустыңны онытырга ярамаган кебек, укып чыккан китабыңны да онытырга ярамый. Бу эш мөмкинме соң?» Г. Кутуйның әнә шундый юллар белән башланган мәкаләсе дөнья классикларының, азатлык өчен көрәшчеләрнең китапка ихтирамы хакында булган гыйбрәтле мисаллар белән бара.

*...Без яңа тормыш алып киләбез,*
*Урамнар, безгә юл бирегез!*
*Барабаннар сугып үтәбез без,*
*Ал байраклар белән күрегез!*

Бу — Һади Такташ. Такташ вафат булгач, «Киләчәккә хатлар»дан өзек бирелә. Шул көнге газета редакциясен күз алдына китерик.

«...— Булмас! Булмас!— «Кызыл яшьләр» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасына шигъри баш уйлап утырган шагыйрь Галимҗан Мөхәммәтшин сыгылып төште.— Кемнән ишеттең бу имансыз гайбәтне!

Бу, һич кәтелмәгән, җан тетрәткеч хәбәрдән соң редакция җансыз калды.

Ниһаять, Алиш урыныннан торды (номерга китәчәк КазГРЭС турындагы очеркны язып утыра иде):

— Иптәшләр, барлык газеталардан җыелган гранкаларны икенче санга калдырыгыз, бу полоса мәрхүм...— тавыш кинәт тетрәнде, киселде... Тынлык. Бераздан тагын әллә кайдан, баздан килгән кебек тоныкланып дәвам итте,— мәрхүм Такташ турында...— Тавыш тагын киселде...» (Ибраһим Сәлахов истәлегеннән).

Шагыйрь үлгәннән соң да аның эзе «Яшь ленинчы»да суынмый. Элек тә, хәзер дә аның шигырьләре, аның хакындагы истәлекләр газетада басылып тора.

*Эшең белән иркә бәби түгел,*
*Кече большевик син, пионер!*

Хәсән ага Туфанның 30 нчы елларда язылган бик күп әсәрләре газета укучыларга барып ирешкән. «Яшь ленинчы» яңадан чыга башлагач, икенче санга ук ул Һади Такташ турында истәлекләр белән катнаша. Шуннан бирле гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул үзенең нәни дусларыннан аерылмады. Үзенең эшләрен бүлеп, нәни дусларының шигырьләренә күзәтү ясауны да олы бурыч дип санады. «Чәчәкләр очалармы» дип исемләнгән бу мәкалә мәңге тутыкмас җәүһәрләр белән, акыллы киңәшләр белән тулы.

«Балалар алдында үземне бурычлы саныйм». Хәсән ага Туфанның бу сүзләре колакта яңгырап тора. 1931 елда «Яшь ленинчы» газетасы язучыларга, сәнгать әһелләренә мөрәҗәгать белән чыккач, Хәсән Туфан беренчеләрдән булып аваз бирә. 1974 елны бу хакта Хәсән ага безнең хәбәрчебезгә болай дип җавап биргән иде: «Яшь ленинчы» газетасының язучыларга, сәнгать кешеләренә махсус рәвештә мөрәҗәгать итүе бернечә тапкыр булганлыгын беләм. Мондый мөрәҗәгать итүләр — балаларыбыз үтенече, димәк, ишетелми, үтәлми калмаска тиешле үтенеч». Шул ук истәлекләрендә ул Җәлил белән хезмәттәш дуслыгы хакында да искә алып китә (1974 ел, 5 октябрь саны): «Җәлил белән без ул Казанга килеп чыкканчы бер-беребезне белә идек, ул монда килеп рабфакта укый башлагач, дуслашып киттек. Дуслар идек. Мәскәүгә барганда мин аның янында, Казанга кайтса ул миндә. Бергәләп шигырь язу, тәрҗемә итү безнең өчен уртак эшкә бер өлеш иде». Хәсән Туфан газетабыз өчен А. С. Пушкин, Т. Шевченко әсәрләрен тәрҗемә итә. «Интернационал» Кави Нәҗми белән аның тәрҗемәсендә газетабызда басыла. Халкыбыз тарихында легендага әйләнгән әнә шундый әдипләр Бөек Ватан сугышы елларында таң калырлык каһарманлыклар эшләгән яңа бер буынны тәрбияләп үстерделәр.

Шагыйрь Шәраф Мөдәррис әйткәнчә, алар сугыш башланганда 20—22 яшьлек егетләр генә иде. 1941 елның 24 июнь санында Җәлилнең көрәштәше, фашист тоткынлыгында җәзалап үтерелгән шагыйрь Рәхим Саттар уртак фикерне берләштереп мондый ялкынлы шигырь белән чыга:

*Бөек Ватанымның һәр атламы*
*Штык белән яулап алынган,*
*Идел буйларында чәчәк аткан*
*Ата-бабаларның каныннан...*

1961 елда газетаның яңадан чыга башлавы укучылар өчен генә түгел, язучылар өчен дә олы бер шатлык булды. Беренче саннардан ук кайчандыр А. Алиш, Ф. Кәрим, Галимҗан Мөхәммәтшин кебек язучылардан киңәшләр алып үскән язучылар актив языша, ярдәм итә башладылар. Газетада шул ук исемнәр. Әмма инде мәктәп укучылары түгел, авыр елларны кичкән язучылар Нәби Дәүли, Шәраф Мөдәррис, Мәхмүт Хәсәен, Җәвад Тәрҗеманов һәм башкалар.

«Туган ягым — яшел бишек» китабым чыкканнан соң, мин бик күп хатлар алдым. Димәк, әсәрдәге уй-фикерләр кешеләргә барып җиткән. Шушы турыда уйлап публицистик мәкаләләр белән чыгыш ясарга план корып йөри идем, балалар газетасыннан «Туган ягым — яшел бишек» дигән операция башларга җыенуларын әйтеп, операция штабын житәкләүне тәкъдим иттеләр». 1974 елда, Гомәр ага Бәширов әлеге операцияне җитәкли башлагач, йөзләгән пионер дружиналары, мәктәп укучылары бу хәрәкәткә кушылдылар. «Гомәр ага, без үзебезнең мәктәп янында бакча утырттык, чишмәләрне чистарттык»,— әнә шундый хатлар редакциягә ява башлады.

Балаларның күбрәк белергә, матурлык дөньясына тиранрәк керергә омтылышы шулкадәр көчле ки, алар үзләрен борчыган сораулар белән язучыларга, сәнгать әһелләренә бик күп хатлар җибәрәләр. Әнә шул теләкләрне канәгатьләндерү теләгеннән газетабыз «Сиңа әйтер сүзем

бар» башы астында очрашулар оештырды. Бирәдә Ә. Еники, М. Әмир, Н. Дәүли, Г. Ахунов, М. Мәһдиев, М. Юныс, Г. Минский, Н. Фәттах, Р. Фәйзуллин, Б. Камалов, Р. Гатауллин һ. б. бик күп язучылар теләп катнаштылар һәм катнашалар. «Яшь ленинчы» чыннан да бу очрашулар белән моңа кадәр күрелмәгән тәрбияви дәресләр бирү мәктәбе ачып җибәрде. Никадәр кадере, әти-әниләргә, укытучыларга мөнәсәбәт, ил байлыгын арттыруда синең өлешең — нинди генә темалар күтәрелми бу дәресләрдә!

Җәлил, Алиш традицияләрен дәвам итеп, газета үзенең битләрендә коммунистик тәрбиягә киң урын бирә. «Алар Ильичка ант иттеләр» рубрикасы газетабыз укучыларының яраткан бүлегенә әверелде. Бу операция аларны илнең төрле почмакларына алып барды. Бик күп кыңа кешеләр белән таныштырды. Хәтта әлебездән читтә дә Ильичка ант биргән зур кешеләр белән таныштылар алар. Балаларның якын дусты, Италиянең бөек язучысы һәм шагыйре Джанни Родариның ант сүзләре үзенең ихласлыгы, тирәнлеге һәм көрәшчән дәрте белән безнең игътибарыбызны үзенә җәлеп итте. Без аны эзләп табып, татар балаларына мөрәҗәгатен газета аша укучыларыбызга җиткердек. Ә бу рубрика буенча ВЛКСМ Үзәк Комитеты В. И. Ленинның тууына 110 ел тулуга багышлап «Иптәш Ленин, мин Сезгә рапорт бирәм!» дигән девиз астында комсомол һәм пионер газеталары арасында Бөтенсоюз конкурсы игълан иткән иде. «Яшь ленинчы» бу конкурста катнашты һәм беренче урынны алды. Газета ВЛКСМ Үзәк Комитетының 1 нче дәрәҗә дипломы белән бүләкләнде, ВЛКСМ Үзәк Комитеты «Комсомол даны» елъязмасына кертелде. Бу эштә язучылар безнең иң зур таянычларыбыз. «Син бүгенге көннең Корчагинымы?» Шушы рубрика белән чыккан мәкаләләрне укучылар көтеп алалар. Муса Җәлил исемендәге республика дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь һәм прозаик Фәнис Яруллинның исеме һәркемгә таныш. Аның шушы рубрикада чыгыш ясавы балалар өчен көтеп алынган бер вакыйга булды.

Кайчандыр «Тылсымлы көзге» дип, уйлаган, ялкауларны чагылдырган Шәүкәт Галиевнең көзгесеннән шаян, шук, тапкыр Шәвәли килеп чыкты да, балалар дөньясының якын дустына әверелде.

«Балалар иҗат эшен аерата яраталар. Алар язган әйберләргә бик сак карагыз. Кимчелекләре булса, рәнҗетмичә генә аңлатырга тырышыгыз. Язучылык эшенең никадәр җаваплы, авыр эш икәнен, аңа бөтен гомереңне тулысынча багышларга кирәк икәнен балалар аңларга тиеш. Иҗат эшенә керешкән баладан да сылурак бала юк бу дөньяда». Бу сүзләр Габдрахман ага Әпсәләмовның редакциягә язган иң соңгы хатыннан. Ул аны вафатына ике көн кала гына редакция хезмәткәрләренә җибәргән. Васыять кебек яңгырый бу юллар!

Күренекле шагыйрь Сибгат ага Хәкимнең 1974 елның 9 октябрендә безнең газетабызда язып чыккан юллары искә төшә: «Яшь ленинчы» хәзер дә иң укыла торган, үзенең балалык йөзен җуймый, озак еллар буена саклап килгән иң популяр газеталарның берсе.

Ни өчен дип уйлыйм? Үз-үземә җавап бирәм: чөнки традициясе зур. Шул зур традициянең моннан соң да дәвам итәчәгенә ышанам мин».

Бүген ышанып әйтә алабыз: Татарстан язучылары Җәлил, Алиш, Кәрим биреп калдырган эстафетаны кулдан кулга ышанычлы каләмдәшләргә тапшырып баралар. Әдәби бүлекне алып барган Марс Шабаев исемен бер буын шагыйрьләр һәм язучылар үзләренең әдәби олы эшкә керешү алдыннан остазлары саныйлар. 70—80 елларда әдәбиятка килгән бер төркем яшьләрдә аның дисталәгән хатлары саклана. Шул ук әдәби бүлектә соңыннан эшләгән Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Зөлфәт, Роберт Миңнуллиннар бу эстафетаны алып киттеләр.

Безнең газетабызда эшләмәсәләр дә, мәңгелек яшь ленинчылар булып калган, һәрвакыт безнең арабызда булган Газиз Мөхәммәтшин, Хәсән Сарьян, Фаил Шәфигуллин хакында балалар беркайчан да онытмыйлар. Газиз абыйларының «Яшь хикәячеләр» клубы, Сарьян абыйларының «Яшь талантлар клубы» аларны хикәя язуның серләренә төшендерде. Ә Фаил абыйларының хикәяләре, сабыйлар белән үзе дә сабый булып, тиң күреп сөйләшүләре безнең газетабыз тарихында үзенә бер матур бит булып калды.

Газетабыз мактаулы олы юл үтте. 60 ел эчендә ул һәрвакыт язучыларның җылы кулын тоеп яшәде. Бүген ул үзенең өлкән туганы «Казан утлары» аша һәммәсенә рәхмәт әйтә.

**Роза ТУФИТУЛОВА,**

«Яшь ленинчы» газетасы редакторы.

## Күзлек хуҗасын эзли

Утырыш барганда Кәрим Тинчурин күзлеген эзли икән. Бик озак эзләгәннән соң артистлар сорый:

— Ни эзлисез, Кәрим абый? — диләр.

— Менә, күзлегемне әллә кая куйдым!— ди Тинчурин.

Барысы да шаркылдап көлә башлый:

— Кәрим абзый, күзлегегез маңгаегызда бит! — дигәч, Кәрим Тинчурин күзлеген төшереп кия дә башкаларга кушылып көләргә тотына:

— Мин күзлекне эзлим, күзлек мине эзли икән ләбаса! — ди.

## Сәнгать корбаны

1924 нче елда артистлар Мәкәрим Мәһдиев, Галләм Саттаров, Сара Садыйкова «Җырчы Гайшә» исемле спектакль белән Донбасска китәләр. М. Мәһдиев Гайшәнең исерек атасын уйный. Җырчы Гайшәне Сара Садыйкова башкара икән. Галләм Саттаров бай егете булып уйный, ди.

Спектакль барышында бай егете Гайшәнең атасын исертеп, кызны көчләргә азаплана. Шул чакны сәхнәгә таза-таза берничә шахтер атылып менәләр.

— Син монда, Донбасска килеп, кызларны мыскыл итеп йөрисеңмени әле, кабахәт! — дип, бай егетен уйнаучы Галләм Саттаровны бөтереп алып, кыйный башлыйлар.

Исерек ата булып уйнаучы Мәһдиев тә сикереп тора, Гайшәне уйнаучы Сара Садыйкова да бичара Галләмне шахтерлардан аралый башлыйлар.

— Егетләр, бу бит спектакль, бу театр бит. Ул бай малае түгел! Тимәгез аңа, ул бит артист Галләм Саттаров! — дип, артистлар, ялвара-ялвара, аңлатырга тырышалар.

Тамашачыларның бер өлеше шахтерларны залга төшәргә үгетлиләр, әлеге егетләр сукрана-сукрана сәхнәдән төшеп, үз урыннарына утыралар.

Спектакль азагында артистлар белән таныштырганда тамашачылар бөтен уйнаучыларга да гөрләтеп кул чабалар. Ләкин Галләм Саттаровка килеп җиткәч, зал башта тынып кала, аннан соң гүләп кычкыра:

— У-ух, кабахәт! — дип, Галләм Саттаровка нәфрәт ыргыталар.

Клубтан таралганда да, шулай сүгә-сүгә, Г. Саттаровны кунакханәгә кадәр артыннан кычкырып озата баралар. Галләмне уртага алып, саклап баручылар булмаса, хәлләр шактый мөшкел булыр иде.

Алардан котылып, кунакханәгә кереп бикләнгәч:

— Син аларга үпкәләмә, дускай! — дип артистлар Г. Саттаровны юатырга телиләр.

Г. Саттаров моңа каршы:

— Сәнгать корбаннар сорый инде! — дип җавап бирә.

*«Кызыклы хәлләр»не журнал өчен Батулла әзерләде.*

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

30 июльдә узган ачык партия җыелышы көн тәртибенә КПСС Үзәк Комитетының «Комсомолга партия җитәкчелеген яхшыртып бару һәм яшьләргә коммунистик тәрбия бирүдә аның ролен күтәрү турында»гы карары яктылыгында Татарстан язучыларының бурычлары» дигән мәсьәлә куелды.

Җыелышта партбюро секретаре Р. Мөхәммәдиев доклад белән чыкты. Фикер алышуларда язучылар Р. Ишморат, Л. Ихсанова, Н. Дәүли, шагыйрь Ә. Рәшитов, театр белгече Б. Гыйззәт, композитор С. Садыйкова, Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин һ. б. лар катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАР ЯРДӘМЕ

26 июньдә Татарстан Язучылар союзы идарәсе секретаре М. Хәбибуллин җитәкчелегендә бер төркем язучылар — Ә. Гадел, К. Кәримов, Р. Низамиев, Ә. Мушинский һәм Ә. Рәшитов Питрәч районы авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре белән очраштылар. Алар шулай ук «Татпотребсоюз» совхозы эшчәннәренә печән чабуда да булыштылар.

## ӘГЕРҖЕДӘ ӘДӘБИ АТНАЛЫК

Шагыйрьләр Г. Латыйп, Рәшит Әхмәтҗанов, прозаик Р. Кәрами 15—19 августта Әгерҗе районы игенчеләре янында булдылар.

Район үзәгендә культура эшчеләре белән очрашканнан соң, алар «Коммунизмга», Ленин, Жданов, Чапаев исемендәге колхозларның ындыр табакларында, җәйләүләрдә игенчеләр, терлекчеләр алдында үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары белән уртаклаштылар, яшь һәм башлап язучылар белән әңгәмәләр үткәрделәр.

## АРХЕОГРАФИК ТАБЫШЛАР

Быел июль аенда университетның Археографик экспедициясе ике төркемгә бүленеп эшләде: тарих фәннәре докторы, профессор М. Госманов җитәкчелегендәге зур төркем күрше Мари АССРның Бәрәңге районындагы унлап татар авылында булды һәм 140 кульязма китап, 70 ләп документаль чыганаклар җыйды; составында КДУның Совет чорына кадәрге СССР тарихы кафедрасы өлкән укытучысы Г. Хәбибуллин һәм журналыбызның фән бүлеге редакторы Ж. Миңнуллин булган икенче төркем Татарстанның Чүпрәле районында эшләде. Мари АССРда эшләгән төркем тарафыннан унлап җырбәет дәфтәрләре, күренекле татар шагыйре һәм галиме Г. Утыз-Иманинең «Морад-елгарифин» әсәренең күчермәсе, Т. Ялчыголның «Рисаләи Газизә»се, Урта Азия төрки поэзия үрнәкләреннән Шаһ Мәшрәбнең биографиясе белән бергә зур күләмле диваны, ягъни шигырьләр җыентыгы, Куканд ханлыгы тарихы, юриспруденция, тарих һ. б. буенча китаплар, документлар җыелды. Документларның иң зур күпчелеген экспедиция хезмәткәрләренә Мари АССР Бәрәңге районы Мәзар башы авылыннан Мәнфүсә ханым Гайнетдинова тапшырды. Чүпрәле районында да XVIII—XX йөз башларына караган әдәби, тарихи ядкарьләр тупланды. Шулай ук бу районда элек татарлар арасында киң таралган «Яр-яр» исемле йола җырының күләмле нөсхәсе булуы ачыкланды.

## ГОРЬКИЙНЫҢ КАЗАН «УНИВЕРСИТЕТЛАРЫ»

М. Горькийның Казандагы музеенда яшь Алексей Пешковның Идел буендагы бу шәһәргә беренче тапкыр килүенә 100 ел тулуга багышланган яңа экспозиция оештырылды. Анда музейга язучының туганнары бүләк иткән фоторәсемнәр бар.

М. Горькийның Казанда яшәү чорына багышланган күчмә күргәзмәне Татарстанның күп кенә шәһәрләрендә яшәүчеләр да карый алачак.

## ГЕРОЙ-ШАГЫЙРЬГӘ БАГЫШЛАП

Украина ССРның Закарпатье өлкә культура йорты каршында эшләүче интернациональ дуслык секциясе Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты патриот-шагыйре Муса Җәлил турында әңгәмәләр циклы оештырды. «Муса Җәлил — татар халкының батыр улы», «Муса Җәлил һәм Украина», «Муса Җәлил иҗатының интернациональ характеры» дигән темаларга әңгәмәләр «Художпром» фабрикасында, «Ремыттехника» һәм көнкүреш химиясе заводларында, чик буе заставаларының берсендә һ. б. урыннарда булды.

## АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ ЛЕНИНГРАДТА

1—16 августта Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының Ленинградта иҗат отчеты булды. Ленин комсомолы исемендәге театр бинасында барган бу иҗат отчетының беренче көнендә Татарстаннан килгән кунакларны шәһәрнең театр җәмәгатьчелеге исеменнән Ленинград театр, му-

зыка һәм кинематография институты ректоры Н. Волынкин котлады һәм иҗат уңышлары теләде. Җавап сүзе белән Г. Камал исемендәге театрның баш режиссеры, СССРның халык артисты, РСФСР һәм ТАССР Дәүләт премияләре лауреаты М. Сәлимҗанов чыкты. Гастрольләрне ачу тантанасында ТАССР культура министры И. Н. Алиев катнашты.

Камаллылар Ленинград шәһәрендә «Бирнәсез кыз» (А. Островский), «Сүнгән йолдызлар» (К. Тинчурин), «Татар хатыны нилэр күрми» (Г. Ибраһимов, Х. Сәлимҗанов), «Качаклар» (Н. Исәнбәт), «Әниләр һәм бәбиләр», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Моңлы бер җыр», «Диләфрүзгә дүрт кияү» (Т. Миңнуллин әсәрләре) спектакльләрен күрсәттеләр.

Театрның фойесында Татарстан предприятиеләрендә эшләнгән милли киемнәр, сувенирлар, популяр артистларыбызның җырлары язылган грампластинкалар да сатылды.

Театрның «Әниләр һәм бәбиләр» спектакле Ленинград телевидениесе аша күрсәтелде.

## КИТАПХАНӘГӘ — ШАГЫЙРЬ ИСЕМЕ

РСФСР Верховный Советы Президиумы карары белән Алексеевск район Советы башкарма комитеты культура бүлегенең үзәкләштерелгән китапханә системасы филиалына — Биләр авыл китапханәсенә шагыйрь Кол Гали исеме бирелде.

## ШӘРИФ КАМАЛГА БАГЫШЛАП

Оренбург шәһәренең «Россия» культура сараенда татар совет әдәбияты классигы Шәриф Камалның тууына 100 ел тулу уңаена багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрелде.

Шәриф Камалның тормыш һәм иҗат юлы турында Х. Ямашев китапханәсе каршында эшләп килгән әдәби берләшмә җитәкчесе Зиннур Шакиров сөйләде.

Орденлы укытучы Гөлсем Хәсәнова, партия һәм хезмәт ветераны Сабит Якуповлар 20—30 елларда Оренбургта Шәриф Камал белән очрашулары турында истәлекләре белән уртаклаштылар.

Сакмар районының Түбән Чебенке авылы урта мәктәбе директоры Рәшит Исхаков Шәриф Камалның әлеге авылда коммуна төзүдә катнашуы турында яңа материаллар туплаган. Аның чыгышын тамашачылар зур кызыксыну белән тыңладылар.

Фойеда язучының тормышына һәм иҗатына багышланган күргәзмә оештырылган иде. Кичә үзешчән сәнгать көчләренең зур концерты белән тәмамланды.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен драматург Туфан Миңнуллинга, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 22 июнь Указы белән, «РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет әдәбияты һәм матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы Рафаил Төхфәтуллинга, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 1 июнь Указы белән «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм 60 яше тулу уңаеннан шагыйрә Энҗе Мөэминова КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Совет сынлы сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен рәссам, СССР Художниклар союзы члены Гайшә Абдрахмановна Рахманкуловага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 6 июнь Указы белән, «Татарстан АССРның халык художнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Нәтиҗәле фәнни-педагогик һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының совет чорына кадәрге СССР тарихы кафедрасы мөдире, тарих фәннәре докторы, профессор Госманов Миркасыйм Габделәхәтовичка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 4 июнь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Казан дәүләт культура институтының кафедра мөдире Рауза Фатыйховна Усманова, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 13 июнь Указы белән «РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

# Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары

## Азат Вергазов



Азат Фатих улы Вергазов 1932 елда Пенза өлкәсенең Неверкин районы Карновар авылында укытучы гаиләсендә туган. Зеленодольск районының Зур Карауҗа урта мәктәбен, Казан дәүләт педагогия институтының тарих һәм филология факультетын тәмамлый, Совет Армиясендә хезмәт итә. Аннары Зеленодольск районы мәктәпләрендә укытучы, уку-укыту бүлеге мөдире һәм директор булып эшли, Казан профессиональ-техник училищесында укыта. 1974 елдан ул Казан телевидениесенең әдәби драматик тапшырулар редакциясендә өлкән редактор булып эшли. КПСС члены.

1969 елда «Беренче карлыгачлар» исемле коллектив җыентыкта шигырьләре дөнья күрде. 1978 елда «Дулкыннар ни сөйли?», 1980 елда «Ташу» исемле повестьлары аерым җыентык булып басылып чыкты.

## Ямаш Игәнәй



Ананий Нестерович Малов (Ямаш Игәнәй) 1938 елның 19 январенда Сарман районы Ләке авылында туа. Урта мәктәп һәм Лубян урман техникумын тәмамлаганнан соң лесничий ярдәмчесе булып эшли, балалар укыта. Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. 1965—1978 елларда Баулы һәм Мамадыш район газеталарында бүлек мөдире булып эшли. 1967 елда В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетын тәмамлый. Хәзер КамАЗ төзелешендә эшли.

1981 елда «Сәфәр чыгам» исемле беренче җыентыгы, балалар өчен «Йолдыз булып ян» (1983) исемле шигырь китабы басылып чыкты.

## Әмир Мәхмүдов



Әмир Гобәй улы Мәхмүдов 1947 елда БАССРның Әлшәй районы Габдрәшит авылында туган. Раевкада (район үзәге) урта мәктәп тәмамлагач, Бәре дәүләт педагогия институтының рус теле һәм әдәбияты факультетында укый. Институттан соң Совет Армиясендә хезмәт итә. КПСС члены.

Н. К. Крупская исемендәге педагогия институтының эстетика кафедрасы каршындагы аспирантурада укый. М. Җәлил иҗатының идея-эстетик үзенчәлеге турында кандидатлык диссертациясе яклый — бу хезмәте «Эстетический идеал в творчестве Мусы Джалиля» (Казан, 1980) исемендә китап булып та басылды. Ә. Мәхмүдовның тәнкыйть мәкаләләре һәм шигырьләре илебезнең күп журналларында русча һәм башка телләрдә басылып чыктылар. 1983 елда аның «Матурлык тантанасы» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Хәзерге көндә Ә. Мәхмүдов — Казан дәүләт педагогия институтында доцент, әдәбият һәм эстетика фәннәре укытучысы.

# МАТУРЛЫК ҺӘМ МУЛЛЫК ҖЫРЧЫСЫ

Рәссам булу теләге анда мәктәптә укыган елларда ук беленә. Унҗиде яшендә ул үзенең туган җире — Смоленскида үткәрелгән күргәзмәдә катнаша. Шактый иртә ачылган иҗат бөреләренә мәрхәмәтсез сугыш җиле кагыла: Евгений сәнгать музасын сугыш коралына алыштыра. Менә шушы авыр сынау елларында ул көтелмәгән очрашуга юлыга. Мәскәү янындагы сугышларда яраланган егет, госпитальдә дәваланган чакта, күренекле совет нәкышчесе М. В. Нестеровның «Күптән үткән көннәр» исемле китабын укып чыга һәм, кайнар тәэсирләр астында, атаклы рәссам белән очрашырга карар кыла. Өлкән яшьтә һәм авыру булуына карамастан, очрашырга теләк белдергән һәм яшь солдат белән чын күңелдән фикерләшкән М. В. Нестеров образы Евгений Владимировичның хәтерендә гомер буе саклана. Тәҗрибәле остаз тарафыннан әйтелгән акыллы сүзләрне ул сугыштан соң Эстония дәүләт художество институтында укыганда да, 1953 елда Казанга кайтып, иҗат һәм педагоглык эшчәнлеген башлап җибәргәндә дә онытмый.

Беренче коймак төерле була, диләр. Ә менә Е. Зуев өчен ничектер киресенчә килеп чыкты: ул үзенең беренче натюрмортлары белән үк уңышка иреште. Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы (Мәскәү, 1957) уңаеннан оештырылган күргәзмәдә Е. Зуевның «Яз», «Җәй», «Көз», «Кыш» исемле әсәрләре РСФСР Культура министрлыгының I дәрәҗә дипломына һәм РСФСР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасына лаек була. Нәкъ менә шушы елларда натюрморт рәссамның яраткан стихиясенә әверелә. Бер жанрга бирелгәнлек, әлбәттә, замандашларыбыз портретларын, тематик картиналар, пейзажлар иҗат итәргә комачауламый — рәссам бу юнәлештә дә уңышлы эшли.

Маturлык һәм муллык... Е. Зуев натюрмортлары белән танышканда безгә әнә шундый дөнья ачыла. Рәссам буларак аның фикерләү үзенчәлекләре «Рус натюрморты», «Казах киезендәге җиләк-җимеш», «Татар натюрморты» кебек әсәрләрендә аеруча ачык чагыла.

«Өчпочмак һәм пәрәмәч» — «Татар натюрморты» триптихының үзәк өлеше. Әлеге әсәрендә автор татар милли ашамлыкларының үзенчәлекләрен кабатланмас рәвештә ачып бирүгә ирешкән. Биредә рәссамның стиле дә ачык төсмерләнә. Күренеп тора: ул детальләштерүгә, контрастлык эффектына артык бирелми, төшке аш өстәленең бер почмагын натурадан күчерергә дә тырышмый, ә тәлинкәдәге җылы һәм йомшак өчпочмак белән пәрәмәчләрне, татлы кош телен, хуш исле бавырсак һәм гөбәдияне иҗат фантазиясе һәм профессиональ осталык белән, алдан уйлаган төгәл композиция буенча сурәтләргә омтыла. Чигүле милли сөлге композициягә төгәлләнеш бирә шикелле. Күңел җылылыгы белән өретелеп, югары сәнгать осталыгы белән эшләнгән мондый натюрмортларны рухы белән халык тормышы җирлегенә тоташкан һәм күпмилләтле совет халкының милли традицияләрен тирәнтен хөрмәт иткән рәссамнар гына иҗат итә аладыр.

Диләрә САДЫЙКОВА,
Татарстан сынлы сәнгать музееның
фәнни хезмәткәре.

Тышлыкның дүртенче битендә: РСФСРның халык артисты, Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Айрат Арсланов.

Рөстәм Мансуров фотолары.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 1985 ЕЛДА

Укучыларыбыз, көз айлары җиткәч, журналның алдагы ел планнары белән кызыксына башлыйлар. Әдәбият сөючеләрнең бу кызыксынуы бик табигый, һәм без сезгә үзебезнең «серләр»не ачып салабыз икән, дуслыкны дәвам итү җәһәтеннән монысы да гаять дөрес булачак.

Татар совет әдәбиятының иң күренекле әсәрләре, гадәттә, укучыларыбызга иң элек «Казан утлары» аша барып ирешә. Журнал сәхифәләре шаһит: СССР һәм РСФСР дәүләт премияләре һәм Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган әсәрләр үз вакытында иң беренче журнал битләрендә басылып чыккан. Социаль һәм әхлакый проблемаларга багышланган, заманча яңгырашлы роман һәм повестьларга, пьеса һәм хикәяләргә, поэма һәм шигырьләргә журнал киләчәктә дә киң урын бирәчәк.

1985 елда совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүенә 40 ел тула. Әлеге тарихи вакыйга уңаеннан да күп кенә материаллар, фронтовик әдипләрнең истәлекләре бирeләчәк. Журнал битләрендә иң яхшы хикәяләргә «Батырлык дәвам итә» конкурсы бара. Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышланган әлеге конкурска май аенда йомгак ясалачак.

Әлбәттә, журналның йөзен иң беренче чиратта күләмле проза әсәрләре билгели. Алдагы ел нинди яңа әсәрләр белән сөендерер соң? 1985 елда «Казан утлары» үзенең укучыларына берничә роман тәкъдим итәчәк. Алар арасында, мәсәлән, Хисам Камаловның «Безне өйдә көтәләр», Гөлсем Мөхәммәдованың «Эзләнүләр», Чиләбедә яшәүче язучы Рөстәм Вәлиевнең Габдулла Тукай турындагы «Дөнья гаме» дип исемләнгән романнары бар. Алдагы ел өчен повестьларыбыз киштәсе дә буш тормый. Шундый әсәрләрдән Аяз Гыйләҗевнең «Тәмәкене ташладык, рәхәт чигә башладык», Нәби Дәүлинең «Без дөньяга килдек», Гамил Афзалның «Юл башы», Сәет Шәкуровның «Артист» исемле повестьларын әйтеп китәргә мөмкин.

Билгеле булганча, 1986 елда сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 100 ел тула. Бу олы юбилейга әзерлекне журнал быел ук башлаган иде. Киләсе ел саннарында да, алда әйтелгән романнан тыш, халык шагыйре турындагы истәлекләр, әсәрләр урын алачак. Күренекле революционер Мулланур Вахитовның тууына 100 ел тулу уңаеннан, шулай ук Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, М. Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлына кагылышлы эзләнүләр, Х. Туфан, Ш. Маннур һ. б. турында бирeләчәк истәлекләр укучыларыбызда зур кызыксыну уятыр.

«Бүгенге татар поэзиясе һәм аның илкүләм яңгырашы» дип исемләнгән түгәрәк өстәл янындагы сөйләшү дә күпсанлы укучыларыбыз күңелендә тәләктәшлек табар дип ышанабыз.

Журнал киләсе елда да татар халкының килеп чыгышы һәм культура тарихыннан кызыклы яңа материаллар бирүне дәвам итәчәк.

Кыскасы, 1985 елда да «Казан утлары» күпмеңләгән укучыларның йортына һәм йөрәгенә һаман яктылык һәм игелек нурлары илтәчәк! Безнеңчә, дуслыкның көче нәкъ менә шунда да инде.

Безнең индекс — 73210.

Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал